Казан утлары

июль № 7
1966

КАЗАН УТЛАРЫ

АЙЛЫК ӘДӘБИ ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-ПОЛИТИК ЖУРНАЛ
ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАРЫ СОЮЗЫ ОРГАНЫ
КЫРЫК БИШЕНЧЕ ЕЛ ЧЫГА

7

ИЮЛЬ

1966

Бу санда:

ХИКӘЯЛӘР ҺӘМ ШИГЫРЬЛӘР

М. Шолохов. Миңле командир. Хикәя 3
И. Салахов. Колагир. Хикәя 10
Ә. Маликов. Шигырьләр 20
Р. Гәрәй. Шигырьләр 22
М. Маликова. Кыр ягы. Хикәя 24
Р. Фәйзуллин. Шигырьләр 33
Р. Әхмәтҗанов. Шигырьләр 37
Р. Төхфәтуллин. Алсу болытлар. Хикәя 40

ДУСЛАР ҖЫРЫ

С. Эралиев. Йолдызларга сәяхәт. Поэмадан өзек . 46

ОЧЕРК

В. Юдин. Съезд делегаты 51

СӘНГАТЬ КЕШЕЛӘРЕ

М. Латифуллин. Җырга салып хат җибәрәм . . . 57

БӨЕК ОКТЯБРЬНЫҢ 50 ЕЛЛЫГЫНА

Л. Антов. Артистның тормыш юлы 64

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

Ш. Маннапов. Әнвәр Давыдов поэтикасы 94

ӘДӘБИЯТ ТАРИХЫНА МАТЕРИАЛЛАР

Һади Такташ хатлары 103
М. Госманов. Яңа табылган әдәби, тарихи истәлекләр . . . 118

КПССның
ТАТАРСТАН ӨЛКӘ
КОМИТЕТЫНЫҢ
ГАЗЕТА ҺӘМ
ЖУРНАЛЛАР
НӘШРИЯТЫ
КАЗАН

ФИКЕР АЛЫШУ, БӘХӘСЛӘР

М. Гайнуллин. Дөреслекне төгәл яктыртыйк. . . 124
Р. Сафаров. Тукайга — яхшы тылмач. 128
Ш. Байчура. Инәсеннән җебенә кадәр. 132

ӘДӘБИ ТЕЛ МӘСЬӘЛӘЛӘРЕ ТУРЫНДА СӨЙЛӘШӘБЕЗ

Ф. Ганиев. Милли телләрнең функцияләре һәм үсү диалектикасы. 135

КИТАП КҮЗӘТҮ

Э. Касыймов, Т. Галиуллин. Гүзәл шигърият хәзинәсе. 138
Г. Иделле. Иҗат җимешләре. 142

ШАГЫЙРЬ ТУРЫНДА — ШАГЫЙРЬ

Р. Гатауллин. Шагыйрь күңеленә сәяхәт. 144

ТӨРЛЕСЕННӘН

И. Рәми. Чәй һәм чәйчеләр. 146

САТИРА һӘМ ЮМОР

Ш. Шәрәпов. Игелекле ир; Җаен тапты. Шигырьләр 149
А. Шамуков. Чүлмәкче белән исерек. 150
Ш. Галиев. Дусларча шаярулар. 151
Укучыларыбызга җавап. 153
Яңа китаплар. 154
Әдәбият һәм сәнгать яңалыклары. 156
Р. Яхин. Китмә, сандугач!.. Җыр. Г. Зәйнашева сүзләре. 160

Редакциягә килгән кульязмалар кире кайтарылмый.

Редакциянең адресы: *Казань, ул. Баумана, 19. Дом печати, 2 этаж.*
Телефоннар: җаваплы редактор — 2-68-21, җаваплы секретарь — 2-68-21, бүлекләр — 2-39-52.
Хатлар өчен: *Казань, почтамт, почтовый ящик 63. Редакция «Казан утлары».*

Михаил Шолохов

МИҢЛЕ КОМАНДИР

Хикәя

Үткән 1965 ел — Михаил Александрович Шолохов өчен, безнең совет әдәбияты өчен аеруча истәлекле. Бердән, аның 60 еллык юбилее бәйрәм ителде, икенчедән, күп милләтле әдәбиятыбызның иң алдынгы сафында барган олы әдип, оста сәнгатьче һәм җәмәгать эшлеклесе, ялкынлы коммунист Михаил Шолоховка Нобель премиясе бирелү совет әдәбиятының уңышларын дөнья күләмендә тану булып яңгырады. Мәшһүр «Тын Дон» эпопеясы, «Күтәрелгән чирәм» романы, «Кеше язмышы» һ. б. хикәяләре белән М. Шолохов иҗаты миллионлаган совет укучыларының һәм бөтен прогрессив кешелек дөньясының күңелләрендә күптән кайнар һәм тирән мәхәббәт казанган иде инде. Бу бүләк исә әнә шуның рәсми бер гәүдәләнеше булды.

Татар укучысына М. Шолоховның «Күтәрелгән чирәм» романы, «Тын Дон» эпопеясы, «Кеше язмышы» хикәясе һ. б. күптәннән таныш һәм сөеп укылалар. Әмма башлангыч иҗат чорларында гражданнар сугышының кайнар эзләре буенча язылган күп кенә хикәяләре («Дон хикәяләре») моңарчы билгеле түгел иде әле.

Без журналның бу санында укучыларыбызны М. Шолоховның 1924 елда язылган «Миңле командир» («Родинка») исемле хикәясе белән таныштырабыз.

I

Аның квартиры — биек яр буенда.

Тәрәзәдән Дон елгасының кара-кучкыл су өсте, аръяктагы яшел болыннар зәңгәр офыккача җәйрәп күренеп торалар. Төннәрен, жил-давылда, дулкыннар яр астына ук килеп бәрелә, тәрәзә капкачлары инрәпинрәп шакылдый, гүя су күтәрелеп, идән астына елышкандай, дулкыннар хатаны селкеткәндәй тоела.

Өстәлдә — кимерелгән сөяк, бер кыерчык ипи, хәрби карта һәм соңгы сводка ята; саргайган плакатлар өстенә чәчелгән патрон гильзаларыннан — күкертле дары исе, тезүле йөгәннән — ат исе аңкый... Ә тәрәзә янындагы агач эскәмиядә, күксегән юеш стенага аркасы белән эскадрон командиры утыра. Күшеккән кулында — карандаш, алдында — анкета. Кыска, кырыс юллар: **Кошевой Николай. Эскадрон командиры. Игенче казак. РКСМ члены.**

«Яшь» турысына житкәч, карандаш теләр-теләмәс кенә 18 дип теркәп куя. Әмма ул олысымаграк: киң җилкәле, иелебрәк йөри, күз төпләренә нурланып вак кына җыерчыклар җыела...

— Малай гына бит үзе, яшел курай! — диләр эскадрондашлары шаярту һәм эчке бер дулкынлану белән. — Ә бүтән шундый командир табып кара син! Ярты ел инде бер югалтусыз диярлек сугышларда йөрибез, ике банданы тар-мар иттек, күпне күргән карт командирлардан да болайрак, иң кыен бәрелешләрдән җиңеп, исән-имин алып чыга!

Тик Никола гына үзенә унсигез яшь булудан ояла иде. Анкеталарда әлеге шул теңкәсенә тигән графага житү белән, кулындагы карандашы кыюсызлана, яңаклары уттай яна башлый. Атасы анын — казак, димәк, тумышы белән ул да казак. Хәзер инде төштә күргәндәй генә хәтерли: аңа әле биш-алты яшь кенә булгандыр, этисе аны үзенең казачи атына атландырып йөрткән иде:

— Ялына ябыш, улым, ныграк тотын! — дип кычкыра этисе. Кухнядән әнисе дә чыккан, йөзе агарынган: әле атны тезгеннән тотып барган иренә карый, әле ат сыртына четердәп ябышкан улының нәни аяккулларына бага, үзе гүя Николенькага көч бирергә тырышып елмая иде...

Күптән инде бу. Югалды шул Николаның атасы герман сугышында, суга төшкәндәй эзсез югалды. Шуннан бирле һичбер хәбәр-хәтере юк. Анасы да мәрхүмә — беркеме калмады. Атасыннан мирас булып, бары атка һәвәслеге һәм сул аягында, тубыктан югарырак, күгәрчен күкәе хәтле генә миң калды. Унбиш яшенәчә бай казакларга ялчылыкта йөреп, тир-хезмәт түкте. Аннары, бер озын гына шинель сорап алды да, станица аша узган кызыл полкка ияреп, Врангельне тукмарга китте.

...Быел җәй аңа военком белән Донда су коенырга туры килгән иде. Военком контузияле башын чайкалтып, тотлыга-тотлыга:

— Син, бб-раток, бә-бә-бәхетле, да-да, миң — бәхет билгесе ул,— дип Николаның кояшта янган киң җилкәсенә дусларча шапылдатып сугып куйды. Яшь командирга исә әллә ни булды: ап-ак тешләрен генә күрсәтеп, көлемсерәгәндәй итте дә бар көченә ярдан суга томырылды. Чумып калыккач, ачынып әйтте:

— Юкны сөйләмә, чудак! Мин бәләкәйдән ятим калып, работниклыкта үстем, ә син бәхет дигән буласың!

Һәм елга аръягындагы комлыкка таба пошкыра-пошкыра йөзеп китте.

II

Никола, дагалы итекләре белән иртәнге тынлыкны бозып, болдырга чыкты. Көн аяз, салкынча иде. Баскычтан төшеп, чия бакчасына үтте, чык тамчылары белән энҗеләнгән үләнгә чалкан ятты. Абзар-кура ягыннан хуҗа хатынның сауган сыерын тынычландырып сөйләнүе, бозауның имәргә сорап мөгрәве, чиләк төбенә шыбыр-шыбыр сөт акканы ишетелә иде.

Кинәт шыгырдап ян капка ачылды, эт өрә башлады.

— Командир өйдәме? — Взводный тавышы иде бу. Никола тиз генә чирәмнән калкынып, сорау белән җавап кайтарды:

— Ни бар анда?

— Станицадан чапкын килде, пакет белән! Сальский округыннан банда басып кергән, Грушинский совхозы алынган, ди...

— Чакыр үзен!

Хәбәр китергән чапкын ак күбеккә баткан атын тезгененнән тотып килгәндә, бичара ат кисәк кенә ал аякларына чүгеп, бер якка әйләнеп төште һәм өзек-өзек бер-ике генә хырлап алды да, абалап өргән эткә пыялалы күзләрен текәп, җан бирде... Малкай үлде, чөнки хуҗасы аны

кырык чакрым буе бертуктаусыз куа-куа чапкан: өч тәре тамгасы сугылган пакет адресатка мөмкинчә тизрәк житкерелергә тиеш булган!

Никола пакетны ачты: председатель ашыгыч рәвештә эскадроннан ярдәм сорап язган. Шундук өйгә керде, үзе кылычын бәйли, үзенең башында уйлар кайный: «Их, берәр яры укырга китәсе иде!.. Каян тагы бу бандасы килеп чыкты... Военком йөзгә бәреп әйтә: эскадрон командиры имеш, бер сүз дөрес яза белмисең, ди... Чудак ул... Чиркәү мәктәбен дә бетерә алмый калуыма мин гаепле, диярсең... Тагын шул бандалар... тагын кан... туйдырды инде, тәмам жык булдым...»

Карабинын тага-тага баскычка чыкты. Ә йөгерек фикерләре, артыннан калмыйча, такырдан чапкан юргадай, һаман алга омтылалар: «...шәһәргә китәсе, укырга керәсе иде...» дип, күңеленә тукыйлар иде...

Абзарга атын иярләргә барганда, әлеге үлгән атның танавыннан саркып төшкән кара кан тасмасын күреп, читкә борылып үтте.

III

Көз. Кыр юлының жилләр ялаган тигезле-тигезсез тәгәрмәч эзләренә кәдрә-көрән юл үләне сарган, куе-биек алабута һәм киндер тармасы үскән. Далада ерактан ук гәрәбәдәй ялтырап күренә торган эскерт һәм кибәннәргә, мөгаен, бу юл белән жәен печән, көлтә ташыганнардыр... Ә олы юл — такыр шлях буйлап телеграмм баганалары сузылып киткән. Алар көзге пыскак яңгырга, аксыл томаннарга да карамастан, чокыр һәм сызалар аша атлап-атлап, отыры алга чабалар. Шул шлях буенча атаман үзенең бандасын алып бара: иллеләп кылыч — совет власте белән килешә алмаган Дон һәм Кубань казаклары. Өч тәүлек инде, сарык көтүеннән куып алып кителгән бүре өердәй, әле юлдан, әле юлсыз гына дала чирәмен таптап, качып баралар. Алар эзеннән, күрә-күрә, Никола Кошевой эскадроны куа килә.

Бандада — һәммәсе патша хезмәтен үткән, күпне күргән казаклар, усал-чая халык! Ә шулай да атаманның күңеле тыныч түгел, ул борчыла: вакыт-вакыт өзәңгегә басып, карчыгадай үткер күзләре белән даланы капшый, тирә-якны күзәтә. Донның теге ягында зәңгәрсу тасма булып күренгән урманнарга хәтле чакрымнарны исәпли... Исәпләре аны әллә кайларга, үткәннәргә алып китә...

...Жәйнең чилләсендә эссе кояш астында әлсерәп яткан дала бервакыт гажәеп бер көмеш чыңы белән тула торган була. Бу — «гарновка» бодаеның эре тук башаклары шулай кыштырдаша. Бодай кылчыклары, яшь егет мыегы төсле, караеп килә. Ә арыш кешене кумәрдәй булып үсә дә үсә...

Сакалбай-станичниклар исә бакча артларына, комсу балчыклы түбәсу жирләргә түтәрәмләп кенә арыш чәчәләр. Гомергә уңмый ул, элек-электән үк дисәтинәсенә утыз поттан да артык чыкмый. Алай да чәчәләр, чөнки аннан кызлар күз яшедәй ару самогон куыла. Борынгы ата-бабалардан ук шулай килә инде ул... Дон казакларының гербына аракы мичкәсендә утырган шәрәкәй казак сурәте юкка гына төшерелмәгән, күрәсең... Күзләрен бөтен хуторы-станицасы исереп-махмырлап йөри: әрәмә талыннан үргән читәннәр аша аллан-тилпән чайкалган кызыл өсле папахалар күзгә чалына...

Менә шуңадыр, атаман бер көн дә аек булмый, кучер һәм пулеметчылары да сиртмәле тачанкаларына басып, атларын ава-түнә куалар...

Жиде ел инде атаманның туган нигезен күрмәгәненә. Башта — Германиядә әсирлек, аннан — Врангель, кояшта изрәп яткан Истамбул, чәнечкеле тимер чыбык белән уратылган лагерьлар, аннары — төрек каегында Кара диңгез аша кичү, Кубань камышлыклары һәм — ниһаять, бандалыкта йөрүләр...

Менә ул — әгәр әйләнеп баксаң — атаманның тормыш юлы! Шуңа аның жаны, жәйге кызуда сазламык балчыгындагы аеры тояк

эзләре кебек, мүкләнеп каткан. Әллә нинди билгесез өянәк аны эчтән кимерә, бөтен тәне сыкрый. Бу бизгәкне бернинди эчемлек белән дә басып булмасын сизенә атаман, тик тыела алмый... Бер аек көне юк. Чөнки даладагы арыш басулары шундый хуш ис аңкытып серкәләнәләр — чыдар әмәл юк, хутордагы кара кашлы солдаткалар шундый саф самогон куалар — чишмә суыннан аергысыз була, эх!

IV

Иртә таңда җиргә беренче салкын кырау төште. Тегермән буасындагы төнбоек яфракларына, әйтерсең, көмеш чәчелгән. Куляса канатларында төсле пыяладай ялтыраган нечкә генә боз кисәкчекләре дә күренгәли иде.

Нәкъ шул иртәдә Лукич карт авыраеп китте: биле сызлый, аяклары кургаш кебек, җирдән аерып булмый. Сөякләре үзенә, тәне үзенә вата, сызлана. Көчкә-көчкә өстерәлеп кенә тегермәнен бер әйләнеп чыкты. Яшьләнеп торган күзләре белән өскә караса, түбә кыегы астында, бик бирелеп, күгәрчен гөрли, аяк астыннан гына бер оя тычкан балалары чыелдашып үтә. Күксеп әчегән мүк исе белән яңа тарткан ашлык исе кушылып борынга керә. Тегермән астындагы су, ниндидер бер ят тавыш чыгарып, субай баганаларын ялап-ялмап имә. Карт, беравык колак салып тыңлашып тора да, чуалган сакалын тараштырып, умарталыкка таба атлый...

Чиннеккә кереп, толыбын бөркәнеп яту белән, изелеп йокымсырап китә. Авызын бераз ачып, җылы сулыш белән тын алганда, селәгәе сакалына, мендәренә ага...

Кичке эңгер-меңгер. Инде картның хәтасы күренми, елгадан күтәрелгән аксыл томан тегермәнгә таба сарыла.

Лукич, уяну белән, умарталар арасына кереп китте. Ләкин шул чак урман авызыннан килеп чыккан ике атлының берсе аңа дәште:

— Картлач, монда кил әле!

Лукич сүлпән генә әйләнеп, шик белән карады. Бу тынычсыз елларда шундый кораллы кешеләрне, сорамый-нитми азык-ашлык алучыларны, ул бик күп күргән һәм андый халыкны гомумән, тегенди-мондый төрләргә аермастан, берсен дә өнәми иде.

— Ятьрәк атла, карт үгез!

Лукич, төссез иреннәре белән үзенчә нидер мыгырдана-мыгырдана, умарталар арасыннан әкрен генә өстерәлеп килде дә бер читтәрәк басып калды.

— Без кызыллар, бабакай... Син курыкма, — дип йомшаграк эндәште атаман. — Банда артыннан куып киләдер идек тә, менә үзебезнекеләрне югалттык... Кичә моннан бер-бер отряд узмадымы?

— Уздылар кемнәрдер.

— Кайсы якка киттеләр?

— Шайтан беләме аларны...

— Синең тегермәндә берәрсе калмагандыр?..

— Юк! — диде Лукич кырт кына һәм әйләнеп китәргә борылды...

— Тукта әле, картлач! — Атаман атыннан сикереп төште, дугадай кәкре аякларында басып кала алмыйча, егыла язды. Каты самогон исе аңкытып:

— Коммунистларны кыр-рабыз без, менә шул, картлач! Әбезнең кем булуыбыз ансы сиңа кирәк түгел! — диде дә тагы сөрлегеп китте, тезгене кулыннан ычкынды.— Синең эшең шул — безгә җитәрлек кадәр «җим» бир дә май кап! Аңладыңмы? Тиз бул. Кая ашлык?

— Юк шул, — ди Лукич, үзе читкә карый.

— Ә менә бу ам-барда ни нәрсә?

— Төрле иске-москы гына... ашлык юк анда...

— Әйдә-ле, күргәз!

Атаман картны яртылаш жиргә иңгән кыйшык келәт алдына жилтерәтеп китерде дә ишекне тибеп ачып жибәрде. Бура эче тулы бодай һәм арпа иде.

— Бу нәрсә? Ашлык түгелмени, карт сволочь!

— Ашлык, милай... Тарткан өчен түләү бит бу. Мин аны ел буе бөртекләп жыйдым. Ә син атларга түкмәкче...

— Синеңчә, нехай безнең атлар ачтан кәкрәйсен, ә?! Нәрсә син, кызыллар яклымы әллә? Үләсең киләме?!

— Аллам сакласын, кызгана күр, бер дә юкка харап итмә! — Лукич бүреген салып, атаманның аягына ава, йонлач кулларын тотарга, үбәргә итә...

— Әйт: сина кемнәр ошый — акларммы, кызылларммы?

— Ярлыка, балакаем... Кичер томана картның ахмак сүзләрен, жәзалама...— дип, карт елап-инәлеп атаманның аяк астында ауный, итекләреннән кочаклый...

— Кызыллар яклы түгелмен, дип ант эч!.. Чукынып кына түгел, карт төлке, жир белән ант ит!

Карт тешсез авызына кушучлап туфрак каба, аны ачы күз яшьләре белән чылатып чәйни...

— Так, так... Ну, житәр, ышанам хәзер! Тор, карт шайтан!

Лукич оеган хәлсез аякларына баса алмый азаплана, атаман аңа карап, мыскыллы көлемсерәп тора.

Ул арада инде әллә каян килеп тулган атлылар бурадан арпа-бодай ташыйлар, алтындай бөртек яртылаш юлга, ишек алдына, ат аяк асларына коела, әрәм-шәрәм була...

V

Таң. Соргылт юеш томан.

Сакчы тоймады: Лукич шым гына, үзенә мәгълүм сукмаклар белән, башта әрәмәгә чыкты, аннан — иртәнге сизгер йокымсырауга талган урман эченә килеп керде. Картларча терек-терек тәпили торгач, жил тегермәнен дә үтте. Менә басу капкасыннан хуторга керәм дигәндә генә, кинәт томан эченнән ике жайдаклының тонык сызымталары калкып чыкты. Таң тынлыгын кисеп, тавыш яңгырап китте:

— Кем килә?!

— Мин бу... — диде Лукич тешсез авызын мүкелдәтеп, үзе куркудан бөтенләй коелып төште, дер-дер калтырана...

— Кем соң син? Пропускаң бармы?

— Нишләп йөрисең бу вакытта?

— Тирмәнче мин... Мондагы су тирмәненнән... Кирәк эшләрем белән кайтуым иде...

— Ниткән эшләр ул? Әйдәле командирга! Алдан атла!.. — дип кычкырды берсе, аты белән картның үкчәсенә бастыра язып. Лукич ат танавының жылы сулышын жилкә артында тойган хәлдә, аксый-теркелди хутор урамыннан китте. Мәйданга житәрәк, чүлмәк түбәле йорт алдында туктадылар. Тәрәзәдә ут жемелди иде. Озатучы жайдаклы, авыр сулап, атыннан төште, тезгенен коймага чалып:

— Минем арттан! — диде дә, кылычын шалтырата-шалтырата өй алды басмасыннан менеп китте...

Керделәр. Лукич, куе тәмәке төтененә чыдый алмыйча, төчкереп жибәрде. Тизрәк бүреген салып, түргә карап чукынып алды.

— Менә бу картны тоттык. Хуторга кереп килә иде.

Никола, башын өстәлдән күтәреп, йокылы-уяулы, ләкин кырыс тавыш белән:

— Кая бара идең? — дип сорады карттан.

Лукич алга атлап куйды, шатланып-каударланып сөйләргә тотынды:

— Наныкайларым, үзебезнекеләр икәнсез ләбаса, ә мин тагы теге

зобаныйлар дип торам... шүрләвемнән сорарга да кыймадым... Тирмәнче мин, касатик... Оныттың эрәзе: урман аша узганда, миңа сугылган идегез, мин әле сиңа сөт тә чыгарган идем...

— Я, шуннан ни әйтәсең?

— Шуны әйтәм, карлыгачым: теге шул, ни... аты коргыры, бандалар килеп басты... кичә караңгы төшкәндә. Күрәк онынннан бөртекләп җыйган ашлыгымны алдылар, атларына биреп, түгеп-чәчеп бетерделәр... Җәберләделәр, мәсхәрә иттеләр, мин карт кешене җир белән ант иттереп, туфрак ашаттырды башлыклары...

— Хәзер кайда соң алар?

— Шунда яталар әле. Бөтен ызбамны аракыга батырдылар, чүмерәләр генә, канальялар. Сезгә белдерергә дип чабып килүем иде, бәлкем, шул зобаныйларга бер чара табарсыз...

Командир, бабайга елмая төшеп, эскәмиядән кузгалды:

— Атларны иярләргә! — дигән боерык өйдән — ишек алдына, аннан — урамга чыгып таралды. Никола инде тәмам уяу иде, ләкин шинелен кигәндә, йөзеннән ниндидер йончулык кыяфәте чагылып узды.

VI

Таң алды.

Ялсыз, йокысыз төннәрдән тәмам кагаеп саргайган Никола, атын чаптырып килеп, пулеметчылар янына туктады.

— Без атакага ыргылу белән, банданың уң флангысына яудырыгыз! Канатларын сындырырга кирәк аларның!

Һәм, шундук атына сугып, цепькә җәелгән эскадронына таба чабып китте.

...Туйралык артында ниндидер хәрәкәт бар: шлях ташында ат тояклары чыкылдаганы ишетелә. Бераздан дүртәрләп тезелгән — урталарында тачанкалы — атлылар колоннасы яланга килеп чыкты.

Шул чак иртәнге тынлыкны ярып, Никола тавышы яңгырап китте:

— Галопом алга-а-а-а!

Эскадрон дәррәү гөрелдәп, колоннага каршы ябырылды. Иң алда, аргамагына камчы белән сыза-сыза, артындагы пошкыру һәм ат тояклары гөрелтесен бөтен җаны-тәне белән тоеп, Никола Кошевой оча иде.

Урман авызыннан ярсып-ярсып пулемет ата башлады.

Ут астында калган дошман колоннасы таш шлях буйлап ике якка — учениедәге кебек тиз һәм ташкындай җәелеп, цепькә таркалды.

* * *

...Үзәнлектәге куе курайлыктан йоннарына кырмавык ябышып беткән карт бүре килеп чыкты. Башын алга сузып, бераз тыңлашып торды: якында гына атышалар, ике яктан да дулкын-дулкын булып гүләүләр яңгырап килә иде...

— Тук! — дип, зиреклектән аталар. Ә басу артындагы түбәлек кайтавазлап:

— Так! — дип җавап бирә.

Тагын да ешрак:

— Тык-тык-тык!..

Түбәлек янә:

— Так-так-так! — дип кайтара...

Бүре ашыкмый гына өстерәлеп иңкүлеккә, саргайган камышлы үзәнгә төшеп китә...

...Атаман, өзәңгегә баскан килеш, сугыш кырын күзәтә, вакыт-вакыт аның боерык һәм сүгенүләре яңгырый иде:

— Бирешмәгез! Тачанкаларны ташламаска!.. Урманга каер... урманга таба, аналарыгыз чәнчелгере!..

Тик соң инде: тачанка янында кучер һәм пулеметчылар кайнаша, мичәү бауларын кисәләр, ә цепькә таркалган банда, туктаусыз кой-

ган пулемет утына түзә алмыйча, паникага бирелеп, сугыш кырыннан өелеп-өелеп кача башлый.

Атаман, атын борып, чигенүчеләрне туктатырга ташлана. Ләкин шул чак, үзе артыннан бөтен көченә куып, кылычы белән кизәнә-кизәнә бөркеттәй канатланып очкан берәүне күреп кала. Иңендәге буркасы, күкрәгендәге бинокле буенча ерактан ук атаман аның гади кызылармеец булмавын чамалый, бик яшь, хәтта мыексыз икәнен төсмерләп ала, ниһаять, ачудан кыйшайган йөзен, җилгә кысылган күзләрен күрә...

Атаман тезгенне ныграк тарту белән, аты ал аякларын күтәреп, бер урында биеп торды, шул арада билбавына кыстырган маузерын суырып чыгарды да, теш арасыннан сүгенә-сүгенә:

— Авызында сөте кипмәгән көчек! Әйдә кизән, кизән, кизәнәгенне бик тиз корытырмын мин! — дип, якынлашкан саен зурая барган кара буркага төзәп, атып та җибәрде. Җиде-сигез сажин чабып барганнан соң, Николаның аты сөрлегеп, алга ауды. Никола исә буркасын иңеннән ташлап, ата-ата йөгерә, түмгәктән-түмгәккә күчә, атаманга таба һаман якынлаша бара иде...

Шул чак урман артында ниндидер җәнлек улап җибәрде дә кинәт тынып калды...

Кояшны әледән-әле соры болытлар томалый, юл, урман һәм дала өстеннән кара күләгәләр йөгерешә иде...

«Аңсыз бозау, кайнарлана, үз башыңамы ашкынасың»,— дип мыгырдана атаман һәм тегенең обоймасында патроны беткәнен сизеп ала да, тезгенен бушатып, карчыгадай аның өстенә томырыла.

Иярдән сыгыла биреп, бар көченә кылыч белән чаба, бер мизгел кылыч сабы аша яшь командирның гәүдәсе изрәп, җиргә шуып төшкәнен дә тоеп кала.

Атыннан сикереп төшү белән, атаман иң элек бинокльне умырып ала. Аннары шикләнеп карана да командирның дерелдәп яткан аякларыннан хром итекләрен салдырырга ябыша.

Берсен җиңел башкарды. Икенчесенең оегы сыдырылган иде, ахры. Җиргә утырып, тез астына аягын терәп, бик усал сүгенеп торып тарткан иде, — оегы белән үк шуып чыкты, ә ялангач балтырында, тубыктан югарырак, күгәрчен күкәе тикле генә миң күренеп китте...

— Аһ! — атаман кара көеп төште, калтыранган куллары белән суынып барган башны иплап кенә, әйтерсең, уятудан курыккандай, йөзе белән өскә таба әйләндерде:

— Улыка-аем, Николушкам! Бәгырь каным минем... Ничек болай булды соң бу?! Әйтсәнә бер сүз, бер генә сүз...

Киң җилкәләреннән ипсез кочаклап, сүнеп барган күзләренә бага-бага, канлы күз кабакларын ачарга тырыша, улының авызыннан күбекләнеп-оешып килгән канга куллары буялып бетә... күтәреп бастырырга итә, селкетә — гәүдә әле йомшак, нишләтсәң дә бөгелеп кенә төшә...

Ләкин инде Николушка күгәргән тел очын нык тешләгән, гүяки ниндидер бик зур, бик мөһим бер серне ычкындырудан сакланган иде...

Атаман, улының гәүдәсен күкрәгенә кыса-кыса, туңа барган кулларыннан, бармакларыннан үпте-үпте дә, маузерының салкын корыч көпшәсен авызына кабып, атып җибәрде.

* * *

Кич. Сирәк урман артыннан искән җил атлар пошкыруын, өзәңгеләр чыңлавын, кешеләр сөйләшкән тавышларны алып килә... Менә бер төркем җайдаклылар күренә.

Шул чак атаманның тузгыган башы өстенә кунаклаган уләксә козгыны теләр-теләмәс кенә күтәрелеп очып китте һәм көзнең төссез соры күгендә бераздан бөтенләй эреп, күздән югалды.

Ф. ФӘСИЕВ тәрҗемәсе.

Ибраһим Салахов

КОЛАГИР

Хикәя

Акан Сире[1], шагыйрь һәм көй чыгаручы буларак, казакъ авыз әдәбиятында күренекле урын тота. Аның тормыш юлы турында хикәяләр, пьесалар һәм поэмалар языла. Көкчәтау өлкәсендә Акан Сире исемендә авыллар, колхозлар бар. Аның кабере өстенә һәйкәл куярга әзерлек бара. «Колагир» легендасы хәзерге көнгә хәтле казакъ халкының зур куанычы һәм даны! Шуның өчен дә Акан Сиренең «Колагир» бәете телдән төшмичә җырлана.

Бу хикәяне язу алдыннан мин Көкчәтау тирәсендәге Акан Сире булып үткән бик күп авылларга бардым, шагыйрьне күргән яки аның тормыш юлын, шигырьләрен белгән аксакаллар белән күрештем. Аларның озын-озын әңгәмәләрен, думбырада уйнап, үләң әйтүләрен тыңладым. Монда бу әсәрне язуда ярдәм иткән хөрмәтле аксакаллардан: Көкчәтауда торучы Омар Казбековка, Җилтаулыктан Карабалага, Акын авылыннан Корманкуҗага һәм башка чалларга тирән ихтирам белдереп, рәхмәт әйтәм.

АВТОР.

Сары Арка күгендә яңа, якты бер йолдыз калыкты. Бу — Колагир йолдызы иде...

Борынгылар сүзе.

Ат — казакъның канаты, ышанычлы юлдашы, иң зур куанычы һәм елап юылмас кайгысы. Әмма бу көннәргә кадәр казакъ даласында Колагирдәй җанвар тумаган.

Сүз сүздән туа, далалар урап йөри. Әңгәмә серле йомгак булып акрын сүтелә.

Урта йөзнең Чыңгыз нәселеннән килгән Туксанбай Акмолла иленда аеруча даны чыккан бай була. Ул тугыз ир егет үстерә. Һәр баласына өлеш итеп меңәр елкы билгели. Аның үзендә тагын затлы нәселле атлардан торган йөзләгән өерләре кала.

Туксанбай, туганнан алып дигәндәй, ат өстендә була. Ул үзенең озын гомер юлында бик күп яхшы атлар күргән. Тоягын тоякка урап юырткан юргалар, башына буй җитмәс аргамаклар, аккош кебек сузылып, аягын җиргә тидерми оча торган тулпарлар байның өерләрен данга күмгәннәр. Һәрбер туйда-җыенда тугыз бәйге[2] Туксанбай кулына эләгә. Ләкин гомеренең соңгы баскычында дала, җәйләү, өер-өер елкылар аның карамагыннан китәләр. Кояш җәйләү артына байый башлый. Йолдызлар кабынмыйлар. Караңгы, кап-караңгы төн урап ала Туксанбайны... Таң атмый. Кояш билгесез томан эчендә адашып кала. Караңгылык. Сукырлык! Шулай да Туксанбай дөньяның йөгәнен кулыннан ычкындырмый, нык тота. Ул ак киездән тегелгән утау өйдә[3], дүрткә

---

[1] Сире — җырчы, шагыйрь мәгънәсендә.
[2] Тугыз бәйге — ат ярышларында бирелә торган иң зур бүләк.
[3] Утау өй — өлкән өй.

бөкләнгән каймалы тикәмәт[1] өстендә, зур мендәргә янтаеп калгый. Аның киң маңгае елкы картасы кебек җыерылган. Күз кабаклары астында хәрәкәтсез ике сызык. Яңак сөякләре калкып өскә чыкканнар. Иягендә каурый сыман бер генә тотам ап-ак сакал.

Көннәрнең берендә калгып утырган Туксанбай кинәт ят бер тавыш ишетеп сискәнеп китә. Каурый сакал калтырана башлый, ул ачулы тавыш белән кычкыра:

— Бу авылда җан иясе бармы?!

Ул торып утыра, өч тубылгы чыбыгыннан үрелгән камчы сабын ике учлап кысып тота.

Киез өйнең ишеген ачып, тиз генә бер яшь егет керә дә, җиргә тезләнеп, камчысына таяна:

— Ата, ни боерасыз?

— Бер тулпарның тояк тавышы ишетелә. Безнең илнеке түгел. Күзеңне салчы, колыным.

— Караен, ата, хәзер...

Егет киез өйдән чыгып, авыл читендәге үргә күтәрелә дә ерак далага күз ташлый.

Казакъ баласының ярым кысык күзләре үткен. Алар бик ерактан күрәләр. Аның хәтере далада очраган һәрбер үрне, ташны, чокырны, хәтта бер генә тапкыр күзгә чалынган җанвар өнен дә онытмый. Әмма яшь егет бу юлы далада күз туктарлык бер генә дә чит карачкы күрми.

— Ата, — ди егет киез өйгә кире кайтып, — әйләнә-тирәдә бер җан да юк.

Туксанбай елан чаккан шикелле сикереп тора. Кулындагы тубылгы саплы камчысын ачу белән егетнең йөзенә ата.

— Күзең чыкканмы әллә? Тояк тавышыннан башым ярылырдай булды гой.

Елан кебек атылып килгән камчыны егет житез генә тотып ала да киез келәм кырыена куеп, сүзсез генә чыгып китә.

Найзатумар артыннан кояш күтәрелә. Озын корык сөйрәгән елкычы бияләрне иртәнге савымга әйди. Куйлар акрын гына утлап тауга күтәреләләр. Егет үр өстендә озак әйләнә. Ләкин Туксанбай чал тойган тулпар күренми.

Киез өйнең ишеге ачылуга, Туксанбай ачулы тавыш белән тагын сорау бирә:

— Я, килдеме?

Егет бер җавап та бирми, тик агарып китә.

— Авыл үлгәнме әллә? Тулпар килеп җитте гой. Уңмаган бала!

Чалның бөтен тәне калтырана, маңгай җыерчыклары тыгызланып, берсен-берсе кисешәләр. Кавырсын сакал бертуктаусыз селкенә. Егет тавышсыз артка чигенә. Ишек ябыла. Туксанбай киез өстеннән камчысын капшый, ачынып зарлана:

— Тәңрем, син нигә аларга күрми торган күз бирдең?!

Менә егет, чабып барган ат өстеннән сикереп төшеп, киез өйнең ишеген ачты:

— Ата, күренде!

Өстенә бихисап чапан, башына киң, төлке кырпулы бәрхет бүрек, аягына читекләр киеп, инде киез өйдән чыгарга әзерләнгән чал, бу хәбәрне ишеткәч, тынычланып, киредән түргә уза. Аякларын сузып утыра да кулын тезләренә куеп тынып кала.

---

[1] Тикәмәт — киез келәм

— Бәрәкалла! — Ул тирән сулап тын ала, уң кулы белән сакалын учлый. — Кунакларны хөрмәт белән каршы алыгыз.

Казакъ иле өч йөзгә бүленә: олы йөз, кече йөз, урта йөз. Менә шушы өч йөзнең иң күркәм жирендә урта йөз балалары тора. Ул жир — Сары Арка. Менә шушы Сары Арка жирендә күп ырулар жәйләү булып күчәләр. Алар арасында — Караул. Караулда — Яхшылак. Яхшылак илендә иң өлкән утау өй булып Карымса бай утыра. Карымса байның бердәнбер ат тотары — ир баласы була. Ләкин язмыш Карымса байдан ачы көлә. Аның таянычы, өмете булган ялгыз улы Жәгъфәр куркудан телсез кала. Бала үзе төскә матур, эшкә кыю була. Ул аеруча атта йөрергә ярата. Жиде-сигез яшьтән үк иң йөгерек атларга атланып, бәйгеләрдә катнаша, беренче бүләк һәрвакыт Жәгъфәр атына туры килә. Ләкин бала бер генә сүзне дә тулы итеп әйтә алмый. Бары ым белән генә сөйләшә. Карымса бай кара кайгыда йөри.

Жәгъфәр шулай сакау килеш ундүрт яшькә житә. Беркөнне Карымса авылындагы балалар күлгә балык тотарга баралар. Аларга Жәгъфәр дә иярә. Аның кордашлары байтак балык тоталар. Ә Жәгъфәргә бер балык та чиртми, калкавыч һаман су өстендә калкып тора. Балалар аннан көләләр.

Кинәт Жәгъфәрнең калкавычы батып күл төбенә чума. Балалар барысы да кызыксынып аның янына жыелалар. Жәгъфәр кармак сабын тарта башлый. Тегеләр, нәрсә булыр икән дип, тавыш-тынсыз кармакның чыкканын көтәләр. Кармак тиз генә чыкмый, ниндидер авыр балык аны жибәрми, тирәнгә тарта. Жәгъфәр оятыннан гарьләнеп, кызарып, кармакны бар көченә тарта... Кармакка эләгеп, ниндидер, балаларга таныш булмаган хәшәрәт килеп чыга. Жәгъфәр куркуыннан кармак сабын ташлап, һуштан язып егыла. Башка балалар чыр-чу килеп, төрлесе төрле якка качалар. Менә шушы икенче куркудан Жәгъфәрнең кинәт теле ачыла.

Карымса бай зур туй ясый — даланың өлкәннәрен — аксакалларны, муллаларны һәм бик күп халыкны мәжлескә чакыра. Симез-симез биялар, куйлар, сыерлар суела. Саба-саба кымыз эчелә. Өч йөзнең кадерле акыннары — шагыйрьләре килеп Карымса байны ялгыз улының теле ачылу белән котлыйлар, үлән әйтәләр. Йөзләгән тулпар-чабышкылар бәйгегә китәләр. Егетләр күкбар һәм тарту уеннарына катнашалар. Атаклы батырлар көрәштә көч сынашалар. Дала зур бәйрәм төсенә керә — Карымса байның шатлыгын бүлешә.

Жәгъфәр тиз арада думбырада уйнарга өйрәнә һәм үлән әйтә башлый. Кайда туй, кайда уен — Жәгъфәр шунда иң кадерле кунак. Аның иркен, киң тавышы, тапкыр һәм тирән мәгънәле жырлары, думбыра кылларын оста чиртүе даланың кара кашлы, ак йөзле гүзәл кызларын, яшь киленчәкләрен генә түгел, буз егетләрен, ир-азаматларын, илнең ак сакаллы өлкәннәрен дә үзенә жәлеп итә. Жәгъфәрнең булдыклылыгына чын күңелдән куаналар, мактыйлар. Соңгарак халык аны Жәгъфәр дип түгел, ә олылап Акан Сире дип атап йөртә башлый.

Ә кайберәүләр, аның данын көнләп, буз егетнең юлына кара күләгә булып басалар. Бу кара эчле дошманнарның башында Морзалы Шөбәкнең алты баласы: Баялы, Бигалы, Сиралы, Норалы, Сирдәле һәм Моканәле тора. Казакълар, куян үлеме — камышта, егет үлеме — намуста, диләр. Акан да намус өчен көрәшә. Сүздә дә, жырда да, дум-

бырада уйнауда да, бәйгедә дә алдынгылыгын бирми. Ул иртә таңнан ярышка әзерләп куелган йөгерек атына атлана, кара бөркетен иңбашына кундырып, Каратазысын — ау этен ияртеп сунарга чыга.

Дала өстенә хуш исле тыныч төн килгәч, жырчы ыруның иң матур кызларыннан берсе булган Оркыяның сөт шикелле ак өенә бара. Яшьлек уен-көлке, күңел рәхәтлеге белән мавыга. Үзе артыннан бертуктаусыз күзәтеп йөргән бәла-казаларның, кайгыларның тау кебек ишелеп, бер көн үз өстенә төшәсен уена да китерми Акан...

Илтуры бай һәр язны Кызыл яр ягына барып елкы җыеп йөри. Ул бу елкыларны үзенең иркен җәйләүләрендә багып симертә дә аннан Күкчәтау, Куянлы ярминкәләренә илтеп сатып, тиенгә тиен файда ала.

Менә шул Кызыл яр ягыннан килгән елкылар арасында сары бия була. Аңа башта Илтуры бай үзе дә, ялчылары да игътибар итмиләр. Калын карлы, буранлы, салкын кыш килә. Елкы, гадәттәгечә, тибендә йөри. Менә шунда елкычының сары биягә күзе төшә, гаҗәпләнеп аны күзәтә башлый.

Беркөнне елкычы Илтурыга килеп:

— Бай, сары биянең кызык бер гадәте бар, — ди. — Ул төнге суыкта, елкы өеренннән аерылып, көртә чыга. Һаман җил якка ята, өстеннән бу күтәрелә.

— Бәрәкалла, — ди Илтуры бай куанып, елкычысын янына утырта, — ашаганың калҗа булсын, чырагым. Сары биянең колыны — тулпар. Өстеннән күтәрелгән бу — шул тулпарның эссесе.

Бай, күңелле хәбәргә куанып, саранлыгын да онытып җибәрә, өлкән хатынын чакырып, елкычыга корт изгән бер аяк шулпа бирергә куша.

— Эч, карагым. Ит — иткә, шулпа-биткә. Тик сары бияне эттән, бүредән, яман күздән сакла, — ди.

Яз башында сары бия колынлый.

Карымса бай үзенең туганы Илтурыга бу язны кунакка килә. Атасы белән бергә Акан Сире дә килә.

Алар Илтурыда күп көн кунак булалар. Өйгә кайтыр вакыт җитә. Кунакларны озатыр алдыннан Илтуры, йола буенча, Акан Сирегә бүләк бирергә тели.

— Оялма, колыным, ни теләсәң шуны сора. Чебен җанымнан башкасын аямыйм, бирәм, — ди.

Акан Сире, казакъ гадәте буенча сый-хөрмәт өчен күп рәхмәт әйтеп, мал-җанга исәнлек теләгәннән соң, Илтурыга үзенең теләген әйтә:

— Өлкән агам, миңа сары биянең колыны Колагирне бирсәң, түбәм күккә тияр иде, — ди.

Колагир кунаклар белән бергә Алкакүл җәйләвенә күзгала. Илтуры аларны ярты юлга хәтле озатып куя. Юлдагы болакка туктап атларны сугарып торганда, болар янына бер сынчы[1] килә. Ул атлар арасында Колагирне күреп:

— Бу ат — тулпар. Ул чабышларда алдынгылыкны бирмәс. Ләкин... — ди ул, бераз уйланып, — усал күздән саклагыз.

---

[1] Сынчы — ат белгече.

Акан Сире Колагирне һичбер кешегә күрсәтми — үзе торган киез өйдә, чаршау артында гына асрый. Ул аңа су урынына бия сөте эчерә. Ашарга бары солы гына бирә. Колагир үзенең буе белән башка казакъ атларыннан аерылмый. Урта буйлы. Төсе кола. Башы сыер башына охшаш, җәенке. Муены нечкә, сыйраклары кыска. Койрыгы толым-толым булып үзеннән-үзе үрелгән. (Бәйгедә ул үз койрыгы белән үзен кыйнап бара икән.) Колагирне иярләгәндә, һәрвакыт ике егет иярләгән. Коешкан[1] салганда, койрыкны бер кешегә җыеп күтәреп торырга, икенче кешегә кидерергә туры килә торган булган. Чапканда Колагирнең арткы ике тоягы өзәңгегә тиеп-тиеп китә икән.

Колагир өч яшьлек чагында сигез архарны куып җитә. Бу хәбәр Сары Аркадан чыгып, өч йөзнең барлык далаларына тарала. Халык һәрбер җирдә Колагир турында сөйли башлый. Казакъ даласындагы зур бәйгеләр Колагирдән башка узмый. Ә Колагир һәр бәйгедә беренче булып килә.

Ириминдә Сагынай дигән бай туксан дүрт яшенә җитеп дөньядан китә. Сагынайның улүенә бер ел тулганда, аның ыруы зур мәҗлес үткәрә. Бу мәҗлескә Кызыл яр, Күкчәтау, Караткүл, Каркаралы, Баян, Сими, Тургай, Алтай, Җидесу һәм башка дуаннардан[2] халык җыела. Алар үзләре белән сугым мал, кымыз һәм бәйгегә иң яхшы атларын алып киләләр. Җыенга Акан Сире дә Колагире белән чакырыла. Ләкин Аканның атасы Карымса:

— Балага рөхсәт. Догамны бирәм, ләкин Колагир калсын, — ди.

Караул ыруы борчыла. Халык Карымсадан Колагирне зур бәйгегә кушуын, ил алдында Сары Арканың дәрәҗәсен төшермәвен үтенә. Карт бөгелми:

— Сүзегез — алтын, аксакаллар. Ләкин күңелем тартмый.

Бай шулай дип илнең сүзен кире кага. Ыруның өлкәннәре өченче тапкыр Карымсаның утавына килеп, Караул ыруының үпкәсен әйтәләр.

— Илнең өлкәннәре, яхшылары сезгә карап торыр. Ялгыз баланны бирәсең. Дүрттоякны бирмисең. Караулның тереләре дә, әрвахлары да сезгә риза түгел.

Чал кайгы тулган күзләре белән вәкилләргә карый да тирән көрсенеп:

— Ил сорагач — барсын... — дип куя.

Шундук озак юлга әзерлек башлана.

Берничә көннән соң Карымса улы Акан Сирене юлга әзерли. Янына батыр егетләр кушып бирә. Аканның чапанына юллык акча тектерә.

Карт Карымса ике кулын күтәреп юлчыларга фатиха бирә:

— Тәңрем юлыгызны уң кылсын. Көндез йоклагыз, төндә йөрегез. Колагир янында төне-көне ике егет булсын. Юлдашыгыз — Хөзер-Ильяс, бер ходаем үзеңә тапшырдым.

Карт Карымсаның эчкә баткан, сүнеп барган күзләрендә яшь тамчылары күренә.

Еректан күк күкрәгән тавыш ишетелә. Офыкны кара болытлар каплап ала. Найзатумар ягыннан салкын җил исә. Юлчылар кузгалалар. Төш авышкач, алар Туксанбай авылына җитәләр.

---

[1] Коешкан — ияр тоткыч каеш.
[2] Дуан — хәзерге төшенчәдә өлкә.

Туксанбай ерак юлдан килгән мөсафирләргә кунак ашы әзерләтә. Көне-төне туйганчы кымыз эчелә. Куйның башын, хөрмәт белән, Акан Сире алдына куялар.

Аштан соң, киез өстенә җәелгән ашъяулыкны җыеп алалар. Туксанбайның иң кечкенә улы — кыска сыйраклы, юан гәүдәле шадра Илүбай маңгаендагы тирен терсәге белән сөртә-сөртә җиз ләгән, җиз комган алып килә. Кунаклар кулларын юып, шундук яннарындагы мамык мендәрләргә янтаялар. Акан Сире думбырасын ала.

Колагирне махсус тегелгән киез өйдә тоталар. Аның янында сакта ике егет тора. Алар бу өйгә берәүне дә кертмиләр, карт Карымсаның юлга кузгалыр алдыннан биргән фатихасы һәм боерыгы онытылмый. Колагир Сары Арканың намусы бит ул.

Эчәгедән ясалган кыллар тартылалар, чыңлап калтырыйлар, аннан, тулпар ат кебек, ашкынып җилә башлыйлар. Акан Сиренең һәрбер тыңлаучыны сихерләп ала торган моңлы тавышы яңгырый:

Башка судан бер кашык зәм-зәм артык,
Дәрья булып, дингез булып акмаса да,
Сузеннең, кидәй-байгыш, кадере юк,
Иртәдән кичкә кадәр какшасаң да.
Бай булсаң, гариплегең һич беленми,
Аягың өч урыннан аксаса да.
Ат гүзәл, айгыр сылу ялы белән,
Бай — чичән, мулла — галим малы белән.
Эт булып бу дөньяда көн күргәнче
Кидәйне алсын ходай табы[1] белән...

— Чырагым, — сукыр карт калтыраган кулы белән Акан Сиренең аркасыннан сөя, — Туксанбайның үз күзе белән Колагирне күрәсе килә.

Акан Сире хөрмәт белән баш ия:

— Өлкән агамның күңеле Колагирдә булса, минем куанычым, әлбәттә, далага сыймаслык...

Туксанбай урыныннан тора. Кунаклар да аягүрә басалар. Аксакалның җилкәсенә Акан чапан сала, киң кырпулы бүреген кидерә һәм култыклап тышка алып чыга. Авыл уртасына халык җыела. Утау өе янындагы кечерәк ак киез өйнең ишеге ачыла. Ике егет, ике яклап йөгәннән тотып, Колагирне өйдән алып чыга. Колагир колакларын торгыза. Күзләрен зур ачып карый. Борынын югары күтәреп, хәвеф-хәтәр юкмы дигән кебек һаваны иսни. Кинәт ул өркеп артка чигенә. Ике егет аны, йөгәнгә асылынып, көчкә тотып калалар. Тамашачылар тына. Хәтта сулыш алулары да ишетелми. Туксанбай, кунаклардан узып, икеөч адым алга атлый. Бөтен игътибары белән Колагиргә текәлә, сүнгән күзләре белән йотылып карый башлый...

Колагир дә бу күңел күзе белән сокланып карауны аңлаган кебек тынычлана, дуламый. Ике егет Колагирне салмак кына атлатып авыл курасы буйлап әйләндерәләр.

Соңгы тапкыр әйләнгәч, Колагирне Туксанбайның каршына туктаталар. Карт туп-туры Колагирнең янына килә, калтыраган ябык кулы белән атның аркасыннан сыйпый, сөя, муеныннан кага. Аннан борылып:

— Күңелем бозылды, алып китегез Колагирне, — ди.

Кунаклар аптырап калалар.

---

[1] Таб — сыйныф мәгънәсендә.

Туксанбай аягын бөкләп җиргә утыра. Барлык халык җиргә чүгеп Туксанбайга текәлә.

— Чырагым, — ди чал, бер кулы белән сакалын учлап. — Үз гомеремдә елкы баласын күп күрдем, ләкин Колагирдәй атны ходай миннән аяган... Тоягы уң, башы аман булсын тулпарның.

Карт башын түбән ия, нәрсәдер уйлана, маңгай җыерчыклары таралалар. Аның салкын, сары йөзе кинәт яктырып китә:

— Үзең сайлап тугыз өер елкы ал. Унынчысын үзем бүләк кылам. Бу җанварны Туксанбайга багла, туган.

Акан әдәпле төстә картның соравын кире кага. Егетләр атларына атланалар.

Туксанбай, Акан Сирегә фатихасын биреп, Карымса байга ил өлкәннәренең сәламен әйткәннән соң, дога кыла:

— Сары Арканың йолдызы сүнмәсен...

Күктә йолдызлар кабына. Ерак тау тезмәләре артыннан яртылаш ай күтәрелә. Дала ат тоякларыннан дерелди. Колагир Иримин җиренә ярышка бара. Йолдызлар тагы да яктырак яналар. Ай тагын да биегрәк күтәрелә. Колагир, Колагир! Нигә туктамыйсың, нигә Караул җәйләвенә кире борылмыйсың, җанварым?!.

Батраш Күксакал — Алтай иленең бер карчыгасы. Күзе — ут, уе — агу, кулы — кан, аягы — үләт авыруы, башы — бәла. Ул Алтайны күп әйләнгән, күренгәнгә тырнагын батырган, таудан таш булып атылып, илнең күзеннән канлы яшь агызган. Аның артында кара күләгә булып атасы Бигәйдар торган. Алдында исәпсез күп мал җәелгән. Астында һәрвакыт йөгерек ат булган. Шулай да Батрашның нәфесе туймаган, туктамаган. Ул Алтайдан чыгып, Алатауга, Балхашка, Күкчәтауга — өч йөзнең өчесенә дә ташланган. Язгы йолкыш бүре булып, кара төндә кара уй белән өстерәлгән. Һәрбер урдә шымчы булып озын колагын салган. Батрашны мирза иткән — аның күк тулпары Күктойгын була. Ул елкы баласының сирәге, зирәге һәм гүзәле санала. Алтай җирендә Күктойгыннан йөгерек ат булмый. Ул барында бүләкне башка бер елкы баласы да ала алмый. Батраш шул Күктойгынны Сагынайның мәҗлесенә алып килә.

— Баш бүләк минеке. Бәйгене мин отам, — дип күкрәк кага.

Акан Сире халык арасында. Ул думбырасын уйнап җырлый:

Туры атны иярләп менсәң иде,
Өке[1] тагып юргалатып йөрсәң иде.
Кызлы авылның нәкъ түшеннән төн буенча
Иркәң өчен янып-көеп йөрсәң иде.
Сүз салып җиңгә аша иркә җаңга,
Кордаш кызың белән уйнап-көлсәң иде.
Ишарәләр, ымлар белән сүз кузгатып,
Кыз серен җиңгәсеннән белсәң иде...

Киез өйгә халык сыймый. Кирәгәнең киезләрен күтәреп, тыңлаучылар берсе өстенә берсе ябырылалар. Ят илдән килгән яңа көй, яңа җыр Ириминнең кунакларын бу өйгә җепсез бәйли. Бервакытта да күрелмәгән тынлык. Халык, Аканның һәрбер сүзен отып алырга тырышып, аның авызына караган. Җитез бармаклар думбыра кыллары өстендә уйныйлар.

[1] Өке — ябалак канатыннан эшләнгән бизәк.

Шагыйрь шулай ялкынланып, янадан-яңа җырлар җырлый. Үзенең иң матур көйләрен уйный. Аның күңеле дала күге кебек якты һәм керсез...

Ә якында, бик якында, караңгы, кара болытларның куерганын, аларның көтмәгәндә күкрәп яшьнәвен Акан Сиренең күңеле сизми...

Төнлә сибәләп вак яңгырява. Ул тузанны гына бастыра. Таң алдыннан болытлар таралалар. Далада кояшлы, якты көн туа. Төн буе Аертау битендә утлаган елкылар, куйлар Усак күл ярына җыелып, ашыкмыйча гына су эчәргә төшәләр. Күл дулкынланмый, көзге сыман ялтырап ята. Терлекләр үз шәүләләренә үзләре хәйран калып, аптырап карап торалар. Дала яңгырдан соң гына була торган хуш ис, чәчәкләр исе белән сулый.

Ириминнең җәйләвенә халык сыймый. Казакъ даласының барлык ыруларының өлкәннәре, буз егетләре, атаклы батырлары, сылу кызлары, сүзчән киленчәкләре, саран карчыклары, бер урында тынып торуны белмәүче, туп кебек тәгәри торган бала-чагасы — барысы да монда. Алар төркем-төркем булып Усак күл каршындагы үргә күтәреләләр. Бу хәтле халык җыенын җәйләү бервакытта да күрмәгән була.

Көткән көн килеп җитә. Зарыгып, өметләнеп, хәвефләнеп көткән минутлар, шау-шу, ыгы-зыгы башлана.

Ярчыларның[1] тамаклары карлыга. Халык үргә җыелып мәйдан кора. Мең дә өч йөз баш тулпар бәйгегә кузгала. Биш мең ике йөз тояк җирне тетрәтеп, тузан туздырып Кыз-Качкан болынына ашыга.

Акан Сире Колагиргә атланып чабучы Карабаланың битеннән үбә. Башына, колакларын каплап, яулык бәйли. Күтәреп Колагиргә атландыра. Тынычсызланып биеп торган Колагирнең тезгененнән уң кулы белән тотып, сул кулы белән аның муеныннан сыйпый. Бу чакта Аканның күзләре Колагирдән башка бернәрсәне дә күрми:

— Бу бәйге — кыргын! Атыңда яхшы утыр. Җил якка чык. Колагиргә тузан йоттырма. Алдыңа бер-ике ат чыгарып, тезгенне кагып кына бар. Камчылама. Әнә теге күк үзәнне күрдеңме? — Акан, кулын сузып, Усак күлнең аръягындагы вак таллыкка күрсәтә. — Шунда килеп җиткәндә тезгенеңне бушат, үз иркенә куй җанварны.

Акан тезгеннән кулын ала алмыйча озак тора. Ат та, бала да тынычсызланалар.

— Ал, — ди Акан кинәт йокыдан уянып киткәндәй, — хуш, Колагирем. Аман килгәнеңчә ике күзем юлда булыр...

Батраш салпайган иреннәрен бармагы белән казып ямь-яшел насбаен ала да җиргә төкерә. Аның кипкән мүк төсле күк сакалы калтырана, ике күзе юлда.

Кыз-Качкан үзәненең бирге ягындагы карагайлыкта, күләгәдә яткан өч егет урыннарыннан торалар. Аларның икесенең кулында күсәк, өченче егетнең кулында озын саплы айбалта...

[1] Ярчы — игълан йөрүче

Кинәт җир тетрәп китә. Кыя ташлар өстендә калгып утырган бөркетләр сискәнеп күккә күтәреләләр. Кыр кәҗәләре, боланнар төрлесе төрле якка ыргылалар. Кара болыт булып тузан күтәрелә. Мең өч йөз ат — биш мең ике йөз тояк җирне казып, ут чыгарып, берсен-берсе кагып, таптап, Иримингә таба юнәлә. Ялгыз карагайлар, суы кипкән үзәннәр, вак әрәмәлекләр, далада адашып торып калган кыя ташлар, кылган ябынган көмеш дала ашыгып артка чигенә. Мең өч йөз ат кыр казлары кебек бер-бер артлы тезелешеп, тузанга күмелеп оча.

Җир туктаусыз дерелдәп, сулкылдап тора.

Бәйгенең алдына күк ялкын кебек атылып Күктойгын чыга.

Карабала тезгенен бушатып Колагирнең ялын кочаклап ала. Кинәт күсәк күтәрелеп атка суга. Колагирнең авызыннан канлы күбек атылып чыга. Аның алдыннан дүрт тулпар бара. Атлар урдән төшәләр. Колагир икенче кистән астыннан чабып уза.

Усак күл артыннан тузан күтәрелә. Иримин үренә җыелган халыкның сабыры бөтенләй югала.

Башкалардан аерылып күл читенә ике ат чыга. Акан Сиренең талган күзләре Колагирне танып яктырып китә.

— Җанварым! Я хода, мәдәт бир!

Ике ат Иримингә килеп җитәр алдыннан, соңгы уйсулыкка — суы кипкән Еланлы үзәненә төшеп югала.

Кинәт кояшта айбалта ялтырап китә. Колагирнең муеныннан кан ага. Ул киселгән башын өстерәп беркадәр чабып барганнан соң, гөрселдәп җирга ава.

Карабала кычкырып елап яр астына тәгәри.

Үзәннән ялгыз ат — күк ат күтәрелеп чыга.

Акан Сиренең йөрәге өзелеп киткәндәй була. Аның күз алды караңгыланып, башы әйләнеп китә.

Халык берсен-берсе таптап, шау-гөр килеп, кайсы куанып, кайсы пошынып, Сагынайлыларны җиңүче Күктойгынны каршылый.

Бәйге бүләген Күктойгын ала.

Кояш оятыннан кызарып, елап байый. Бу төндә Иримин күгендә якты бер йолдыз сүнә. Шуңа Сары Арка иле караңгыланып кала.

Акан Сире елый-елый ерткыч тырнагындагы болан шикелле өзгәләнә.

Ниһаять, шагыйрь акылын җыя, сөекле Колагиренең канга баткан, киселгән башын күтәрә:

— Ни булды, ой-бай-ай, Колагирем?!
Чишмәм идең, күңелемнең суы кипте.
Йөрәгемнең таянычы, юанычым,
Бу җирдә кемнәр сине харап итте?..

Чынлап миннән китүеңме, Колагирем?
Янымда иркәләнеп тора идең.
Башма-баш кызга алышмас, җанварым,
Басылырмы үлгәнгәчә кайгы-чирем?

Колагир, атаң — тулпар, анаң — шоңкар,
Сугып алдым конан[1] чакта сигез архар.
Син идең җан атым да, канатым да,
Табылмас инде миңа синдәй тулпар...

[1] Конан — өч яшәр ат.

Аканнын тыны кысыла. Аның жыры, канаты сынган ак кош кебек талпынып, күтәрелә алмыйча жирдә кала. Усак күлдән дымлы, салкынча жил исә. Дулкыннар ачуланып берсе өстенә берсе ишелә башлыйлар. Болытлар арасыннан ялтырап ай чыга. Шагыйрь күзен ача.

Акан Сире Колагирнең башын ике кулы белән кочаклап, аның салкын күзләреннән үбә.

Хуш инде, калдың минән, Колагирем,
Еласам да тормадың, елаган идем,
Дөньяда ялгыз йөреп җәфа чиктем,
Язмышым — күрәчәгем бу да минем.

Колагир, хушлашам мин ил алдында,
Гәүдән калды синең ятып Еландыда.
Аерылдым янымдагы ялгыз аттан...
Тормадың, сыкрадым да, еладым да...

Ерак офыкта таң кызара.

Акан Сире Колагирнең башын алып ак яулыкка урый.

Далада ялгыз бер казакъ бара. Аның кулында думбыра, аркасында ак яулыкка төргән атаклы тулпар Колагирнең башы...

Колагирнең һәлакәтеннән соң Акан Сиренең йолдызлары бер-бер артлы сүнә башлый. Башта хатыны Оркыя вафат була. Аның артыннан Карабөркет һәм Каратазы исемле ау этләре үлә. Акан Сире авылын ташлап далага китә. Аның бердәнбер юлдашы думбыра була. Шагыйрь, бай гаиләдән чыгуына карамастан, бар рухы белән байларга, биләргә, муллаларга — хаксызлыкка, кеше көченнән файда күрергә тырышучыларга каршы чыга. Ул җәйләүдән җәйләүгә туктап, авылның иң ярлыгидәйләренә думбыра уйнап, үлән әйтеп, шигырьләр сөйли, әйләнә тирәдәге хаксызлыкларны фаш итә, халыкны көрәшкә чакыра.

КҮКЧӘТАУ.

Әдип Маликов

Яндырылган хатлар

Тирә-ягы диңгез,
Уртасында сагыш.
Үсми монда бодай,
Дулкынланмый арыш.
Тирә-ягы таулар,
Буйларында дотлар.
Самурайга каршы
Төбәлгәннәр туплар.
Без атауда тордык
Ил кушканын үтәп.
Килә иде хатлар,
Килә иде күпләп.
Хат эчендә яфрак —
Бакча тәмәкесе.
Туган як төтене,
Туган җирем төсе.
Килә иде хатлар
Солдат өйләреннән.
Саф мәхәббәт җыры —
Яшьли сөйгәнемнән.
Килә иде алар
Миңа яшәү алып.
Мин аларны йөрттем
Ранецыма салып.
Август төне иде,
Приказ килде кинәт...
Без хатларның барын
Утка яктык җыйнап.
Дөрли учак теле,
Йөрәкләрне ялмый,—
Яктысында солдат
Патроннарын барлый.
Нәфрәт үскән саен
Арта барды көчем,—
Мин дошманнан алдым
Янган хатлар үчен.
Күчте ал таңнарга
Шул учакның нуры...
Саумы, туган ягым,
Саумы бодай кыры!

Алда өр-яңа юзлар

Бер юлдан барабыз,
Бер йөкне күтәреп,
Төшмәсен сиңарга авыры.

Юлларда сикәлтә,
Юлларга чык куна,
Каршылый бураны, яңгыры.
Каршылый томаны...
Син куе томанда
Югалып торгандай итәсең.
Томаннар тарала,
Син читкә борылып,
Яшьләнгән күзеңне сөртәсең.
Бер юлдан барабыз,
Көне бар, төне бар...
Йолдызлар кул изи ерактан.
Фәрештә шикелле,
Син күккә ашасың.
Мин сине табам да
югалтам.
Табам да югалтам...
Ә йөкнең авыры
Сиңа да, миңа да бер төшкән.
Югалту бик авыр...
Син шунда яңадан
Елмаеп чыгасың бер төштән.
Бер баксаң — син гади,
Гәрәбә шикелле
Балкыйсың утәдән-утәгә.
Ә кайчак нур булып,
Гөлләргә кунасың,
Табалмам шикелле иртәгә.
Бер юлдан барабыз...
Елмая чәчәкләр.
Алар бит төрлеләр, серлеләр.
Җыр булып әйләнә дә,
Миңа кун. Ә алда—
Яңа яз,
өр-яңа бөреләр.

Әйтелми калган сүзләр

Тол елгасы — агым су,
Йөзә тулган ай.
Яшьлек хатирәм калган
Синдә Солтанай[1].

Көттек таңнар атканын
Толның ярында.
Булырсың дип уйладым
Һәрчак янымда.

Яшьлекнең бар үз җыры—
Була бер генә.
Әйтелми калган сүзләр
Кала күңелдә.

Аерды безне юллар,
Һәм ярсу еллар.
Очрашу көтеп талды
Сузылган куллар.

Еракта,
бик еракта
Калдың, Солтанай.
Йолдызлар киңлегендә
Йөзә тулган ай...

Соң инде эзләсәм дә
Йөргән эзләрне.
Тигезләде барын да
Тормыш безнекене.

[1] Солтанай — авыл исеме. Барда районында.

Рәшит Гәрәй

Сәлам сезгә Себердән

Кич кайтканда арып кайткан
Тәндә шундый җиңеллек!
Ничек аунап ятмак кирәк
Хыялларга бирелеп...

Себер карты бүләк иткән
Тунымны киям өскә.
Ә сез әле йоклыйсыздыр
Иртәнге сәгать өчтә.

Монда инде җиде тулган,
Вакытның рәхәт чагы.
Һавасын сулап кайтырга
Тайгага чыгам тагы.

Таныш сукмаклардан үтәм
Сокланып тирә-якка.
Әйтерсең, шомыртлар монда
Кышын да чәчәк ата.

Ап-ак булып утыралар
Бәс сарган ботаклары.
Үзләренә әсир итеп,
Юлыңнан туктатмалы.

Каршыдагы тау битләрен
Каплаган куе томан.
Аларга йөзәр аршынлы
Зәңгәр шәл япкан сыман.

Шуңа бит монда күкләр дә
Зәңгәрерәктер кебек.
Әй, ничек соң куанмыйсың
Бу матурлыкны күреп!

Шушы якка гашыйк булып,
Үссен иде улларым.
...Ылыслы урман эченә
Алып керә юлларым.

Куе урман эчендә дә
Тарала инде эңгер.
Туган җирдәге дусларым,
Ә сездә әле төндер.

Төндер әле... Монда инде
Кояш чыгып өлгергән.
Хәерле иртәләр теләп,
Сәлам сезгә Себердән!

Тайга эчендә

Ничек күрми торганбыздыр
Монарчы:
Каршыбызга килеп басты
Сунарчы.

Эт тавышы ишетелде
Колакка...
Бераздан без сунарчыда
Кунакта.

Кай арада әзерләп тә
Китергән:
— Яле, житешегез куян
Итеннән.

Туңгансыздыр, бераз жылынып
Алыгыз.
Аз димәгез, моны бүлеп
Салыгыз.

Юл хәлләре узгалады
Миннән дә.

...Безгә урын түшәде ул
Идәнгә.

Безнең белән бергә ятты
Үзе дә.
Арылган... Тик йокы керми
Күземә.

Жил ажгыра әле һаман
Урманда.
Күңел тыныч янда дуслар
Булганда.

Арган юлчы күреп төнге
Утымны, —
Эзләп тапсын, әй, минем дә
Йортымны.

Килеп керсен яңгырлардан,
Тузаннан.
...Юлчылардан жанымны да
Кызганмам.

Сабан туен көткәндә

Озын колга тотып, яшь егетләр
Урам буйлап яулык җыялар.
Кызлы йортлар турына җитәр-җитмәс,
Хәбәр салып җырлап куялар:

— Һәй, сеңелләр, көттермәгез,
Без киләсен белдегез...
Кайсы гына яшь батырга
Насыйп булыр сөлгегез?..

Сөлгеләргә иярәп чыксын, әйдә,
Чиккән яулык, чиккән янчыклар.
...Кыз чакларын сагынып, тәрәзәдән
Карап калсын әби-карчыклар.

Килен булып төшкән вакытларын
Искә алсын әле апалар...
Җыр авазы шаулап керсен өчен
Ябылмыйча кала капкалар.

Чал агайлар чыга егетләрнең
Яулык җыйган чагын карарга.
Кызлар күзе төшкән дусларымнан
Көнләшергә әзер алар да.

Яшерен-батырын түгел: көнләү хисе
Үземдә дә минем җитәрлек.
...Эх, бер шигырь яза алсаң иде
Сабантуйга бүләк итәрлек.

Ферма буйларында эзләр бар

Ферма буйларыннан үтәм көн дә,
Ферма буйларында эзләр бар.
«Безнең ферма кызы чит авылга
Китә икән», — дигән сүзләр бар.

Төн йокысы качты һәммәбезнең,
Уңганнарга ия күп тә соң!
Кемнәр белгән шушы Халидәнең
Кайсыбызга гыйшык тотасын?!

Бер истәлек итеп саклар микән
Без җибәргән сөю хатларын?..
Бала-чага көтә ачылуын
Кыз китәчәк яшел капканың.

Һәркайсына берәр кучтәнәче
Булмый калмас әле кияүнең.
...«Нинди матур кызны кулыбыздан
Ычкындырдык»,— диеп сөйләүнең

Ни кирәге бар соң сөлге таккан
Атлар выжлап үткәч каршыңнан?..
Егет булсаң, кызны бирмәс өчен
Тотып ал син атның башыннан.

Мәхәббәтен яулап ал син кызның,
Күп булыр ул илдә көндәшләр.
Ә сынатсаң: «Ярын ятка бирмәс
Егет бу!» — дип, сиңа кем дәшәр?

Китаптанмы, халык теленнәнме
Мин ишеткән шундый сүзләр бар.
...Ферма буйларыннан үтәм көн дә,
Ферма буйларында эзләр бар.

Мәдинә Маликова

КЫР ЯГЫ

Хикәя

Дилбәргә хат килде. Ул бизәкле конвертны алды да үзләреннән ерак түгел паркка йөгерде. Беркем дә күрмәгән тыныч җирдә, ялгызы гына укып чыгасы килде аның бу хатны.

Парк эче тын. Рәт-рәт тезелгән ак каеннар сары, кызгылт, көрән яфракларын сукмакларга, ачык җирләрдәге яшел чирәмгә түшәгәннәр инде. Ә тирәкләр ямь-яшел әле.

Тирәкләр саргаймаган. Алар Чишмәдә дә шулай яшелдер.

Чишмә... Бүген Дилбәргә килгән, аның күңелен җилкендергән бизәкле конверт та Чишмәдән иде. Кыз хатны тиз генә ачып укый алмады. Аның күз алдына Казаннан еракта, бик еракта, тау астында утырган зур авыл килеп басты...

* * *

Дилбәр укый торган студентлар группасы «Чишмә» колхозының шефы исәпләнә иде. Быел җәй дә алар колхозга урып-җыюда ярдәм итәргә булдылар. Дилбәрнең моңа кадәр авылга барганы юк иде, чөнки аны, күзе начар күрү сәбәпле, врачлар авыр эштән азат итеп килделәр. Бу юлы комсомол җыелышы тарала башлагач, чая телле Разия:

— Иң соңгы анекдотны ишеттегезме: Дилбәр авылга китә! — дип шаркылдап көлде. Аңа башкалар да кушылдылар.

Дилбәр башта аптырап калды, аннары кинәт гарьләнде, кимсенде, ләкин сер бирмәскә тырышты, шаярган булып җавап кайтарды:

— Бер дә анекдот түгел, дөрес сүз бу!

— Һи-и, әниең җибәрәме соң сине!

Җамал апа башта кызын үгетләп тә, ачуланып та карады. Ахырда, Дилбәрнең үз сүзендә нык торуын күреп, кулын селтәде:

— Бар-бар, күреп кайт! Рәхәткә чыдый алмый башлагансың икән. Идәндә аунап, иртә-кич коры бәрәңге ашап, тузан эчендә таңнан-танга ат урынына эшләп кайт. Соңыннан андый эшләрдән ваз кичәрсең үзең дә! — диде.

...Чишмәдә аларның өчесен — Разияне, Санияне һәм Дилбәрне квартирага Сорур апага урнаштырдылар.

Аларның каршысына, авызын ачып, зур кара күзле, озынча битле ун-унбер яшьлек малай килеп чыкты. Бу Сорур апаның кече малае Рафис икән. Чемоданыннан чыгарып биргән кәгазьле канфите өченме, әледән-әле елмаеп караганы өченме, ул Дилбәргә бик тиз ияләште. Ишек алдында малай аның учына комганнан су салып торды, йөгереп кенә кызыл башлы сөлге китереп бирде. Ә кояш кичкә борылгач, үзе белән мәктәп бакчасына чакырды:

— Дилбәр апа! Әйдә мәктәпкә барыйк! Минем түтәлләрне күреп кайтырсың!

Гаҗәп кызык авыл булып чыкты бу Чишмә! Урам ягына һәр өй түренә диярлек пар агач утыртканнар: менә пар каен, пар өрәңге, пар

миләш, пар алма, пар шомырт, пар сирень куагы. Мәктәп турында, башларын бик югары күтәреп, юан, туры кәүсәле, киң колачлы пар тирәк үсеп утыра. Шәһәр урамнарындагы кыркылган түгәрәк башлы зәгыйфь агачларга күнеккән Дилбәргә бу тирәкләр искиткеч биек, матур, мәһабәт булып күренделәр. Бик күптәнгедер бу тирәкләр. Аларга, мөгаен, Рафисның бабасы үрмәләгәндер. Челтәрле яшел бөркәнчекләре кулагәсендә хәзерге әбиләр әйлән-бәйлән уйнагандыр...

Рафис Дилбәрнең чуар сарафаны итәгеннән тартты:

— Әйдә инде! Керик!

Шифер түбәле, зур тәрәзәле яңа мәктәптән юеш йомычка исе аңкыды. Дилбәр белән Рафис кечкенә капкадан бакчага керделәр. Рафис карлыган, кура җиләге куакларын, алма агачларын, яшелчә түтәлләрен күрсәтеп мактанды. Кыяр түтәлендә үскән күгелҗем сабаклы үсентеләрне күрсәтте:

— Болары — алма. Төштән утыртканыем. Ике ел була инде. Киләсе елга ялгыйм мин аны. Әнис алмасы ялгыйм, матур да, тәмле дә була.

Аннары койма янына узды.

— Монысы — виноград! — Рафисның тавышы горур яңгырады. — Кара әле, тәлгәшләре нинди! Күзгә хәтле җитешә әле ул.

Дилбәр яшел төймәләрне учына салып карады. Җимеш димәсәң хәтере калыр! Әмма ямьсез була икән башта бу виноград! Ай-һай, күзгә бу төймәләр пыяладай үтә күренмәле, балдай татлы, бармак башыдай эре җимеш булып житешер микәнни?

Кинәт капка ягыннан:

— Әй, син! Кемне алып кердең безнең бакчага? Виноград ботарлыйсызмы? — дигән тавыш ишетелде.

Дилбәр артына борылып карасa, капка төбендә түгәрәк йөзле, почык борынлы бер шук малай басып тора.

Рафис кызарынып-бүртенде:

— Синең ни эшең бар анда? Кит моннан, Хәмит-кәмит!

Малай көлә-көлә урам уртасына йөгереп чыкты. Бер төркем балачага узып бара икән, ул шуларга әләкләргә тотынды:

— Рафис күзлекле апасын бакчага алып килгән. Виноградны ботарлыйлар!

Балалар коймага сарылдылар һәм гаҗәпләнеп Дилбәргә текәлделәр.

Ахырда зур кара күзле кызчык кыюсыз гына сорап куйды:

— Апа, син Зөһрә апа урынына килдеңме әллә?

— Нинди Зөһрә апа? — дип сорады Дилбәр.

— Укытучы. Китте ул бездән. Сез дә укытучымыни?

— Әйе, укытучы.

Балалар шаулашып алдылар.

— Әй, яңа укытучы икән бит!

— Нишләп виноград ботарласын ул?

— Әйдәгез, киттек!

Балалар шаулашып үз юлларына киттеләр.

— Кая баралар алар? — дип сорады Дилбәр Рафистан.

— Көтү каршына. Мин дә барам. Әйдә, киттекме?

Көтү кайтырга иртәрәк икән әле. Бала-чага, чыр-чу килеп, ике урамлы уйнарга тотынды. Дилбәр, юл кырыендагы зур ташка утырып, аларны күзәтте. Менә юлдан зәңгәр «Волга» үтеп китте. Машинадагы елтыр күзле кеше Дилбәргә гаҗәпләнеп карады.

— Председатель бу! — диде Рафис.

Көтү кайткач, балалар таралды. Рафис белән Дилбәр дә кайтыр юлга чыктылар. Аларны атлы кеше куып житте. Арбада майлы кием кигән абый, аның янында Мөнирә, әлеге «Син укытучымы?» дип сораган чибәр кызчык.

Абзый кеше атын туктатты.
— Исәнмесез! — диде ул карлыкканрак тавыш белән. — Әйдә, утырыгыз... Алып кайтам.
Мөнирә абзыйга якынрак сыенды. Рафис шунда ук сикереп арбага утырды да яныннан урын күрсәтеп:
— Утыр, Дилбәр апа! — диде.
Дилбәр бер майлы арбага, бер сарафанына карады.
— Юк, Рафис, утырмыйм. Син кайта тор, мин җәяү генә...
Ат кузгалды. Кыз да, малай да бераз Дилбәргә карап бардылар. Шунда гына Дилбәр аларның бер-берсенә гаҗәп охшаш икәнен күреп алды. Икесе дә озынча битле, зур кара күзле, икесе дә бик җитди. Тукта! Атлы кеше дә шундый ук уйчан кара күзле, шундый ук озынча чибәр йөзле бит! Рафис белән Мөнирәне бу абыйның игезәк балалары дип белерсең!
Ул кайтып җиткәндә, атлы туктаган, Сорур апа уңайсызланган кыяфәттә капка төбендә басып тора иде.
— Төш, Рафис, — диде ул.
— Су буена чаклы гына барыйм инде, әнкәй!
— Төш, улым, төш! — Сорур апа Рафисның кулыннан тартып арбадан төшерде.— Ә синә... ничә әйттем инде,— диде ул атлы агайга әрнүле тавыш белән. — Бала алгысытып йөрмәсәң...
— Әткәй, әйдә инде! — диде Мөнирә.
Атлы дилбегәсен какты. Рафис, җил капка аратасына ябышып, атлы киткән якка карап калды. Ә Сорур апа, Дилбәрнең өйгә кергәнен дә сизми, өстәлгә капланып елый иде. Ак яулыгын башыннан салып, өстәлгә ташлаган, нечкә толымнары калтырана... Дилбәр Сорур апаны ни дип юатырга белмәде, бары тик атлы кеше белән Сорур апа арасында ниндидер бәйләнеш барын бөтен йөрәге белән сизенде ул...
Кызлар идарәгә киткән булганнар икән, аларны Сорур апа тынычланып, елмаеп каршы алды, кыстый-кыстый җылы сөт, ярып пешергән кайнар бәрәңге белән сыйлады.
Аннары кызлар, киенеп-ясанып, клубка чыгып киттеләр.
— Бродвейга чыгабыз,— диде Разия Дилбәргә.— Матуррак киен, авыл кызлары һушлары китеп егылырлык булсын. Күзлегеңне салсаң да ярар, монда әллә ни күзәтер нәрсә юк. Так что безне күзәтсеннәр.
Дилбәр, бүген Сорур апаның бер үзен калдырырга ярамас, дип уйлады. «Талчыктым, чыгып йөрисем килми», — диде.
Рафисны йоклаткач, Сорур апа өй алды өстәленә җырлап торган самоварын китереп куйды.
— Әйдә, кич утырыйк алайса. Дөнья хәлләрен сөйләшик.
Сорур апа кызның ата-анасы, туганнары, ничек үсүе, укуы турында сорашты. «Сез бәхетле чакка туры килдегез шул!» — дип аның язмышына кызыкты, аннары ачылып китеп, үз тормышын сөйли башлады.
— Яшьтән үк бәхетем булмады минем. Сугыш алдыннан олы апам үлеп китте. Ике кызы ятим калды. Мин унтугызда гына идем әле. Менә сиңа ничә яшь? Егерме берме? Синнән дә яшь булганмын әле. Әнкәй мәрхүмә әйтә: «Чык, кызым, җизнәнә, — ди. — Балалар үги ана кулында үскәнче, үз апалары кулында булырлар. Ятим итмик сабыйларны!» — ди. Үземнең дә йөрәк таш түгел, кызганам. Тәки бардым җизнигә. Яз көне иде. Авылдагы йола буенча, шушы өй түренә ике алмагач утырткан идек. Кырык беренче елның кышында корыдылар... Ике ай да тормадык, сугыш башланып, җизнәм димме, ирем димме, китте дә барды. Юньләп ир рәхәте күрмәдем, буйга да узмадым, ичмасам. Ике кызны тәрбияләдем, этиләре исән кайтыр, дип өметләндем.
Юк, кайтмады. Сугыш бетәр алдыннан, шул каһәр төшкән Германиядән үле хәбәре килде. Нишлисең инде... Шул кызларым белән юанып яшәдем. Гомер үтте, кызлар үсте. Буйга җитеп, канатланган кош

кебек, очтылар да киттеләр. Борынгыларның: «Ир бала, ир бала!» — дип юкка гына авыз сулары корымаган шул. Хак икән картларның сүзләре, кыз үстерсәң — кешегә бүләк, ул үстерсәң — үзеңә терәк икән. Бирсә ир бала булса, үз янымда нигезләнеп калган булыр иде, мөгаен. Шулай итеп, ялгыз калдым. Яшь идем бит әле, утыздан узсам да, кырыкка житмәгән идем....

Сорур апа күрсенде, «аңларсыңмы» дигән кебек, Дилбәргә сынап карады. Аннары, тәвәккәлләп, сүзен дәвам итте:

— Авылда ишегеңне йозаклап, йөрәк сереңне биклап яткырып булмый. Монда минем үткәнемне белмәгән кеше юк... Гөнаһ шомлыгы диген, бер заман гашыйк булдым бит. Син беләсеңдер инде яратуның ни икәнен?.. Әллә белмисең дәме әле?

Дилбәр сүзсез башын иде. Юк, аңа әле янып-көеп сөярдәй кеше очрамады. Мәхәббәтне китаптан укып кына белә ул.

— Менә шул. Яраткан кешең — гаилә башы, бала атасы булса, гыйшык дигәнең үзе бер газап икән... Мин аның комбайнында салам төшереп тора идем... Көн-төн эшлибез... Басу ерак, икәү генә калган чакларыбыз да була. Аның йөрәге дә таш түгел бит. Дөресен әйткәндә, ярата иде ул мине. Хәзер дә ярата... Балага узганымны белгәч, тәмам тинтерәдем. Бер уйлыйм, үз балам, үз йөрәк парәм, малай булмасмы, дип, икенче уйлыйм, бөтен авыл битемә төкерер, оятын кая куярмын, дип. Шулай итеп, малай таптым...

Сорур апа алъяпкычын кайтарды да, маңгаендагы тир бөртекләрен сөрткән булып, бер очтан күз төпләрен ышкып алды.

— Авылда хикмәт инде. Барысының да авызында бер сүз: атасы кем дә атасы кем. Үзем әйтмәсәм дә, сизенәләр инде кем икәнен. Житмәсә, малаем тач әтисенә ошаган, суйган да каплаган инде менә.

Дилбәр арбадагы кара күзле өч кешене исенә төшерде.

— Атасының күңеле тарта малайны. Жаен тапкан булып килеп керә дә: «Күрсәт әле!» дип ялына, сөеп туймый. Хатыны сизенеп берничә тапкыр тәрәзәләремне кырып китте. Юкка хур булып йөрде инде. Мин ничек ике бала атасын аннан тартып алыйм, ди? Бүтән хатыннар да мине якламады. Тол калганнары: «Бездә дә жан бар, әмма синен кебек семья бозып, ятимнәр үрчетеп йөрмибез», — дип сүктеләр... Читенлеген үзем генә белдем инде. Ярый әле, кызларым кырый какмады. Акчасын, әйбер-карасын жибәреп тордылар. Олы кызым һаман чакырды. «Монда торма, әнкәй, — ди. — Ичмасам, Рафис атасын бөтенләй күрмәс, сиңа да жиңелрәк булыр», — ди. Бер заман, түзәр әмәлем калмагач, өйне бикләдем дә малайны житәкләп чыгып киттем. Бер елга якын шәһәрдә тордык. Артык түземем житмәде. Һич кенә дә күнегә алмадым. Авылны сагындым. Шәһәрнең шома таш урамнарына баскан саен, аяк тавышым, кайтып кит, кит-кит-кит, дип такылдый. Ни булса, шул булыр дип, кире кайттым. Рафисны житәкләп, басуга бардым... Кыяр тавына менеп, як-ягыма карадым да елап жибәрдем. Басулар иксез-чиксез, иген каерылып уңган. Сагындырган икән жирнең жыерчыклы йөзе!

— Ничек? — дип кайтарып сорады Дилбәр.

— Жир дим, жир сагындырган. Ихатамны кат-кат әйләнеп йөрдем. Койма буендагы кычытканнар да йөрәккә якын тоелды...

Әңгәмә шунда өзелде: кызлар кайтып керде. Урынга яткач, Дилбәр Сорур апа сөйләгәннәрне уйлап, бик озак йокыга китә алмады.

...Икенче көнне кызлар ындыр табагына эшкә чыктылар.

Дилбәр сер бирмәскә, кеше көлдермәскә тырышты. Кызлар ял итәргә утырсалар да, ул эштән туктамады. Авыл апалары кебек үк итеп капчыктан бөркәнчек ясап, башына киде дә транспортердан шыбыр-шыбыр коелган борчак астында озын саплы ашлык себеркесе белән көшелнең чүбен себерде.

Разия, сарыга буялган чәчләрен җилфердәтеп, килгән бер машина янына йөгереп бара, шофердан папирос сорый. Менә без нинди, янәсе, шәһәр кызлары! Ә төш турында күлмәген салып, көшел өстенә җәйде дә сузылып ятып кояшта кызынды. Сания дә аның янына ятты.

Апалар алай гаеп сүзе ычкындырмасалар да, еш кына алар ягына гаҗәпләнү, ачу катыш караш ташладылар. Ә ындыр табагы механигы — агач аяклы абзый — көшелне читтәнрәк урап узды.

Кичен, икәүдән-икәү генә калгач, Дилбәр Сорур апа тормышы турында сүз кузгатты.

— Хәзер элекке кебек үк кимсенеп йөрмим инде, — диде Сорур апа. — Председатель дә, бригадирлар да кырын карамый. Ни сорасам, шуны бирәләр, хәлемә керәләр. Тик Рафиска читен. Атасы күз алдында булса да, «әткәй» дип әйтер кешесе юк. Үскәч, «Күрәсем дә килми сине!» — дип ташлап чыгып китмәс микән? Яшь кешенең каны кызу, акылы сай булучан. Аңлар микән мине?

— Ни гаебегез бар сезнең аның каршында? Ничек инде аңламасын,— диде Дилбәр.

— Ю-ук, алай димә син. Гаебем зур инде, анысында шик тә юк. Тик менә аңа, сиңа сөйләгән кебек итеп, барысын да ачып салып булмый бит. Ни дисәң дә ир бала... Хәзер яшьләргә дүрт якка юл ачык. «Синең белән тормыйм, космонавт булам» дип чыкты китте. Аны бәйләп тота алмыйсың! Туган җирен минем кебек яратырмы ул? Анасы янында калырга теләрме?

Бу сөйләшү Дилбәрне бик нык уйланырга мәҗбүр итте. Җитмәсә, Сорур апа мәсьәләне Дилбәрнең үзенә күчерә:

— Менә син — укытучы кеше. Ана күңелен дә, бала күңелен дә аңларга тиеш кеше. Менә Рафисны ничек тәрбияләр идең син? Кеше баласы — агач түгел. Аның күңелендәге кирәксез уйларны агач ботагын кискәндәй кисеп ташлап булмый.

Аннары ялгызлыгына уфтана:

— Синең кебек бер туганым булса, бергә торсак, малайга һаман акыл биреп торыр иде. Рафис сине бер күрүдә яратты... Юк шул, юк, ялгызлык! Аның укытучылары да үзебезнең авылныкы бит, күбесе мине гаепли...

Дилбәр янә уйланды, янә аптырады. Рафис, Мөнирә... Бер ата балалары. Икесе ике фамилиядә. Берсенең «әткәй!» дип әйтер кешесе янында, икенчесе «ялгыш туган!» Ничек тәрбияләргә, нинди карашлар, хисләр үстерергә алар күңелендә?

Дилбәр Рафис белән күбрәк вакыт бергә булырга тырышты. Билгеле инде, Рафис янына бала-чага җыела, Дилбәр аларга китаптан укыганнарын сөйли, алар белән уйный, мәктәп бакчасына йөри торган булды.

Шулай көндез ындыр табагында эшләп, кич бала-чага белән уралып, Сорур апаның зарын тыңлап йөргән көннәрнең берсендә, Дилбәр тормышында кечкенә генә үзгәреш булды.

Төштән соң кемдер Дилбәрнең башына салынган капчык-бөркәнчегеннән тартты. Транспортер тырылдавы, борчак шыбырдавы аша Дилбәр кеше килгәнен бөтенләй сизмәгән. Борылып караса, сары чәчләре кепкасы астыннан бүселеп чыккан, таза гына гәүдәле шофер басып тора иде.

— Карагыз әле! — диде ул, Дилбәрнең колагына иелеп. — Миңа грузчик кирәк иде. Басуга барып кайтмыйбызмы?

Дилбәр капчыкны салып, себеркесен куйды да, капрон яулыгын рәтләп бәйләп, сүзсез генә кабинага барып утырды.

Егет папирос кабызды, машинасын кузгатты. Менә алар авылдан чыктылар да басу юлына борылдылар.

Полоса буйлап шактый баргач, борчак җиренә килеп җиттеләр.

Комбайн килеп туктады. Машина кузовына шаулап борчак акты. Дилбәр аны көрәк белән тигезләп таратып торырга тиеш иде.

Кузов яртылаш кына булды. Комбайн кузгалды. Шофер Дилбәргә:

— Төшегез! Тагын бер әйләнеп килгәннәрен күтәргә туры килер! — диде. — Бер кырык минуттан киләләр алар. Әйдәгез, әнә агач күләгәсенә барып утырып торыйк. Ашыйсыгыз киләме?

— Рәхмәт!

— Әйдә, тартынып тормагыз!

Шофер кабинадан сумка алды. Аннары җиргә газета җәеп, сумкасыннан пешкән йомырка, ипи-тоз, бер банка хөрмә компоты чыгарды, кесәсеннән пәке алып, банканы ачты.

— Әйдә, рәхим итегез! Сез компот яратасыз бит.

— Каян белдегез?

— Кибеттә берьюлы өч банка алганыгызны күргән идем.

Чыннан да, Дилбәр Сорур апаны, Рафисны компот белән сыйлаган иде шул.

— Кара син аны! Күзегез очлы икән!

— А как же! Таныш булыйк инде — Нурзаһит! — дип, егет зур, көчле кулын Дилбәргә сузды.

Аның үткен карашыннан Дилбәр уңайсызланып калды, кызарынды. Ул үзенең сипкелләреннән, күзлек киеп йөрүеннән читенсенә иде.

— Укытучы булырга исәп, димәк? — диде Нурзаһит.

— Әйе.

— Кайсы фәннән инде?

— Рус теленнән.

— Кара син аны. Ә менә минем рус теленнән һич баш эшләми. Диктантларны көч-хәл белән өчлегә язам. Мин быел кичке мәктәпне очлап чыктым. Авыл хуҗалыгы институтына сугылып карарга исәп. Заочно. Математикадан ничек булса да тапшырам мин. Менә рус теле генә аяк чалмаса...

Басуга таныш «Волга» килеп туктады. Аннан елтыр күзле, озын буйлы, утыз яшьләрдәге кеше чыгып, кара свитерын тарткалап куйды.

— Председатель бу безнең, — диде Нурзаһит.

Дилбәр белән Нурзаһит машина янына килделәр. Менә комбайн да килеп җитте. Аннан тузанга баткан ике комбайнчы төште.

— Калдырасыз бит, егетләр, ә? — диде председатель. — Менә борчакның күпмесен таптап кына узгансыз.

Дилбәр шунда гына борчак җыеп алынган җиргә игътибар итте. Урыны-урыны белән җирнең буеннан-буена борчак ята. Ул инде җиргә бөтенләй ауган, тапталган.

— Без нишләтик инде аны, иптәш Мәрвиев, — диде комбайнчы гаепле тавыш белән. — Ургыч алмаган аны, таптап кына үткән. Комбайн белән алып булырлык түгел!

— Да, батмый бу болай, ярамый! — Председатель бер уч салам йолкып алды. — Соңыннан кул белән җыярга туры килер. Нихәтле уңыш югала, ә! Кешесе дә юк бит аның!

Ул эре адымнар белән покослар ягына барып, аларны күтәреп карады. Аннары тагын машина янына килде.

— Ярар, егетләр, эшегездә булыгыз! — диде ул комбайнчыларга. — Күп калмады, тырышырга туры килер. Давай, шулай килешик әле: бүген чык төшкәнче урырга. Син, Нурзаһит, аларны ташлап китмә.

Аннары ул елтыр кара күзләрен Дилбәргә текәде.

— Ә сез яңа укытучы түгелме соң? Нишләп идарәгә килеп чыкмыйсыз?

— Юк, мин студентка.

— Шулаймыни? — Бу җавапны ишеткәч, председательнең Дилбәрдән күңеле сүрелгәндәй булды. — Мин, укытучы килгән икән, дип сөе-

һәм тагын. Балалар белән ураласыз бит, бер көнне мәктәп бакчасында да нидер эшләп азаплана идегез. Исемегез ничек әле?

— Дилбәр.

— Дилбәр, менә борчак җирен чистартырга балаларны оештырасы иде бит, ә? Безнең укытучылар кайсы ялда, кайсы мәктәпне рәтләү белән мәшгуль, берсе декретный отпускада. Балалар белән уйнап йөрергә генә түгел, эшләргә дә осталыгың бардыр, бәлки?

Дилбәр ык-мык итеп, бер юньле сүз әйтә алмый торган арада, Мәрвиев нәтиҗә ясап куйды:

— Ярый алайса, килештек. Ярдәм кирәк булса, бригадир булышыр. Безнең башка басулар чиста, монда гына сыйфат бозылган. Шушыны җыярга ярдәм итсәгез, бик шәп булыр иде.

Ничек булды соң әле бу? Нишләп Дилбәр: «Юк, булдыра алмыйм!» — дип әйтмәде?

Моңарчы өйдә бар эшне әнисе эшли, институтта исә Дилбәр уртача гына, тыныч кына студент булып, аңа бер эш тә ышанып тапшырмыйлар иде. Шушы яшенә җитеп, Дилбәр бер тапкыр да хезмәтнең тәмен татып карамаган иде әле.

Ә хезмәтнең тәме тозлы һәм ачы икән. Иртән Дилбәр Рафисны ияртеп, тыкрыкларның чыклы үләнен таптап, балалар җыеп йөрде. Өлкән укучылар бар да колхоз эшендә, өйдә бары тик Рафисның яшьтәшләре генә калган иде.

«Бу сабыйлар белән шулкадәр зур басуны ничек чистартып бетерермен!» — дип пошынды Дилбәр.

Әмма сабыйлар эшкә нык булып чыктылар. Дилбәрнең үзенә алардан калышмас өчен, адәм көлдермәс өчен бик нык тырышырга туры килде. Көннәр бер-берсенә тоташып, тир тамчылары, кояшның рәхимсез кыздыруы, куллар талчыгуы, билләр сызлавы, балаларның шау-шуы белән генә хәтердә калдылар.

Әмма соңгы көнне бүгенгедәй хәтерли Дилбәр.

Менә алар үр башына менделәр дә туктадылар. Шунда бер еллык үлән басуы башлана. Бетте. Бүтән иеләсе, йолкыйсы, тырышасы юк. Дилбәр артка борылып карады. Никадәр җир үткәннәр алар, никадәр яңа кибәннәр куйганнар! Дилбәр шушындый кечкенә, сыдырылып беткән куллары белән күпме борчак йолкыды! Ә бит ул үз янындагы балалар белән бергә бу басу уртасында алландагы кырмыска кебек кенә!

Әнә басу һаман түбәнгә, үзәнлеккә төшә. Үзәнгә авыл урнашкан. Дилбәргә авыл көмеш тасма белән бәйләнгән искиткеч зур чәчәк букетын хәтерләткән кебек тоелды. Авыл очында елганың теге як ярында җимеш бакчасы. Алмагачлар, линейкага баскан пионерлар сыман, саф-саф тезелеп торалар. Текә тау бите бакчаны төньякның ачы җилләреннән саклап тора.

Тау өстендә калкулыкларда—басулар. Әнә лимон кабыгыдай сары—арыш басуы, алтын-сары — бодай басуы, ямь-яшел — кукуруз басуы, кап-кара — борчак җирен трактор сөреп киткән. Ә читтәрәк бер-бер артлы алты комбайн йөри. Соңгы борчакны сугып бетерәләр. Моннан караганда, алар нәни коңгызлар кебек кенә. Әмма бу иксез-чиксез басуларга шул комбайннарны йөртүче кешеләр хуҗа.

Шушы икән инде ул «җирнең җыерчыклы йөзе!» Кешеләрнең күчелен тарткан, йөрәген җилкеткән гүзәллек шушы икән инде!

— Дилбәр апа! — дип кычкырды Рафис. — Әйдә, җиләк ашарга киттек!

Алар шау-гөр килеп үзәнлеккә йөгерделәр. Кызык, бу үзәнлек Чишмә саз асты дип атала. Ә үзенең сазы да, чишмәсе дә юк. Тар гына уйсулык. Үләне кояшта кибеп, саргаеп беткән. Үләннән биегрәк сабакта кып-кызыл, баллы җир җиләкләре пешеп утыралар. Башта Дилбәр иелеп ашады. Аннары балалардан үрнәк алып, утырып, ятып аша-

ды. Кызлар яулыкларына, малайлар фуражкаларына җиләк җыйдылар.

Кайтырга чыккач, балалар, берсен берсе бүлә-бүлә, бу урынның тарихын сөйләделәр:

— Борынгы заманда урман булган бу җирдә!

— Урман уртасында сазлык, диген!

— Чишмәсе дә булган!

— Безнең бабайлар урманны кисеп бетергәч, сазлык корыган, чишмәсе кипкән. Җиләге белән исеме генә калган.

Кичен Мәрвиев Дилбәрне идарәгә чакыртты.

— Рәхмәт, зур рәхмәт! — дип кулын кысты ул Дилбәрнең. — Бик зур ярдәм иттең. Институтны кайчан бетерәсең әле син?

— Соңгы елым укыйм.

— Бигрәк шәп! Бетергәч тә безгә кил. Мәнә мәктәп директоры белән үзем сөйләшермен, запрос җибәрербез. Синең кебек кешеләр бик кирәк безгә.

— Чакыруыгыз өчен рәхмәт!

— Нигә, әллә шәһәрдәге уңайлыклар монда булмас дип уйлыйсызмы? Әнә урам уртасына чишмә суын китердек. Шәһәрдә андый тәмле суны таба да алмыйсың. Газы да булыр, баллоннар белән кайтара башладык инде.

Аннары сүзне кинәт борып куйды:

— Ярый, анысын уйларбыз. Ә хәзергә син ул укучыларны таратма. Әнә, Әхмәтҗан абзый бакчада карлыган коела дип зарлана. Шуңа әзрәк ярдәм итәрсез.

Эссе кояш нурлары астында янып-пешеп кура җиләге җыйгач, бөтенләй хәлдән тайгач, алар рәт-рәт тезелгән ак каеннар, зифа тирәкләр арасыннан яшел чирәмле тар сукмак буйлап су буена йөгерәләр иде. Биек ярдан коелып төшеп, елгага кереп китәләр иде.

Елганың суы чип-чиста, төбе сап-сары ком. Дилбәр тирәнрәк җирендә утырып юына, су муеннан гына була. Сай җирендә балалар елга төбендәге комга корсаклары белән яталар, башлары су өстендә кала.

— Дилбәр апа! — ди Мөнирә. — Кыш көне бу төштә каток ясарбыз, әйеме! Башта болай шуып була. Буран булса, карны чистартасың да суны бәкедән генә алып сибәсең. Менә күрерсең, мин конькида малайлардан шәп шуам.

Эшләнмәгән эшләр, күрмәгән матурлыклар күп калды Чишмәдә. Рафис:

— Безнең таулардан кыш көне чаңгы шуарга бик шәп, — дип мактанган иде. — Бергә шуарбыз, Дилбәр апа, яме!

— Мин сине безнең басуларны әйләндереп алып кайтырмын әле, — дигән иде шофер Нурзаһит. — Кыр ягы, диләр, урманы юк, күңелсез, диләр. Безнең басулардагы тирән күлләр, чылтырап аккан чишмәләр, җиләкле уйсулыклар, яшел полосалар любой урманнан матуррак. Менә үзең күрерсең.

Әмма Дилбәр аларның берсен дә күрергә өлгермәде.

Авылдан китәр алдыннан гына яңгырлар башланды. Шундый яман су көннәренең берсендә балалар белән җыелышып комга барганнар иде. Комны яңа төзелгән мәктәп ишек алдына сиптеләр.

Су буена, күпер төбенә җиткәч, Нурзаһит кабинасыннан сикереп төште дә кузовтагы бала-чагага сызгырды:

— Ягез, коелыгыз! Тәяп карагыз әле, кайсыгыз көчлерәк икән?

Малай-шалайлар ашыгып, чыр-чу килеп эшкә тотындылар. Шофер да кулына көрәк алды:

— Ну шәп тә соң комы. Асыл ком! Мәктәп ишек алды келәм җәйгән кебек була инде моны сипкәч!

Дилбәр көлеп җибәрде:

— Ком асыл була димени!

Нурзаһит бераз тын алырга туктаган арада гына, Дилбәр аның күрәген алды:

— Бир әле, мин дә бераз төйим әле!

Менә ул юеш комны ашыгып кузовка ата башлады. Булмаган, җебегән икән дип уйлый күрмәсеннәр тагын. Дилбәр, башын да күтәрмичә, автомат кебек ашыгып эшләде.

...Басу, бакча һавасы, чишмә суы бик шифалы икән. Бибисорур апаның стенадагы көзгесе каршына баскач, Дилбәр үзен күреп сокланды. Ул бераз ябыкты, биле нечкәреп, буе зифаланып китте. Бөтен кыяфәтендә горурлык, ныклык сизелә. Маңгай чәчләре кояшта уңып, алтын йөгертелгәндәй җемелди. Бите каралды, сипкелләре сизелмәс булды. Зур зәңгәр күзләре, кыйгач кара кашлары күзлек пыяласы аша күренми дип уйлый иде Дилбәр. Ник күренмәсен, күрәсе килгән кеше бик күрә аны!

Авылдан киткәндә, Нурзаһит студентларны машина белән аэродромга илтеп куйды. Вак яңгыр сибәләп тора, болытлы моңсу көн иде. Студентлар аэродромның юеш үләненә сикереп төшкәч, Нурзаһит җаен китереп Дилбәргә:

— Әйдә, кире кайтабыз, — дигән иде.

— Юк, — диде Дилбәр, — чакыруың өчен рәхмәт.

Кабинага утырып, машинасын кайтыр якка боргач та, егет ишеген ачып, Дилбәргә ишарә ясады:

— Әйдә!

Кыз дулкынланып, елмаеп аңа кул болгады.

Авылдан кайтканда күңеле дә бик алгысап кайтты Дилбәрнең! Мәктәптә эшләү бик авыр, кыен, нервларны какшата дип, әтисе-әнисе белән киләчәктә китапханәдә генә эшләячәге күптән инде хәл ителеп куелган булса да, хәзер аның бу эшкә бер дә күңеле тартмый башлады. Төшләренә карлыган тәлгәшләре, борчак покослары, сабыр табигатьле Рафис, кызу канлы Хәмит керде.

Һәм, ниһаять, һич көтмәгәндә, Чишмәдән менә бу хат килеп төште. Бизәкле конверттагы адрес бик пөхтә итеп, нәкъ матур язу дәфтәренә язылганча тырышып язылган. Рафис кулы. Дилбәр конвертны сак кына ачып, эченнән шакмаклы дәфтәр битләре алды.

— «Дилбәр апа, исәнмесез!

Сезгә безнең класста укучылардан бик сагынып күп сәлам. Үзебезнең хәлгә килсәк, безнең класста «2»ле алучы юк. Сезне кышкы каникулга кунакка чакырабыз. Конькиларыгызны алып килегез, каток ясап куярбыз...»

Аннары төрлесе төрле якка сикергән шук хәрефләр тезмәсе киткән. Хатны Хәмит дәвам иткән, күрәсең:

«Дилбәр апа! Эх, җәл, алма җыйганчы тормадың. Шундый күңелле булды. Мин сиңа бик тәмле алмалар сайлап җыеп куйдым. Килгәч сыйлармын. Миңа рус теле китабын алып кил әле. Яме!

Классташлар исеменнән Хәмит, Рафис!»

Онытмаганнар! Чишмәдә эзләре суынмаган икән әле Дилбәрнең. «Кайт, көтәбез!» дигәннәр. Чынлап торып көтәләр микән? Аңа серен сөйләгән, «синең кебек туганым булсын иде!» дигән Сорур апа киләчәге өчен һаман ут йотып йөри микән? Ә Нурзаһит аның турында ни уйлый икән? «Менә шәһәр кызы бик кыланып йөргән иде, койрыкны сыртка салды», — дип сөйләүчеләр дә бардыр әле.

Дилбәр авыл кешеләренең, Сорур апаның, Нурзаһитның үзенә бик-бик якын булуын тойды. Рафисның, Мөниранең, башка балаларның киләчәгенә битараф була алмаячагын сизде. Яшел таулар, җиләкле үзәннәр, иркен басулар, Сорур апа әйтмешли, җирнең җыерчыклы йөзе чакыра иде аны.

Равил Фәйзуллин

Минем телем

Минем телем —
меңәрләгән ишләре күк,
тыйнак тел ул;
гайрәтләнмәс артык, һаваланмас,
яңгырыйм дип, чәчрәп кабаланмас,
егәр чиген белер, йөрер жирен...

Басынкы ул:
халыкара конгрессылар,
парламентлар ачып йөрми,
акча, чеклар битенә менми.
Сугыш ачмыйлар минем телемдә,—
капитуляция ясамыйлар...

Минем телем —
меңәрләгән ишләре күк,
моңлы тел ул.
Үзенә җай, үзенә ятыш аның көе:
«Сак-Сок»лары, «Рамай»лары, «Сарман»нары,
«Гөлҗамал»ы, «Карурман»ы, «Әллүки»е!

Гавәми ул,
бик гади ул.
Минем телдә иген үсә,
сөт парлана, җеп эрләнә,
сабын кайный, тире иләнә...
Туендыручылар,
киендерүчеләр дигәндә
минем телем исенә төшсен!

●

Әгәр җирдә
вулканнар сукылдарлык фаҗига чыкса...
Миңа
сукырлар күзләрен шар ачып караячак:
«Төсләрдә алдандың!..»
Телсезләр шыр ярып кычкырачак:
«Авазларны аералмадың!..»
Аяксызлар йөземә басачак:
«Хәрәкәтләрдә ялгыштың!..»

Фаҗигага юлыкмыйк дисәк,
иң яхшысы
бүген үк
дөньяга, тирә-юньгә җентекләп карыйк,
авазларга — сизгеррәк...

●

Болын кебек бу маңгаем
вакыт мөһер суксынгамы?
Кукрәкләргә сыенргамы?
Батырлар чардуганына
иелеп орыныргамы?
Уйланып, шәфәкъне күзләп,
тәрәзәгә терәргәме?
Туган җиргә капланганда
чирәм эзе төшсенгәме?..

Башны тотып уйлаганда
маңгаемнан — уч төбенә
җыерчыклар күчәр төсле...

Иңемә кулларың орынгач

Буран котырган төндә,
кечкенә бүлмәмдә,
уйда изрәп утырганда
иңнәремә минем
әллә апрель,
әллә май кагылды?

Тәнем буйлап кинәт
зәңгәр гөрләвекләр йөгерде,
ләйсән яңгыр исе
яңагымны сыйпап узды,
күзләремә тулган зур шатлыктан
керфекләрем ябылалмый калды,
көндәлдә булган инсафсыз сүзләр
иреннән тәгәрәп
идән ярыгына төшеп югалдылар...
Өстәлдәге агач ручка яфрак ярды,
урындык аяклары сөенешеп үзара
пышылдаштылар
(такмак язучы шагыйрьдән акыллырак булып
күренделәр алар бу минутта),
язу машинасындагы хәрефләр
иң игелекле сүзләр язарга әзерләнделәр...
Туңган тәрәзәдә бөгелгән кулларың чагылышы
салават күпере ясады;
урамнан — шул күпер өстеннән —
безнең тәрәзәгә елмаеп,
изге күңелле кеше узды...

Котсыз суык көнне
шыксыз бүлмәмә син яз китердең.
Чын күңелдән рәхмәт сиңа!
Әгәр һәр кергән бүлмәгә яз ясасаң,
миңа күңелле булмас...
Тик шулай да бүлмәләргә,
кемнекенә генә булса да,
көз китермә, яме!

•

Читләрдән әйләнеп кайттым.
Ә Әмәт тавындагы ай
тамчы да үзгәрмәгән.

Бераз үзгә, бераз бүтән,
әллә ябыккан инде?
Йөзеңдә буйлы күләгә,
әллә яулыктан инде?

Күзеңдә сабырлы сагыш —
газаплы көткәнгәме?
Керфекләреңне аралап
күп төннәр үткәнгәме?
Җир ич! Язлар, гөрләвекләр
үзенекен иткәннәрдер,
безнең өчен ятим юк дип,
сипкелләр сипкәннәрдер.
Сынапмы, ятлар, болаймы
күңелеңә чирткәннәрдер...

Шулай да татлы ашкыну
сагыну, өмет ташкыны
сүнеп үк җитмәгәндер.
Калгандыр нәрсә дә булса
күңелең юшкынында:
ахыргы чиктә шатлыктан
елашкан кич турында.
Хәтерлимсең, яшь һәм яңгыр
яңагың чылатканны,
мин сине, ә син үземне
арганчы елатканны;
татулашкач, сабыйлар күк
җитәкләшеп кайтканны...

Калгандыр нәрсә дә булса,—
шулаймы? Әйт, яшермә!
Юк булса — горур китәрмен,—
куралмассың яшем дә!

•

Урман караучы кызының
үрмә таҗы ландыштан!

Малай чак дәфтәреннән.

Сине күптән күргәнем юк,—
бик еракта торасыңдыр.
Урман кызы түгелдерсең,
инде ана булгансыңдыр:
тормышның авыр, җиңелен
тәнеңдә тоясыңдыр...

Кайчак бик күрәсем килә,
Бик-бик сөйләшәсем килә...
Тик куркам: ай, кыен булыр,
син үрмә таҗсыз булсаң,
каршымда ханым булып,
сын кебек басып торсаң.

Юк,
яхшысы, күренмә син.
Мин нәләндем бугай,
үткәннәргә кайтмак булсам,
исемә төшереп шулай,
сиңа аталган сүзләремне
кабатлыйм яңабаштан:
«Урман караучы кызының
үрмә таҗы ландыштан!
Урман караучы кызының
үрмә таҗы ландыштан!»

●

Күкне иңдереп,
башны идердең.
Мин бит — тургай!

Төннәремне кудың.
Яктыртучы бөҗәк бит мин!

Җырларымны будың.
Мин бит — аваз!

Миннән барысын алдың.

Мародерның күзе төшмәгән
үлек кулындагы сәгать кебек —
ялгыз мин калдым...

●

Вулканнар бар диңгез төбендә.
Әллә ниләр кайный күңелдә.
Бар җиһанга ярасы иде дә!..
Ярар, сабыр, калсын бүгенгә.

Иртәгесен иртүк уй туа:
«Без бит бу дөньяга ир туган!
Ярыл фикер! Чишел тойгылар!
Чыгарып сал, башка ни тулган...»

Кичен янә шәфәкъ күгендә.
Әллә ниләр сызлый күңелдә.
Ирексездән иреннәр көйли:
Вулканнар бар диңгез төбендә.

●

Өшеткеч бәс, кар сырышкан
чия ботакларына!
Көяшка да ут өстәр дәрт
янса да каннарымда,—
барыбер җирдә җылының
җитмәгән чаклары ла...

Бөреләр нурга тиенми,
кешеләр — җылы сүзгә.
Табигатькә рәнҗик микән,
үпкәликме үзебезгә?

Рәшит Әхмәтҗанов

●

Умырзаяларны сагынудан
Кояш булдым инде бозларга.
Сөю серен чәчәкләргә яшереп,
Уңжиде яшь тула кызларга.

Язгы күкрәү — минем үз күкрәвем,
Үз күкрәгем аны сыйдыра...
...Идел ташыганда, уф, янам, дип,
Ләйсәнәдән имеш су сора.

Ләйсән яңгырлары китердеме,
Кызый, илгә синең исемне?
Кара төндә бөтен йолдызларга
Ак күңелем дидем мин сине.

1965.

Алдан әйт...

Дөньяда буран... Ничек соң
Тын гына шигырь сөйлә.
Эх, кышкы төннәр күңелдән
Кояшны эзләп килә.
Я кырда җилләр ыжгыра —
Әйтерсең бүген менә
Бәхетсез ятып елый күк
Кешеләр йөрәгенә...
Мин бала чагымнан килгән
Көтүче егет булам.
Алдан әйт — нәрсә куркыныч,
Нинди җил, нинди буран?
Бураннар алар йөрәкнең
Үтәчәк көне генә.
Ал гөлләр — безнең бүләк ич
Кешеләр гөмеренә...
Бәхетсез кеше елый дип,
Сөйләдем юри генә.
Кыюлар ятып еламый
Кешеләр йөрәгенә.
Бу кышкы төннәр күңелдән
Кояшны эзләп килә.
Иртәгә кояш нәкъ минем
Күңелдән чыкмас димә.

1965.

●

Алмагачның бары бер алмасы —
Ярый инде...
        корып калмаган?!
...Кемдер гүя мине — җәй малаен
Алсу алма биреп алдаган.
Ә мин җирдә әле бер нарасый —
Иренемә бал, күзгә нур тама.
Еласам мин әгәр,
Елама дип,
Алсу алма биреп алдама.

1965.

Ятимлек

Ятим, ятим...
Әгәр үги ана
Чакырмаса пешкән ашына —
Сабый гомер буе әнкәсенең
Ялан аяк йөгерә каршына.

1963.

●

Оча бөркет, шаша — бу давылда
Һәлак булган аның баласы.
Мина да бит шул давыллар аша
Диңгезләрне кичеп барасы.

Горур җаннар үлми — һәлак була!
Бөркет мине күзли — мин китәм:
«Бу да, балам кебек, горурлыктан
Һәлак булыр ахры», ди микән.

1962.

●

Күләгәм мине үчекли:
    — Кеше,
Син көчле булгач — нигә арыйсың?
Ә син, күләгә, кояш каршына
Минем белән ник бергә бармыйсың?

1965.

Тамчы монологы

Озак гиздем мин болытта,
Күктә генә.
Кояш төшкәне бар җирдә
Күкрәгемә.

Эссе көндә син, сандугач,
Мине эчтең.
Мин дөньяга моңлы җырың
булып күчтем.

Чүлләр сыман иреннәргә
Ничә кабат
Тамдым, тамдым сулыш булып,
Күзгә карап.

Әйтәләр тик — бер тамчының
Нәрсәсе бар?
Кемнәргә соң шулкадәрле
Бу дөнья тар?!

1965.

Җиңүләргә бардың...

Зыя Мансур истәлегенә

Ак розалар җилдән тибрәнмәде,
Алар үскән бу җир тетрәде...
Яңа кабер —
Яңа авыр яра
Алган бүген җирнең күкрәге.

Ни күрсәк тә бергә күрербез дип,
Әйткән идем дә бит үзеңә —
Походларда чакта солдатлар соң
Күрешәләр мени тиз генә.

Күзләремә йөрәк ышанмый да,
Күзләрең шул, шагыйрь, йомылган.
Гомерем буе гашыйк булып торган
Күк гөмбәзе ябылган сыман.

Хушлашабыз,
Җырлый-җырлый бүген
Китәсең бит, китеп барасың...
Кешелекнең озатасы килми,
Җибәрәсе килми баласын.

Син беләсең —
Безнең йөрәкләрдә
Яшәми ич кеше кунакта.
Безнең белән җиңүләргә бардың,
Көрәшләрдә калдың бер сафта.

Ак розалар җилдән тибрәнмәде,
Алар үскән бу җир тетрәде...
Яңа кабер —
Яңа авыр яра
Алган бүген җирнең күкрәге.

11. 11. 65.

Рафаил Төхфәтуллин

АЛСУ БОЛЫТЛАР

Хикәя

Башта түзде Илдус. Менә-менә больницага килеп житәрләр дә, докторлар аңа дару бирерләр, аякның авыртуы туктар, дип түзде.

Дару бирмәделәр. Киресенчә, бик авырттырып укол кададылар. Аннары, тагы да авырттырыбрак аякны тартырга, борырга, тагын әллә нишләтергә тотындылар. Тәннең бөтен тамырлары чытыр-чытыр өзелгәндәй булды, коточкыч авырту тел очына кадәр килеп житте...

Ә күзлекле доктор абый ачулана:

— Син, нәрсә, егет, аяксыз калырга телисеңмени? Аяксызлар айга оча алмый. Аяксызларны Марска да җибәрмәсләр. Давай, давай, егет, батыр бул, түз! Без әле синең белән...

Нәрсә эшләргә теләгәндер ул доктор Илдус белән — анысын ишетеп булмады. Кинәт күздән утлы-яшелле очкыннар чәчрәде, бу ялтыр күзлек тә, бик зур абажурлы түшәм дә зырылдап әйләнә башлады. Шулай бөтен дөньясы зырылдап әйләнде-әйләнде дә, барысы да карасу томанга уралып, юкка чыкты...

...Күзне ачуга, якында гына бик күп алмалар өелеп тора иде. Шундый да эре, кып-кызыл алмалар. Чын алмалар микән бу? Әллә төштә генә күренәләрме? Төштә генә булса булыр, берсен алып ашыйсы иде. Иреннәр дә, авыз эче дә бик кипкән. Алып ашыйсы иде бер алма.

Илдус үрелә, ләкин шул чак бик авырттырып аякка китереп сугалар.

— Ой!

— Уяндыңмы, батыр егет? — ди аңа чал чәчле бер абый.

— Мин... Берне генә алмакчы идем, абый. Иренне генә чылатырга.

— Нәрсә, әллә су китеримме?

— Ю-ук. Алма кирәк иде. Алырга ярамагач, кирәкми инде. Мин сүз белән әйтсәң дә аңлар идем, абый. Бигрәк каты суктың аякка.

— Әәә... — ди чал чәч, үзе елмайган була. — Аягыңа мин сукмадым сугуын. Ләкин шулай авыртыр инде ул беразга. Нихәл итәсең... Ә син алмаларыңны аша, улым, аша. Әниең китерде аларны. Әле яңа гына чыгып китте. Эшкә соңга калам, ди. Тиздән әтиең килер, диде.

Менә ничек икән. Әтисе аны больницада калдырып киткән икән. Әнисе дә алмалар китергән дә үзе эшкә киткән.

Бая аякны тарткан бүлмәдән аны инде башка бүлмәгә китереп салганнар. Биредә койкалар тезелеп киткән. Илдусныкын да кертеп санасаң, барлыгы биш койка. Барысында да авырулар ята.

Аяк инде ул кадәр авыртмый, сыкрап кына тора. Ләкин нигә шулхәтле авыр соң ул? Кыймылдатып та булмый. Бәй, таш итек киертеп куйганнар ич аның аягына. Шундый калын таш итек.

— Абый!

— Нәрсә, улым, тагын бер алма алып биримме?

— Бир. Абый, минем аякка нигә таш итек киерттеләр икән?

— Сынган аякны шулай итәләр инде аны, улым. Селкенмәсен, тизрәк тазарсын өчен шулай гипс белән катырып куялар.

— Ә минем аяк сынмады, абый. Авыртты гына. Сынса, каны чыгар иде. Бер бөртек тә каны чыкмады.

— Сөяге сынгандыр анын. Врачлар беләләр инде алар. Рентгеннан карыйлар бит алар... Син укыйсынмы?

— Икенче класста инде.

— Уһу! Нишләгәндә сынды соң ул аяк?

— Сикергәндә. Биеклеккә сикерә идек. Миңа бер малайны гына узасы калган иде инде. Витя Потаповны гына. Аны да узсам, класста беренче урынга чыга идем. Менә бит... Булмады инде.

— Һмм... Беләсеңме, улым, Витяны узу өчен нишләргә кирәк?

— Нишләргә, абый?

— Иң беренче, әнә ул «булмады инде» дигән фикерне башыннан алып ташларга кирәк. «Була, барыбер булдырам!» дияргә кирәк. Шулай итсәң, бөтен теләгеңә дә ирешәсең. Чын-чын!

Илдус, әллә урыныннан сикереп тормакчы булып инде, башын калкыткан иде, нәкъ баягыча аякка китереп суктылар. Күздән яшь атылып чыкты. Чал чәчле абыйга моны күрсәтмәс өчен, башын стенага таба борды. Сиздермичә генә җәймәгә күзләрен сөртте.

Яңадан бу якка таба борылса, абый һаман да каш астыннан гына аңа карап утыра, кулына бер папирос алган да акрын гына шуны әвәли иде. Илдус бу куллардан күзләрен ала алмыйча карап торды. Шундый да зур иде бу куллар, һәр бармагы Илдусның беләгеннән аз гына нечкәрәк булса булыр. Шунысы бик сәер. Бу юан бармаклар арасындагы папирос шырпы зурлыгы кебек кенә күренә иде.

— Абый! Ә синең кай җирең авырта?

— Минем дә шул аяк инде, улым. Сугышта фашист осколкасы эләккән иде. Егерме елдан артты менә, һаман да шул тынычлык бирми.

— Алып ташлый алмыйлармы осколкасын?

— Берсен алып ташлаганнар иде дә, тагын калган, күрәсең.

— Бик авырттыра торгандыр инде ул, ә, абый?

— Авырта дисәң, авырта ул. Ә мин тотам да әйтәм аякка: «Шаярма, авыртмыйсың!» — дим. Шулай дигәч, авыртканы басыла. Чын-чын!.. Ә синең әтиең сугышта булганмы?

— Ю-ук. Минем әти сугыш вакытында малай гына булган әле ул. Миннән аз гына зуррак булган.

— Шулаймы? Хәзер кайда эшли әтиең?

Илдус, кашларын җыерып, кулындагы алмасын ашарга тотынды. Янәсе, ул бу сорауларны бөтенләй дә ишетми, менә бу алманың кайсы җиреннән капсаң тәмлерәк булыр икән — янәсе, хәзер ул бары тик шул турыда гына уйлый...

Чал чәчле абый, папиросын авызына кабып, урыныннан торды. Койка башына сөялгән таягын алды, аксаклый-аксаклый ишеккә таба юнәлде.

□

Кич җитте. Палатада ут кабыздылар. Ә Илдусның әтисе һаман килми дә килми.

Ялтырап торган зур гына тартма күтәреп, сестра керде. Илдус инде белә: укол кадый торган әйберләр салынган тартма ул. Бу юлы инде Илдуска кадамаслар. Бирегә килү белән бер, бая көндез тагын бер кададылар ич.

Ах, юк икән әле. Сестра ике абыйга укол кадады да әнәсен күтәреп Илдус койкасына таба килә.

— Апа, миңа кададылар бит инде. Ике мәртәбә кададылар.

— Тизрәк тазарыйм дисәң, түзәсең инде, егет.

— Әй, апа...

— Я, я! Бездә алай врач әйткәнгә карышмыйлар.

— Апа дим...

Шунда Илдус Шәяхмәт абыйның (чал чәчле абыйның исеме шулай икән) үзенә карап торганын күреп алды да шып туктады. Ярар инде, әйдә, кадасалар кадарлар. Әнә Шәяхмәт абый кебек итәсе иде. «Шаярма, авыртмыйсың! Бер бөртек авыртмыйсың», — диясе дә чыдыйсы...

Сестра укол кадыйсы урынны салкынча юеш мамык белән ышкый башлады. Илдус күзләрен чытырдатып йомды да эченнән генә кабатларга тотынды: «Шаярма, авыртмыйсың! Бер бөртек авыртмыйсың! Авыртмыйсың! Ау...»

Дөресен генә әйткәндә, авыртты да инде бераз.

— Безнең Илдус уколдан курыкмый! — диде Шәяхмәт абый. — Аның бит тизрәк тазарасы бар.

— Әлбәттә! — диде сестра.

Шәяхмәт абый белән Илдусның күзләре очраштылар да мәгънәле генә елмаештылар.

Их, тизрәк кенә әтисе килсен иде дә Илдусның хәзер уколдан бер бөртек курыкмавын күрсен иде. Юкса, бая аякны тартканда кычкыргач та, укол кадаганда да кычкырадыр Илдус, дип уйлый торгандыр әле әтисе. Килсен дә күрсен иде менә!

Аннары мондагылардан берәрсенең тагын: «Әтиең кайда эшли?» — дип сораулары бик ихтимал ич. Әгәр сорасалар, һаман-һаман алма ашаган булып кына котылып булмас шул инде...

Юк, яңадан да алай сорауларын теләми Илдус. Күргән инде! «Әтиең кайда эшли?» — дип сораганда, «Пожарник минем әтием», — дисәң, тоталар да авызларын ерган булалар. Җитмәсә, көлә-көлә, җыен юк-барны сөйли башлыйлар. Янәсе, пожарникның бар белгәне йокы. Имеш, йокысыннан ул артына ут капкач кына уяна...

Бирегәгеләр дә алай авызларын ермый торсыннар әле. Иң элек, Илдусның әтисен үз күзләре белән күрсеннәр. Нинди яхшы кеше икәнлеген күрсеннәр. Аннары һич тә алай көлә алмаслар.

Коридорда аяк тавышы ишетелгән саен, Илдус ишектән күзен алмый.

Кайвакыт аяк тавышы алар ишек төбендә үк туктый. Илдус башын күтәрә. Шыгырт итеп ишек ачыла да, аннан я сестра, я авырулардан берәрсе килеп керә.

Юк, килми әтисе.

Коридорда инде аяк тавышлары бик сирәгәйде. Шәяхмәт абый почмактагы койкада ятучы авыру янына барып утырды. Ап-ак йөзле, кап-кара кашлы ул абыйның шофер икәнлеген дә, аның ашказанына операция ясаганнарын да хәзер инде Илдус белә.

— Тазалыкның кадерен авыргач кына беләсең икән аны, — ди шул абый. — Җүләр бит ул безнең шофер халкы. Таң тишегеннән торып, ерак рейска чыгып китәсең. Ни эләксә шуны кабып, көн озын бара бирәсең. Төн житеп, күзләр әлҗе-мөлҗе килә башлагач кына, берәр җирдә ялга туктыйсың. Шунда, «әйдә, арганнар бетеп китсен әле» дип, берәр йөз граммны каплап куясың. Иртәгесен баш миендә шистерналар шыгырдый, кайда ул ашау, бер стакан чәй эләксә әлгә, эләкмәсә юк, тагын юлга! Ничек ашказаны түзсен дә, ничек йөрәк чыдасын? Авыргач кына искә төшә дә бит...

— Нәрсә ул тазалык! — дип, сүзгә кушылды Шәяхмәт абыйның теге як күршесе. Бөдрәрәк сары чәчле ул абыйның сукыр эчәгесен кисеп алганнар. Үзе нефть чыгаручы оператор булып эшли икән. Шунысы кызык: үзе дә гел мәзәк кенә елмаерга яратучы ул абый сүз башладымы, палатада барысы да көлешергә тотыналар. Сүзеннән дә көләләр, эчен тотып сак кына атлап йөрүеннән дә көләләр. Бу юлы да шулай булды.

— Тазалык ул — сукыр эчәк!

— Майлы калжа ул тазалык, — дия-дия, барысы да дәррәү көлешеп алдылар.

Ләкин бөдрә чәчле абый көлмәде. Аның чырае бик житди, хәтта ачулы иде.

— Тазалык, имеш... Тазалыкны югалту гына әле ул, чепуха! — диде, урыныннан торып. — Менә син бәхетеңне югалтып кара. Монысы инде — да!

Һәм ул, янадан койкасына авып, стенага таба борылып ятты.

Беразга палатада тып-тын булып калды.

Шәяхмәт абый акрын гына тамак кыргалап куйды.

— Болай түгел микән ул, егетләр, — диде. — Тазалык белән бәхет — алар икесе дә бертуганнар түгел микән? Чын бәхет яулап алыр өчен корыч тазалык кирәк булган кебек, «бәхетем югалды» дип, борыныңны салындырдыңмы, һәртөрле чирләр, кара сөлек кебек, тәнеңә килеп ябышырга гына торалар бит алар.

— Фәлсәфә сатуы җиңел, — дип мыгырданды сары чәч.

Шәяхмәт абый аны ишетмәде дә бугай, алдына гына караган килеш дәвам итте:

— Мин болай уйлыйм, егетләр. Тазалыгыңны саклау да, бәхетеңне кулыңнан ычкындырмау да, башлыча, кешенең үз кулында, минемчә.

— Үз кулыңда гына булса иде, — дип, сары чәч янадан мыгырданып куйды.

— Юк, кимендә туксан проценты кешенең үз кулында болар. Әнә Рәис үзе үк әйтә бит, тазалыкның кадерен авыргач кына беләсең икән, ди. Ай, элегрәк белсәче!.. Ә сиңа, Коля, шуны әйтәсем килә минем. Без инде менә ничә көн бергә ятабыз, синнән генә шуны ишетәм: «Вера мине ташлап китте», — дисең, «Араны аның туганнары бозды», — дисең. Әниеңә дә үпкәлисең килә. Кеше үз уңышсызлыгына, үз бәхетсезлегенә бүтәннәрне генә гаепли башладымы, мин һәрвакыт шигәя калам. Барысыннан да күбрәк, үзең гаепле түгел микән, егеткәем, диясе килә.

Коля акрын гына бу якка таба борылды, күзләрен тутырып Шәяхмәт абыйга карап куйды.

— Аңламыйсың син, Шәяхмәт Галеевич, — диде дә зыр итеп янадан стенага әйләнеп ятты.

Бик тә гаҗәп иде бу. Көнозын кешеләрне көлдереп, үзе дә гел елмаеп йөрде ул Коля абый. Инде менә кич житкән иде, аннан да ачулырак кеше юк...

Шәяхмәт абый, аксаклый-аксаклый, үз койкасына килеп ятты.

— Сиңа, Коля, бик ныклап бер уйлап карарга кирәктер бу турыда.

Коля дәшмәде.

Коридорда янадан шык-шык аяк тавышлары ишетелде. Илдус башын калкытты. Шыгырт итеп ишек ачылды да, сестра килеп керде.

— Йокларга вакыт, иптәшләр. Отбой. Ике минуттан утны сүндерәм, — дип, чыгып та китте.

Килмәве булды микәнни инде әтисенең? Инде менә, утны сүндерсәләр, килсә дә кертмәсләр. Нигә килмәде икән соң ул?

— Ә шулай да, хәтерең калмаслык түгел бу дөньяга, — диде аргы башта бер карлыкканрак тавыш. Илдус күтәрелеп караса, түрдәге иң кырый койкада ятучы авыру икән. Сары гына йөзле, сакал-мыегы булмаса да, бабай икәнлеге бер караудан күренеп торган ул авыру көн буе бер сүз дә сөйләшмәде диярлек. Илдус аның кай жире авыртканын да, исемен дә белми. Шулай да аның бик каты авырганын чамалап була. Врач та, сестра да аның янына бик еш керәләр, үзе ул урыныннан да кузгалмый.

— Нигә алай дисең, Петр Иванович? — диде Шәяхмәт абый.

— Хәтерең калыр да! Уйлап карагыз. Дөньяның иң мескен бер мәхлугы ташбаканың гомере өч йөз ел. Карга булып карга йөз ел яши. Ә кеше... Дөньяда иң көчле, иң акыллы җан булган кеше исә, алтмыш-җитмеш яшькә җиттеме, кабер якасына карый башлый. Гарьлек, валлаһи!

— Минем дә укыганым бар бу турыда, — дип, Рәис тә эләктереп алды. — Кит балыгы, мәсәлән, дүрт йөз ел яши икән, ә чуртан ике йөз илле ел яши дигән...

— Аны әйтәсең син! — диде карлыккан тавыш. — Мексикада бер кипарис агачының яшен исәпләп чыгарганнар. Беләсезме, күпме килеп чыккан? Ун мең яшь! Бер агачка ун мең ел гомер, ә кешегә... Шулай да, бик гаделсез бу табигать.

Шәяхмәт абый, гадәтенчә, тамагын кырып куйды.

— Ләкин, егетләр, без шунысын онытмыйк. Кешенең бер көн гомере генә дә ташбаканың ике йөз ел гомеренә чагыштыргысыз бит ул...

— Әйттең сүз! Кем әле монда ташбака булырга тели? — диде Коля, һаман да стенага карап яткан килеш.

Барысы да көлеп җибәрделәр.

Ул арада ашыгып кына сестра килеп керде.

— Иптәшләр, отбой. Тыныч йокы! — диде дә «челт» иттереп утны сүндереп чыгып китте.

— Әнә шулай матур итеп, мәгънәле итеп яшәргә өйрәнеп беткәч кенә, бер заман биленне язып күтәрелеп карасаң, гомерең кояшы инде баеп та бара. Менә шунысы аның гарьлек! — диде карлыккан тавыш.

— Шуның өчен дә Николай Островский әйткән... — дия генә башлаган иде Шәяхмәт абый, сестра ишекне ачып, кырыс кына пышылдады:

— Шәяхмәт Галеевич, тынычлык!

— Бетте, Ниночка, бетте.

Беразга кадәр койкалар шыгырдавы, йөткереп куюлар, тын гына уфылдаулар ишетелеп торды. Аннары, акрынлап, тып-тын булып калды.

Ләкин Илдусның аз гына да йоклыйсы килми иде әле. Аяк инде әллә ни авыртмый, ләкин менә монда, күкрәк турысында, ниндидер бер нечкә әрнү һаман да борчып тора иде. Килмәде бит этисе, никадәр көтеп-көтеп тә килмәде. Шуңа әрнидер инде күңел...

Нигә килмәде икән ул? Әллә инде менә болай микән... Бервакыт этисе өйгә бик соңга калып кайтты. Йөзе гадәттәгедән артык кызарган, үзе сәер генә елмая иде. Әнисе аны бик каты тирги башлады. «Ярамый бит сиңа, ник эчтең?» — диде. Әллә бүген дә шулай булды микән?

Ул көнне, әнисе шулай ачуланганда, Илдус этисен бик кызганган иде. Әгәр бүген дә шундый хәл булса, бу юлы инде кызганмас. «Әнә Рәис абыйныкы кебек, ашказанына операция ясарлар әле», — дияр. «Тазалыкның кадерен авыргач кына беләсең аны», — дияр.

У-у, никадәр күп иде бит Илдусның этисенә сөйләр сүзләре. Иң элек, аяк авыртканда да, укол кадаганда да, «Шаярма, авыртмыйсың!» дип әйтергә кирәклеге турында сөйлисе бар иде. Ташбаканың ике йөз ел, ә кит балыгының дүрт йөз ел яшәве турында да сөйләргә кирәк. Ун мең яшьлек теге агач турында да сөйлисе иде. Ә кешенең бер көн гомере генә дә ташбаканың ике йөз ел гомеренә чагыштыргысыз. Бу турыда да сөйлисе булыр.

Шәяхмәт абый да әле йокламаган икән. Әнә койкасын шыгырдата-шыгырдата бу якка таба әйләнеп ятты. Илдус сак кына пышылдады:

— Шәяхмәт абый!

— Нәрсә, улым! Аяк авыртамы?

— Ю-ук... Шәяхмәт абый, мин бая дөрес әйтмәдем бит. «Булмады инде», дип юри генә әйттем икән. Булдырам әле мин, барыбер Витя Потаповны да узам. Менә больницадан гына чыгыйм.

— Молодец, улым. Әйдә, хәзер йоклыйк инде. Йокласаң, тизрәк тазарасың ул.
— Йоклыйм. Шәяхмәт абый, аннары мин бая әйтмәдем, пожарник минем этием. Шундый әйбәт ул үзе, тик менә... Нигәдер килмәде.
— Килер. Күрерсең, иртәгә үк килеп житәр. Бүген бушый алмагандыр.
— Әһе... Шәяхмәт абый, ә син кайда эшлисең?
— Буровой мастер мин. Я, улым, йоклыйк инде.
— Йоклыйбыз.

Тагын тып-тын булып калды. Ләкин йокламаучылар алар гына түгел икән әле. Бераздан Коля да акрын гына пышылдады:
— Шәяхмәт Галеевич, сез бая әйтеп бетермәдегез, нәрсә диган ул Островский?
— Нәрсә диганме? Ишеткәнең дә бардыр инде... Болай диган: шундый итеп яшәргә кирәк ки, мәгънәсез-максатсыз үткән көннәрең өчен ахырдан газапланып үкенерлек булмасын, диган.
— Даа... Әйтүе ансат та...
— Коля, әйдә, бер тәмәке тартып керик әле. Сүзем бар сиңа. Иптәшләргә йокларга комачауламыйк, әйдә, чыгыйк әле.

Алар шыпырт кына чыгып киттеләр. Кайчан әйләнеп кергәннәрдер, Илдус сизмәде, йоклап китте.

Күпме йоклагандыр, тагын аягына суккан кебек булып, сискәнеп уянды. Аягы гына түгел, тагын әллә кай жирләре бик авырта, бөтен тәне авыраеп калган кебек иде. Бик жайсыз шул болай гел чалкан ятулары. Шуңа бөтен жир сызлыйдыр.

Илдус эченнән генә: «Авыртмый, бер жирем дә авыртмый», дип кабатлый-кабатлый, төрлечә әйләнгәләп, иплебрәк ятарга тырышты. Менә болай итеп, авыртмаган аякны өскә үк бөгеп, ике кулны ике якка жәеп яткач, жайлырак икән. «Шаярма, авыртмыйсың! Бер жирем дә авыртмый, авыртмый...»

Палатада барысы да йоклыйлар иде. Торырга иртәдер шул әле. Хәер, бик озак көтәсе дә калмагандыр инде. Әнә бит, тәрәзәләргә кызгылт яктылык төшкән. Таң атадыр, күрәсең. И, кара инде, болытлар нинди матур булып калганнар. Алсу-кызгылт, алсу-алтынсу төсләргә бизәлгәннәр болытлар. Их, менә хәзер шунда кадәр сикерсәң икән дә шул алсу болытның бер кисәген учыңа йомарлап төшсәң икән ул. Болытлар, алсу болытлар!..

□

Ләкин бу алсу болытлар таң шәүләсе түгел иде әле.

Шәһәр янындагы газ-бензин заводында бик зур янгын чыкты ул төнне. Илдусның этисе больницага барырга чыккач, тревога сигналын ишетеп, тизрәк шуңа чапты. Коточкыч янгын белән төн буе көрәш барды. Әгәр мәкерле ялкын газ складына кадәр житсә, күз алдына китереп булмастай дәһшәтле шартлау булачак, йөзләрчә өйләр жимерелачәк, меңнәрчә корбаннар булачак иде.

Янгынчылар үз-үзләрен аямыйча ут белән көрәштеләр. Бик күбесенең битләре, куллары пеште. Хәлдән таеп егылган чаклары да булды, ләкин шунда ук тагын торып, көрәшкә ыргылдылар.

Ниһаять, мәкерле янгын жиңелде.

Таң алдыннан битләре, куллары пешкән егерме алты янгынчыны, шулар арасында Илдусның этисен дә, шушы ук больницага китерделәр.

Илдус бу вакытта тагын бик тәмле йокыга талган, төшендә, кулканаткайларын жилпи-жилпи, алсу болытларга таба очып бара иде...

ДУСЛАР ЖЫРЫ

Сөенбай Эралиев

ЙОЛДЫЗЛАРГА СӘЯХӘТ

Поэмадан өзек

Кыргыз шагыйре Сөенбай Эралиев әдәбиятка кырыгынчы елларда килә. Үзенең иҗатын күренекле кыргыз шагыйре Алыкол Осмонов тәэсирендә башлап җибәргән Эралиев, «Ак-Меер» поэмасын язып, үз тавышы белән яңгырап, хәзерге кыргыз поэзиясенең алдынгылары сафына чыга. «Ак-Меер»дән соң да ул, кыргыз шигъриятенең традицион алымнарына буйсынып һәм аның үзенчәлекле формасын саклап, берничә поэма яза.

Соңгы елларда Эралиев иҗатында принципиаль эзләну, кыргыз поэзиясендә яңа эпоха — космос эпохасының рухын тасвирларга сәләтле яңа ритмнар, интонацияләр, образлар эзләү күзгә чагыла. Аның «Йолдызларга сәяхәт» поэмасы бу юнәлештә уңышлы тәҗрибә булып, яңа кыргыз поэзиясен үстерүдә киң мөмкинлекләр ача һәм ирекле шигырь формасын канунлаштыра.

«Йолдызларга сәяхәт» — автор хыялындагы циклның беренче поэмасы.

Без монда укучыларыбызга шул поэманың берничә бүлектән торган өзеген тәкъдим итәбез.

5

Йолдызлар — балалар уйный торган шарлар,
сары, яшел, зәңгәр, ак төслеләр...
Күк йөзендә очып йөри алар.
Ләкин аларның баулары минем кулда,
уч төбемдә җыеп тотам барысын да.
Шуңа барлык йолдызлар да
миңа ышаныч белән карый сабыйлардай.

6

Кырыйлары офыкларга төшкән күк гөмбәзе
зур бер лимон агачына охшаш:
җимешләрен тирбәтә ул салмак кына,
күзге төннәрдәге кебек шаулап тора,
миңа хуш исләрен бөркеп
хыялларым сафландыра.

7

Йолдызлар — минем иртәнге маршрутны,
мине көткән яңа ачышларга юлны
яктыртучы
яшел светофор яңгыры.
Мин шат аларның бу кадәр күплегенә!
Һәрбер яңа йолдыз белән мин яшәрәм.
Һәр яңа йолдыз белән дөнья яңара.

8

Җир!
Син хәзер шундый ерак миннән,
үзең шундый, шундый якын.
Ялгыз, якты өметем син — сиңа карыйм,
күз алалмыйм.
Җирдә яшәгәндә,
сөйгән ярым торган өйгә карый идем,
аның якты тәрәзенә карый идем,
ул эз салган юлдан күзем алмый идем,
хәзер сиңа карагандай карый идем.
Минә хәзер миллионлаган йолдызларга түгел,
бер йолдызга — сиңа тартылам, Җир,
туган кырларымның үләннәрен сагынам,
борын ярып кергән әрем исен сагынам
һәм алардан башка яши алмам сыман.
Мин — мондагы синең җанлы тавышың:
«Тыңлагыз, мин — Җир!» дип,
бар йолдызларга кычкырам.
Гәүдәңнең бер кисәге мин, туган Җирем,
далаларың, мәһабәт тауларың белән,
шәһәрләрең, халкың, ак таңнарың белән,
уйнап искән йомшак, рәхәт җилең белән,
өметләрең белән, сөюләрең белән
күк иләнә очып менгән бер утрау мин,
синең йөрәк парәң булып гизеп йөрим.

9

Сөю!
Син үзең дә галәм кебек чиксез, серле,
һава кебек,
хыял кебек,
үлчәп булмый сине.
Әлегә мин күрмәгән ят дөньяларның
тылсымлы һәм гаҗәп табигате төсле,
син һәрвакыт гаҗәп, мавыктыргыч, көчле.
Минем һәр көн йөри торган урамымдай
һәркайчан да миңа таныш һәм якын син.
Күзгә күренмисең,
кулга тотылмыйсың,
яшисең тик хисләр, тойгыларда,
мөмкин түгел һич тә аеру сине миннән.
Шуңа минем уйлар аерылалмый синнән!

Йолдыз булып,
йолдыз булып,
йолдыз булып күренәсең,
кайда барсам да, күз алдыма киләсең.
Космос миңа синең сулышыңны китерә,
космос — Җир белән күк кушылуымы әллә,
нигә синең исең космоста да аңкый?
Аңлатуы читен.
Җирдә дә шулай ук
үләннәрдән,
чәчәкләрдән килә иде синең исең,
яши иде син һәр әйбердә дә:
ноябрьның йомшак карында да,
әкрен генә искән җилләрдә дә,
янгырларның озак җырында да.

Без таныштык автобуста:
зәп-зәңгәр төн
сарып алган иде бөтен җир өстен.
Йомыркасын ватып чыккан чебешләрдәй
чыелдаша йолдызлар җир утларына.
Ә тын шәһәр төнге бишек җырына
йокымсырап утыра талгын гына.
Төндә автобуста барабыз без.
Күз карашым сиңа төбәлгән:
чәчләреңә
төн карасы кушылып үрелгән,
кулларыңа арык суларының
аклыгы бирелгән,
каек кебек кыйгач кашларың сызылган,
алар сулый
көчле музыканың тирән моңы сыман.

Син миңа ят —
чөнки сине беренче кат күрәм,
Миңа таныш —
чөнки хыялымда син бар иден күптән.
Үзеңдә никадәр кояш утлары бар,
ялкыннарың кинәт чолгап алды мине,
әгәр дә тик бер чаткысы гына төшсә,
бөтен җирне янгын каплап алыр иде,
безнең автобустан
көлләр генә калыр иде.

Син карыйсың —
мин йөземне читкә борам,
тәрәзәдән төбәләм төнгә,
карыйм светофорның яшел күзләренә.
Текәлеп карап озаталар безне алар.
Канатларына ут капкан кошлар сыман
төнне ярып
уза выжлап машиналар,
«Шушындый да караңгы төн булыр икән!»
(дип уйладым эчтән генә шунда.)
Ә син күккә карадың да,
болай дидең
(димәк, минем уйларымны белгән идең):
— Әгәр тыңлый белсәң,
йолдызларның тавышларын ишетеп була:
Әйдә икәү бергә яныйк,
җир безне күрсен!
Әйдә бергәләп елмайыйк,
җир безне сөйсен!
Бала чактан күнеккән мин
тыңларга йолдыз җырларын.
Беләм, безне —
кешене сагынганын аның.
Бар йолдызлар көтә безне.
Алар бездән алмый күзне.

Төн — ябалак, корымдай кара,
утлы күзләрен акайтып тора,
канатларын җәеп салган —
бөтен җирне каплап алган.
Йолдызлар бер кабынып, бер сүнеп торалар,
болындагы чикерткәләр кебек алар,
бер җырлыйлар чыңлап, бер тыналар.
Мин, әлбәттә:
«Кайсы йолдыз? Кая?» дип сорашкан булып,
сиңа һаман якынрак елыша барам.
Син янымда минем —
шуңа йөрәк тибә леп-леп,
йөрәк тибә йолдызлар чыңлаган кебек.
Сиңа барлык чәчәкләр хуш исен биргән!
Синең янда мин чәчәкләр исен сулыйм.
Мин хәтерлим,
Әйе, хәтерлим барысын да.

Юк, син анда уйламадың,
әйе, уйлый да алмадың,
җирнең исен
сулар ул дип
ерак йолдызлар каршында.

10

Бер уч туфрак,
бер йотым һава,
бер бөртек кояш нуры биреп,
җир
кешене күкрәге белән туендыра.
Язмышың турында уйлыйм мин җир-ана:
атом гасыры,
космос гасыры
минем гәүдәм аша атылып үтеп бара.
Вакыйгалар теше шыкырдавын
куркудан тын калып чикләр тыңлап тора.
Ә җир иштеп ята,
җир гүзәллекне ярата.
Ул йөкле хатындай,
ята яңа өметләргә төренеп,
агачларны җимешләргә күмеп,
яшь яңа язлар биреп.
Планета кояшны сөя,
кояш — хәят аңа,
бәхетне ул баласыдай кочагына ала,
җир яшь бөтен тереклеккә җан өреп:
кулы бушамый эшләрдән,
мие бушамый уйлардан,
ә күзләре аның ят планеталарда.
Җир гел хәрәкәттә, ул үз эшен белә:
тәненнән пар күтәрелә,
ә маңгай тирләре энҗе йолдыз булып
тамып төшә аның күкрәгенә.

11

«Ни хәлләрдә икән анда балам?» —
диеп уйлыйсыңдыр, анам,
карыйсыңдыр биек тауларыңнан.
Һәрбер үләннең күзе белән,
һәрбер агачның күзе белән,
бөтен дөньяң — киң җир йөзең белән
бер тәрәзәгә әйләнеп,
шул тәрәзә аша карыйсыңдыр миңа.
Таулар —
синең мускуллы, көчле кулларың — таулар,
матурлыгын, горурлыгын
биргән иде миңа алар,
мине тотып калыр өчен
хәзер миңа сузылалар.
Беләм, ана, минем өчен син янасың да көясең!
Чөнки мин — кеше, мин синең ялгыз балаң,
күпме гасырлар буена мине сөеп үстергәнсең.
Син дә минем ялгызым, бердәнбер анам.
Йолдызлар иленнән үз илемә карыйм,
синең бөеклегең минем җанга иңә.
Әнә сине күрәм аста:
гүя минем йөрәгем син,
күкрәгемнән чыккансың да,
асылынып торасың күк
ниндидер бер нечкә кылда;
әкрен генә йөзәсең син,
төрле-төрле төстәсең син.
Борчу чолгап ала мине:
ул кыл өзелеп китәр төсле,
минем бәхетем бетәр төсле...
Очып киткән чакта күтәрелеп,

моңаеп калдың, анам, син тилмереп:
син торасың сулыш алырга да куркып,
күз ачып карарга куркып һәм тын калып,
җилгә тарала ак чәчең дулкынланып.
Әле дә син тынгы тапмыйсың:
горур да син, борчыласың да,
төннәр буе керфек какмыйсың,
кайгы хәсрәттә син җир-ана,
елгалардай ага уйларың да
далалардан, урман буйларыннан.

12

Тирә-ягым — гаҗәп зур бер кала.
Өнсез кала.
Утлары йолдызлар булып яна.
Аның йортлары югала
　　　　　　　　　　томанда, төн карасында,
тик тәрәзәләрдән төшкән утлар гына
чекрәеп карыйлар миңа —
　　　　　　　　　　җир улына.
Кайчак тәрәз алларыннан,
караңгыга чумган шул өйләрнең,
　　　　　　күзне камаштырып үтә фаралары
күзгә күренмәгән автомобильләрнең.
Тынлык. Тирән тынлык.
Җибәрәсе иде бер кычкырып,
этләр һаулап өрсен иде,
кешеләр йокыдан торсын иде,
таныш түгел юлаучыны — мине каршы алсын иде.

13

Карыйм артымдагы эзләремә:
буразналар булып кала алар,
чирәм җирләрдәге иген сыман
　　　　　　　　　　салмак чайкалалар.
Йолдызлар атылып чуарлый алар өстен,
сабандагы сыерчыклар көтүе төсле.
Менә алар очып куналар
Күңелемнең яшел ботакларына.
Йолдызларның өнсез моңнары
яңгырый минем колакларымда.

НУРИ АРСЛАНОВ тәрҗемәсе

ОЧЕРК

Василий Юдин

СЪЕЗД ДЕЛЕГАТЫ

Автобус Аксубайга кич белән генә килеп җитте. Түбә кыекларыннан эре-эре тамчылар тама, көньяктан җылы җил исә — кыскасы, яз якынлашуы һәръяктан беленеп тора иде.

Аксубай. Таныш авыл бу миңа. Бик күптән, 1934 елның салкын январь аенда булган идем мин монда. Ул вакытта илебез партиянең XVII съездына, соңыннан социализм төзүчеләр съезды булып тарихка кергән съездга, әзерләнә иде.

Коммунистларның һәр съезды — партиябез, илебез, халкыбыз тарихында гаять зур әһәмияткә ия булган вакыйга. Ленин әйткәннәрне тормышка ашырып, коммунистлар үзләренең һәр съездында хезмәт кешеләренең якты киләчәгенә — коммунизмга якынайта торган гигант эшләрнең планнарын билгелиләр...

Ул вакытта да аксубайлылар киләчәк турында, һәрьяклап үсеш турында зур күтәренкелек белән фикер алышалар иде.

Бу юлы да мин биредә шундый тантаналы көннәрдә, XXIII съездга, коммунизм төзүчеләр съездына, әзерлек көннәрендә килдем.

Моннан утыз елдан артык элек биредә күргәннәрем турында уйланып, озак кына тукталышта басып тордым. Ул вакытта ук күрәштә һәм хезмәттә чыныккан күп кенә коммунистлар эшли иде монда. Аларның күбесе хәзер юк инде: кайберләре Бөек Ватан сугышында һәлак булды, кайберләре утыз җиденче елда югалды... Ничектер, авыр булып китте, күңелгә сагыш үрләде... Аңардан арынырга теләп, тиз-тиз үзәккә таба атладым. Алда — ак таштан салынган райком бинасы.

Райкомның беренче секретаре Юрий Александрович Кузнецов гади һәм киң күңелле кеше икән. Ул мине ачык чырай белән каршы алды. Монда килүемнең сәбәбен белгәч, теләр-теләмәс кенә елмайды да:

— Әлбәттә, Харитонов турында язарга кирәк, — диде. — Минә дигән оештыручы, минә дигән җитәкче. Съездга да делегат итеп сайланды. Күләгәдә калырга тиешле кеше түгел. Тик менә... аңа колхоздан китәргә туры килер кебек. «Аксубай» совхозына директор итеп җибәрергә телиләр...

Шул вакыт телефон шалтырады.

— Менә күрәсезме, — дип сүзен дәвам итте секретарь, трубканы куйгач. — Казаннан ашыктыралар. Расларга чакыралар. Ләкин барып чыгаргамы икән?.. Хәер, баргач үзегез күрерсез...

●

Өч көн дә үтмәгәндер, мин Алексей Алексеевич Харитонов турында шактый нәрсә белеп өлгердем.

Әлбәттә, элек аттa сөйрәлеп килгән колхозларны алдынгы хуҗалыклар дәрәҗәсенә күтәргән, акыллы, эшлекле председательләр республикада аз түгел. Алар турында күп язылды. Әммә, миңа калса, Алексей Харитонов андыйлар арасында да аерым урынны алып тора кебек.

Тыштан караганда бүтәннәрдән ул берни белән дә аерылып тормый. Урта буйлы, таза гына гәүдәле яшь кенә бер кеше. Утыз бишләрдән артык түгел. Күзләре тыныч, акыллы карый. Биографиясе дә бик гади. Медянка дигән кечкенә генә чуваш авылын-

да туган. Урта мәктәпне тәмамлагач, армиядә хезмәт итеп кайткан. Аннары читтән торып педагогия институтын бетергән һәм урта мәктәптә завуч булып эшләгән.

...Без фермаларны йөреп кайттык та кургәннәребез турында идарәдә азрак гәпләшеп алдык. Озак сөйләшергә туры килмәде, әле берсе керде, әле икенчесе. Әлбәттә, юкны-бушка аударырга түгел, һәрберсенең эше, йомышы бар. Менә шул кергәннәр белән мөгамәләсеннән председательнең кешеләргә карата мөнәсәбәтен бик яхшы күрергә мөмкин иде. Дөрес, ул һәркемгә дә гел уңай җавап кына биреп утырмады, кайберләрен борып та чыгарды. Ләкин мондыйлар үзләренең хаксызлыгын белеп киттеләр.

Менә безнең алда өстенә кара тун кигән, тулы битле, юан гәүдәле бер агай тора. Ул мотоцикл алырга ссуда сорап килгән. Председатель нииндидер бер калын гына журнал чыгарып актарды да:

— Мөмкин түгел. Бирә алмыйм, — диде. — Үзең беләсең бит, шулай килештек: гаебе булганнарга, сынау срогы үткәнче, бүләкләр һәм ссудалар бирмәскә. Бу колхозчылар ихтыяры, гомуми җыелыш карары, сезнең карар. Ул карарны бозарга минем хокукым юк.

Бу кеше үзе әйбәт кенә шофер булган икән. Ләкин спиртлы эчемлекләр белән шаяра башлаган, өендә скандал кубарган, эшкә чыкмый калган чаклары булган. Идарә утырышына куеп тикшергәннәр, шоферлыктан алып бүтән эшкә күчергәннәр. Сынау срогы билгеләгәннәр.

Тәэсире булган, хәзер эчүен ташлаган, эше дә ярыйсы бара икән. Әмма сынау срогы бетеп җитмәгән.

— Гариза язып кара, — диде председатель, урыныннан торып. — Идарә утырышында карарбыз. Бәлки, идарә членнары каршы килмәсләр.

Аңардан соң Петр Сякаев керде. Ул кайсыдыр авылдан бура алып кайтырга трактор сорады.

— Ике-өч көн көтсәк ничек булыр икән, Петр Федорович, — диде Харитонов. — Берсе дә буш түгел бит. Урман ташыйлар, тирес чыгаралар.

— Янмый әле, түзәрбез, — диде Сякаев, елмаеп. — Бу мәшәкатькә үзең гаепле бит. Мөмкинлегең булгач, кечкенә өйдә яшәмәссең инде. Ә ул мөмкинлекне син бирдең. Шулай булгач инде мәшәкать тә синең аркада. Үзең гаепле...

«Үзең гаепле» — шаяртып әйтелгән булса да, зур мәгънә бар бу ике сүздә. Колхозчының тормышын бөтәйтү, аның хезмәтенә лаек яшәү шартлары тудыру турында кайгыртып үткән бик күп йокысыз төннәрне, шатлыкларны һәм кайгыларны үзләренә туплаган бу сүзләр. Менә шуңа күрә дә ул биредә үз кеше, якын кеше. Менә шуңа күрә дә колхозчыларның аны үзләрендә калдырасы килә...

●

Иске Тимошкино авылында яңа өйләр ул кадәр күп түгел әле. Күп кенә өйләрнең түбәләре салам белән ябылган. Ләкин шул ук вакытта күп кенә салам түбәле өйләрнең өстендә телевизор антенналары беркетелгән колгалар утыра. Әйе, салам түбә өстендә телевизор антеннасы бик үк табигый нәрсә түгел.

— Контраст бик күзгә бәрелә, — дим мин Харитоновка.

Председатель моңсу гына елмаеп куя.

— Әйе, күзгә нык бәрелә алар, — ди, җитдиләнеп. — Әмма, дөресен генә әйткәндә, төзелешне башлап кына җибәрдек бит әле. Алты ел эчендә авылның йөзен үзгәртү бик үк җиңел эш түгел. Моңа тикле кешеләрнең уе икмәктә иде. Икмәккә туенгач, мал-туар асрарга да мөмкинлек туа башлады, кием-салымны да кайгырту кирәк иде. Яшерен-батырын түгел, кием-салымга бик бетәшкәннәр иде. Ә хәзер әнә кара — шәһәр кешеләреннән нәрсәләре белән аерылалар. Күрерсең, бернича ел үтәр — салам түбәле йортларның эзе дә калмас. Алар урынына стандарт таш йортлар күтәрелеп чыгар. Хәзер Казан архитекторлары яңа авылның генераль планын эшкәртәләр. Менә-менә кирпеч заводы салырга керешәбез...

Председатель тынып калды, авыр сулап куйды һәм, авыл өстенә карап:

— Әйе, иске йортлар күп әле, — дип сүзен дәвам итте. — Торсыннар әле хәзергә. Авыл яңаргач та, берничәсен калдырыр идем әле. Үткәнне искә төшереп, хәзергенең кадерен белергә ярдәм итә алар. Авыр эшләр машинага көйләнгән терлекчелек биналарына, куәтле агрегатларга бик тиз күнегәбез без. Үткәнне онытабыз. Ә аларның кадерен белергә кирәк, бик кирәк...

●

«Үткәнне искә төшерү» дигәч тә, председатель революциягә кадәрге үк вакытларны күз алдында тотмады, әлбәттә. Ул «үткән заманнар» белән хәзерге көнне бары тик алты ел вакыт аерып тора.

...Алтмыш беренче елның башы.

«Победа» колхозыннан КПСС райкомына берсеннән берсе шомландыргыч хәбәрләр явып кына тора: терлекләр кырыла, чәчүгә әзерлек өзеклек алдында, кешеләр эшкә чыкмый, җитәкчеләр типтерәләр...

Бу хуҗалыкны аякка бастыру өчен район җитәкчеләре күп чаралар күрде: машиналар белән ярдәм иттеләр, ссудалар да биреп карадылар. Әллә ничә председатель алышынды. Райком районлагы иң алдынгы колхоздан алып, иң эшлекле председательне дә бу колхозга тәкъдим итеп карады. Ләкин элекке председатель тирәсенә тупланган «үз кешеләр» төркеме колхоз хисабына типтереп яшәргә өйрәнгәннәр һәм бу кандидаттан да беренче сөйләшү вакытында ук баш тарттылар. Янәсе, «чит кеше» кирәкми, ул мондагы хуҗалыкның тәртибен белми, «үз кеше» булсын! Ә «үз кеше»ләр элеккечә типтерә бирделәр, колхоз һаман артта сөйрәлүче булып кала килде. Өшәнгән җир уңыш бирмәде: урып-җыюлар бетә, ә икмәк хөкүмәт заданиесен дә үтәргә җитми. Терлекчелектән дә керем аз. Ферма каралтылары ярым җимерек хәлдә. Терлек тә бик вак, җирле нәсел генә. Кемнең нәрсәгә кулы тисә, үз йортына алып кайту ягын гына чамалый. Кыскасы, һәр тармакта хуҗасызлык хакимлек итә.

Шуңа күрә колхозга чын хуҗа кирәк иде. Ләкин бу таркалган хуҗалык белән җитәкчелек итүне кем үз өстенә алсын!..

Вакыт уза торды. Февраль дә үтеп китте.

Партия оешмасының чираттагы җыелышы тагын да «председатель мәсьәләсенә» багышланды. Райкомның беренче секретаре иптәш А. Гнеденков та, кирәк була-нитә калса дип, чираттагы кандидатын ияртеп килгән иде...

Леонтий Степанович Петров та зур өмет белән килде җыелышка. Моңа кадәрге «үз кеше»ләрнең ничек җитәкчелек итүләрен аңа белмәскәме соң? Ә «чит» тәкъдим ителсә, әлеге «үз кеше»ләр барыбер аның гаебен табачаклар һәм, ничек кенә булмасын, сайламау чарасын күрәчәкләр. Бармы соң тагын үзебездә председательлеккә яраулы кеше?.. Агроном мәктәп турысында кинәт туктап калды. «Бар андый кеше, бар. Үзебезнең кеше», — дип чак кына кычкырып җибәрмәде ул.

Җыелышта райком секретаре сүзне кыска тотты: коммунистлардан шушы җыелышта ук «чын хуҗа» табуны таләп итте. Ләкин үзе уйлаган кандидатураны әйтмәде. Ияртеп килгән кешесен хәтта җыелышка да чакырмаган иде ул. Шау-шу купты. Әле бер, әле икенче фамилияне әйтеп карадылар...

Менә ябык кына, кечкенә генә буйлы, олы яшьләрдәге бер кеше — агроном Леонтий Степанович Петров сүз сорады. Шау-шу тынганны да көтмәде, бер генә сүз әйтте:

— Харитонов...

Аяз көнне күк күкрәп, яшен яшнәгәндәй булды, Леонтий Степановичның ишетелер-ишетелмәс кенә көчсез тавышы залга гаҗәеп нык тәэсир итте: кинәт халык тынып калды.

— Сез үз кешебез булсын дисез,— дип дәвам итте ул.— Менә мин үз кешебезне тәкъдим итәм. Харитонов Алексей Алексеевич. Безнең мәктәпнең завучы. Бездә туды, бездә үсте, үз җиребез кешесе. Мужик Алякка пичче [1] малае. Кулак Васяниканың батрагы иде Алексей Никитич. Алякка пичче грамотасыз көенчә дә, ун елдан артык колхозга җитәкчелек итте. Аның колхозы, хәтерегездәдер, алдынгы урынны бирмәде. Алексей Алексеевич югары белемле. Педагог булуы комачау итмәс. Математик ул. Ә математик булу председатель өчен бик кирәк. Исәп-хисапны белмәдек, шуңа шул көнгә калдык: хәзер исәпләр нәрсәбез дә күп түгел инде.

Зал һаман тып-тын иде. Райком секретаре да дәшмәде. Хәер, аның үзенә дә бу фикер килгән иде. Шуңа күрә дә яңа кандидатны бирегә чакырмады бит ул. Колхоздашлары, Харитонов үзе ни әйтер?..

---

[1] Пичче — абый (чувашча).

Партия җыелышы председательлеккә Алексей Харитоновны тәкъдим итте.

Колхозчыларның гомуми җыелышы бик пассив башланды. Колхоз парткомының кайбер членнары гына чыгып сөйләделәр. Колхозчылар тып-тын утырды. Аларга кемне председатель итеп куйсалар да барыбер иде. Күп сайладылар ич инде председательләрне... Кешеләр күңелендә җитәкчегә карата ышаныч сүнгән иде.

Арткы рәтләрдән кемдер әйтеп куйды:

— Әйбәт артист икәнен беләбез. Укытучы буларак та начар түгел, диләр. Әмма ләкин бит җир скрипка түгел... Сайлап карыйк инде. Күмәч белән туендыра алмаса, һич булмаганда, концертлары белән күңелне юатыр...

— Дөрес сөйләмисең, — дип каршы төште аңа икенчесе. — Җир дә үзенә күрә скрипка. Әмма безнең җир — бозык скрипка, көйне боза... Шунысы гаҗәп: Алексей Алексеевич үзе соң ник дәшми? Ничек уйнатырга уйлый икән ул җир-скрипканы?

Җыелышка председательлек итүче Харитонов ягына карап куйды. Алексей Алексеевич урыныннан торды да, салмак кына атлап, трибуна янына килде. Килгәч тә, беравык сүз башламый торды.

— Дөресен белергә телисезме? — дип башлады ул сүзен, — күзләрен бер ноктага текәп, кырыс тавыш белән. — Менә беренчесе: үзем теләми генә эшкә башлыйм. Үземнең дә теләгем юк, әни дә ризалык бирми, хатыным да елап калды. Икенче дөреслек: авыл хуҗалыгын начар беләм. Монысы әле әллә ни түгел. Өйрәнермен, сезнең шәкертегез булырмын... Хәзер өченче дөреслек: әгәр дә мәгәр сайлыйсыз икән, белеп торыгыз: аяк чалучыларга карата усал булачакмын. Монда да сезнең ярдәм кирәк булачак. Кем белә, бәлки, ни дә булса чыгар...

Харитоновны бертавыштан сайлап куйдылар. Ләкин аңа карата да ышанып җитмәү сизелеп тора иде...

●

— Җыелышта үземә күрә әтәчләнгән булган идем, — дип сөйли хәзер Харитонов. — Хәтта речь тә тоткан булдым. Ә өйгә кайткач, уйлап-уйлап тордым да куркып киттем. Төне буе йоклый алмадым, уйланып яттым. Иртән торып, дәресләр планын тиз-тиз генә төзедем дә мәктәпкә киттем. Ике-өч көн идарәгә барып күренмәдем. Дүртенче көнне райком секретаре мәктәпкә килеп кермәсенме. Кулында печать. «Я печатьне кабул итеп аласың, я партбилетыңны бирәсең», — ди.

...Авыл әкренләп кенә томанлы караңгылык эченә чума. Берәм-берәм тәрәзәләрдә утлар сүнә. Харитонов төн караңгылыгына ышыкланып, фермага юнәлә. Кеше күзенә чалынмый торган урынга яшеренеп сәгатьләр буена күзәтә. Менә берзаман атлы арба тавышы ишетелә. Күләгәләр пәйда була. Атны амбар янына туктаталар. Тавыш-тынсыз гына ике капчык он арбага менеп ята. Аннары арба кырга таба юнәлә.

— Кем ул? Тукта!

Мондый хәлләр еш кына кабатлана. Берсе дуңгыз баласы урлап тотыла, икенчесе печән белән... Әлбәттә, мондый эшләр судтан башка гына яки башка җитди чаралардан тыш кына хәл ителми. Ләкин бу кискен чаралар иске тәртипләрне яклаучыларга ошап бетми. Һәр яңалык аларның кискен каршылыгына очрый. Ике көннең берендә диярлек аны район үзәгенә, партком секретарена чакырып торалар: янәсе, ул халык белән хисаплашмый. Ләкин Харитонов үз юлында нык тора. Шантаж белән дә, янау белән дә өркетергә исәплаүчеләр булмый түгел. Элекке ревкомиссия председателе Кузьма Тимаков хәтта халык алдында аны «корткыч» дип белдерүгә барып җитә...

Әмма хәзер заманасы башка. Утызынчы еллар түгел. Күсәк күтәреп янаучылар да, нарядның үтәлешенә комачау итүчеләр дә яки тез чүгәргә, яки авылдан күчеп китәргә мәҗбүр булалар. Коммунистлар үз дигәннәрен итәләр: колхозда хезмәт дисциплинасы ныгый. Торган саен хуҗалыкка көч керә бара. Председатель бер генә эшкә чыкмау очрагын да, бер генә тәртипсезлекне дә игътибарсыз калдырмый.

— Колхозның көченә, үз-үзләренә ышаныч тудыру өчен көн-төн тырышырга туры килде, — дип хәтерли ул вакытларны Харитонов. — Миңа карата да аларда ышаныч тудырырга кирәк иде. Кичләрен колхозчыларның өйләренә кереп сәгатьләр буена гәпләшеп утыра идем. Үти алмаслык вәгъдәләр бирмәдем, дөресен генә сөйләдем. Хаер, вәгъдә бирерлек нәрсә дә юк иде әле... Үз фикерләрем турында Леонтий Степанович белән киңәшләштем. Төннәр буе киңәшеп утыра идек, планнар корабыз, аларны гамәлгә

ашыру юлларын эзлибез. Беренче елны ук колхозчыларга бүләргә — акчалата да, икмәкләтә дә — резерв таптык. Күп түгел иде, әлбәттә: хезмәт көненә икешәр килограмм икмәк, 20 шәр тиен акча! Ә аннан алдагы елда икешәр йөз грамм икмәк тә 4 әр тиен акча гына бүленгән иде. Түләүсез ашханә ачып җибәрергә булдык. Боларның барысы турында да башта гомуми җыелышта әйттек. Ышанмадылар:

— Борчакны шәп сибә бу, — диделәр. — Әбинең чуар тавыгы да алтын күкәй салам дип вәгъдә биргән, ди...

Ашханәне җыелыштан соң ук ачып җибәрдек. Производствода эшләүчеләр, механизаторлар, шоферлар өйләренә кайтып йөрми башладылар. Ә көзен, бик кыенлык белән булса да, хезмәт көненә бүлү турындагы вәгъдәбезне дә үтәдек. Халыкның күңеле кинәт күтәрелеп китте...

Һәм шулай итеп боз кузгала. Колхозчыларда председательләренә карата ышаныч туа. Алар булсын дип, күңел биреп эшли башлыйлар. Тиздән моның нәтиҗәсе дә үзен күрсәтә, колхоз үргә таба юл ала.

Алты ел эчендә бөртеклеләрнең уңышы өч тапкыр, шикәр чөгендере уңышы ике мәртәбә арта. Бары тик узган ел гына да кырчылыктан 135 мең сум саф табыш алына.

Әмма республикада «Победа» колхозы бөртеклеләр һәм шикәр чөгендереннән алынган уңыш белән генә данлыклы түгел. Бу колхозда терлекчелек белән яшелчәчелек тә киң колач белән үсә. Терлекләрнең нәселе яхшыртыла, продукциянең үзкыйммәте елдан-ел кими бара.

Ә хезмәт көненең бәясе алты-җиде ел эчендә 19 тапкыр үскән!

Төзелеш эшләре дә колхозда киң колач белән алып барыла. Алты ел эчендә унбиш терлекчелек, биш производство-административ биналары, өч культура һәм медицина объектлары салынган. Аларга ике йөз мең сумнан артык акча тотылган. Бирсдә балтапычкы тавышлары җәен дә, кышын да тынып тормый.

Кайдан соң килгән алар барысы да?

— Җир мәрхәмәте һәм кешеләр хезмәте аларның чыганагы, — дип җавап бирер иде Харитонов бу сорауга.

Әйе, җирнең кадерен белергә өйрәнгәннәр бу колхозда. Җиргә карата аларның мөнәсәбәте кайгыртучан, ягымлы, анага булган ихтирамга охшаш. Ә мондый мөнәсәбәт булганда, җирнең мәрхәмәте зур. Бик сизгер ул. Бише белән кайтара ул үзенә куйган хезмәтне.

Кешеләр дә үсәләр, тиз үсәләр. Элек авылдан качкан кешеләр дә берәм-берәм туган җирләренә кабат кайтып төпләнәләр.

Колхозда хезмәт гвардеецлары сафы торган саен арта бара. «Победа» колхозы агрономы Леонтий Петровка РСФСРның атказанган агрономы исеме бирелде [1]. Бригадир Николай Росчислов, механизатор Алексей Красильников, тракторчы Федор Шуркин, комбайнчы Никита Степанов, сыер савучы Валентина Гуслякова, кошчы Валентина Сорокиналарның исемнәрен бөтен республика белә.

«Победа» колхозы хезмәт иләре киләчәккә кыю карыйлар.

— Планнарыбыз зур, — ди председатель. — Алар колхозның хәзерге ныклы экономикасына нигезләнде һәм яңа бишьеллык план директиваларыннан чыгып эшкәртелде.

Әйе, колхозның киләчәктә хәл итәләсе зур һәм катлаулы эшләре күп әле. Терлекчелек буенча специальләштерү, аның нәселен яхшырту әле тәгәлләнмәгән. Ныклы азык базасы булдыру мәсьәләсе дә колхоз өчен җитди проблема. Чөнки табигый көтүлек һәм болынлык җирләр юк. Чәчүлекләрнең структурасын яхшыртасы бар. Терлекчелектә һәм башка тармакларда авыр кул көче сорый торган хезмәт процессларын машинага көйләү һәм шул нигездә продукциянең үзкыйммәтен киметү буенча алда тау кадәр эшләр тора...

— Нигезле белемнәре булган кадрлар җитми әле бездә, — дип сүзен дәвам итә Алексей Алексеевич. — Колхозда әллә ни хәтле катлаулы машиналар. Ләкин югары

[1] Журналыбызның бу саны биткә салынган вакытта СССР Верховный Советы Президиумының 1966 ел, 23 июнь Указы нигезендә Леонтий Степанович Петровка Социалистик Хезмәт Герое исеме бирелде. (Ред.).

белемле инженерыбыз юк. Терлекләр саны елдан-ел арта бара — ветврач та кирәк. Бүтән тармаклар буенча да белгечләр җиткерсәк әйбәт булыр иде. Тиздән боларга ирешәбез дип торабыз: хәзер югары һәм махсус уку йортларында колхоз исәбенә 8 кешебез белем ала...

Харитоновның скрипка белән дус булуын әйткән идек. Әйе, ул менә дигән скрипкачы, гармоньчы һәм... менә дигән спортсмен. Элеккеге профессиональ артист, Ватан сугышы инвалиды Петр Литт белән берлектә алар үз авылларында зур үзешчән сәнгать коллективы тәрбияләделәр. Аның җитәкчелегендә оештырылган физкультурниклар коллективы республика ярышларында ел саен диярлек алдынгы урыннарның берсен алып килә... Гомуми җыелыш вакытында әлеге колхозчының аның артист булуына төрттерүе шулай итеп юкка гына түгел иде. Ләкин ул эшләтә дә белә, калачын да, балын һәм маен да ашата, еш кына сәхнәгә менеп тә, менә дигән уены белән колхозчының күңелен таба белә. Аның концертын тыңлаганда, тамашачылар уч төпләре кабарганчы, гөр килеп, кул чабалар...

Менә нинди председатель булып чыкты Харитонов!

Хәзер «Победа» колхозы членнары үз председательләренә ышаналар гына түгел, аны яраталар, аның белән горурланалар. Аксубай райкомы секретаре Ю. А. Кузнецовның югары оешмаларның Харитоновны совхоз директоры итеп чакыруларына теләктәшлек белдермәве дә нәкъ әнә шуңа бәйле: колхозчылар аны үз итәләр. Бу хәбәр колхозга килеп җиткәч тә, колхозчылар бердәм карарга киләләр: «Бу эш барып чыкмас! Әгәр Казанда безнең теләк белән исәпләшмиләр икән, Мәскәүгә, Үзәк Комитетка барып җитәрбез!»

Мәскәүгә барып йөрергә туры килмәде, «Победа»лыларның теләкләрен Казанда ук искә алдылар — Харитонов үз постында калдырылды. Ә ул Норлаттан Хезмәт Кызыл Байрагы орденын тагып кайткан көнне колхоз идарәсенә котлап килүчеләрнең исәбе дә хисабы да булмады. Һәркемнең, югары хөкүмәт бүләге белән котлап, яраткан председательләренең кулын кысасы килде.

Мәскәүгә ул үзе барды. Аны Татарстан коммунистларының XXXII конференциясендә КПССның XXIII съездына делегат итеп сайладылар...

Председатель колхоз идарәсе тәрәзәсеннән урамга караган да тирән уйга чумган. Ә урамда кояш нурында ялтырап, күңелле итеп челтери-челтери, язгы гөрләвекләр ага. Бер-берсеннән уздырырга тырышып, канатларын кага-кага, сыерчыклар сайрый. Ләкин председательнең күзләре аларда түгел, ул каядыр бер ноктага текәлгән. Уйлары борынгы Кремльдә, Съездлар сараенда. Ул бит бернечә көн элек кенә анда грандиоз масштаблы яңа бишьеллык планны тикшерүдә һәм кабул итүдә катнашты.

Уйлар, уйлар... Алар киләчәккә чакыра. Съездлар сараенда барган утырышларда, яңа бишьеллыкның канатландыргыч саннарында, анда башкарылган бөтен дөнья өчен әһәмияте булган зур эшләрдә үз хуҗалыгының киләчәген тагын да ачыграк итеп күрде ул. Бу съездда партиянең колхозчыларның, барлык хезмәт ияләренең теләкләреннән, омтылышларыннан чыгып эш итүе тагы да ачыграк, тагы да калкурак булып чагылды. Халыкның һәм партиянең бу бердәмлеге киләчәккә ышанычны тагы да арттыра, шул киләчәк өчен көрәштә яңадан яңа көчләр үсти...

●

УКУЧЫЛАР СОРАВЫ БУЕНЧА

Хөрмәтле редакция!
Без Гөлсем Сөләйманова, Зифа Басыйрова, Илһам Шакиров, Әлфия Афзалова кебек артистлар башкарган җырларны яратып тыңлыйбыз. Тик аларның тормышлары, ничек артист булулары турында газета-журналларда бик аз языла. «Казан утлары» журналы битләрендә яраткан артистларыбыз тормышын ешрак, күбрәк яктыртсагыз икән.

ХӘЛӘФ ГӘРӘЕВ,
Кыргызстан ССР.

Мәгъсүм Латифуллин

ҖЫРГА САЛЫП ХАТ ҖИБӘРӘМ...

«Навои» театрының ачык тәрәзәләреннән урамга таралган моңлы җырны шәһәр өстендәге йолдызлар да, тротуар буйларындагы зифа топольләр дә йотлыгып тыңлыйлар кебек. Әйтерсең, бу җыр кояшлы Үзбәкстан иленә Идел дулкыннары герелтесен, ак каеннар шыбырдавын, бодай кырларында сайраучы тургайлар моңын алып килгән. Нинди яңа җыр бу? Татар көйләрен көчле тавыш белән шулай оста яңгыратучы артист үзе кем икән?

Рояль янына баскан җырчыга прожектор яктысы төшерделәр, залда утыручылар бинокльләрен сәхнәгә төбәделәр. Башын арткарак ташлап, «Әнием, күз нурым, кот мине, кайтырмын» дигән сүзләрне тирән кичереш, йөрәк җылысы белән яңгыратучы коңгырт күзле, аксыл йөзле бу уйчан егет — Татарстанның атказанган артисты Илһам Шакиров иде.

...Алгы рәтләрнең берсендә утыручы өлкән яшьтәге апа яулык почмагы белән күзләрен сөртте. Бу — күптәннән Ташкентта яшәүче татар хатыны Фәрхия түти иде. Җыр тәмамланып алкышлар яңгырагач, ул елмаерга тырышты һәм «Рәхмәт, балам!» дигән сыман баш иде.

— Бис! — дип кычкырдылар залдан.

— Илһам Шакиров тагын җырласын!..

Илһам җырын тыңлап, Фәрхия түти нык тәэсирләнде. Ул яңадан Бөек Ватан сугышы елларында фашистлар кулында әсир калып һәлак булган улын хәтеренә төшерде. Әнием, күз нурым, көт, кайтырмын дип, улы, Мирхәте, җыр аша хат җибәргәндер сыман тоелды аңа. Илһамны якыннан күреп сөйләшү теләге белән Фәрхия түти артистларның урамга чыгуларын көтте. Ләкин алар гостиницага китеп өлгергәннәр иде.

Алма-Ата, Дүшәнбе, Чимкент, Сәмәрканд шәһәрләрендә концертлар биреп арыган Илһам, гостиницага кайтып, йомшак диванга ауган гына иде — ишек шакыдылар.

— Керегез,— диде ул, урыныннан торып.

Өстенә чуар күлмәк кигән Фәрхия түти килеп керде.

— Илһам улым, берүк ачуланма инде капылт керүемә,— диде Фәрхия түти, туктаусыз сөйләнеп,— минә тәрә улым Мирхәтимем бар ие. Ул авыз-борын, йөз-күз, төшләрен күрсәтеп көлемсерәүләре тач син ие... Сугышта әрәм булды лабаса, мимечләр тереләй мичтә яндырганнар булып чыкты үзен.

— Тереләй яндырганнар?! Крематорийдә?!.

— Ие, ие, улым. Ә аның тавышы минә тәрә суйган да каплаган синекенә... Синең радиодан «Әниемә хат» дигән җыруыңны ишеттем исә йөрәгем өзгәләнә. Әллә мин әйтәм, Мирхәтимем, мескенкәем...

Ничек юатырга соң бу ананы? Нинди җылы сүзләр әйтергә аңа? Илһам кровать кырында яткан чемоданына иелде һәм, ашыгып-ашыгып, нидер эзләргә кереште.

— Апа, җаным, миннән истәлек булыр. Бу — «Әниемә хат» җыры язылган пластинка.

— Мең рәхмәт сиңа, улым,— диде Фәрхия түти пластинканы бик кадерләп алып,— атаң-анаң синнән игелек күрсен.

— Абзый исәнме соң апа? — диде Илһам, Фәрхия түтинең хисләрен уртаклашырга теләп.

— Юк шул, утыз җиденче елны суга төшкәндәй югалды...

Илһам көрсенеп тамак кырды. Йокларга яткач та, караңгы түшәмгә текәлеп, бик озак уйланды ул. Фәрхия түти сүзләре бала чагында үткәргән авыр көннәрне хәтеренә төшерде. Илһамның да әтисен утыз җиденче елның көзендә алып киткәннәр бит. Әнисе Нуриәсма түти алты бала белән тол калган. Илһам иң төпчеге, аңа ул чакта нибары ике яшь булган.

Бөек Ватан сугышы еллары. Киндер чалбар балакларын тезенә кадәр сызганып куйган ялан тәпиле Илһам сабанчылар янына килеп җитте. Әмма беркем дә аңа игътибар итмәде. Илһам, йөзен алъяпкычы белән каплаган һәм үксеп кара җир өстенә утырган әнисен күргәч, шомлана калды. Бер төркем хатын-кыз, Нуриәсма түтине әйләндереп алганнар да, аны төрле сүзләр белән юатырга тырышалар. Әле генә почта йөртүче кыз сабанчылар яныннан узган һәм Нуриәсма түтигә улы Имаметдинның сугышта батырларча үлүе турында хәбәр китергән икән.

Илһам өйләренә караңгы төшкәндә генә кайтты. Әмма йортка керәсе дә, ашыйсы һәм йоклыйсы да килми иде аның. Төн. Илһам капка төбендә утыра. Шул чак югары очта гармонь тавышы яңгырады. Гармоньга кушылып Имам абыйсы җырлап җибәрер кебек. Юк шул, кушылып җырлаучы ул түгел, бөтенләй икенче кеше:

Бу — вакытлы гына юксынуым,
Дусларымның исе китмәсен...

Ни өчендер, бу яңа көй Илһамның тетрәнгән күңеленә якын, бик үз булып тоелды. Илһам урыныннан торды һәм, еракта гы гармонь тавышына кушылып, эчтән генә көйне кабатлады.

Иртәгесен капка төбенә җыелган картлар Илһам авызыннан моңландыра да, дәртләндерә дә торган яңа җыр ишеттеләр. Бары да тынып калды, тормыш авырлыгын күп күргән картларның йөзләрен уйчан кырыслык пәрдәсе каплады. Ахырда гына көтүче карт, телгә килеп, көрсенеп әйтеп куйды: «Бу баланы, каләҗемә белән балтырган ашыннан коткарып, икмәкле кәҗүнний йортка укырга бирсәң, кем булыр ие икән?»

Ул йокысыннан уянганда, кояш шактый югары күтәрелгән. Ташкент урамнарында хәрәкәт көчәйгән иде. Илһам тәрәзәне ачып җибәрде, бүлмәгә, бөркелеп, бакчадан хуш исләр керде. Күпмедер вакыт ул ачык тәрәзәдән кояшлы урамга, трамвайларга

карап торды. Фәрхия түтинең дә, минем әнинең дә язмышы бер чамада икән. Юкса, икесе дөньяның ике башында бит инде. Хәзер нишли икән Фәрхия түти? «Иртәгә чәйгә кил, коймак пешереп көтәрбез, күршеләрем дә була», дигән иде. Кая инде вакыт. Ике сәгатьтән репетиция башларга кирәк. Җитмәсә, йөргәндә өйрәнермен дип, үзе белән яңа җырлар алган иде.

Илһам, юынырга дип тоткан сөлге, сабын, теш порошогы кебек әйберләрен кире куйды да, кулына каләм һәм кәгазь алып, өстәл янына утырды. Ул газета соравы буенча мәкалә язарга тиеш иде. Хәзер менә төпле бер фикер туды шикелле. «...Әниләребез, чабата киеп булса да, безгә итек таптылар, үзләре ач булса да, безне тук иттеләр, дәрес юлга илтергә тырыштылар, илгә, халыкка турылыклы булырга өндәделәр. Ата-ана алдындагы бурыч Ватан алдындагы бурыч белән аерылгысыз үрелгән. Димәк, ул — бәяләп бетергесез. Олы, изге!..» Илһам мәкаләне язып бетерде һәм ишекле-түрле йөри башлады. Ул Яңа Буләк авылын уратып алган урманнарны һәм әнисен сагынып, яшьлек елларын күз алдына китерде.

●●

Иң кече улының да буйга үсеп җитүен әле генә күргән сыман, зәңгәр альяпкыч итәгенә кулларын сөртә-сөртә, Нуриәсма түти Илһам янына килеп басты. Ул урта мәктәпне тәмамлаган көнне дә Илһамның шушы өстәл янында утырып хат язуын карап торган иде. Илһам бик озак итеп, ашыкмыйча һәм уйланып язды ул хатны. Аннары, бик изге эш эшләгән кебек, кәгазьне дүрткә бөкләп конвертка тыкты, конвертның ябыла торган өлешен бәрәңге белән келәйләп ябыштырды да почтага йөгерде. Хат Казан дәүләт консерваториясенә иде. Илһам тормыш юлын консерваториядән башларга кирәк дигән фикергә килде. Бу юлны укытучылары, авылдашлары да дөрес дип тапты: Илһам җырчы булырга тиеш, диделәр. Нуриәсма түти күңеленнән төпчек улына изге теләкләр теләде. Тик, күпме генә көтмәсен, консерваториядән Илһамга бернинди дә җавап килмәде.

— Алабуга институтына китәргә туры килә, әни,— диде Илһам акрын тавыш белән,— укытучы булырга.

— Укытучы булу һәйбәт инде, улым,— диде Нуриәсма түти, Илһамның бу яңа теләген дә куәтләп,— укып бетергәч, авылга кайтырсың, үзебездә эшләрсең.

Хат язылып беткәнче, Нуриәсма түти сүзсез генә Илһам янында басып торды.

...Керү имтиханнарын биргәч, Илһам яңадан авылга кайтты. Мендәр, юрган, китапише әйберләрне алып китәргә кирәк бит инде. Ә күңеле бөтенләй икенче нәрсәдә. «Рәшит Ваһапов, Гөлсем Сөләйманова, Зифа Басыйрова кебек җырчылар ничек олы юлга чыга алганнар икән? Казанга үзем барып карасам, ничек булыр? Консерваториядә кабул итү имтиханнары беткәндер инде. Нишләргә?» Капчыгын иңсәсенә салып, капка төбенә чыккач, Илһам үзен борчыган әйберләрне әнисенә сөйләде: «Әни, мин Чаллыдан пароходка утырып, Казанга барып кайтмакчы булам. Бәлкем, консерваториягә кереп булыр».

Казанга килеп төшкәндә, кичке утлар кабынган, күктә йолдызлар җемелди иде. Илһам консерваторияне эзләп тапты, каршыдагы агачлар кулагасенә сыенып, якты тәрәзәләр аша эчтә йөрүчеләрне күзәтте. Нинди бәхетле кешеләр укый икән монда?..

Икенче көнне Казаннан китәргә дип йөргәндә, ул урамда таныш егетләрен очратты. Әле өмет чаткылары сүнеп үк җитмәгән икән. Студент егетләр Илһамны музыка мәктәбендә укытучы Болдрева ханым белән таныштырдылар.

— Училищеда имтиханнар тәмамланды, шулай да Ильяс Вокасич белән сөйләшеп карыйк әле,— диде ул.

Директор Әүхадиев шунда ук музыка белгечләреннән берничә кешене чакыртты, Илһамны тыңларга һәм тиешле бәя бирергә кушты. Бик тырышып, чын күңелдән җырлады Илһам. Директор өсталенә «Илһам Шакировта табигый талант, аңарда абсолют слух!» дигән язу килеп керде. Шулай итеп, Илһам Казан музыка училищесында укый башлады.

...Училищеда дәресләр тәмамланды. Студентлар өйләренә таралдылар. Илһам, буш класс эзләп, коридор буйлап бара иде, каршысына җыр укытучысы Елена Александровна Абросимова очрады.

И. Шакиров сәхнәдә.

— Шакиров, син мондамени әле?

— Әйе, Елена Александровна,— диде Илһам, уңайсызланып,— минем фатирымда пианино юк. Берничә сәгать утырырга рөхсәт итәрләр микән?

— Итәрләр. Вахтерларга әйтеп китәрмен. Теләгән кадәр әзерлән. Әйдә әле, мин сиңа бер бүлмә күрсәтәм.

Абросимова коридорның уң ягындагы бүлмәгә керде, пианиноның капкачын ачып, клавишларга баскалады. Аннары, Илһамга карап:

— Бу яхшы пианино һәм синең тавышка ятыш... Шушында әзерләнергә тырыш.

Елена Александровна артыннан ишек ябылуга, Илһам пианино алдына утырды һәм, куллары белән йөзен каплап, уйга калды. Бигрәк олы җанлы, кече күңелле һәм сизгер кеше инде бу Елена Александровна. Соңгы көннәрдә Илһамның акча мәсьәләсендә кысылыбрак яшәгәнен каян белде икән. Оялып торма, акчаң бетсә әйт, ярдәм итәрмен, ди бит. Гаҗәп!

Илһам кулларын клавишлар өстенә куйды һәм акрын гына уйный башлады. Училищеның якты тәрәзәләреннән урамга көчле җыр таралды.

Йокысыз төннәр, зур тырышлыклар әрәмгә китмәде, Илһам дүрт еллык училище программасын бер елда тәмамлады һәм консерваториягә керде. Менә ул хыял иткән зур музыка дөньясы!

1957 елның июнь ае. Муса Җәлил исемендәге татар дәүләт опера һәм балет театрында фестивальдә катнашучы яшь талантлар ярышы бара. Илһам беренче тапкыр зур сәхнәдә. Ул Салих Сәйдәшевнең «Кара урман шаулый» җырын башлады.

Бу — патша Россиясе вакытында баш күтәргән крестьяннарның эчке хисләрен, уйларын, теләк-омтылышларын сөйли торган тарихи җыр. Илһам җырның эчке аһәңен тирән тоеп, көчле тавыш белән җырлады:

Карурман шаулый, эчтә ут кайный.

Көй, кайдыр китеп тыну белән, залда көчле алкышлар яңгырады. Илһамны кабат сәхнәгә чакырдылар.

— Күрдеңме, кадерлем Илһам,— диде Елена Александровна, дулкынланган Илһамны каршы алып,— милли колоритны бозмыйча, татар моңын тулысынча саклаган хәлдә, профессиональ башкару техникасы үзен акладымы? Aклады!

— Рәхмәт, Елена Александровна,— диде Илһам кулъяулыгы белән тирләгән йөзен сөртеп. Консерваториягә кергәнче миңа, анда синең тавышны бозып чыгарачаклар, дип әйтүчеләр дә булган иде...

— Яңадан матур бер сыйфат үсеп килә сездә. Шуны үзегез сиздегезме?

— Юк, Елена Александровна...

— Димәк, ул табигый сыйфат.

— Нинди сыйфат ул Елена Александровна?

— Сәйдәшев бу музыкада сыйнфый көрәш идеясен үткәрә бит,— дип аңлатты укытучы.— Көйдә моң күп булса да, аңарда киләчәк зур җиңүгә ышану тойгылары өстенлек ала. Ә моң шул замандагы халык кайгысын сурәтләүче фон итеп бирелә. Аңлашыламы? Сез менә шуны яхшы аңлап, ул фикерне тагы да үстереп башкара алдыгыз. Бу бик зур отыш!

Илһам театрның сул канатындагы киенү бүлмәсенә керде һәм урындыкка утырды. Киемнәрне чемоданга тутырырга кирәк иде, ул ашыкмады. Аның күләсе, шатланасы, яңадан зал яңгыратып җырлыйсы килде. Күп каршылыклардан соң беренче зур җиңү яулап алынды бит! Ул фестиваль лауреаты булды!

Консерватория баскычларыннан югары менгән саен, сәнгать горизонты да киңрәк күренде. Илһам башкаруындагы җырлар тапшыруны сорап, радиога хатлар килде, газета битләрендә, афишаларда аның исеме күренә башлады.

●●

Илһам вагон тәрәзәсеннән карап бара. Паровоз төтене таралып артта кала. Дулкыннарга охшаш таулы урманнар күренә. Илһам офык белән урманнар тоташкан сызыктагы зәңгәрсу томанлыкка текәлеп, акрын гына «Тәфтиләү»не көйли. Мәскәүдә булачак зур концертта җырланырга тиеш көй бу. Тукай юбилее уңае белән оештырылган концерт Колонналы залда үткәрелә икән, анда зур сәнгать осталары да, язучылар да булачак бит. Җитди һәм нык әзерлек таләп ителә. Тукай сүзләренә язылган җырларны башкарам икән, шагыйрь образын гәүдәләндерергә, ул яшәгән катлаулы чорның рухын бирә белергә кирәк. «Зиләйлүк», «Әллүки», «Пар ат» җырлары зур вакыйгалар турында сөйлиләр... «И мөкатдәс, моңлы сазым! Уйнадың син ник бик аз?» — ди шагыйрь. Аның соңгы минутларын хәтерләтә бу сүзләр.

— Моңланамсың, егет? — диде кемдер, аның җилкәсенә кулларын салып. Каршысында шагыйрь Хәсән Туфан басып тора иде.

— Хәсән абый, исәнмесез, сез дә бу поездда барасызмыни?

— Әйе, күрше вагонда. Әйдә безнең вагонга, Илһам, күңеллерәк булыр,— диде Хәсән Туфан,— Фатих Хөсни, Афзал Шамов, тагын берничә шагыйрь бара. Рөстәм Яхин да безнең янда.

— Рөстәм Яхин барамыни? — диде Илһам җанланып,— алайса киттек, Хәсән абый.

Алар икенче вагонга килеп кергәндә, язучылар күңелле сөйләшеп, көлешеп утыралар иде.

— Уһу, көткән әзләгәнне җирдән таптым бит,— диде Яхин, Илһам белән күрешеп,— хәлләр ничек?

— Яхшы гына,— диде Илһам елмаеп,— яңалыклар бармы?

— Бар бит, Илһам дус. Син әйткән фикер менә бик озак борчып йөрде. Бер әйбер туа шикелле, синең тавышка ябышып торачак!

— Шулаймы! — диде Илһам шатланып,— тизрәк, Рөстәм абый. Сусап торам. Киң итеп, күкрәкне киереп, бөтен сулышка җырларлык булсын.

— Диңгез сымак очы-кырые күренмәгән булыр. «Китмә, сандугач!» җыры. Синең алда тагын нинди планнарың бар?

— Аннары, менә әле генә башыма бер фикер килде,— диде Илһам,— сез дөрес дип табарсызмы? Тукай сүзләренә язылган җырлардан һәм Тукайга багышланган музыкаль әсәрләрдән тулы бер композиция төзеп җырлаганда, ничек булыр икән?

— Әйбәт булыр. Бик шәп яңалык бу. Планнарың бик гүзәл. Уңыш телим, Илһам дус!

Күрше купеда утыручылар арасында татар кешеләре дә бар икән. Бер күзлекле егет белән Нәзирә исемле кыз, рөхсәт сорап, Илһамнар янына килеп утырды. Рөстәм Яхин елмаеп Илһамга карады, аннары, «рәхим итегез» дип, кара кашлы, кара күзле Нәзирәгә урын бирде. Яшьләр кыю күренәләр иде. Алар, бер дә тартынып тормастан, җыр, театр сәнгате турында сүз башладылар.

— Гафу итегез, сез, Рөстәм абый, композитор буласыз дип беләм, ә сез, җырчы, Илһам Шакиров? — диде Нәзирә йомшак тавыш белән.— Ачуланмагыз, Илһам иптәш, сезгә бер соравым бар иде. Сез гел татар халык көйләрен, моңлы җырларны гына җырлыйсыз. Бик яратып тыңлыйбыз. Ә аны башка халыклар аңлый микән?

— Сез моның белән нәрсә әйтергә телисез? — диде Яхин, Илһамга җавап бирергә ирек куймыйча.

Кыз әллә уңайсызланды, әллә фикерен туплый алмаган иде, тәртелеп калды. Сүзне кызның юлдашы, күзлекле егет дәвам итте.

— Без үзебез Свердловскидан,— диде егет күзлеген төзәтеп киеп,— заводта эшлибез. Татар яшьләре, җыелабыз да, үзебезнең җырчылар турында бәхәс алып барабыз. Нигә, без әйтәбез, Шаляпин, Рәшит Бейбутов һәм Утесовлар шикелле, безнең татар җырчылары бөтен дөньяга таныла алмыйлар? Бары моңлы, озын җырларны гына башкаргангадыр дип уйлыйбыз.

— Дөрес, минем фикер дә шулай иде,— диде Нәзирә.

— Мин классик музыканы да, башка халыкларның җырларын да, хәзерге композиторлар әсәрләрен дә җырлый алам,— диде Илһам,— әмма безнең үз бурычыбыз бар бит!

Илһам әлеге яшьләргә музыка сәнгате турында күп нәрсә сөйли алыр иде. Андый кешеләргә сөйләп тә, җырлап та бик яхшы аңлата белә ул. Консерваториядә укыган вакытта яшьләрнең бер өлеше, Илһамның күбесенчә халык җырларына әһәмият бирүен күреп: «Примитив» музыка белән генә шөгыльләнә, классикага теше үтми», диделәр. Әмма дәүләт имтиханнары вакытында Илһам, халык җырларын башкару белән бергә, Гендельның «Крекс» ораториясеннән бер өзекне итальян телендә, Рахманинов романсларын, Гуноның «Фауст» операсыннан Валентин каватинасын, Җәүдәт Фәйзинең «Тапшырылмаган хатлар» операсыннан Искәндәр монологын зур осталык белән башкаргач, йөз чөерүчеләр гаҗәпкә калдылар. Ә вокаль факультетының кафедра мөдире профессор Зөһрә ханым Бәйрашева, бик куанып, рәхәтләнеп, аңа «Отлично» билгесе куйды. Ә менә бу эшче егет белән чибәр кызга ни әйтәсең? Илһам Рөстәм Яхинның аларга биргән җавабын дөрес дип тапты һәм, аны раслагандай елмаеп, баш иеп утырды:

— Тормышта һәр халыкның музыка культурасы ике тармактан үсеп бара,— диде Рөстәм Яхин,— әгәр халык сәнгате үсмичә, профессиональ сәнгатьтән артка калса, бу нормаль күренеш түгел. Алар икесе тигез, параллель үсеп барырга тиеш. Менә Илһам Шакировның халык моңнарын, халык җырларын башкаруы — аның халык сәнгатен үстерүдәге хезмәте. Ул — укымышлы, югары музыка культурасына ия булган җырчы. Ул үзенең профессиональ осталыгы белән татар халык сәнгатен зур сәхнәгә күтәрү өстендә эшли. Нәкъ сез теләгән проблеманы чишү юлларын эзли. Сезнең рус халык җырчысы Зыкинаны тыңлаганыгыз бармы?

— Бар,— диде Нәзирә.— Ул чит илләргә дә барды бит.

— Дөрес, күп илләрдә булды. Ә бит Зыкина джаз музыкасына иярми. Рус халкының милли җырларын, милли моңнарын саф килеш башкара. Аның җырларын бүтән халыклар аңлыйлар ич. Илһам Шакировны да бик аңлыйлар! Робертино Лоретти — итальянча, Радж Капур — һиндичә, Роза Багланова — казакъча җырлап дан алдылар. Ә Илһам Шакиров шул илләрдә татарча җырласа, аны яратмаслар идемени? Бик яраталар. Әле күптән түгел генә Париждан Татарстанга хат килде. Анда французлар Илһам Шакиров башкаруында «Кандыр буе», «Сагать чылбыры», «Мәдинәкәй» кебек татар җырларын бик яратулары турында язалар. Яңадан Илһам Шакиров тавышы язылган пластинкаларны сорыйлар.

— Французлар?

— Әйе, французлар. Әле быел тагын Польша, Самоли, Чехословакия, Болгария, Румыния илләреннән килгән туристлар да татар пластинкаларын яратып алып киттеләр. «Шүрәле» балеты күп илләрдә яңгырый бит. Менә шуның кебек инде...

Мәскәүгә җиткәнче Илһам күңеленнән әлеге әңгәмәне кичереп барды.

...«Зиләйлүк» көен җырлаганда, Илһам Колонналы залда тавышының үзенә бертөрле яңгыравын тойды. Бу яңгыраш аңа тылсымлы көч бирде, ул иркенәеп, күкрәгеннән ургылып чыккан киң сулыш белән җырлады. Җырда халык моңы аша татар кызының трагик хисләре яңгырый. Яшь кызны мәсхәрә кылып, урамга ташлаган бай кешегә карата нәфрәт тойгылары үсә бара. Шагыйрь: «Сәялгәнсең чатта баганага, яфрак төсле сары йөзләрең... Бигрәк моңлы карый күзләрең» — дип, татар кызының кара язмыш кулында һәлак булуын, газраилнең канлы тырнагында газап чигүен күрсәтә. Бай һәм мәсхәрәләнгән ярлы кыз арасында сыйнфый каршылык упкын шикелле тирән күренә... Илһам бу хисләрне төшенке итеп түгел, «бәрыбер дәреслек өсһә калкыр!» дигән мәгънә белән яңгыратып тәмамлады.

Колонналы залны кул чабулар гөрелтесе күмде. Мәскәү тамашачылары аны сәхнәдән төшерергә теләмәделәр. Сәхнә уртасына куелган Тукай портреты да елмая кебек иде.

Концерттан соң киенеп вестибюльгә чыкканда, Илһамны шактый күп кешеләр көтеп тора иде. Ул аларны үзен көтеп торучылар дип уйламады һәм, иптәшләренә ияреп, урамга таба юнәлде.

— Илһам, бер генә минутка бире кил, пожалуйста,— диде Хәсән Туфан аны култыклап алып,— иптәшләр сиңа рәхмәт әйтергә телиләр.

Монда РСФСР язучылары союзы председателе Леонид Соболев, казакъ язучысы Сабит Муканов, Тукай әсәрләрен русчага тәрҗемә иткән рус шагыйрьләре һәм башка күп милләт кешеләре бар иде. Алар Илһамның «Тукайча өздереп һәм моңлы итеп» җырлавына зур бәһа бирделәр. Кайчандыр Иранда яшәгән, соңыннан СССРга кайткан әзербәйҗан шагыйрәсе Мәдинә ханым Гюль-Ген аерата дулкынланган иде. Ул үз китабының тышына: «Татар халкының гүзәл улына, Тукай һәм Муса Җәлил онытына зур рәхмәтем истәлек булсын! Илһам! Җырлавың шикелле үк матур үтсен гомерең!» — дип язды һәм Илһамга бүләк итте.

Хәсән Туфан кешеләр алдында Илһамга бер сүз дә әйтмәде, бары елмаеп, сүзсез бәсып кына торды. Кешеләр таралып, урамга чыккач исә, матур җырлаганы өчен рәхмәт әйтмичә булдыра алмады. Ә Фатих Хөсни «маладис» дип кул кысышып алу белән юкка чыкты. Аның каравы, берничә көннән газетада Фатих Хөснинең Мәскәүдә узган Тукай кичәләре һәм концертлар турындагы мәкаләсе Илһамда зур хис тудырды. Илһам газетадан үзе турындагы юлларны укыгач, концертка җитди әзерләнүнең бушка китмәгәнен аңлап куанды. Газетада әйтелгәнчә, «Халык моңнарын күңел биреп, Илһамча оста башкарганда» башка халыклар алдында йөзебез кызармас!

Хуҗа Насретдин мәзәкләре

АЛТЫ ИКМӘК

Хуҗа һәр көнне алты бөтен икмәк алып кайта икән. Аның күршесе:

— Я Хуҗа, нигә син көн саен алты бөтен икмәк алып кайтасың? — дип сораган.

Хуҗа аңа:

— Берсен үзем ашыйм, берсен ташлыйм, икесе белән бурычымны түлим, ә икесен бурычка бирәм, — дигән.

Күршесенең аңламыйча гаҗәпләнеп торуын күргәч, Хуҗа аңа:

— Шуны да аңламыйсыңмыни? Димәк, берсен үзем ашыйм. Ташлыйм дигәнем — хатынымның анасына бирәм, бурычымны түлим дигәнем — әти-әниемне ашатам, ә калган икесен балаларыма бирәм, — дигән.

ХУҖА — ОСТА АТУЧЫ

Яз көне солдатлар атарга өйрәнү өчен далага чыканнар. Аксак Тимер солдатлар белән бергә Хуҗаны да алып чыккан. Сүз уңаенда Хуҗа кайчандыр үзенең яхшы атуы турында әйткән. Тимер, моны ишеткәч, Хуҗага җәясеннән атарга кушкан.

Хуҗа атарга теләмәсә дә, патша кушкач, җәясен тартып укны атып җибәргән. Ләкин угының читкә тайпылуын күргәч, Хуҗа: «Рота командиры менә шушылай ата торган иде», — дигән. Аңа тагын бер ук биргәннәр, анысы да читкә киткән. Бу юлы Хуҗа: «Кала башлыгы менә шушылай ата торган иде», — дигән.

Өченче ук, көтелмәгәндә, төзегән җиргә барып кадалгач, ул масаеп: «Хуҗа абзагыз менә шушылай ата ул!» — дигән.

Җыючысы А. ӘХМӘТ.

Бөек Октябрьның 50 еллыгына

Локман Аитов

АРТИСТНЫҢ ТОРМЫШ ЮЛЫ

Әти өйдән куып чыгаргач[1]

Абый белән миңа Пермьда торырга җай калмады. Татар байлары безне эшкә алмый, кәмитчеләр, шамакайлар дип хурлыйлар гына иде. Әле дә ярый бер таянычыбыз бар — икебез дә бераз русча беләбез. Шулай итеп, язын рус байларында төрле эшләр эшләп, җәйгә Казанга барырга юллык акча әзерләдек. Әгәр Казанда да эш таба алмасак, Мәкәрҗә ярминкәсе якларына барып чыгарга, бәхетне шуннан эзләп карарга исәп иде.

1909 елның җәе. Без пароходта Казанга килдек. Шәһәрдә безнең туганнар да, белеш-танышлар да алай күп түгел иде. Без Мулланур абыйның әтисе Муллаҗан Вахитовларга төштек. Алар ул вакытта Петропавловский тыкрыгында (хәзерге Муса Җәлил урамында) торалар иде. Безне Муллаҗан абзыйның икенче хатыны Варвара Захаровна якты чырай белән каршы алды. (Мулланур абыйның үз әнисе Өммегөлсем җиңги, аерым рәвештә, Московская (хәзерге Киров) урамында, Апанаевский подворьеда яши иде.) Озак та үтмәде, Муллаҗан абзый белән Мулланур абый да кайтып керде. Гөр килеп чәйгә утырдык. Мин Мулланур абыйдан күземне ала алмыйм. Аның өстендә яшькелт сукнодан тегелгән студентлар киеме, җилкәләрендә погоннар! Ул фуражкасын салып куйды да:

— Ерак илләрдән килгән туганнарым минем! — дип арабызга кереп утырды.

Без аңа Пермьда беренче тапкыр татарча театр куюыбызны, спектакльдән соң шәһәрдә шау-шу кубып, җыелган акчаның расходларны да капларга җитмәвен, уйнаучылар үзләре өчәр сумнан салышып шуны каплавыбызны сөйләдек. Спектакльдә катнашкан кайбер приказчикларны байлары урыннарыннан чыгаруын да әйттек. Әтинең безне өйдән куып чыгаруын да яшермәдек. Мулланур абыйны бу хәбәрләр бик борчыды.

Мулланур абый 1905—07 ел революциясенең Пермь тирәсендә яшәүчеләргә, бигрәк тә татарларга, булган тәэсире турында сорашты. Мотовилиха заводындагы 7—8 мең эшченең 3—4 көн буена эш ташлап торулары, шул уңай белән Пермьга күп кенә атлы казакларның килүе, приказчикларның баш күтәрүләре, Агафуровларда хезмәт итүче татар приказчиклары белән бергә Муллаҗанның туган энесе Габдулла абыйның да эш ташлауда актив катнашуын әйткәч:

— Молодец, Габдулла абзый! — дип шатланып куйды.

Бу минем Мулланур абый белән беренче очрашуым түгел, мин аны 6—7 яшьләремдә чакта ук, Кунгур шәһәренә әнием белән кунакка барганда күргән идем. Ул вакытта Мулланур абыйлар бабалары Гәрәй Вахитовлар йортында торалар иде.

Мулланур абый 1885 елда Кунгур шәһәрендә туган. Муллаҗан абзый белән Өммегөлсем апа, бердәнбер балалары булган Мулланурны, шәһәр һавасы начар дип,

[1] Дәвамы. Башы 6 санда.

Кунгур өязендәге башкортлар яши торган Казый авылына алып китәләр. Өммегөлсем апа 16 яшьтән үк кияүгә чыга һәм Мулланурны бик яшьләй тапканлыктан булса кирәк, бик үк сәламәт булмый. Бала да гәүдәгә кечкенә, ябык, чандыр, чөнки ул вакытсызрак — җиде айдан туган бала була. Шуна күрә, алар авылда яшәүне артыграк күрәләр. Мулланур унынчы яшькә чыккач, аны Кунгурга алып килеп, русча укырга бирәләр. Мин ул вакытта алты-җиде яшьтә генә булганлыктан, Кунгурдагы беренче очрашуны артык күз алдыма китерә алмыйм. Шулай да, томанлы гына булса да, ул очрашу миндә бик җылы тойгы калдырган.

Мәкәрҗәдә

Мәкәрҗә!.. Кемнәр генә бирегә килергә ашкынмый! Байлар, хуҗалар бирегә комсыз нәфесләрен басарга, типтерергә, акча түгәргә, күңел ачарга килсәләр, безнең ише приказчиклар, шәкертләр исә берәр эш эзләп, бәхет өмет итеп, байларның типкеләрен алырга, маңгай тирләре түгәргә килә.

Дөрес, мондый шәкертләрнең үткенрәкләре, кесәләрендә беркадәр маялары булганнары, татарча газета-журнал һәм китаплар белән сату итә. Кайберләре кибетләр арасында вакытлы эшкә яллана. Шулай итеп, болар Мәкәрҗәдән бераз өс-башларын юнәтеп, кышын мәдрәсәдә укыганда ачка үлмәслек запас әзерләп тә кайталар. Эш эзләп йөрүчеләрнең исәбе дә, хисабы да юк.

Ярминкә уртасында «Самокат» дип атала торган зур мәйдан: анда карусельләр әйләнә, «томанный» картина күрсәтелә. Атаклы Никитин циркы да шунда. Мәйдан артыннан ук «Хәсрәт бакчасы» китә. Биредә, чыннан да, бик моңсу, бик күңелсез. Көндезләрендә бирегә бай хуҗалар кереп чыккалый. Алар төрле эшләргә яллыйлар. Байлар тезелеп утырган ярлыларга күз йөртеп кенә үтәләр. Берәрсенең тазалыгы яки кыяфәте ошаса, янына килеп, баштанаяк карап чыгалар да, нинди эш барлыгын белдергәч, номерына килергә кушалар.

Мин, гадәтемчә, вывескалар, афишалар, игъланнар укып йөрим. Чү, бу ни бу! Татарча афиша!

«...Мәшһүр артистка Гыйззәтуллина-Волжскаяның катнашы белән «Сәйяр» труппасы тарафыннан спектакль бирелә. Сәхнәгә куеладыр: «Хуҗа һәм приказчик».

Афишаны кабат-кабат укып чыктым. Урын эзләү кайгысы онытылды. Минем теләк татар артистларын күрү иде. «Барыйм әле, берәрсен күреп булмасмы», дип, «Самокат»тагы шул театрны эзләп киттем.

Барып кереп, швейцардан: «Биредә татар артистларыннан кем дә булса бармы?» дип сорадым. Ул: «Әнә алар, репетиция ясап яталар», дип әйтеп тә бетермәде, бүлмәдән башына котелок эшләпә, өстенә сюртук кигән озын буйлы бер кеше килеп чыкты. Мин аның артист булуына шикләнмичә башымны идем. Ул минем каршыма килде дә:

— Нихәл, чибәр егет? Кемне эзлисең? — дип сорады.

Шундый мәһабәт кешенең ачык күңеллелегенә мин гаҗәпләндем. Үземнең Пермь шәһәреннән килүемне, театр сөюче булуымны әйттем. Ул: «Әйдә алайса, таныш булыйк. Мин артист Нурый Сакаев булам!» дип кулын сузды. Шуннан соң ул Пермь хәлләрен сораштырды да: «Без дә шул якларга барып чыгарга исәп тота идек... Әйдә әле, мин сине Кариев белән таныштырыйм», дип, култыклап алып кереп тә китте.

Бер диванда Кариев, Мортазин, Волжская нәрсәдер сөйләшеп утыралар иде. Мин аларның һәркайсы белән кыяр-кыймас кына танышып чыктым. Кариев, Пермь шәһәре, гомумән Урал яклары турында сорашты: «Сезнең якларда татарлар күпме? Без труппа белән барып чыксак, ничегрәк булыр?» дип, бәйнә-бәйнә сорашты. Мин үзем белгәннәрнең бөтенесен әйтеп бирергә тырыштым. Алардан бер дә аерыласым килми иде, үзебезнең беренче тапкыр татарча спектакль куюыбыз хакында да сөйләдем, ул якларга бару яхшы булыр дип, Урал якларын мактадым. «Бүген булачак спектакльгә билет кайдан алырга мөмкин икән?» дигәч, Кариев: «Син инде, егет, үзең дә театр уйнаучы булгач, шуның өстенә тагын хезмәтсез, эш эзләп килүче дә булгач, билет алып маташмассың, акчаң ашарга кирәк булыр, кич белән сәгать җиделәрдә кил, билетсыз гына карарсың. Безгә азрак булышырсың да...» — диде.

Кайтканда аягым җиргә дә тимәде, чөнки бу көн, бу сәгатьләр минем өчен гадәттән тыш зур шатлык иде. Бу көнгә хәтле мин артистлар хакында газеталардан гына

«Сәйяр» труппасы. 1909 ел.

укып белә идем. «Ай, үзләрен күрсәң иде!» дип, хыялланып кына йөрүче идем. Менә ул хыяллар чынга әйләнде! Мин кичке сәгать җидене ничек җиткерергә белмичә аптырап, театрга сәгать алтыда ук барып чыктым да сәхнә артына кердем.

Артистлар белән танышлык арта башлады. Барый Болгарский да бик кече күңелле кеше икән, танышып, сөйләшеп утырдык.

Бераздан Кариев та килеп җитте, мине күреп: «Ә, егет, килдеңме? Әйдә әле минем белән», дип алып китте. Залны күрсәтте һәм главный ходта торучы контрольгә мине тәкъдим итеп: «Менә бу егет безнең кеше, ул сезнең белән менә шушында булыр һәм залдагы тәртипне карар», диде. Миңа: «Син инде, егет, яхшы кара, күз-колак бул, билетсыз кешеләр кермәсен, син бүген театрның администраторы урынында!» — дип, мине калдырып китте.

Менә берзаман халык җыела башлады, зал шыгрым тулды. Өченче звонок бирелгәч, пәрдә дә ачылып китте.

Галимҗан бай булып — Кариев, хатыны булып — Сәмитова, кызлары Бибиҗамал ролендә Волжская, Садыйк байны — Нурый Сакаев, приказчик Мортазин һәм яучы карчык булып Барый Болгарский уйнадылар. Бу артистларның уйнаулары мине хәйран калдырды. Бөтенләй дөньямны оныттым. Башта ишек төбендә генә басып тора идем, аннан күчә-күчә алга барып җиткәнемне, мине сихерләгән сәхнәгә якынлашканымны сизми дә калганмын. Кариев йомшак кына характерлы бай образын аеруча матур башкарды. Аның сүз арасында: «Яхшы сөйлимме мин?» дип, гадәтенчә, әйтеп куя торган сүзләре бик озак вакытлар онытылмыйча колагымда яңгырап торды. Яучы карчык ролендә уйнаган Барый Болгарскийны таныр хәл дә юк, ир кешенең хатын-кыз булып шулай уйный алуы мине аптырашта калдырды. Садыйк бай — Нурый Сакаев белән ана ролендәге Сәмитова да бик соклангыч образлар тудырдылар. Иң ахырда, барысыннан да гаҗәбрәге, минем күңелдә иң тирән эз калдырганы Бибиҗамал ролендәге Сәхипҗамал Волжскаяның уйнавы булды. Бер изелгән татар кызының шундый мөлаемлыгы, шул ук вакытта, ата-аналарының аны көчләп бер карт байга кияүгә бирүләренә батыр каршы торуы, сөйгән егетенә кияүгә чыгып, үз теләгенә ирешә алуы ул заманда акылга сыймаслык хәл иде. Волжскаяның шуларны чын итеп, зур киеренүләр аша уйнап күрсәткән вакытларында, залда тыныч кына карап утырырга һич

мөмкин булмады. Тамашачылар кызның батырлыкларына шатландылар, кайгыларына көенделәр. Пәрдә ябылгач: «Волжская! Волжская!» дип кычкыра-кычкыра пәрдәне өч-дүрт мәртәбә ачарга мәҗбүр иттеләр. Бу күренешләрне күргәч, мин дә шашып калдым. Чөнки моңарчы ирләр алдында бер кәлимә сүз әйтергә кыймаган татар кызының йөзләрчә ирләр алдында сәхнәгә чыгып, шундый батырлык күрсәтүе, татар кызларының хакын таләп итүе, әлбәттә, гадәттән тыш кыю адым иде.

Берничә көннән соң «Казанга сәяхәт» белән Галиәсгар Камалның «Кайниш» әсәре куелды. Бу спектакльләрне тагы да кызыксынып карадым. Өстәвенә, без уйнаган әсәр, «Казанга сәяхәт»тә куелды. Мина үзем уйнаган Мәҗит хәлфә ролен бирделәр. Чын театрда, чын артистлар арасында, беренче тапкыр сәхнәгә чыгу гомергә дә онытылмаслык, иң бәхетле көннәремнең берсе булды.

Сәхнә артыннан гына карап торсам да, Гата бай ролендәге Кариев уйнавыннан көлә-көлә рәхәтләндем. Халыкны әйткән дә юк, атаклы артистка сүз әйтергә ирек бирмичә кул чаптылар.

Атаклы гармоньчы Ф. Тунишев. 1909 елда.

Шулай итеп, ике атнадан артыграк вакыт эчендә, «Сәйяр» труппасының артистлары белән якыннан таныштым, биш-алты спектакль карадым һәм кайсыберләрендә үзем дә катнаштым. Күнелләрем күтәрелеп китте, эшсез йөрүем дә онытылды, сәхнәгә булган мәхәббәтем көннән-көн арта барды...

Шул көннәрдә Фәйзулла Тунишев концерты да булды, аның белән дә танышып: «Безнең халыктан да шундый гармоньчы чыгар икән?» дип, тагын хәйран калдым. Чөнки мин бу көнгә кадәр Пермьда гастрольгә килгән рус уенчыларыннан мәшһүр Петр Невскийны гына күргәнем бар иде. Фәйзулла Тунишевның рус көйләреннән башка татар халык көйләрен дә кечкенә гармоньнарда зур осталык белән уйнавы, шунын өстенә тагын үзе уйнап, үзе биеп җибәрүләре сокландыргыч иде.

Мәкәрҗәдә үткән бу көннәр рухи яктан канәгатьләндерсә дә, материаль яктан киресенчә булды, акча бетеп китте.

«Сәйяр» труппасы артистлары белән аралашып, алар белән мавыгып йөри торгач, ике атналап вакыт узып китте. Кариев минем русча укый-яза белүемне, сөйләшүемне күргәч, мина афишаларга рөхсәт алу артыннан йөрү эшләрен дә тапшыра башлады. Шунлыктан, минем абый янына кунарга кайтмаган көннәрем дә бик еш була иде.

Абый: «Бу малай үзенә урын таба алмый ахры. Ничек кенә булса да тизрәк урнаштырырга кирәк», дип уйлаган булса кирәк, көннәрнең берендә миңа:

— Локман, мин сиңа урын таптым. Троицк шәһәренең Габделвәли Бакиров атлы яшь баена приказчик кирәк икән. Иртәгә беркая да чыгып китмә! — дип кисәтеп куйды. Бу сүз мине бер яктан куандырды, чөнки мин һаман абый җилкәсендә яши идем. Белеп торам: аның үзенә дә көн итүе җинел түгел. Икенчедән, иләнеп житкән

артистлардан аерылу бик авыр иде миңа. Алар арасында вак-төяк эшләр башкарып йөрү генә дә никадәр рухи байлык бирә иде бит!

Нишләмәк кирәк, абый сүзеннән дә чыгып булмый.

Икенче көнне абый мине байның магазинына алып китте. Без анда таза гына гәүдәле, европача киенгән, әле сакал-мыек та чыкмаган бер кешене очраттык. Мин ялланасы яшь бай Габделвәли Бакиров шул үзе икән. Абый: «Минем энем Локман шушы була инде», дип мине таныштырды. Бай мине баштан-аяк карап чыкты да:

— Ярый, энегез миңа ошады! — дип, хезмәт шартлары турында сөйли башлады һәм.— Аена унбиш сум жалование түләрбез. Ашау-эчү үзеннән булыр. Үзең кая теләсәң, шунда фатирда торырсың. Юл расходларын үз өстебезгә алабыз. Менә сиңа унбиш сум акча, юлыңнан калганы ашарыңа булыр! — диде дә, кыска гына хат язып, миңа сузды.— Менә монысын, барып төшүеңә безнең магазиндагы доверенный Хәсән абзыйга бирерсең. Иртәгә үк юлга чыгарсың,— диде.

Кичен труппадагы артистлар белән саубуллаштым. Алар миңа төрле киңәшләр бирделәр. Кариев белән Мортазин Троицкига баргач нәрсәләр эшләргә кирәкне аңлаттылар. Яшьләрдән түгәрәк оештырырга, театр эшләрен кузгатырга куштылар. Үзләренең дә килеп чыгачакларын әйттеләр.

Икенче көнне абый мине пароходка утыртып озатып җибәрде.

Троицкида

Троицкига килеп, Бакировларда бер ай гына эшләргә өлгергән идем, сәүдәгәр бай Яушевлар шәһәрдә пассаж ачып җибәрделәр дә башка кибетчеләрне бөтенләй аяктан ектылар. Бу сәүдә бинасы биш катлы булып, Мәскәүдәге «Мюр-Мюрюлиз» пассажы стилендә салынган иде. Яңа пассаж иң кыйммәтле йон-ефәк, алтын-көмеш, өс-баш, аяк киемнәре, ашау-эчү, хуҗалык товарлары, хәтта керосин, дегет кебек нәрсәләр белән сәүдә итә башлады. Кыскасы, бу магазинда, башка кибетләргә кермичә, ни теләсәң шуны сатып алырга мөмкинлек бар иде. Яушевлар бер бу шәһәрнең бөтен сәүдәсен үз кулларына алып кына канәгатьләнмичә, тирә-якка киң тамыр җәеп җибәрделәр. Пассаж, ваклап сату белән бергә, зур күләмдә күпләп сату эшен дә алып бара, аңа товар алырга ике-өч йөз чакрымнардан киләләр, йөкләр егермешәр-утызар дөягә төялеп озатыла иде.

Пассаж ачылып, Яушевлар үзләренә приказчиклар яллый башлагач, мин дә Бакировлардан шунда күчтем. Чөнки иске хуҗага унбиш сумга хезмәт итүе кыен булды, ул акча ашау белән фатирга түләүдән артмый иде. Яушевлар исә миңа утыз сум тәкъдим иттеләр. Ләкин эшләтүләре ике генә түгел, өч өлеш авыр булды.

Казаннан да приказчиклар китертелде. Шулар арасында Мөхәммәт Вәлишин, Шакир Мәүлүтовлар да бар иде.

Троицк яшьләре белән аралаша башлаган идек инде. Озак та үтмәде, Казаннан килгән егетләрне дә үзебезгә тартып, драма түгәрәге оештырдык һәм спектакль куярга әзерләнә башладык. Ләкин бу шәһәрдә спектакль кую тагын да авыррак эш булып чыкты. Бирегә дини карашлар гадәттән тыш көчле иде. Яушевларның өлкәннәре ишанга кул биргән мөрит тә булгач, приказчикларның күбесе безнең түгәрәккә якын килергә шүрлиләр иде. Хатын-кызларны әйткән дә юк инде, ирләрдән дә түгәрәккә йөрүчеләр аз булды.

Без Г. Камалның «Беренче театр»ын сәхнәгә куярга әзерләндек. Скрипкада, мандолинада уйнаучылар, җырлый, шигырь сөйли белүчеләр дә табылды. Үзебезчә, ярыйсы гына концерт булырга тиеш иде. Ләкин рөхсәт алыр вакыт җиткәч, эшебез тагын комга терәлде. Полицмейстерга рөхсәт сорап баргач, ул шәһәрдәге муллалардан һәм кайбер байлардан ризалык юк, алар каршы киләләр дип, рөхсәт бирмәде. Без башлаган эшебезне туктатмас өчен башка юллар эзләдек. Казан, Уфа кебек шәһәрләрдә мондый кичәләрне җәмгыяте хәйрия файдасына уздыралар дип ишеткәләгән идек. Без дә Троицкидагы шундый «җәмгыятькә» мөрәҗәгать итеп карадык. Кайда ул! «Сезнең гөнаһлы эштән җыйналган акчаларыгызга безнең җәмгыять мохтаҗ түгел» дип, якын да җибәрмәделәр.

Көннәрнең берендә, бәхеткә каршы, Чикризов дигән приставны, урамда барган вакытында, атып үтерделәр. Аның 4—5 кешелек семьясы файдасына шәһәрдә игәнә

жыюлар китте. Рус театрында да, шул семья файдасына дип, бер кичә үткәрделәр. Без дә моны күреп, тукта әле бу хәлдән файдаланып калыйк дип, полицмейстерга бардык. Без дә шундый кичә үткәрмәкче идек дигәч, «Вот, молодцы!» дип, озак уйлап тормыйча, афиша һәм программаларыбызга «разрешаю» язып, кул куеп, печатен сугып җибәрде. Шуннан шәһәрдә гауга күтәрелде. Мулла-мунтагай койрыклары афишаларыбызны ерткалап йөри башладылар. Ләкин бу эшләр килемгә зыян китермәде, чөнки билетларны, магазиннар һәм йортлар саен кереп, городовойлар үзләре сатып йөрде. Шуннан соң, театр карарга баручыларны, шулай ук уйнаучыларны кыйнарга кирәк дигән сүзләр таралды. Бу сүзләрне игътибарга алып, театр эчендә һәм тышкы якларында полиция кешеләре куелды. Ниһаять, шушы шартларда, декабрь аенда мәшһүр Зәйнулла ишан хәзрәт тора торган Троицк шәһәрендә беренче мәртәбә татар театры уйналды. «Беренче театр» әсәрендә Вәли ролендә мин, Вәлинең хатыны Гафифә ролендә Миннулла Мөхәммәтҗанов, Хәбибрахман ролендә Мөхәммәт Вәлишин, Фатих ролендә Габдулла Юсупов, Хәмзә бай ролендә Ибраһим Шагдалиев уйнадылар. Концерт бүлегендә 7—8 кеше катнашты.

Гомумән, кичә матур үтте. Халык та күп килгән иде. Городской театр бинасы шыгрым тулы булды. Бай хатыннары пешереп китергән паштетлар, чәкчәкләр белән тулган буфет та бар иде. Буфетның сәүдәсе дә шәп булды, акча күп җыелды. Шулай итеп спектакль куеп, теләгебезне үтәдек. Әмма ахыры бар бит әле, исәп-хисабын ничек эшләргә? Килемнең барысын илтеп бирү әрәм тоелды. Шуннан, үзара сөйләштек тә, түгәрәккә париклар, берничә төрле сәхнә киемнәре тектереп, шулай ук, 3—4 мандолина алып, боларның барысына да счетлар яздырып, һәм аларны кичәнең расходына кертеп, шуннан калганын полицмейстерга илтеп бирдек. Ул тикшереп-нитеп тормады, канцеляриягә тапшырыгыз, диде. Кыскасы, бүре дә тук, сарык та исән калды.

Беркадәр вакыт узгач, Пермьнан Салих Айманов белән Шиһап Баһаветдиновлар җәмәгатьләре белән килеп төштеләр. Тагын Казаннан да берничә егет килде, безнең түгәрәк зураеп китте. «Казанга сәяхәт» белән Галиәсгар Камалның ике пәрдәлек «Кайниш» дигән әсәрен әзерли башладык. Берәздән «Бәхетсез егет»нең ирләр генә катнаша торган бер пәрдәсен уйнадык һәм концерт бирдек.

Шушы вакытларда Троицк шәһәрендә беренче мәртәбә егерме кешедән торган татар кыллы оркестры төзелде. Моның җитәкчесе Салих Айманов иде. Мин дә бу

1910 елда Троицк шәһәрендә төзелгән беренче татар кыллы оркестры.

оркестрда контрабаста уйный башладым. Шулай итеп, безнең «Милли музыка һәм драма түгәрәге» ай саен диярлек спектакльләр куя һәм әдәбият-музыка кичәләре үткәрә башлады. Бу кичәләрнең берсендә Троицкида атаклы саналган гармоньчы, җырчы Мирфәез Бабаҗанов та катнашты.

Бу кешене мин моңарчы күргәнем юк, бары тик граммофон пластинкаларыннан гына ишетеп белә идем. Ул уртача гына буйлы, шактый симез һәм азрак корсагы да чыгып торган, хатын-кызларныкы төсле нечкә тавышлы бер кеше икән. Шундый юан кешенең нечкә тавыш белән сөйләшүе, бигрәк тә, чирелдәп җырлавы бик кызык иде. Ул үзе саф татарча киенә, читек-кәвештән йөри, намазын калдырмый иде.

Шушы елларда Пермьда калган иптәшләрем белән хатлар алыша идем. Бу хатларның берсендә 1910 елның җәендә шәһәребезгә «Сәйяр» труппасы килүе һәм өч спектакль куеп китүе турында хәбәр иттеләр. «Хуҗа һәм приказчик» пьесасында, дустым Шакир Вахитов (Шамилский) асрау кыз ролендә беренче мәртәбә сәхнәгә чыккан. Мин моны ишетеп бик шатландым һәм тәбрикләп хат яздым. Әйбәт тавышы белән танылган Фәттах Латыйпов та, приказчиклыгын ташлап, җырчы-артист булып киткән. Моңарчы әле бездә сәхнәдә концерт бирә алырлык җырчыларыбызның булганы юк иде.

1911 елның язында Яушевлар приказчиклар арасында чистарту уздыра башлады. Беркадәр хор фикерле, аң керә башлаган приказчикларның берсен дә калдырмыйча эштән куып чыгардылар. Абый белән мине дә кудылар.

Берәр ай чамасы эшсез йөргәннең соңында, «Садыйк Яушевларның варислары» исемендә йөртелгән фирмага хезмәткә ялландым. (Болары да шул ук Яушевлар нәселеннән.) Яңа хуҗаларымның уллары Касыйм, Закир минем белән дуслашып киттеләр. Чөнки алар да безнең драмтүгәрәк белән кызыксынучылар, мандолинага өйрәнүчеләр иде. Улларының бу эшен анасы сизеп алгач (аталары үлгән иде), балаларыбыз юлдан чыга икән дип борчыла башлый һәм, элекке хуҗам Муллагали абзыйга барып, безнең өстән зарлана. Муллагали Касыйм белән Закирның опекуны иде.

Көннәрнең берендә Муллагали Яушев безнең кибеткә килеп керде һәм минем анда эшләгәнемне күреп алды да, доверенный Кутузовны чакырып: «Нигә сез без куып чыгарган приказчикларны, бездән рөхсәтсез үзегезгә хезмәткә аласыз? — дип тиргәде һәм: — Хәзер үк чыгарыгыз!» — дип приказ биреп китте. Шулай итеп — янадан расчет. Мина бу шәһәрдә торырга мөмкинлек калмады. Ни күрсәм шуны күрермен дип, Пермьга кайтып киттем.

Сәхнә осталары белән очрашулар

Ике ел аерылып торганнан соң, 1911 елның җәендә туган шәһәргә кайтып төштем. Берәр ай чамасы эшсез йөргәннән соң, Гәрәй хаҗи Насыйров дигән байга ялландым.

Көз көне приказчиклар җәмгыяте тарафыннан клуб ачылды. Мин дә, шул җәмгыятьнең члены булганлыктан, клубның активына әйләнеп киттем. Бу вакытта Пермьда иске иптәшләрдән Хәйретдин белән Нуретдин Хәнҗәровлар, Фатыйх Юсупов, Әхәт Вәлиев, Насыйбулла Чикин һәм Шакир Шамилскийлар бар иде. Шулар белән спектакль куярга җыелып йөргән вакытта, Фәттах Латыйпов белән Мохтар Мутин гастрольләре килеп төштеләр. Без боларның концертларын оештыру өчен көн-төн чаптык. Халык шактый җыелды, концерт күңелле узды. Фәттах Латыйпов үзенең моңлы җырлары белән халыкның күңелен яулады. Үз җырчысын күптән зарыгып көткән халык Латыйповны кат-кат сәхнәгә чыгарып алкышлады. Мохтар Мутинның репертуарында Габдулла Тукай, Сәгыйть Рәмиев шигырьләре иде. Мутинның мәһабәт тавышы, романтикага бирелеп, әчке тойгы белән сөйләве халыкка бик ошады.

Икенче атнаны Фәттах Латыйпов һәм Мутин катнашында бер спектакль куелды. Баш рольләрдә Мохтар Мутин белән Фәттах Латыйпов уйнадылар. Без, драма түгәрәге членнары, кечерәк рольләрне башкардык. Бу спектакльдән юллык акча җыеп алынгач, алар Кунгур шәһәренә китеп бардылар.

Озак та үтми, Пермьга Мәрьям Искәндәрева дигән җырчы хатын килеп төште. Без бу нечкә тавышлы хатынның тавышын граммофон тәлинкәләреннән ишетеп белә идек. Үзен күргәнебез юк иде. Төшкән номерына барып, таныштык, сөйләштек.

— Сез инде, чибәр егетләр, беренче җырчы Мәрьям апагызны ким-хур итмәгез. Концертны оештыруда булышыгыз. Минем администраторым да юк, арагызда берәр булдыклырак егетегез булса, үзем белән алып китәр идем! — диган булып, кашларын сикерткәләде. Мондый кыланышлары бик үк кәефкә ошамаса да, нишләмәк кирәк? Чибәр апаның 30—40 афишасын алып, билетларын да сата башладык..

Ф. М. Латыповъ
къ предстоящему КОНЦЕРТУ.

Гаҗәп хәл — кибет хуҗаларына билетлар тәкъдим итеп йөргәндә, башка вакытта безнең спектакльләргә аяк та басмаган Мортаза хаҗи Тимкин, мине күреп алды да: «Кая әле, егет, Мәрьям туташ концертына миңа алданрак урыннардан ике билет бир әле», дип, акчасын чыгарып салмасынмы! Приказчикларын да: «Барыгыз, барыгыз, шәп җырлый ул», дип димли башлады. Мин бу хәлгә шаккаттым, ни дияргә дә белмәдем. Кичен клубка бардык. Ләкин халык күп түгел. шуның өстенә, бик чуар, башка вакытларда театрларга аяк та басмаган карт байлар һәм аларның доверенныйлары гына күренә иде. Билет аз сатылганлыктан, Мәрьям туташ концертны башламаска кирәк дип кыбырсынып маташты. Халык исеменнән диган булып, бер-ике бай кереп үтенгәч, концертын башлады. Беренче бүлектә бары тик җырлар гына булды. Программасының дәвамы да егерме минуттан артмады. Антракт вакытында Агафуровларның доверенные Закир Козлов поднос тотып сәхнәгә менде дә сөйли башлады:

— Җәмәгать, шәһәребезгә беренче мәртәбә безне ихтирам итеп, милли җырчыларыбыздан Мәрьям туташ Искәндәрева килгән, без аны яхшы итеп каршы алырга, шулай ук, рәхмәтләр әйтеп озатырга тиешбез. Ләкин, тәэссефкә каршы, халкыбыз аз килгән, бүгенге кичәдән җыелган акча Мәрьям туташның расходын капламый. Шуның өчен дә без, хәлебездән килгәнчә, аны бу кыенлыктан коткарырга тиешбез. Менә, башлап могътәбәр байларыбыздан Мортаза хаҗи Тимкин әфәнде егерме биш сум, үзем ун сум бирәм,— дип, подноска акчалар чыгарып салды. Һәм шуннан тагын биш-алты кеше унар сум, бишәр сум акча салдылар.

Концертның икенче бүлеге башланды. Бу бүлектә биюләр булырга тиеш иде. Башта татарча, аннан үзбәкчә биеде. Русча да биеп күрсәткән булды. Ахырда «Корсак биюе» диган бер кыланышны үтәргә чыкты. Биюченең кыяфәте әдәпсезлекнең чигенә җитә язып киткән иде, аның мондый кыяфәтен күргәч, залдагы хатын-кызлар төкереп чыгып ук киттеләр. Ирләр исә шаркылдап көлешергә тотындылар. Ә теге иң алдагы рәттә утырган хаҗи әфәнделәр, күзлекләрен төзәтә-төзәтә, кәефләнеп кул чабачаба, Мәрьям туташны өч-дүрт мәртәбә чыгардылар. Мондый хәлне күргәч, хаҗи абыйларның тырыша-тырыша «милли җырчыбыз» диган булып ярдәм җыеп бирүләре-

Әптери ролендә Л. Аитов.

нең серенә төшендек. Ул хатын Мәкаржә, Эрбет ярминкәләрендә хажиларга, байларга таныш булган шансонетка Мәрьям туташ икән!

1912 елның башында Фәттах Латыйпов янадан Пермьга килеп, минем янда, апаларда, квартирда торды. Җыелышып «Уйнаш»ны сәхнәгә куйдык. Хатын-кызларны сәхнәгә тарту мәсьәләсе һаман да кыен иде әле, шулай да, күп кыстый торгач, Бәхрелхәят апаны Сәрбиҗамал ролен уйнарга күндердек. Ике атна репетиция ясагач, спектакль яхшы узды. Әхмәтҗанны Латыйпов, Могъләифә карчыкны Мәрьям Вәлиева, Әптери ролен үзем, Әнвәр бай ролен Әхәт Вәлиев, маклер Фәтхерахманны Насыйбулла Чикин уйнады. Бу спектакльгә Нуретдин Хәнҗәров белән Шакир Шамилский гына катнаша алмады. Алар рус театрындагы Пельцер фамилияле артистка сәхнә техникасы буенча кичке дәрескә йөриләр иде.

Шуннан берничә көн уткәч, Фәттах Латыйпов: «Казанга Волжская янына барам, аннан Уфага яна татар труппасы төзү хакында сөйләшергә китәм, әгәр арагызда безгә кушылырга теләүчеләр булса, рәхим итегез, мин телеграмма җибәрермен», дип, саубуллашты да китеп барды.

Яз көне Пермьга гастрольгә татар халкының тагын икенче җырчысы Камил Мотыйгый килеп чыкты. Таныштык, сөйләшеп утырдык. Моңарчы без аны да граммофон пластинкаларыннан гына ишетеп белә идек, үзен күргәнебез юк иде. Без, гадәттәгечә, аның концертын оештыру эшенә керештек. Ләкин Мотыйгыйның халык җыю һәм реклама мәсьәләсе үзенә бер төрле формада булып чыкты. Концерт җомга көн булырга тиеш иде, ул шушы көнне мәчеткә бара да намаз бетүгә бик шәплэп, кычкырып корьән укып җибәрә. Мәчеттәге халык шаккатып кала. Утырган җиреннән сузыла-сузыла бу хәйран хәлне күзәтә башлыйлар. Чөнки моңарчы мондый мәһабәт тавышлы корьән укучының Пермь мәчетендә ишетелгәне юк икән. Соңыннан мәчет алдында аның чыкканын көтеп торалар, ул урамга чыккач, бер-берсеннән, бу кем дә, бу кем, дип сораштыра башлыйлар. Шулай итеп шәһәргә Камил Мотыйгый килүе турында хәбәр таралды. Аның җырлавы белән кызыксыну бердән көчәеп китте һәм билетлар да яхшы гына сатыла башлады.

Кичәгә халык шактый күп җыелган иде, концерт та бик уңышлы үтте.

Баритон тавышлы икән, күбрәк кыска көйләр җырлады, озын көйләр ни өчендер бик аз булды.

Май ае житте. Уфадан, Фәттах Латыйповтан, телеграмма килеп төште. «Волжская Уфага килде, труппа төзибез, килегез», дип язган. Бу телеграмманы алу белән Нуретдин Хәнҗәров, Шакир Шамилский, Фатыйх Юсупов — өчәүләп Уфага киттеләр. Шул айда Уфада «Нур» труппасы төзелә. Мин дә бу иптәшләр белән китәргә тиеш идем, ләкин көзгә солдатка караласым булгач, китә алмадым. Ул вакыттагы закон буенча, һәр кеше үзенең атасы туган авылга барып каралырга тиеш булганлыктан, миңа Әгерҗегә кайтырга кирәк иде.

Бу хәлдән соң бер ун көн вакыт үткәч, Казаннан гастрольгә «Сәйяр» труппасы килеп төште. Труппаның администраторы Әхмәт Кулалаев, режиссер Вәлиулла Мортазин, артистлар — Барый Болгарский, Зәки Баязитский, Габдрахман Мангушов, суфлер Касыйм Шамил, һәм яшь артисткалардан Гөлсем Болгарская белән Мәрфуга Иманская иделәр. Кариев Казанда авырып калган, килә алмаган иде.

Гайни ролендә С. Волжская

Шуннан «Сәйяр» труппасы спектакльләрен оештыру эшенә керештек.

Беренче спектакльгә Ярулла Вәли әсәре — «Ачлык кушты» драмасы куелды. Әсәрнен Пермьда беренче тапкыр куелуы сәбәпле, кызыксыну зур булды. Икенче спектакль Галиәсгар Камалның «Банкрот»ы булды. Сиражи бай ролен Кулалаев уйнады. Хатыннар ролендә уйнаучы артистлардан: Барый Болгарский белән Зәки Баязитский Пермь халкын хәйран калдырдылар. Тамыр кайнатучы карчык ролендә Зәки Баязитскийның уены бигрәк тә онытылмаслык булып истә калды.

Өченче спектакльдә Мортазинның русчадан татарчалаштырган комедиясе «Качкыннар» һәм «Кайнанай өйдә булса, эшнең асты өскә килә» куелды. Труппаның ике артисткасыннан берсе — Гөлсем Болгарская «Ачлык кушты», «Банкрот» спектакльләрендә халыкка бик ошады. Гомумән, труппаның гастрольләре бөтен яктан уңышлы булып үтте. Артистлар үзләре дә бик канәгать булып, рәхмәтләрен әйтеп, Чиләбе шәһәренә киттеләр. Аннан, Троицкига барабыз, диделәр.

Берничә көннән соң Мортазин-Иманский Троицкидан миңа шушындый хат салды: «Мөхтәрәм Локман әфәнде, җанәбегезгә чук сәлам. Үземез саг-сәламәт Троицкига килеп җиттек... Чиләбедә сезне белгән кешеләр бик күп икән. Ике мәртәбә уйнап, яхшы гына сборлар алдык. Чиләбегә Кариев та килеп җитте. Бергә-бергә «Шәһәр серләре»н куйдык, яхшы чыкты... Хат язгыыз, ни хәбәрләр бар, кайтканда, бәлки, Пермьга тиярбез. Язучы Мортазиннар. 1912 ел, 30 май».

Июль аеның ахырларында «Нур» труппасы гастрольгә килеп чыкты. Мин аларның килүләрен ишетеп, шунда ук яннарына ашыктым, барысын да сагынган идем. Барыбыз да Сәхипҗамал Волжскаяны татар дөньясында тагын бер яңа труппа төзүе белән тәбрик иттек. Озак кына сөйләшеп утырдык. Макаржәдә очратканнан соң минем аны күргәнем юк иде. Труппада үзем белән бергә үскән иптәшләр дә булгач, алар миңа туганнарым шикелле тоелды. Без барыбыз да бу яңа труппаны оештыручы, ана житәкчелек итүче беренче татар кызына кулыбыздан килгән ярдәмнәрне күрсәтергә тырыштык. Мин труппаның эшләренә бөтен көчемне салырга, аларга һәрьяклап булышырга тырыштым. Һәр спектакльдә катнашып уйнау өстенә, оештыру эшләренә дә якыннан торып булыштым. Составларында уники кеше: Сәхипҗамал Волжская, Фәхернисә Сәмитова, Фатыйма Дулатова, Лиза Сыртланова, ирләрдән — Шакир Шамильский, Гыйлаҗ Казанский, Нурый Сакаев, Фәттах Латыйпов, Нуретдин Хәнҗәров, Фатыйх Юсупов, Мөхтар Мутин һәм Тукумбитов иде. Беренче спектакль шәһәр театрында булып, Вәзирзадәнең «Мөсибәте Фәхретдин» драмасы куелды.

Аннары Галиәсгар Камалның «Бәхетсез егет»е зур әзерлек белән куелды. Бу спектакльдә Волжская бер-берсенә капма-каршы булган ике образны — Гайни белән гимназистка Гайшә ролен гәүдәләндерде. Залда утыручыларның берсе дә ике рольне бер үк артистка башкара дип уена да китермәде. Хәтта соңыннан миннән: «Гимназистка ролен нинди кыз уйнады? Аларның артисткалары дүртәү генә бит, бу бишенчесе кем соң?» дип, үз туганнарым да сораштырды.

Оренбургта

Солдаттан котылгач, артист булырга хыялланып йөрүче Заки Тайсин дигән егет белән уйлаштык та, байларыбыздан расчет алып, Оренбург шәһәренә китеп бардык. Анда без «Нур» труппасы белән очрашырга тиеш идек. Һәм шулай булып чыкты да.

Оренбургка килеп, берәр ай эшләүгә, зарыгып көткән «Нур» труппасы килде. алар кышны биредә уздырырга булдылар. Труппа моңарчы Урал шахталарында, Себер алтын прискаларында эшләүче татар эшчеләренә хезмәт күрсәткән, Урта Азия шәһәрләрендә, шулай ук Уфада берничә тапкыр булып узган. Бу юлы труппаның составы да үзгәрә төшкән. Латыйпов белән Мутин труппадан киткәннәр. Тукумбитов авырып больницага кергән.

Оренбург яшьләреннән: Исхак Әлмәшев, Мәхмүт Тупикский, Нургали Якупов, Әхәт Хисамов, Шаһибәк Сакаев һәм Мамсинскийлар да труппага алынды. Коллектив шулай зураеп китте.

1913 елның октябрь аенда шәһәр театры бинасында әзербәйҗанчадан тәрҗемә — «Мөсибәте Фәхретдин» әсәре сәхнәгә куелып, сезон ачылды. Оренбург халкы «Нур» труппасын алкышлап каршылады. Икенче спектакль — Сәгыйть Рәмиевнең «Яшә, Зөбәйдә, яшим мин!» драмасы булды. Бу спектакльдә Сөләйман ролен Шакир Шамилский, Зөбәйдә ролен Сәхипҗамал Волжская башкарып, тамашачыларда тирән тәэсир калдырдылар. Динмөхәммәт мулла ролендә уйнаган Касыйм Шамилне дә халык яратып каршылады. Без дә яңа артистның тууын шушы көнне күрдек. Барыбыз да, уен беткәч, сәхнә артына кереп, аның кулын кысып тәбрик иттек.

Бу кышта «Нур» труппасы материаль яктан да, иҗади яктан да бик ныгыды. Труппа Европа классиклары әсәрләрен кую турында уйлана башлады. Уйланып кына калмыйча, Шиллерның «Мәкер һәм мәхәббәт» трагедиясен куярга әзерлек алып барылды. Оренбургтагы рус труппасы ярдәмендә махсус киемнәр, париклар булдырылды. Баш рольләрдән: Луизаны — С. Волжская, Фердинантны — Ш. Шамилский, Президентны — И. Әлмәшев һәм Вуромны — Гыйләҗ Казанскийлар башкардылар. Мин Гоф маршал ролендә чыктым. Волжская, Шамилский, Казанский, Әлмәшев, Касыйм Шамил үз рольләрендә зур осталык күрсәттеләр. Пәрдә төшкән саен, артистларны кат-кат сәхнәгә чакырдылар, чәчәк бәйләмнәре бүләк иттеләр. Бу спектакль, халык соравы буенча, сезонда берничә тапкыр куелды.

Халык каршында труппаның авторитеты бик нык күтәрелде, тамашачылар атна саен спектакль куюны, яңа әсәрләр күрсәтүне сорый башлады, ләкин сәхнә әсәрләре житешми иде. Үзебез рус әсәрләрен тәрҗемә иткәләдек. Яз якынлаша башлады. Көннәрдән бер көнне, труппабызның житәкчесе Сәхипҗамал Гыйззәтуллина-Волжскаяның бенефисен үткәрергә уйладык. «Җинел хезмәттә» исемендәге драманы (бусы басылып чыккан китап, русчадан эшләнгән, авторын хәтерләмим) сәхнәгә куйдык.

Өченче пәрдәдән соң, юбилярны котлаулар булды. Аңа бик күп бүләкләр тапшырдылар, сәхнә чәчәкләр белән тулды. Халык үзенең беренче артисткасын әнә шулай хөрмәтләде, тәбрик итте.

Март ае ахырларында Таждаровның «Яшь хатын» драмасы куелды һәм Галиәсгар Камалның «Банкрот» комедиясе белән сезон ябылды. Сиражи бай ролен Касыйм Шамил башкарып, үзенең талантлы артист булуын янадан бер кат раслады.

Труппаның алты ай буенча бер шәһәрдә торып, атна саен спектакль куеп чыга алуы «Нур» труппасының яшәү гомерендә беренче күренгән зур һәм шатлыклы факт иде. Моңарчы труппа бер шәһәрдә биш-алты спектакль күрсәтүдән уза алмый, икенче шәһәргә китәргә мәжбүр була торган иде. Чөнки ул заманнарда халыкны театрга тарту, иялäштерү кыен эшләрнең берсе иде. Ул заманда татар артисты ачлыкка да, поезд, пароходларда билетсыз йөрүләргә дә, барысына да түзде. Әмма иң кыены халыкны театрга тарту иде. «Нур» труппасы Оренбургта бу авырлыкны беренче мәртәбә жиңеп чыкты. Ул вакытта яшь булган Шәриф Камал, Мирхәйдәр Фәйзи кебек Оренбург язучылары да, театр эше белән кызыксынып, үзләренең шактый ярдәмнәрен күрсәттеләр.

Труппаның бер урында эшли алуы артистларга сәхнә белемнәрен арттырырга да мөмкинлек тудырды. Без Оренбургтагы рус театры постановкаларына йөри башла-

дык. Җитәкчебез Сәхипҗамал Волжская рус театрында йөрүне, аларның эшләре белән танышу, өйрәнүне көндәлек бурычыбыз итеп куйды. Оренбург рус театрындагы атаклы Малиновская труппасының Разумный, Мичурин кебек сәхнә осталарының яшь татар артистларына зур ярдәмнәре тиде. Рус театрында татар артистлары өчен аерым ложа да калдырылгач, һәр яңа әсәр карап барыла һәм икенче көнне каралган спектакль күмәк рәвештә тикшерелә иде. Мондый иҗади фикер алышулар яшь талантлар өчен зур мәктәп ролен үтәде.

«Нур» труппасы апрель башында, тугыз кешелек состав белән, Идел буйларына, Урал, Себер якларына гастрольгә чыгып китте.

Труппаның гастрольгә чыгып киткән көннәрендә беркадәр боегып калган идек. Ләкин бу хәл озакка бармады. Ярым приказчик, ярым артист кына булсак та, нурлы сәхнә безгә туган өебездән дә якынрак иде, без аннан берничек тә аерыла алмадык. Бакчадагы агачлар яфрак ярып чәчәк ата башлау белән, без дә баш калкыттык. Галиәсгар Камалның «Беренче театр»ын куеп җибәрдек, «Булэк өчен»не халыкка бүләк иттек, «Казанга сәяхәт» һәм башка комедияләрне дә сәхнәгә менгердек. Әхәт Хисамов кебек көр тавышлы, кин күкрәкле егетләребез җыр партиясен алып барды, биюче кызларыбыз биеде, уенчыларыбыз гармонь тартты, мандолина чиртте, скрипка сызды! Оренбург сәхнәсе тагы нурланып, тагы балкып китте. Без киләсе кышта янадан әйләнеп кайтасы «Нур»ны, тагын да ныгып, тагын да остарып, җитлегеп каршыларга тиеш идек. Турысын әйтергә кирәк: Оренбург тамашачысы инде театр күрмичә яши алмый иде. Халык бездән янадан яңаны сорады, без сөенә-сөенә барлык сәләтебезне, яшьлек дәртебезне биреп сәхнәгә үрмәләдек.

Укучыда шундый фикер тууы да мөмкин: «Нур» труппасы гастрольгә чыгып китә, ә труппаның спектакльләрендә катнашып йөргән егетләр-кызлар, шулар арасында Локман Аитов үзе, ни өчен соң Оренбургта кала, ни өчен артистларга ияреп китми? Бик китәсе иде дә бит... Ул замандагы театр труппаларының андый мөмкинлеге юк иде. Ул заманда Петроградта һәм Мәскәүдә генә зур театрларның артистлары гына хезмәт хакы белән тәэмин ителә иде. Хәтта рус театрларының да күбесе хөкүмәт карамагында булмыйча, артистлар аерым хуҗаларга — антрепренерга, анда да әле, ел буена түгел, бер сезонга, берничә айга гына ялланып хезмәт итә иделәр. Татар артистлары исә, үз көннәрен үзләре күреп, күпме билет сатылса, шуңа тукланып яши иделәр. Аларның берниндн гарантияле хезмәт хаклары юк иде. Спектакльдән җыелган акча, иң элек, театр бинасы өчен, вакытлы файдалануга алып торылган костюмнар өчен, кыскасы, иге-чиге булмаган оештыру расходларын каплауга тотыла, шуннан артканын гына (әгәр артса) артистлар арасында маркаларга карап бүленә. Маркалар дигәне шул: артистка, нинди дәрәҗәдәге артист булганлыгына карап, биш, җиде, сигез, хәтта ун марка билгеләнә. Бу югары бәяле маркалар труппаның төп, даими артист-артисткаларына түләнсә, гастрольләрдә катнашмаучы, бер шәһәрдә генә яшәүче ярым профессиональ артистларга бу бәянең 30—40 проценты гына түләнә иде. Керем-чыгымнарны да капларлык булмаган чакларда, артистлар буш кул белән кала иде. Мондый авыр көннәрдә артист бил каешын тарттырыбрак буарга, яки артык әйберен, кием-салымын ламбардка салырга мәҗбүр иде. Закладка салынган әйберен, түләп алырга акча булмагач, бик аз бәягә югалып калган чаклары да еш була иде. Мисал өчен, Сәхипҗамал Волжскаяның бер хатыннан өзек китерик:

«Лукаш![1] Сезгә бер пот сәлам. Без хәзер Петропавелга киттек. Миңа довостребование хат языгыз, җәмс! Шәрәфигә әйтегез, ламбардтагы минем нәрсәләрнең проценты түлгән булса, пожалуйста, түләсен. Акча җибәргәндә, икегезнең дә тоткан акчаларыгызны җибәрермен. Шәрәфинең бер дә язганы юк. Бәлкем, минем нәрсәләрнең срогы тулгандыр да. Сез әйтегез инде. Хушыгыз.

Чиләбе, 21 апрель, 1914 нче ел.

Гыйззәтуллина».

Шушындый сәбәпләр аркасында, гастрольләргә баш рольләрдә уйнаучыларны гына алып чыгалар. Алар составы, күбесенчә, сигез-тугыз кешедән артмый. Ә инде

---

[1] Волжскаяның да, «Нур» труппасындагы артист-артисткаларның да мине шулай яратып атау гадәтләре бар иде. Башлап миңа бу исемне яраткан дустым Г. Казанский кушты.

кечкенә рольләр өчен урыннардагы һәвәскәрләрдән файдаланалар. Театр сөюче һәвәскәрләрне, аз булсалар да, һәр шәһәрдә табарга мөмкин иде. Һәвәскәр бу эшкә атлыгып тора, аңа акчаң да, бернәрсәң дә кирәкми, сәхнәгә чыгып бер-ике сүз әйтсә, шул җитә. Мәшһүр «Сәйяр» труппасында да хәлләр шундый иде. Артистлар сәхнәгә һәвәс яшьләрне бик якын итәләр, аларны үстерергә, өйрәтергә һәркайчан әзер торалар, алар арасыннан аеруча талантлыларны үз араларына тарталар иде. Кыскасы, алар үзләренә алмашчылар әзерләү эше белән бик кызыксыналар иде.

Оренбург миңа ошады, мин мануфактурачы Насретдин Тинишевларда приказчик булып эшли идем. Ләкин мин, приказчик булудан бигрәк, киләчәктә чын артист булу өмете белән яшәдем.

1914 елның ахырына таба, сентябрь аенда, зарыгып көткән «Нур» труппасы, гастрольләрдә йөреп, янадан Оренбургка кайтып төште. Состав үзгәрмәгән диярлек, Касыйм Шамил генә Казанга кайтып киткән, аның урынына Сембердә Барый Тарханов кушылган иде. Кайтып керүләре белән Закир Сәетзаданең «Бичара Бибиҗиһан» исемле драмасына репетиция башладылар. Безнең түгәрәктән дә җиде-сигез кешегә рольләр эләкте. Күп тә үтмәде, шәһәр театры бинасында труппаның кышкы сезоны башланды. Билетлар әллә ничә көн алдан сатылып бетте.

Бу спектакльдә Бибиҗиһан ролендә Сәхипҗамал Волжская, студент Мәхмүт ролендә Шакир Шамилский зур уңыш казандылар. Пәрдәне кабат-кабат ачтырып алкышладылар, сәхнә чәчәкләргә күмелде.

Икенче атнада Г. Камалның «Уйнаш» драмасы белән «Беренче театр» комедиясе куелды. Алданган татар хатыны образын Волжская тагын да камилләштергән иде, аның уены онытылмаслык тәэсир калдырды. «Беренче театр»дагы Хәмзә бай ролен Оренбург халкы өчен яңа артист — Барый Тарханов уйнады. Тамашачыларның да, безнең дә мондый «чын» Хәмзә байны сәхнәдә күргәнебез юк иде әле. Шуннан соң Барый Тарханов Г. Камалның «Банкрот», «Бүләк өчен» комедияләрендә Сиражетдин һәм Әхмәтҗан рольләрен башкарып, Оренбург халкының иң яраткан артисты булып китте. «Сәйяр»да минем Сиражетдинны Кулалаев уйнаганын күреп сокланганым бар иде, әмма Барый Тарханов уенын күреп тәмам хәйран калдым. Бу чын мәгънәсендә сәхнә өчен яратылган зур талант иде. Ул сәхнә техникасына бик бай, аңарда һәр фразадан, һәр хәрәкәттән мәгънә тудыра белү сәләте зур иде.

Хәзер инде труппа зуррак, күп көч сорый торган әсәрләрне дә куярга сәләтле иде. Шундый әсәрләрнең берсе Г. Камал тәрҗемә иткән «Хөкемдә хаталык» трагедиясе булды. Моны сәхнәгә куяр өчен рус театрыннан прокатка махсус париклар, костюмнар алынды. Туккән хезмәт бушка китмәде — әсәр тамашачыларга бик ошады һәм берничә кат уйналды.

Адринаны — Волжская, аның атасы Жан Реноны — Шамилский, ялган граф Лазарьны — Гыйлаж Казанский, президентны — Исхак Әлмәшев уйнады.

Аннан соң Г. Камалның «Дәҗҗал» драмасы һәм А. П. Чеховның «Кыз сорау» комедиясе куелды.

Атна саен, хәтта атнага ике тапкыр уйный башлагач, сәхнәгә куярга әсәр табылмый башлады. Коллектив көче белән пьесаларны русчадан татарчалаштырырга керештек. Болар арасында «Мин-минлек корбаны» шикелле әһәмиятле әсәрләр булган кебек, «Бер сәгатьлек хатын» шикелле җиңелчә комедияләр дә очрый иде. Шундый репертуар кытлыгы көннәрендә Мирхәйдәр Фәйзинең «Кызганыч» исемле драмасы дөньяга чыкты. Куйдык. Уңышлы спектакльләрнең берсе булып узды. Мирхәйдәр Фәйзине Оренбург халкы бик яхшы белә һәм аны үзенең якташ язучысы итеп таный иде. Бу әсәрдә Волжская белән Шамилский аеруча күзгә ташланганлыктан — халык пьесаны тора-тора янадан кабатлауны сорады.

Бу елларда Мирхәйдәр Фәйзи Орскида яшәсә дә, труппа белән нык элемтәдә иде. Волжская белән һәрвакыт хатлар язышып тора иде. Ул заманнарда ук инде матур хикәяләре белән халыкка танылган Шәриф Камал да «Нур» труппасын якын күрә, аның бер спектаклен дә калдырмыйча килеп йөри иде. Без аның сәхнә әсәре язарга җыенып йөргәнен дә сизенә идек. Һәм бу шулай булып чыкты да. Бер көнне шулай Волжская номерында җыелышып утырган чакта, Шәриф Камал килеп керде. Аны зур ихтирам белән каршы алдык. Ул сүзсез генә арабызга кереп утырды да: «Мин сезне эшегездән бүлдем, ахры?» дип сорады. Без аның аз сүзле, тыйнак кеше булуын күптән

белә идек. Ләкин ул бу юлы бик дулкынланган иде. Димәк, улниндидер яңалык алып килгән?.. Һәм менә аның теле ачылды.

— Дусларым! — диде ул. — Минем күңелемне бер нәрсә борчый. Сез инде барыгыз да Оренбургтагы атаклы хаҗиның кем икәнен беләсез.

Язучының нәрсә язачагын аңлавыбыз булды, шаркылдап көлеп җибәрдек.

— Менә мин шул хаҗины сәхнәгә чыгарып бастырырга уйлыйм. Сез моңа ничек карыйсыз?..

Без:

— Бик яхшы, бик мәгъкуль! — дип, язучының бу кыю фикерен хупладык.

Бу заманда муллаларга, хаҗиларга каршы сүз күтәрү, аларга каршы чыгу бик җитди мәсьәләләрнең берсе иде. Шәриф Камалның мондый кыюлыгына безнең исебез китте. Чыннан да, комедия кызыклы һәм әһәмиятле булачак иде. Ләкин аны сәхнәгә күтәреп чыгу... Ай-һай, бу бик хәвефле мәсьәлә бит! Әмма артистлар, моны сиздермәгән булып, язучыны дәртләндерергә тырыштылар. Шәриф ага күңеле күтәрелеп, рухланып кайтып китте. Шәриф Камалның «Яңа комедия язам» дип әйтүе — безнең өчен зур өмет, бәхет иде.

Тагын язлар җитте. Галиәсгар абзыйның «Кайниш», «Бүләк өчен» комедияләрен куеп һәм «Бер бүлектә концерт» биреп, кышкы сезонны ябу — саубуллашу кичәсе уздырдык.

«Нур» труппасы ул кышны Оренбургта 25 спектакль куйды, ун меңнән артык тамашачыга хезмәт күрсәтте. Пароход төшкәч тә, яңадан тугыз кешелек состав белән, Идел буйларына, Урал якларына гастрольгә чыгып китте.

Яңа талантның тууы

«Нур» труппасы Оренбургтан киткәч, дөньяның яме калмады. Быелтыр ук герман сугышы башланганлыктан, яшәү кызыксыз, халыкның рухы төшенке иде. Мин дә, артист булырыма ышанып, приказчиклыгымны ташлаган идем. Ләкин мондый кыен елларда нинди труппа безне үзе белән ияртеп йөри алсын? Әлегә сугышка китеп өлгермәгән 7—8 егет белән труппа сыман бер коллектив оештырдык. Нибары ике кызыбыз бар иде. «Өрәкләр» дигән өч пәрдәле комедияне әзерләргә тотынган гына идек, кызларыбызның берсе кияүгә чыгып китте. Инде нишләргә? Пермьга апама хат яздым. Аның буйга җитеп килә торган Рабига исемле кызы бар иде. Ул гимназиянең дүрт классын тәмамларга да өлгергән иде инде. Музыкага өйрәнер, монда яхшы укытучы бар, дигән сылтау белән шул сеңелемне чакыртып алдырдым.

Рабига Оренбургка килгәч, чыннан да, музыкадан дәресләр алырга тотынды. Нәкъ менә шушы вакытларда сеңелем янына русча укырга-язарга өйрәнергә Фатыйма исемле бер кыз килеп йөри башлады. Бу кыз бик юаш, оялчан, бик йончыган кыяфәттә иде. Ул мойкада (йон юа торган җирдә) бик авыр хезмәттә эшли икән. Төскә-биткә дә чибәр генә үзе. Нишләптер, бу кыз артистка була алыр төсле күренде миңа. Мин аңа, очраган саен:

— Фатыйма! Сиңа безнең түгәрәккә керү кирәк. Спектакльләребезгә катнаш, артистка булырсың! — дия идем. Ул исә:

— Һи, миннән нинди артистка чыксын,— дия дә, сүзне икенчегә борып, сеңелкәш белән сөйләшергә тотына иде.

Шулай, көннәрнең берендә, Нардом бинасында «Өрәкләр» пьесасының соңгы репетицияләрен үткәрергә җыенганда, баш рольләрдән Мәрьям ролен уйнарга тиешле кызыбыздан: «Уйный алмыйм, мине читкә җибәрәләр», дигән записка алдык. Репетициябез туктады, аптырашта калдык. Мин бик тә каушадым, нишләргә дә белмәдем. Чөнки коллектив каршында да, халык каршында да бөтен җаваплылык миндә. Түгәрәкнең җитәкчесе булу өстенә, бу спектакльнең режиссеры да мин идем.

Афишалар ябыштырылган, билетлар сатылган, иртәгә спектакль куелырга тиешле. Шушы хәлдә нишләргә белмичә йөдәп, ачык тәрәзә янында уйланып басып торганда, ни күзем белән күрим, әлеге Фатыйма узып бара! Мин аны күрү белән, яшен шикелле урамга атылып чыктым да: «Туктагыз-туктагыз!» дип кызның артыннан кычкыра-кычкыра чаптым. Фатыйма туктады. Мин аңардан безгә ярдәм итүен сорый башладым.

Иртәгә буласы спектакльне өзмәс өчен бер роль уйнавын. Нардомга кереп, репетиция ясавын зинһарлап үтенә башладым. Кыз уйга калды:

— Булдырып булмас, мин бик куркам,— диде ул.

Мин тагын ялынып:

— Зинһар инде, халык өчен сорыйбыз! Бер дә курыкма. Хәзер Нардомда репетиция ясарбыз да, тагын безнең өйдә кабатларбыз. Менә шулай өйрәнерсен, уйнап чыкканынны үзең дә сизми калырсың. Әйдә, тәвәккәллә бер! — дигәч, ул бераз икеләнеп торды да:

— Ярый инде, алай бик кирәк булгач, тәвәккәлләп карыйм,— дип, минем белән Нардомга керде.

Мин өметсезлектә утырган иптәшләргә:

— Әйдәгез, егетләр! Репетицияне башлыйбыз! Эш төзәлде. Артистка табылды. Таныш булыгыз, Фатыйма туташ! — дип, аны коллективка тәкъдим иттем. Репетиция башладык.

Иң алдан Фатыймага ул башкарачак Мәрьям образының кем булуы турында сөйләп бирдек. Пьесаны баштанаяк кабатладык. Менә шушы кыска гына бер-ике сәгать вакыт эчендә дә Фатыймадагы зирәклек яхшы ук күренә башлады. Аның Мәрьям образына керә башлавы, суфлердан сүзләрне бик тиз отып алуы, күрсәтелгән хәрәкәтләрне онытмавы, рольдә үзен иркен тотып, дәрт белән сөйләве, сүзләрнең мәгънәсен тиз аңлавы, барысы, барысы да кызның талантлы артистка булачагына өмет тудырдылар. Шушы рәвешчә ике көн рәттән әзерләнеп, спектакльне куйдык. Спектакль көтелгәннән дә уңышлырак чыкты. Залда утыручыларның күбесе: «Бу нинди кыз сон, кайдан килгән артистка! Моңарчы кайда уйнаган?» дигән сорауларны яудыра башлады. Сәхнә артына кереп тә сораштылар.

Халыкның болай гаҗәпсенүе бик табигый, чөнки Фатыйманы шәһәрдә танучылар бөтенләй диярлек юк иде. Яшькә дә бик яшь иде әле ул. Ә инде аның шулай тиз арада әзерләнеп, яхшы итеп уйнап чыгуы, чыннан да, үзенә күрә бер могҗиза булды. Коллективның да шатлыгы чиксез иде.

Шәриф Камал да Фатыйманы тәбрик итте:

— Моңарчы сәхнәдә күренгәнегез юк иде, кайда уйнаган идегез? — диюенә Фатыйма оялып, читкә борылды. Шуннан мин:

— Шәриф абый! Фатыйма туташның беренче мәртәбә сәхнәгә чыгуы әле,— дигәч, ул бик гаҗәпләнде.

— Яшәгез, яшә, Фатыйма туташ! Татар театрының зур артисткасы булырга тырышыгыз,— диде.

Ике атнадан соң, тагын бер спектакль куйдык. «Игълан бәласе» белән «Кызлар шулай кызык итә» дигән комедия һәм концерт бүлеге булды. Монысында инде минем сеңелем Рабига Галимованы да уйнаттык. Аны Фатыйма белән икәү күндердек. Беренче уңышы белән бик канатланган Фатыймага иптәш кирәк иде. Шулай итеп, алар икесе «Кызлар шулай кызык итә» дигән комедиядә ике кыз ролен башкардылар. Бу спектакль тагын да уңышлырак узды. Бу юлы уннан артык репетиция ясадык, шуның өстенә, әсәрләр дә зур түгел иде. Ике кыз — икесе дә сәхнәдә үзләрен бик иркен тоттылар.

Коллектив кызларга баеды. Авылга киткән укытучы Дәүликанова да кайтып керде. Шуның өстенә, карчыкларны уйнаучы бер егетебез — Нургали Якупов та бар иде. Хәзер инде без өч-дүрт хатын-кыз булган пьесаларны куярга да курыкмый башладык.

Өч хатын-кыз роле булган, өстәвенә, өчесе дә зур рольләрдән торган «Чын мәхәббәт яки кечкенә сугыш» дигән өч пәрдәлек комедия әзерләргә тотындык. Уннан артык репетиция ясап әсәрне сәхнәгә куйдык. Спектакль башыннан ахырына кадәр җанлы үтте. Кызларның өчесе дә, берсеннән-берсе уздырырга тырышып, ярышып уйнадылар. Бу хәл егетләребезгә дә тәэсир итте, алар да бик тырыштылар. Спектакль бетеп, пәрдә төшкәч, уйнаучыларның фамилияләре белән кычкыра башладылар. Залдан: «Ахмерова, Ахмерова!» дигән тавышлар ишетелде.

Без ул вакытта Фатыйма Хуҗасәетовага Ахмерова дигән сәхнә фамилиясе биргән идек. Афиша, программаларда да шулай басып чыгардык.

Бу спектакльдә Фатыйма үзен Оренбург халкына танытты. Моңарчы беркемгә дә билгеле булмаган ярлы эшче кызның даны кинәт күтәрелде, аның хакында шәһәрдә дә сөйли башладылар.

Шушы спектакль буласы көнне генә шәһәребезгә Казаннан артист Вәли Мортазин, иптәше Мәрфуга ханым Иманская белән, килеп төшкән иде. Бу спектакльне алар да карады. Спектакль беткәч, алар, сәхнә артына кереп, барыбызны да тәбрик иттеләр. Мортазин Фатыйма хакында:

— Локман, бу артисткагыз күптән уйныймы? Бик сәләтле кыз икән. Сез аны кайдан таптыгыз? — дип сорады.

— Ул Оренбург кызы, бүген әле аның өченче мәртәбә генә сәхнәгә чыгуы,— дигәч, ул да бик гаҗәпләнде...

Бу әсәргә репетицияләр башланыр алдыннан мин кызларыбызның барысына да:

— Менә, кызлар, өчегезгә өч роль. Өчесе дә зур рольләр, җаваплы рольләр, пьесаның башыннан ахырына кадәр бара торган рольләр. Бу рольләрне мин сезгә сынар өчен бирәм. Кайсыгыз яхшырак уйнап чыкса, шул кызга бүләк бирәбез һәм ул киләчәк спектакльләрдә дә баш рольләрдә генә уйнаячак,— дигән идем.

Күрәсез, ярыш сәхнә эшендә дә уңышлар китерә торган яхшы чара икән.

Сәрвәр ролендә — Фатыйма Хуҗасәетова, аның иптәш кызы Мәэмүнә ролендә — Дәүликанова, Шөгыйлә ролендә — Рабига Галимова уйнадылар. Икенче көнне җыелышып, бу спектакльгә тикшерү ясаган вакытта, кызларның үзләрен бүлмәдән чыгарып торып, кайсысы яхшырак уйнавы турында фикер алыштык. Өчесенең уенына да яхшы бәя бирелде. Өчесе дә тигез, өчесе дә яхшы булып чыкты. Өчесенә дә көмешчедән монограмма яздырып, алтынланган жетон бүләк итәргә карар чыгардык. Шушы карарны игълан иткәч, кызлар шатлыкларыннан нишләргә белмичә, бер-берсе белән кочаклашырга, үбешергә керештеләр. «Болай беребезне дә җәберсетмичә, өчебезне дә тигез күрүегезгә рәхмәт, иптәшләр. Моннан соң да шулай, тырышып, ярышып уйнарга сүз бирәбез»,— диделәр.

Бер-ике көннән соң, коллектив яңарак чыккан пьесаларга цензурадан рөхсәт алырга дип, мине Петроградка җибәрде. Мин, ун пьеса алып, патша тора торган шәһәргә беренче мәртәбә барып төштем. «Драматическая цензура» дигән бүлекне мең төрле бәлаләр аша таптым да анда утыручы Заһит Шефич Шамил дигән кешегә ун китапны тапшырдым. Ул: «Ун көннән соң килерсең», дип алып калды. Ун көннән соң баргач, җиде китапка, шулар эченнән «Тигезсезләр», «Ямьсез тормыш», «Дәһшәтле серләр» һ. б. га, «рөхсәт ителә» дип язылган, печать сугылган иде. Ә инде өч китапка («Кемдә гаеп»— Ф. Нурмави әсәре, «Яшь гомер» — Г. Коләхметов әсәре, «Чын мәхәббәт» — М. Нуриманов әсәре) рөхсәт бирелмәде. Мин: «Боларына ни өчен рөхсәт бирмисез?» — дип сорагач, ул теләр-теләмәс кенә сузып: «Беренчесе дингә, муллаларга тия торган әсәр, калган икесе дә шулай ук...» — дип, кыска гына җавап кайтарды.

Кайткач, Фатих Әмирханның «Тигезсезләр» әсәрен куярга зур әзерлек алып бара башладык. Унбиш репетиция ясап, сәхнәгә куйдык. Спектакль Городской театр сәхнәсендә бик шәп декорацияләр белән уйналды. Спектакльнең режиссеры Мортазин-Иманский булды, ул инде бу әсәрне Казанда, «Сәйяр» труппасында, куеп килгән иде. Шуның өстенә, бик тырышып ясалган репетицияләр, зур сәхнә, матур декорация аркасында спектакль бик тулы, уңышлы булып чыкты. Халык та спектакльгә күп килгән иде. Спектакль беткәч, халык, аягүрә торып, алкышлап, артистларга чәчәк бүләк итте. Спектакльне карарга Шәриф ага Камал да килгән иде. Ул Фатыйманың уенын аеруча мактап торганда, Мортазин килеп Фатыйманың кулын кысты. Мортазин, Шәриф Камал белән миңа карап: «Иптәшләр, бу рольне Казанда, «Сәйяр» труппасында, Нәгыймә Таҗдарова уйнаган иде. Ләкин ул Рокыя образын Фатыйма туташ кадәр үк башкара алмады. Менә бүген мин Фатыйма туташ башкаруында чын Рокыя образын күрергә мөшәррәф булдым», диде. Бу сүзләр комплимент өчен генә әйтелгән сүзләр булдымы — белмим. Таҗдарованың уйнаганын үзем күрмәгәч, бу турыда фикер йөртә алмыйм. Әмма Фатыйманы Рокыя ролендә күргәч: Фатих Әмирхан бу рольне махсус Фатыйма Хуҗасәетова уйнар өчен язган ахры, диясе килде. Чөнки Фатыйма бүген үзенең Фатыймалыгын бөтенләй онытып, «Тигезсезләр»дәге Рокыяның чын үзе булган иде.

Көннәрнең берендә татар сәхнәсенең танылган артисты трагик Мохтар Мутин Оренбургка килеп чыкты. Аның катнашы белән «Ямьсез тормыш» пьесасы белән «Казанга сәяхәт» комедиясе куелды. Баш рольләрдә М. Мутин (Саттар бай), Фатыйма Ахмерова (һаҗәр), Мортазин-Иманский (Мөхәммәт) уйнадылар.

Фатыйма Хуҗасәетова.

Шушы спектакль белән җәйге сезон ябылды. Шул уңай белән «Вакыт» газетасында (1915 ел, сентябрь, № 1873) мәкалә дә басылып чыкты. «Ф. Ахмерова бердәнбергә җәсарәтен арттырып, сәхнә кешесе (артистка) булып килә. Бу туташтан яхшы-яхшы тына уеннар көтәргә ярый», дип язды ул мәкаләдә заманасының танылган журналисты Кәбир Бәкер.

Бу җәйге сезонда уннан артык әсәр уйналды. Аларның һәрберсендә баш хатын-кыз рольләрдә Фатыйма уйнады. Сәхнәгә яңа аяк баскан яшь көч өчен искиткеч зур уңыш иде бу. Чөнки уйналган әсәрләр арасында «Тигезсезләр», «Ямьсез тормыш», «Оят яхут күз яше», «Хуҗа һәм приказчик» кебек төрле жанрдагы зур әсәрләр дә бар иде. Андагы баш рольләр характеры белән берсе икенчесенә капма-каршы торган образлар иде. Ул елларда «Сәйяр», «Нур» труппаларындагы шактый тәҗрибәле профессиональ артистлар арасында да мондый төрле жанрда уйный алучы хатын-кызлар бармак белән генә санарлык иде.

Фатыйманың сәхнә уңышы турындагы хәбәрләр, билгеле, Оренбург җәмәгатьчелеге теленда гена сөйләнеп калмады, Казанга да барып житте.

Габдулла Кариевның чакыруы буенча, Фатыйма 1916 елның көзендә Казанга «Сәйяр» труппасына китте.

Ул Казанга килгәч, «Шәфкать туташы», «Тигезсезләр»дә уйнап, таланты белән тамашачының дикъкатен җәлеп иткән. Шул көннән башлап ул «Сәйяр»ның төп героинясы Фатыйма Ильская булып танылады...

«Ширкәт» труппасы

1915 елның октябрь айларында Казаннан артист Габдрахман Мангушов килеп чыкты. Төркстан ягыннан Госман Садыйков исемле дөнья гизеп йөрүче бер артист килде, һәм берничә көн үтүгә, кышкы сезонга «Нур» труппасы кайтып төште. Ләкин бу кайтуда «Нур» труппасының составы бик нык какшаган иде. Чөнки баш рольләрдә уйнаучы артистлардан: Шакир Шамилский, Исхак Әлмәшев, Барый Тарханов, һәм Нуретдин Хәнҗәровлар солдатка алынганнар иде.

Көннәрнең берендә, «Нур» труппасы артистлары белән Оренбургта булган түгәрәк членнары бергәләшеп, спектакль куярга булдык. Шул ният белән Нурый Сакаев әнисе квартирасына җыйналдык. (Гомумән андый җыелышлар Хлебный переулокта Снегирова йортындагы шул квартирада күбрәк була иде.) Бу мәҗлескә Шәриф Камал да чакырылды. Ул «Хаҗи әфәнде өйләнә» комедиясен язып бетергән икән, шул әсәрне уку оештырдык. Икенче көнне үк репетиция дә башладык. Бу репетициягә Шәриф Камал үзе дә йөрде. Шуннан, рольләр бүлгән вакытта:

«Шәриф абый! Сезнеңчә, «Хаҗи әфәнде» ролен кем уйнарга тиеш?» — дип сорагач, ул: «Анысы инде сезнең эш, үзегез карагыз», дип куйды. Шуннан соң без: «Сезнең фикерне беләсебез килә иде», дигәч, Габдрахман Мангушовка карады да: «Минемчә, менә Хаҗиның нәкъ үзе утыра», дип көлеп җибәрде. Безнең фикер дә шулай иде.

Башка әсәрләрне куйганда, без уннан артык репетиция ясамый идек. Бу әсәр яңа, шуның өстенә, Шәриф Камалның беренче сәхнә әсәре дә булганлыктан, җитмәсә тагы, һәр репетициядә язучы үзе карап утыргач, төзәтмәләр кертеп баргач, без унбиштән артык репетиция ясарга мәҗбүр булдык. Бу спектакльгә билетлар алдан ук сатылып бетте. Шәриф Камалны Оренбург халкы бик тәкъдир итә иде, шуның өстенә, комедия Оренбург тормышыннан алып язылганга күрә, халык бик кызыксынды. Спектакльгә хәтта комедиянең төп прототибы булган Хөсәен хаҗи үзе дә килгән, сигез кешелек ло-

жаны бер үзе сатып алып, чаршау артыннан гына комедияне башыннан ахырынача караган.

Хөсәен хажи, гомумән, башка хажиларга охшамаган, һәр спектакльгә диярлек йөри, Городской театрның иң зур, сигез кешелек ложасын берәүгә дә сатарга кушмый иде. Семьясы янсә танышлары белән кереп утыра, кайбер вакытта үзе генә килә иде. Бөтенләй килми калса да, ложа акчасын түли иде.

Спектакль гаҗәп яхшы, күтәренке рух белән барды. Уен бэрган вакытта ук артистларга сүзләрен әйтергә дә ирек бирмичә шаркылдап көлеп җибәрүләр, кул чабулар күп булды. Пәрдә төшкәч, Шәриф Камал абыйны һәм артистларны сәхнә алдына чыгарып, һавага чөйделәр, чәчәкләр бүләк иттеләр. Шәриф Камалның беренче комедиясе «Хажи әфәнде өйләнә» (беренче варианты) әнә шулай сәхнәгә Оренбургта менде.

Артист Җәлалетдин ролендә (үз образында) — Нурый Сакаев уйнады.

Бу спектакль халыкка гына түгел, Хажи әфәндегең үзенә дә ошаган булса кирәк, чөнки икенче көнне ложа өчен ун сумны алырга конторага баргач, очрады да:

— Әй, Ай эт, монда кил әле! — дип кычкырды (ул минем фамилияне шулай мыскыллап, Аитов диясе урынга, «Ай этеф» диеп йөртә иде).

— Исәнме, Хажи әфәнде? — дип күрешкән булдым. Үзем шүрләп тә куям. Кичәге спектакль өчен кыздырырга чамалый бугай, дип уйлыйм. Шуннан ул көлеп җибәрде дә:

— Шәп-шәп, бик килештергәнсез! Тик мин сезнең ул артистыгызны танымадым. Юкса мин Казанскийны да, Тарханны да, Нурыйны да, сине дә, сакал-мыек ябыштырып чыксагыз да, барыбер тавышыгыздан таныйм. Әмма бу артистыгызны танымадым. Кем соң ул? — дип сорады. Мин Габдрахман Мангушевның «Сәйяр»дан килүен әйтеп бирдем.

— Алай икән, Хажи әфәнде булып уйнарга Казанның үзеннән махсус артист чакырттык дисез икән алайса, ә! Үзегез генә, пожалый, аның чаклы булдыра алмас идегез шул! — диде дә бик канәгать кыяфәттә көлеп җибәрде.

Шушы көннәрдә Мохтар Мутин тагын Оренбургка килеп чыкты. Төрле шәһәрләрдән җыелган артистлар кышкы сезон хакында, ягъни кемнең Оренбургта калуы, кемнең кая китүе турында, сөйләшә башладылар. Бу мәсьәләне хәл итәр өчен барыбыз да җыелдык. Шул җыелышта барыбыз да бергә кушылып эшләргә диган карарга килдек.

Мохтар Мутин труппаны ничек исемләү мәсьәләсен күтәрде. Бу труппада «Сәйяр» артистлары да, «Нур» артистлары да булып, артистлар ширкәте кебегрәк коллектив килеп чыккач, «Ширкәт» исеме кушарга булдык. Өч кешедән төзелгән режиссерлар коллегиясенә Волжская, Мортазин һәм Мутин сайланды. Минс труппаның администраторы итеп билгеләделәр.

Шушы елның ноябрь башларында Оренбург шәһәрендә, унбиш кешелек состав белән, «Ширкәт» труппасы эшли башлады. Зур гына әзерлекләр белән «Саран» комедиясен (төрекчәдән Галиәсгар Камал тәрҗемәсе) сәхнәгә куеп, кышкы сезонны ачып җибәрдек.

Беренче спектакль дә, әсәр дә яңа булгач, шуның өстенә, афишаларда яңа артистларның да исемнәре күренгәч, халык бик тә күп килде. Баш рольләрдән: Саран Хәмит ролендә — Мутин, Сәрвәтбәк ролендә — Гыйлаҗ Казанский, Нәдидә ханым ролендә — Волжская, Мөкаррәм әфәнде ролендә — Мортазин уйнадылар.

Куелган әсәр бик матур һәм күңелле, җиңел комедияләрдән булса да, ничектер сүрәнрәк чыкты. Халык урыны-урыны белән яхшы каршы алды, шулай ук вакыты-вакыты белән залда сүрәнлек тә чагыла иде.

Озак та үтмәде, тагын «Хажи әфәнде өйләнә»не кабатлап куйдык. Ләкин бу юлы беренче куелудагы состав үзгәрә төшкән иде.

Чираттагы спектакльдә «Хуҗа һәм приказчик» комедиясе куелды. Бу әсәр җидесигез ел буена уйналып килгәнлектән, шомарып, яхшырып беткән иде. Шушы рәвешчә атна саен бер спектакль куя-куя, декабрь аеның ахырына килеп җиттек. Ләкин бу сезон ахырына килеп җиту түгел бит әле. Алда эшләр күп булуга карамастан, коллективта бердәмлек кими башлады. Артистлар арасында кайбер ризасызлыклар да күренгәләде. Мәсәлән, спектакльгә катнашып уйнаган артистларга гына акча бирергә кирәк, спектакльләрдә катнашмый кала торган артистлар була икән, аларга бирмәскә кирәк, дигән сүзләр чыга башлады.

Көннәрнең берендә, шулай гадәттәгечә, спектакльнең икенче көнендә отчет ясар-

га, акча буләргә дип җыелган идек. Волжская бер атна чамасы авыру булганлыктан, бу спектакльдә катнашып уйный алмаган иде. Менә шул вакытта, Мутин: «Катнашмаганнарга акча бирмәгез», дип әйтеп ташлады. Мәсьәлә коллектив каршына куелгач, Волжская:

— Миңа бер тиен дә кирәкми, иптәшләр! Миңа сезнең дуслыгыгыз, тату булуыгыз гына кирәк. Татулык булмаган җирдә эшли алмыйм мин! — дип үпкә белдерде.

Сәхипҗамал Гыйззәтуллина безнең труппабызда күз өстендә каш иде. Без аннан аерым яшәүне, аннан аерылуны күз алдыбызга да китерә алмый идек. Иптәшләр белән киңәштек тә, Волжскаяның номерына бардык һәм үзебезнең «Нур» труппасыннан чыгасыбыз килмәүне, труппабызны таратырга теләмәвебезне белдердек. Сәхипҗамал безне чын күңелдән шатланып каршы алды һәм без, әүвәлдәге «Нур» артистлары, труппабызны яңадан тергезеп, гастрольгә чыгып китәргә булдык.

«Нур» труппасы гастрольләре

Труппага берничә яңа кеше өстәп, 1916 елның январь аенда гастрольгә чыгып киттек. Беренче килеп төшкән шәһәребез Актүбә булды. Анда безне Ильяс ага Кудашов-Ашказарский һәм аның хатыны Фәхрия ханым каршы алдылар. Алар бу шәһәрдә һәвәскәрләрне оештырып, сирәк-сирәк кенә булса да, спектакльләр куеп яталар икән. Без бу шәһәрдә алар белән бергәләшеп ике спектакль куйдык та Орскига китәргә булдык. Актүбәдә эшләребез уңмады. Юллык акчаны да көчкә генә юнәттек. Ильяс аганы да үзебез белән барырга чакырган идек, сәламәт булмавы аркасында китә алмады.

Безнең Орскига ашкынуыбызның сәбәбе — Мирхәйдәр Фәйзинең безне анда чакырып язган хаты булды. Актүбә белән Орск арасы йөз илле чакрым — без анда ат яллап бардык. Мирхәйдәр Фәйзи безне номерлар әзерләп каршы алды. Хәтта Орск яшьләре белән очрашу кичәсенә кадәр оештырды.

Бу очрашу мәҗлесе безнең күңелләрдә аеруча тирән эз калдырды. Чөнки без Орск шәһәренә бик зур газаплар белән барып кердек. Беренчедән, январь аеның көчле бураннарында 150 чакрым җирне ат белән, язгы-көзге пальтолардан, аякларыбызда ботинкалардан гына бик каты туңып, өшеп килдек. Икенчедән, юл өчен ямщикларга күп кенә акча түләргә туры килгәнлектән, Орскига җиткәндә беребездә дә бер тиен акча юк, дисәң дә ялган булмас. Хәтта, труппаның администраторы булуыма карамастан, минем кесәдә дә нибарлыгы илле тиен көмеш кенә калган иде.

Менә шушы авыр хәлләрдә катып-туңып килеп, гостиницада бүлмәләргә урнашкач, куанышкан артистлар, арлы-бирле кулларын уа-уа, бүлмә буйлап йөри башладылар. Кайсылары аякларын салып ташлап, мичкә терәлеп утырдылар да:

— Һай, чәй эчеп җибәрәсе иде дә бит... кесәдә сукыр бер тиен дә калмаган! — диештеләр.

— Хәзер, иптәшләр, берәр нәрсә әмәлләп булмасмы,— дип чыгып киттем дә горничныйга самовар куярга куштым. Үзем каршыдагы кибеттән бер кадак колбаса, ярты кадак күмәч, ярты кадак шикәр, биш тиенгә бер пачка бөртек чәй алып номерга кайттым. Әйберләрне өстәлгә таратып җибәргәч, иптәшләрнең авызлары ерылды, бар да өстәл янына җыелдылар. Өстәлгә парлары чыгып торган самовар да килеп утыргач, юл газабы тәмам онытылды.

Нәкъ менә шундый күңел күтәрелгән вакытта, безнең килгәнне ишетеп, Мирхәйдәр Фәйзи килеп керде. Мирхәйдәр Фәйзи бу елларда Орск китапханәсе мөдире иде.

Сәхипҗамал туташ аның белән электән үк таныш булса да, калганнарыбызның аны беренче мәртәбә күрүебез иде. Без тиз генә урындык алып килеп, аның да безнең белән чәйгә утыруын үтендек. Ул:

— Ничек килдегез, дуслар, юлда бик туңмадыгызмы? — дип сорашты башлады. Без исә:

— Татар артисты ул суда батмый, утта янмый, суыкта туңмый! — диган булдык. Ул көлеп җибәрде дә:

— Шулай кирәк, шулай, бирешергә ярамый! — дип хуплагандай итте.

Бераз сөйләшкәннән соң ул:

— Кадерле дуслар, бүген кич сәгать тугызда шушы гостиница ресторанына сезне кунакка чакырырга рөхсәт итегез. Шәһәребезнең яшьләре, сез татар артистларының

Орскига килүе шәрәфенә очрашу мәҗлесе уздырырга булды. Зинһар, безнең чын күңелдән куелган сый-хөрмәтебезне кире какмасагыз иде,— дип белдерде.

Аның гадилеге, кече күңеллелеге безне бик тәэсирләндерде. Без аны беренче күрүдә үк яраттык. Ул безнең күңелләрне, мәхәббәтебезне яулап чыгып китте.

Без өстәлдәге ризыкларны бик тәмләп, валчыгына кадәр ашап бетереп, бушаган самоварны чыгарып бирдек тә бераз ял итеп алган булдык. Соңыннан, хәзинәдә бар киемнәребезне киенеп, мәҗлескә керергә әзерләнә башладык. Сәгать тугыз тулыр-тулмаста бер егет килеп керде.

— Мирхәйдәр абзый сезнең барыгызны да җыеп алып керергә кушты,— диде ул.— Кунаклар бар да җыелып бетте. Сезне көтәләр, әзер булсагыз, әйдәгез!

Көттереп, назландырып тормыйча, барып кердек. Керсәк, исебез китте, чөнки мондый сый-хөрмәтне гомеребездә беренче мәртәбә күрүебез иде.

Ресторанның зур залында буйдан-буйга сузылган озын өстәл. Без күренүгә, залдагылар бар да аягүрә тордылар. Хөрмәтләп каршы алу, берәм-берәм күрешү, танышу китте. Аннары безнең һәркайсыбызны өстәлнең түр урыннарына утыртып, үзләре калган урыннарга түгәрәкләнеп утырдылар. Өстәлдәге сый-нигъмәт әйтеп тә, санап та бетерерлек түгел иде.

Мәҗлесне ачып җибәрделәр. Башлап Мирхәйдәр Фәйзи үзе, аннан тагын бер-ике кеше сөйләде. Безнең яктан Сәхипҗамал Волжская сүз алып сөйләде.

Мәҗлестә барлыгы кырыкка якын кеше бар иде. Рәсми бүлектән соң уеннар, җырлар, биюләр булды. Ял итү, күңел ачу төнге сәгать икеләргә хәтле барды. Гомумән, мәҗлес бик матур, бик күңелле үтте.

Икенче көнне иртә торуга, һәркайсыбыз җиңнәрне сызганып, эшкә тотындык. Ике көннән беренче спектакльне күрсәтергә булдык. Хатын-кызлар костюмнар әзерләргә, ирләр афиша, плакатлар язарга кереште, Казанский клубны әзерләргә дип китте.

Волжская безгә яңа ияргән Әсма исемле артистканы уйнаячак роле белән таныштыра башлады.

Мин берничә афиша алдым да шәһәр буенча кибетләргә, учреждениеләргә кереп, билет сатып йөри башладым. Эшләр бик уңышлы чыкты. Кая гына барып керсәм дә, көтеп кенә торалар, ачык чырай белән каршы алып, барысы да алдагы рәтләргә билет алырга тырышалар иде.

Иртәгесен беренче куелачак «Уйнаш» спектакленең билетларын сатып бетереп, икенче көндә куеласы «Җиңел хезмәттә» спектакленә билетлар сатарга тотындык. Беренче спектакль бик уңышлы үтте. Волжская Сәрбиҗамалны, гадәттәгечә, яратып уйнады. Казанскийның — Әхмәтҗан, Богданованың — Мөгълифә карчык рольләре дә бик уңышлы чыкты. Мин Әнвәр бай ролен башкардым. Спектакль беткәч, тамаша залы гөр килде. Сәхнәгә Мирхәйдәр Фәйзи менде. «Нур» труппасының Орскига беренче мәртәбә килүе, дүрт-биш спектакль күрсәтәчәге турында сөйләде. Тамашачыларның бу спектакльләргә бердәмлек белән йөрүләрен үтенде, артистларны шушы спектакль белән котлады.

Икенче спектаклебез — «Җиңел хезмәттә» шулай ук шыгрым тулы зал каршында, зур алкышлар астында үтте. Ике көннән соң куйган өченче спектаклебез Мирхәйдәр Фәйзинең «Кызганыч» исемле әсәре булганлыктан, Орск халкы аны аеруча каршы алды. Алдагы рәт билетларын Мирхәйдәр Фәйзи сатарга кушмады:

— Бу спектакльгә миннән билетлар үтенеп сораучылар күп, шуңлыктан мин аларны үзем таратырмын,— диде һәм йөз билет алып китте.

Бу кичә нәкъ бер бәйрәм кебек узды. Артистлар аеруча күтәренкелек белән, рухланып уйнадылар. Халык та бик канәгать иде. Уеннан соң Мирхәйдәр Фәйзине сәхнә алдына чыгардылар, аңар һәм артистларга чәчәкләр бүләк иттеләр.

Шулай итеп, бер атна эчендә өч спектакль куеп, мең сумга якын акча җыеп алдык. Без хәзер үзебезне бай сизә идек. Кибетләргә йөри башладык. Килгәндәге газапларны искә алып, җылы киемнәр, киез итекләр, бүрекләр эзләдек. Моннан соң тагын бер атна торып, яңадан өч спектакль куйдык. Беренчесе — «Бичара Бибиҗиһан», икенчесе — «Кайниш» белән «Беренче театр», өченчесе — «Әдәпсезләр арасында хиҗапсыз кыз» белән «Кыз сорау» һәм концерт бүлеге. Унбиш көндә барлыгы алты спектакль куеп, ике мең сумлап керем алдык. Бу уңышлар үзеннән үзе генә килмәде. Боларны оештыруда Мирхәйдәр Фәйзинең роле, әлбәттә, бик зур булды. Безнең килеп кергән көне-

бездән башлап киту кенебезгә кадәр ул бетен игътибарын безгә бирде. Кая гына, кайчан гына, нинди генә йомыш белән бармыйк, һич кире какмыйча ярдәмен курсәтте. Аның тырышып йөруләре аркасында, театр бинасы өчен дә акчаны аз алдылар, торган номерыбыз өчен дә скидка ясаттырды һәм башкалар һәм башкалар...

Килуебезнең унсигезенче көнендә, кыңгыраулар таккан пар атлы өч кашовка чанага утырып, җылы киемнәр киеп, Орскидан чыгып киттек. Озатырга иптәшләре белән Мирхәйдәр Фәйзи узе дә килгән иде. Чаналарга утырганда һәркайсыбыз янына килеп, яхшылабрак, төренебрәк утырыгыз, салкын кермәсен дип, өзгәләнеп йөрде. Барыбыз белән дә курешеп чыккач, иптәшләр, тагын шулай килеп чыгыгыз, безне онытмагыз, дип кулын селкә-селкә озатып калды.

Юлда артык туңмыйча, исән-сау гына Оренбургка кайтып кердек. Бер-ике көн ял иткәч, җыелышып эш турында киңәш иттек.

Шулай киңәшкәч, Урта Азия ягына гастрольгә китәргә булдык. Чөнки ураза вакытында Оренбургта да, Уфада һәм башка шәһәрләрдә дә халык театрга йөрми иде. Ә Урта Азия ягында, киресенчә, рамазан ае бәйрәм ае саналып, кояш баегач, бөтен үзбәк халкы урамга чыга, кәеф-сафа корып, күңел ачып, төрле тамаша карап йөрергә ярата иде. Чәйханәләр дә кояш баегач кына ачылып, таң атканчы музыкалар уйнап, шыгрым тулы халык булганы хәлдә, сәүдә итәләр иде. Шушыларны исәпкә алып, шушы елда гына басылып чыккан «Дәһшәтле серләр» дигән биш пәрдәле фаҗигане (Г. Зариф әсәре) куярга әзерләндек.

Бу әсәр Оренбургның тирече Тимри бай турында язылганлыктан, басылып чыккач та, ике-өч көн эчендә бөтенләй сатылып бетте. Шуңадырмы, афишаларыбыз чыгу белән үк, билетлар да сатылып беткән иде. Спектакль буласы көнне, мин, гадәттәгечә, ике сәгать алдан театрга бардым. Театр алдында мәхшәр иде. Халык билет эзли. Халык арасыннан көчкә-көчкә генә үтеп, театрга кердем. Театр мөдире мине күреп:

— Ә менә сез кирәк идегез. Хәзер генә полицмейстер телефоннан сезне чакырды,— дигәч, башыма салкын су койгандай булып китте.

Нишләмәк кирәк, бармый хәл юк. Барып кердем. Теге чыраен сытып:

— Бүген нәрсә куясыз? Купецларны хур итә торган әсәр куясызмыни? Куярга запрещаю! — диде. Мин китапны күрсәттем.

— Ничек алай тыясыз,— мин әйтәм,— менә бит, китапның тышында цензура печате бар, куелырга рөхсәт ителә дип язылган.

Ә ул:

— Бу цензура Петроградта, ә монда мин цензура, алыштырыгыз икенче пьесага! — диде дә чыгып та китте.

Шуннан мин кайтып Волжскаяга мәсьәләне аңлаткач, тиз арада төрлебез төрле якка чабып, киемнәр әзерләдек. Грим бүлмәсендә утырган килешкә генә бер кат укып чыктык та, «Әдәпсезләр арасында хиҗапсыз кыз» һәм «Кыз сорау» пьесаларын әзерли башладык. Уен башланырга бер сәгать вакыт калган иде. Бу мәсьәләне халык залга кереп утыргач кына чыгып әйттек. «Җәмәгать! Гаеп бездә түгел, әгәр дә бу әсәрләрне карарга теләмәүчеләр булса, билетларын кассага тапшырып, акчаларын кире алырга мөмкин», дип аңлаткач, шау-шу да булмады.

Шуннан бер-ике көннән соң, ураза кергәч, февраль аенда, труппабызга яңадан чәйханәдә уйнаучы өч кешене — скрипкачы Зыя абзыйны, гармоньчы Сөнгатулла абзыйны һәм пианинода уйнаучы Кадыйр абыйларны алып, барлыгы тугыз кеше булып, Урта Азия ягына гастрольгә киттек. Поезд белән дүрт тәүлек барып, Бохара шәһәренә килеп төштек тә номерларга урнаштык.

Театр биналары булмау сәбәпле, кинотеатр бинасындагы кечкенә генә сәхнәдә, бары тик кинобудкадан бирелгән прожектор яктылыгында гына, ике спектакль куеп алдык. Сборлар әйбәт булмады. Чөнки беркадәр татарлар гына килде, үзбәкләр исә урамда, театр алдында, җыелышып торсалар да, билет алып керергә базмадылар. Бу якларда халык театрга ияләнеп җитмәгән иде әле.

Безнең янга, номерга, Бохара әмире сараенда эшләүче бер үзбәк белән әмирнең тәрҗемәчесе Искәндәр Ахметов дигән татар килгәли иде. Көннәрнең берендә шул Искәндәр исемле әфәнде безнең барыбызны да өенә кунакка чакырып алды. Шунда сөйләшеп утырганда, безнең хәлләрнең бик шәптән булмавын күреп, (бу кешеләр безнең һәр ике спектакльдә дә булдылар) безгә ярдәм итү нияте белән, әмирнең үзенә, ягъни

сараена барып, ярдәм сорарга киңәш иттеләр. Сарайга керү өчен пропуска сыман бер кәгазь биреп, миңа иртәгә сәгать унда шунда булырга куштылар.

Мин икенче көнне билетларны әзерләп Иске шәһәргә киттем. Әмир сарае ишекләрен зур сакаллы, кулларына бик иске мылтыклар тоткан сакчылар саклый иде. Ишекнең ике ягында әллә кай заманнарда ясалган ике пушка тора, аларның тәгәрмәчләре инде яртылаш җиргә баткан иде. Каравылчыларның берсенә язуны бирдем. Ә ул язуга күз төшереп алды да, ишеккә якынрак барып, кулларын берсенә-берсен шап-шоп суга башлады. Бер бәтчә килеп чыкты. Теге аңар минем кәгазьне бирде. Бәтчә малай йөгерә-йөгерә сарайга менеп китте. Бер биш минуттан әйләнеп чыкты да мине үзе белән алып менде. Менгән юлыбыз туннель формасында булып, көндезен дә утлар янып тора иде. Ул мине Искәндәр әфәнде янына китереп кертте. Искәндәр әфәнде исә мине әмир янына алып кереп таныштырды. Әмир диганнәрс кызарып торган тулы йөзле, капкара түгәрәк сакаллы, кырык яшьләрендәге кеше иде. Мин аңа үзебезнең Россиядән килгән мөсафир артистлар булуыбызны, тамаша күргәзеп йөрүебезне сөйләп бирдем дә:

— Менә шул уңай белән, иртәгә булачак тамашабызга сезнең сарай әһелләренең дә кумәк рәвештә килүләрен телибез, сезгә почетный билетлар тәкъдим итәргә килгән идем,— дидем. Әмирнең минем сүзләргә кәефе килде булса кирәк, «Хуп-хуп» диде дә кулын чапты. Шуннан бер кеше килеп керде. Әмир аңа үзбәкчә берничә сүз әйтте. Сонра миңа: «Күпме тора билетларыгызның бәһасе», дигәч, мин әзерләп алып килгән өчәр сумлык йөз билетны өстәленә куйдым. Ул билетларны теге кешегә биреп чыгарды. Шул арада бер бала бер табак пылау күтәреп керде дә тәбәнәк өстәлгә китереп куйды. Шуннан әмир миңа: «Рәхим итегез», дип ымлады. Мин аптырап калдым — ашаргамы, юкмы? Ләкин пылавы бик шәп, базар пылавы түгел иде. Шунлыктан, кызыгып ашарга тотындым. Ул арада, подноска салып, әби патша сурәте төшкән өч йөзәрлек китереп куйдылар да: «Рәхим итеп алыгыз!» диделәр. Моны күргәч, мин ашавымнан тукталып калдым да амин тотарга мәҗбүр булдым.

— Сый-хөрмәтегезгә рәхмәт,— дип, акчаларны алып кесәмә салдым да, әмиргә:

— Үзегез дә бүгенге спектаклебезгә рәхим итегез! — дидем. Бу тагын, күкрәгенә кулын куеп, «Хоп-хоп!» дип, елмаеп калды. Мин чыгып киттем.

Шуннан кайтып бу хәлне иптәшләргә сөйләгәч, аларның күңелләре күтәрелеп китте.

— Димәк, бүген аншлаг тәэмин ителгән икән! — диделәр.

Кассада калган билетлар бик аз сатылды. Шулай ук теге йөз билет буенча да килүче күп булмады. Күп булса, егерме-утыз кеше килгәндер.

Икенче көнне Чарҗуйга киттек. Анда барып ике спектакль үткәрдек. Аннан Мары шәһәренә юнәлдек. Барып төшеп, номерларга урнашкач та, полицмейстерга рөхсәт сорап барган идем: «Рус театрларыннан башка бер театрга да категорический формада рөхсәт юк»,— дип кырт кисте. Без аптырауда калдык. Икенче көнне янадан полицмейстерга барып ялынырга тотындым.

— Бер генә спектакль булса да куярга рөхсәт итегез инде. Юкса, без бу шәһәрдән чыгып китә алмыйбыз. Номерга түләргә дә, поездга билет алырга да акчабыз юк! — дигәч, тегенең азрак күңеле йомшарды.

— Ну, ярар, бер генә спектакль куегыз да, иртәгә үк бу шәһәрдән чыгып китегез! — дип, бер спектакльгә рөхсәт биреп, кул куйды, печатен басты.

Билетлар бик аз сатылды. Залда, күп булса, егерме-утыз кеше бар иде. Спектакль барганда, театр хуҗасы мине, исәп-хисап өчен дип, конторасына чакыртты. Анда, типографиягә егерме сум тиешле дип, бер кеше, плакатлар язганга биш сум тиешле дип, художник, афиша ябыштырган өчен өч сум тиешле дип, тагын берәү — барлыгы өч кеше мине көтәләр иде. Театр хуҗасы мине:

— Нишлибез, исәп-хисапны өзәргә кирәк бит! — дип каршы алды.

Мин аптырап калдым:

— Түләгез! Акча үз кулыгызда ич,— дидем.

— Нәрсәдән түләргә? Сборыгыз 62 сум, расходыгыз йөздән артык! — дип ачуланырга керешге. Аннары кассиршаны чакырып, счетлар буенча түләп җибәрергә кушты.

Шулай итеп Мары шәһәрендә өч-дүрт көн торып, бушлай бер спектакль куеп, Сәмаркандка киттек. Анда да эш уңмады. Ике спектакль куеп, уртача гына сбор алып,

Ташкентка юл алдык. Монда бина табу мәсьәләсе тагы да кыенрак булды. Бер спектакль куйдык та Оренбургка кайтып киттек. Бу бер айдан артык гастрольдә йөрүебез вакытында бары тик тугыз спектакль куйдык. Оренбургка кайтып, берничә көн торганның соңында, Самарага юл алдык. Анда бер спектакль күрсәтеп, Казанга чыгып киттек. Әмма без анда спектакль кую нияте белән бармадык, исәбебез — ял итү һәм Казанны күрү иде. Аннары Сәхипҗамал Волжская, Зөләйха Богданова һәм Гыйлаж Казанскийларның да күптәннән туган шәһәрләренә кайтканнары юк иде. Казанга килеп җиткәч, иң беренче Галиәсгар Камал белән күрешергә, аңа рәхмәтләребезне әйтергә, алып килгән бүләгебезне тапшырырга ашыктык.

Галиәсгар Камал белән очрашу

Ул вакытта Галиәсгар Камал Яңа Аракчино авылында дачада тора иде. Дүртәүләшеп, поездга утырып, аның дачасына киттек. Эзләп таптык.

— Мәрхаба, көтелмәгән кунаклар! — дип, ул безне бик ачык чырай белән каршы алды. Аннары бик кызыксынып эшләребез хакында сорашты.

— Галиәсгар абый! Без сезнең каршыгызда бик бурычлы. Чөнки куйган спектакльләребезнең җитмеш-сиксән проценты сезнең әсәрләрдән тора. Без шуларны сәхнәгә кую аркасында яшибез. Сезгә болар өчен гонорар да түли алмадык. Шуның өчен без гафу үтенергә тиешле,— дидек.

Галиәсгар абыйның мондый сүзләрне ишетергә дә теләмәгәнлеге күренеп тора иде. Ул безне дачасының Иделгә, Ослан тауларына карап торган балконына алып чыкты да өстәл янына утыртты. Үзенең гомер юлдашы Гайшә ханым белән таныштырды. Өстәлгә табын әзерләнде, гөжләп торган самовар килеп утырды. Яңа гына өлгергән каен җиләге салып, рәхәтләнеп сөйләшә-сөйләшә, чәй эчтек.

Гайшә ханым Галиәсгар абыйга караганда буйга шактый кечкенә. Кап-кара чәчле, көйдереп ала торган карашлы, шул ук вакытта, үзенә ихтирам уята торган, олы җанлы хатын иде. Ул сүзгә аз катнаша, ләкин унган хозяйканың мәҗлестә барлыгын һәр минутта тоеп торасың. Сый-хөрмәтнең муллыгы, ләззәте, өйдәге җыйнаклык һәм тәртип без әрсез кунакларны тыйнакланырга мәҗбүр итте.

Беравык утыргач һәм беркадәр иялəшеп тә киткәч, Сәхипҗамал Гыйззәтуллина-Волжская аягүрә басып сүз алды.

— Хөрмәтле Галиәсгар әфәнде! — диде ул,— безнең «Нур» труппасы, сезнең талантлы әсәрләрегезне бер-бер артлы сәхнәгә кую аркасында, менә ничә еллар инде иҗади яшәп килә. Турысын әйтергә кирәк, аралар ерак булса да, без сезне һәркайчан үз яныбызда күреп торабыз. Сезнең иҗат ярдәмегез аркасында, юлыбызда очраган авырлыкларны җиңеп, алга барабыз. Яшәгез, Галиәсгар әфәнде, безнең чын туган абыебыз! Шушы гомерлек дуслыкның истәлеге итеп, безнең шушы кечкенә генә бүләгебезне кабул итеп алуыгызны үтенәбез!

Волжская оялып кына Галиәсгар абыйга алтын хәрефләр белән язылган көмеш портсигар тәкъдим итте. Без аягүрә басып кул чаптык. Галиәсгар абыйның киң маңгаена тир бәреп чыкты. Аның нык тәэсирләнүе сизелә иде. Ул бүләкне бик кадерләп кенә кулына алды да Сәхипҗамалның кечкенә ап-ак кулын зур ихтирам белән үпте һәм, һәркайсыбызның кулларын кысып, йөрәгеннән чыккан сүзләрен әйтте:

— Рәхмәт... бик зур рәхмәт сезгә! Мина күрсәткән мондый зур ихтирамыгызны мин гомеремдә дә онытмам. Мин сезнең авыр тормышыгызны, зур мохтаҗлыклар кичереп, татар театры тудыру юлында күрсәткән гүзәл хезмәтләрегезне беләм, тәкъдир итәм... Мин яңа пьесаларымны язган вакытта, шушы портсигарны ачып, сезне күз алдыма китерермен. Тагын бер тапкыр рәхмәт сезгә!

Аш-судан соң, ул безне, бакчалар күрсәтеп, урман-кул буйларыннан йөртте. Үзенең балык тоту урыннарын, көймәсен күрсәтте... Өч-дүрт сәгать вакытның узганын сизми дә калдык. Поезд килер вакыт якынлашты. Без кайтырга җыендык. Галиәсгар ага, Гайшә ханым белән бергәләп, безне станциягә кадәр озата төште. Бу очрашу безнең барыбызга да гомергә онытылмаслык тәэсир калдырды.

Берничә көннән соң, Сәхипҗамал Волжская, Зөләйха Богданова, Гыйлаж Казанский, Хафиз Сүрмәшев һәм мин — бишәүләшеп, пароходка утырдык та Уфага киттек. Кыш көне үк инде безнең труппаны Уфага чакырып, хат язганнар иде.

Мәҗит Гафури белән очрашу

Идел, Кама, Агыйдел буйларының матурлыклары белән бернична тәүлек зәвыкланып бара торгач, Уфага килеп җиттек. Пароходтан төшкәч, извозчикларга утырып, биек таудан борыла-сарыла шәһәргә күтәрелдек тә туры урамнан киттек. Успенский урамындагы «Уфимские номера» дигән бер катлы агач йортка тукталдык. Уфадагы һәвәскәрләрне туплап, приказчиклар клубында беренче спектаклебезне дә куеп җибәрдек. Уфа халкы безне бик яхшы каршы алды. «Нур» труппасы беренче тапкыр шушы шәһәрдә оештырылганга булса кирәк, халык безне бик үз итә иде. Икенче спектаклебез («Кемдә гаеп», Фәйзерахман Нурмави әсәре) һәм өченчесе (Вәлиулла Мортазинның русчадан тәрҗемә ителгән «Өрәкләр» әсәре) «Новый клуб»та куелды. Монда 450 гә якын кеше сыя, сәхнәсе зур гына. Фойесы да киң, шунда ук беренче класслы рестораны да бар. Гомумән, Уфа халкының иң яраткан клубы шушы иде.

Афишалар бастырырга баргач, типографиядә шагыйрь Мәҗит Гафури белән таныштым. Казанский белән барган идек, ул таныштырды. Мәҗит Гафуриның өстендә кара тужурка, башында кара кәләпүш. Кыскарак кына буйлы, чандыр, чәчләре аксыл сары төстә, кыска гына мыегы да бар. Гадилеге һәм ягымлылыгы белән, беренче очрашуда ук, күңелне үзенә тарта — күптәнге таныштай дус күрә башлыйсың үзен. Типографиядә эше муеннан булуга да карамастан — гаҗәп житез кеше икән — афишаларымны укып-тикшереп чыгарга, хәл-әхвәлне сорашырга да өлгерде. Алай гына да түгел, Волжскаяны, Богданованы, Казанскийны һәм мине өенә кунакка чакырды. Чакыргач, бардык, ике-өч сәгать сөйләшеп утырдык. Эчебездә нинди зар-моң булса, барысын бушаттык. Ул безгә кышкы сезонда Уфада калырга киңәш бирде. Тиешле шартларны булдыруда кулыннан килгән ярдәмен күрсәтергә вәгъдә итте.

Без кайсы шәһәрдә генә булмыйк, менә шушындый олы җанлы кешеләрдә үзебезнең яшәү таянычын таптык. Оренбургта — Шәриф Камал, Орскида — Мирхәйдәр Фәйзи, Казанда — Галиәсгар Камал, Уфада — Мәҗит Гафури һәм Галимҗан Ибраһимов безнең труппаның мәгънәви аталары иде. Сәхнәдә куярга әсәребез булмаса да, нинди дә булса кыен хәлгә төшсәк тә, без һәркайчан алар мәрхәмәтенә сыендык, алар безнең беренче яклаучыларыбыз булды.

Спектакльләребез яхшы узды. Матбугатта да мактап яздылар һәм кышкы сезонда Уфада калуыбызны сорадылар.

1916 елның 3 августында «Тормыш» газетасында шушындый мәкалә басылды: *«31 июльдә якшәмбе көн «Новый клуб» залында «Нур» труппасы тарафыннан театр уйналып, сәхнәгә «Кемдә гаеп» исемле драма куелды.*

Китапның язылышы бик начар булып, вәгазь, нәсихәт вә кирәкмәгән урында милләт өчен эшлим дип лаф орудан гыйбарәт. Шулай булса да «Нур» труппасы бу пьесаны яхшы гына рухлы итеп сәхнәдә күрсәтә алды.

Әсма ролен иҗат итүче мәшһүр артисткабыз Гыйззәтуллина ханым белән мулла ролен уйнаган Казанский үз рольләрен муәфәкъкыятьле чыгардылар. Изелгән, кеше күтәрә алмаслык авыр кайгылар сәбәпле, хәяттән бөтенләй өметен кискән, киләчәге караңгы мулла балдызы Әсманы сәхнәдә күргәндә, аны чынлап кызганасың, ул сиңа әллә ничек якын кебек тоела. Һичкемгә ирек бирмичә, үз сүзен генә итә торган, үзенең шөһрәте, пычрак тойгылары юлына, яшь вә саф бер кызны корбан иткән, шуннан соң да исе китмичә «кирәк булса, икенчене дә табу кыен түгел», дип мактанып утырган мулланы күргәндә, аңар нәфрәт итәсең.

Мулла улы Габдулла белән мулла хатыны Фатиха рольләрен уйнаучы Богданова ханым белән Аитов та ярарлык дәрәҗәдә уйнадылар.

«Нур» труппасын даими сурәттә Уфада калдыру өчен дә тәшәббес ителә. Труппаның да Уфада калырга уе юк түгел.

Хатын-кыздан беренче мәртәбә буларак, милли сәхнәгә чыгып та зур бер муафикъ казана алган Сәхипҗамал ханым вә иптәшләре Уфада калсалар, Уфа халкы шаять аларга ачык йөз күрсәтер, милли сәхнә тызеп бирсәләр, аларны һичбер вакыт хәтереннән чыгармас».

Без рухланып, нығып киттек. Көзгә кадәр бераз йөреп кайту нияте белән, Ижау заводына барырга булдык.

Ижау заводында

Ижевск шәһәрен халык Иж заводы, «Ижау» дип йөртә иде. Бу шәһәр, җиде-сигез квадрат километр урынны биләп утыра. Анда әби патша заманында салынган корал заводларында ун меннән артык эшче эшли. Вокзалы шәһәрдән өч-дүрт километр читтә булып, Воткинск һәм Әгерҗегә йөри торган җирле поездлары да бар. Заводларның үз эшчеләреннән башка, Казаннан һәм башка яктан килеп эшләүче татарлар да бик күп. Завод янында Иж елгасын буып ясалган зур сулык та бар, анда кечкенә пароходлар да йөри. Тау башында Петров дигән аерым хуҗаның ау мылтыклары эшли торган заводы бар. Тау астында эшчеләрнең шырпы тартмасы хәтле генә вак-вак агач йортлары һәм яшелчә бакчалары тезелеп киткән. Бирердә яшәүчеләрнең күбесе — татар эшчеләре. Бу түбән якта кечкенә генә базар сыман урын булып, шәһәрнең үзәк өлеше — тау өстендә, зур йортлар, таш пулатлар һәм магазиннар — барысы да шунда. Сәүдәгәрләр, инженерлар — бай катлау халыклар тау өстендәге зур урамнарда яшиләр. Шунда ук буага карап торган бакча да бар. Халыкның ял итү, күңел ачу урыннары шул бакчада. Үзәк урамда — металлистлар клубы. Без шул клубта беренче спектакль куйдык. Ижевскига моңарчы татар труппасының килгәне юк икән, спектакльләребез бик уңышлы үтте. Эшчеләр безне алкышларга күмде. Ачык әйтергә кирәк, бу заманнарда Ижевскида татар эшчеләре күп булса да, эшче битлеген кигән соры кортлар да шактый иде. Болары сугышка бармас өчен, җайлы урын эзләп, Россиянең төрле якларыннан җыелган килмешәк бай малайлары иде. Алар күп кенә взяткалар биреп, заводка эшче булып учетка керәләр. Дөресендә исә, заводта эшләмиләр, подрядчик, ростовщиклар булып, хезмәт халкының канын суырып яталар иде.

Без Ижевскида ун көнләп тордык та Пермьга киттек.

Бу вакытта безнең иптәшләребездән Шакир Шамилский һәм Нуретдин Хәнҗәровлар, гаскәри хезмәттә булып, Пермь шәһәренең казармаларында яшиләр иде. Алар белән очрашып, туганнарча кочаклашып күрештек. Алар көн саен диярлек безнең янга, номерга, шулай ук спектакльләребезгә дә киләләр иде. Хәтта, шундый килүләрнең берсендә, «увольнительный» алмыйча гына качып килүләре аркасында, штрафка да эләктеләр, бичаралар.

Пермь шәһәрендә өч-дүрт спектакль куеп, җәйге сәяхәтләрне очлап, кышкы сезонга дип Уфага кайттык. Һәм, үзебез белән бергә, апамның кызы Рабига Галимованы да «Нур» труппасының тагын бер яшь артисткасы итеп алып киттек.

Уфадагы 1916—17 елгы кышкы сезон

Сентябрь ае башларында, без инде янадан Уфада идек. Бу вакытта Уфага Газиз Әльмөхәммәтов дигән бер җырчы килгән һәм концерт бирергә әзерләнеп йөри иде. Аның концертында да булдык. Шуны да әйтергә кирәк, бу концертны шагыйрь Шәехзадә Бабич алып барды. Ул, Әльмөхәммәтовның җырлары арасында үзенең көлке-сатирик шигырьләрен сөйләп, халыкны эчләре катканчы көлдерде. Бу шагыйрьне безнең беренче күрүебез иде, аның мәзәккә, юмор-сатирага сәләтенә бик сокланып утырдык.

Шушы көннәрдә Себер ягыннан «Сәйях труппасы» исеме белән шәһәрдән шәһәргә йөргән ирле-хатынлы Заһит Камал һәм Хәдичә Камалова килеп чыктылар. Өс-башлары фәкыйрь, үзләре бик йончыган кыяфәттә иделәр. Алар Уфага спектакль куярга дип килгән булсалар да, безне күргәч, ул уйларыннан кайтып, безнең тәкъдим буенча «Нур»га кушылдылар. Шул рәвешчә, кышкы сезонга әзерләнә башладык.

Нәкъ шушы көннәрдә Уфа һәвәскәрләре татар театрының 10 еллыгына багышланган тантаналы кичә үткәрделәр. Шул кичәдән соң, 26 сентябрьдә, «Новый клуб» залында Мирхәйдәр Фәйзинең «Кызганыч» дигән әсәре белән труппабызның кышкы сезонын ачып җибәрдек. «Тормыш» газетасы 1916 елның 522 санында сезонның ачылуы хакында түбәндәге мәкаләне басып чыгарды:

«26 сентябрьдә «Нур» труппасы, «Кызганыч» дигән әсәрне сәхнәгә куеп, кышкы хөсмен башлады. «Кызганыч» театр китабы булуы җәһәтеннән карaганда, яхшы бер әсәр булмаса да, «Нур» труппасы аны көтмәгән дәрәҗәдә диярлек яхшы чыгарды. Милләт сөючe, малы белән халыкка хезмәт итүче, шулай булса да, искелектән тә-

Фатыйма ролендә С. Волжская.

мам аерылып бетмәгән, үз кәефе өчен бөтен дөньяны корбан итәргә әзер торган Сөләйман бай ролен Аитов, аның ирексез хатыны Мөнирә ролен Галимова бик табигый уйнадылар. Аларның уллары Зиннәт, мөгаллимә Гәүһәр рольләрен Казанский белән Гыйззәтуллина яхшы чыгардылар... Сөләйман байның кызы Мәәлүфә белән кияве Баһау рольләрен Богданова белән Исхаковлар да матур гына уйнадылар. Алар аз булса да бәхетле, рәхәт тормышны вә шулай яши алу мөмкинлеген күрсәттеләр...»

Бу беренче спектаклебез халык тарафыннан зур алкышлар белән каршыланды.

30 сентябрьдә «Мин-минлек корбаны» исемле 3 пәрдәлек драма белән «Бер сәгатьлек хатын» дигән кечкенә комедияне куйдык. Бу драма әсәре, Уфада үткән елларда куелуына карамастан, янадан зур уңыш белән үтте. Эчкече Әхмәтҗан карт ролендә мин уйнадым. Аның кызы Фатыйма ролендә Волжская, аферист Козлов ролендә Казанский һәм Ильяс ролендә Гали Исхаков уйнады.

«Тормыш» газетасы бу спектакльләргә карата да рецензия белән чыкты (1916 ел, № 524).

«Хезмәттән чыгарылган, эчкелек белән тәмам кешелектән чыккан Әхмәтҗан ролен Аитов, аның кызы Фатыйма ролен Гыйззәтуллина, карта уйнап көн күрүче, бөтен эш вә хәрәкәтендә үз файдасын гына күзәтүче Козлов ролен Казанский үз рольләренә чынлап бирелеп уйнадылар. Тамашачыларга драма нык тәэсир иткән булырга кирәк ки, аның иң фаҗигале вакытларында уенны карап торучы халыктан түзә алмыйча залдан чыгып китүчеләр дә булгалады... «Бер сәгатьлек хатын» исә, үз дәрәҗәсендә яхшы көлкеле чыкты, монда уйнаучылар үз рольләрен тигез генә уйнадылар», — дип язылган иде анда.

Бер атнадан Галиәсгар Камалның «Банкрот» комедиясен куйдык. Бу куелуда баш рольләрдән Сираҗи бай ролендә, беренче мәртәбә буларак, мин уйнадым. Спектакль шактый матур үтте.

Әхмәтҗан ролендә Л. Аитов.

Шуннан соң, яңа ел җиту уңае белән — 14 октябрьдә (һиҗри бе-

лән) — «Искусство» кинотеатры залында яңа елны каршылау кичәсе оештырып, Галиәсгар Камалның ике пәрдәлек «Кайниш» әсәрен куйдык һәм концерт күрсәттек.

Концертыбызда ун яшьлек Әминә Бәхтизинаны беренче тапкыр сәхнәгә чыгардык. Бу бәләкәй кызның җырлавы халыкка бик ошады. Аның талантлы җырчы булачагы шул вакытта ук күренеп тора иде.

Төрекчәдән Галиәсгар Камал тәрҗемә иткән (асылда, Мольер әсәре) «Саран» комедиясен әзерләгәндә, баш рольләрдән саран Хәмит ролен миңа бирделәр. Мин көлке рольләрдә уйнарга ярата идем. Саран Хәмит ролен яратып алдым алуын, ләкин китабын бер-ике тапкыр укып чыккач, бераз курка башладым. Сәбәбе: беренчедән, басылып чыккан бу йөз утыз битле китапның яртысыннан күбрәге саран Хәмит сүзләре иде. Димәк, саран Хәмитне уйнаучы 3—4 сәгать буена залдагы тамашачыларны зарыктырмыйча, үзенә каратып, аларның дикъкатен җәлеп итәргә тиеш. Икенчедән, анын Мольер әсәре булуы. Мольер комедияләренең аеруча үзенчәлекләре бар. Алар, спектакльнең башыннан ахырына кадәр, бер тигезлектә, ифрат җинел, шулай ук катлаулы агышны таләп итәләр. Шуның өстенә, алар көлкегә дә бай. Мондый әсәрләрне уйнаганда, халыкның көлүенә артык мавыгып, «тәртәдән чыгып китүен» дә бик мөмкин. Өченчедән, бу әсәрне 1915 елда Оренбургта «Ширкәт» труппасында эшләгәндә бер куйган идек инде. Анда саран Хәмитне Мохтар Мутин уйнаган иде. Ничектер, ул да халыкны кирәгенчә канәгатьләндерә алмады. «Вакыт» газетасында аны тәнкыйтьләп рецензия дә чыкты. Ә бит Мутин күп мәртәбә тәҗрибәле, көчле һәм белемле артист иде. Әнә шуларның барысы да мине чын-чыннан уйланырга мәҗбүр итте.

Гәрчә мин монарчы көлке рольләрдән: «Табылдык»та итекче Фәтхетдин, «Казанга сәяхәт»тә Гата бай, «Өрәкләр»дә Ишми белән доктор Котлыкаев, «Дүрт ягың кыйбла»-да Сәгыйть, «Банкрот»та Сиражи бай һәм башка уннан артык рольләрдә уйнаган булсам да, саран Хәмит кебек аларга караганда күп мәртәбә җаваплы булган рольләрдә беренче тапкыр уйнавым иде. Бу спектакльнең режиссерлары Волжская белән Казанскийга мине борчыган шул сәбәпләрне сөйләдем. Шуннан соң, без өчәүләп, Волжская бүлмәсендә спектакль хакында ике-өч сәгать буена киңәшеп утырдык. Волжская миңа: «Ин элек әле генә сөйләгән шикне башыгыздан бөтенләй чыгарып ташлагыз да яхшы уйнап чыгуыгызга нык ышаныгыз. Артист һәрвакытта үзенең көченә ышанычлы булырга тиеш», диде. Казанский да шактый гына киңәшләр бирде. Бигрәк тә халыкның көлүенә мавыгып китеп арттырып уйнап җибәрүләрдән сакланырга кирәклеген әйтеп күрсәтте. Ахырда, Сәхипҗамал ханым: «Бервакытта да уеныгыз белән кемне булса да копировать итәргә тырышмагыз. Ул начар нәрсә. Образны үзегез эзләп табыгыз. Үзең эзләп тапкан образны сәхнәдә уйнау да җиңел, халыкны да ышандыра», дип, бу киңәшкә йомгак ясады. Миңа бу иптәшләрнең киңәшләре бик тәэсир итте һәм мин, канатланып китеп, роль өстендә нык лап эшли башладым.

Шулай итеп, эзләнә торгач, саран Хәмит образы туды. Спектакль башыннан ахырына кадәр күтәренке рухта барды. Гомумән, спектакль тантаналы булып үтте. Зал шыгрым тулы иде. Кадерле кунакларыбыздан Мәҗит Гафури, Галимҗан Ибраһимов, Фатих Сәйфи, Абруй ханым Сәйфи, Сәгыйть Рәмиев, Сәгыйть Сөнчәләйләр дә бар иде. Аларның һәркайсысы сәхнә артына кереп кулларыбызны кысып тәбрикләделәр. Бу спектакльдә яшь укучылардан Әхмәт Фәйзи белән Риза Ишморат та булдылар. Спектакль хакында «Тормыш» газетасында түбәндәге рецензия чыкты:

«21 октябрьда «Новый клуб» залында «Нур» труппасы тарафыннан «Саран Хәмит» дигән көлке уйналды. Бу әсәр Галиәсгар Камал тарафыннан төрекчәдән тәрҗемә кылынган. Төрекчәгә исә французчадан күчерелгән әсәрдә саран кешенең акчага бирелүе, акча дигәндә аның бөтен нәрсәне онытуы, акча табу — мал җыю юлында саран кешенең әллә нинди түбәнлекләр кылырга да әзер торуы... көленеч итеп тасвир кылынган. Саран бай Хәмит акча алу өчен үзенең улы Сәрвәтбәк белән аның мәгъшукасы Надидәне үзенә никахландыру тугърысында сатулаша вә, ниһаять, аны бернечә мең сум бәрабәренә угълына уступать итәргә риза була.

5 пәрдәдән гыйбарәт булган бу зур әсәр гомумән караганда яхшы гына, тигез генә чыкты. Уйнаучыларның һәркайсы үз рольләрен бер дәрәҗәдә яраклык рәвештә уйнадылар. Саран бай Хәмит ролендә Аитов, яучы карчык Нәзифа ролендә Богданова башкалардан чибәррәк һәм тулырак чыгардылар. Аларның үз рольләрен яхшы төшенеп уйнаганлыклары вә тиешле булган типны чыгарырга муаффакъ булганлык-

Артистка Зөләйха Богданова.

лары перым-ачык күренеп тора иде. Шуның өчен дә булса кирәк ки, бу икәвесе халык тарафыннан бик нык алкышландылар. Хәмитнең кучеры һәм ашчы Рамазан ролен Исмәгыйлов та җанлы гына уйнады. Хәмитнең угълы Сәрнәтбәк ролендә Казанский да ярамаслык түгел иде. Хәмитнең кызы Алмас ханым ролендә Галимова, Хәмитнең экономы Мөхәррәм ролендә Исхаков көтелгән дәрәҗәдә җанлы чыгара алмадылар. Бу рольләр пьесаның үзендә дә яхшы эшләнмәгәннәр. «Саран»дагы Хәмит бай белән ячы карчык Нәзифа типлары һәр халыкта бер төсле диярлек гомуми бер тип булганлыктан, әсәрнең сәхнәдә күбрәк уйналуы матлуб, чөнки халык бер яктан үзенә сабак ала, икенче яктан исә, безгә чит булган халыкның тормышы хакында аз гына булса да мәгълүмат хасил итә.

Театрга халык байтак килгән иде, шулай да мондый урыннарда күренергә тиешле булган байлар сыйныфы белән мирзалар юк иделәр. Бу таифә нигәдер сәхнәбезгә әһәмият бирү, аңа килүне кирәксез саный. Аннан соң халыкның байтагы театрга кечкенә балалары белән килгәннәр. Аларны анда үз ирекләренә җибәргәннәр иде. Шуның өчен ул балалар тамаша вакытында әле бер урынга, әле икенчесенә күчеп йөреп, караучыларның кәефләрен җибәрделәр. Бу балаларның мөрәббиләре андый гомуми булган урынга бала-чагаларын ташымаска, вә китергәч, аларга теләсә нишләп гомуми тәртипне бозып йөрергә ирек бирмәскә кирәк иде.

«Нур» труппасы алдагы җомгага «Тормыш корбаннары» дигән әсәр куячак. Артист вә артисткаларыбызның уйнаган саен кимчелекләрен тутыру, вә алган рольләрен яхшырак чыгара барганлыкларыннан, шул нисбәттә, тамашага килүчеләрнең дә артуы көтелә. Моңар кадәрле күрелгән тәҗрибәләр шуны күрсәтәләр».

(«Тормыш газетасы», 1916 ел, 25 октябрь.)

30 декабрьда, Сәхипҗамал Волжскаяның бенефисына, «Җинел хезмәттә» драмасын куйдык. Халык күп иде. Волжскаяга күп кенә бүләкләр һәм чәчәкләр бирелде. Аның артыннан «Бәхетсез егет» драмасы куелды. Аннан соң, 16 январьда, Гыйлаҗ Казанскийның бенефисын уздырдык. Сәхнәгә Сагыйть Рәмиевнең «Яшә Зөбәйдә, яшим мин!» әсәре куелды. Бу спектакльне әзерләгәндә, язучы, репетицияләргә килеп, безгә булышып йөрде. Сөләйман ролендә Казанский, Зөбәйдәне Волжская, мин Динмөхәммәт ролендә уйнадым. (Бу турыда «Тормыш» газетасының 579 санында рецензия дә басылып чыкты.) Бу бенефис та зур күтәренкелек белән, халыкның Казанскийны бик зур хөрмәтләве белән үтте.

1917 елның январенда, «Тормыш» газетасында (№ 581) түбәндәге мәкалә басылып чыкты.

«Нур» труппасы артистларының распорядителе Локман Аитов бенефисы.

Труппада распорядительлек вазифасы — иң кыен бер вазифа. Чөнки афишалар вакытында чыкмаса да, сәхнәгә куела торган пьеса халыкны үзенә җәлеп итәрлек дәрәҗәдә кызыклы итеп игълан ителмәсә дә, вакытында билетлар өлгермәсә дә распорядитель мәсьүль буладыр. Аннан соң гасабиләшеп беткән артист-артисткалар, үзләренең труппада торган урыннары афишада тиешенчә күрсәтелмәсә дә, распорядительгә бәйләнәләр: ник алай иттең дә ник болай иттең, дип башын катыралар. Ул гына да аз кеби, театрларга килгән халыкны залга тәртипле урнаштыру эше дә распорядитель өстендә. Театрга килүче халыкның берсе икенчесенең урынына утырып, икенчесе урынсыз калса да, хәзер распорядительне шелтәли, аңа барып бәла ясый. Менә Локман

әфәнде Аитовның 26 гыйнварда бенефисы була. Тамашага — «Дурт ягың кыйбла» дигән, Аитовның үзе тарафыннан русчадан алынып тәртип кылынган 3 пәрдәлек көлке куелачак! Икенче бүлектә мәшһүр артисткабыз Гыйззәтуллина-Волжскаяның иштиракы белән һәртөрле Кавказ биюләре күрсәтеләчәк. Кечкенә Уфа җырчысы Әминә туташ Бәхтизина милли көйләремезне җырлаячак. Ибниәмин әфәнде Еникеев скрипка белән кушылачак. Кичәнең бик төрле-төрле вә кызыклы чыгуы көтелә.

Аитов көлке рольләрне яхшы уйнавы белән Уфа халкының мәхәббәтен казанган бер артистыбыз булганлыктан, үзенең бәйрәмендә тагын да яхшырак уйнаячагы исә үз-үзеннән мәгълүмдер...»

Шуннан, 26 январьда, минем бенефисым үткәрелде.

Уфалылар тарафыннан бүләкләр бирелде.

Шул вакытларда Уфада яшәгән язучылардан Галимҗан Ибраһимов, Мәҗит Гафури, Сәгыйть Сүнчәләй, Сәгыйть Рәмиев, Фатих Сәйфи, Абруй Сәйфи, укытучы Еникеевләр көмеш сервиз бүләк иттеләр. Бу кыйммәтле бүләкне сәхнәгә чыгарып тапшыручы Мәҗит Гафури булды, һәм ул миндә хәзер дә саклана.

Шундый авыр шартларда, бер яктан, спектакльләр өчен бина табу кыенлыклары, икенче яктан, репертуар булмавы белән җәфа чигә-чигә, февраль революциясен каршы алдык. Ләкин бу революциянең артистлар өчен бер җиңеллеге дә сизелмәде. Чөнки театр, клуб биналары әүвәлгечә аерым хуҗалар кулында калды. Аренда хакын әүвәлгечә ук каерып алалар иде. Шулай ук афиша, программалар баскан өчен дә типография хуҗалары әүвәлгедән бер дә киметмичә, хәтта артыграк итеп түләтә башладылар. Шулай ук, полиция дә үз урынында калды. Бары тик цензура мәсьәләсе бераз җиңеләйде. Петербург цензурасы пичәтен баскан әсәрнең нөсхәсен сорамый башладылар. Куелачак әсәрләргә рөхсәт бирү урындагы полиция органнары карамагына тапшырылды. Менә шуннан файдаланып, без монархчы куелырга рөхсәт ителмәгән әсәрләрне чемодан төбеннән өстерәп чыгарып куя башладык.

Иң беренче итеп Гафур Коләхметовның «Яшь гомер» әсәрен куярга әзерли башладык. Гәрчә бу әсәр, 1908 елда ук басылып чыккан булса да, бу көнгә кадәр бер труппа тарафыннан да куелганы юк иде әле. Мин бу әсәрдәге Йосыф ролен уйнарга күп еллардан бирле кызыгып йөри идем.

Әсәрдәге рольләрне бүлгәндә, мин коллективка теләгемне аңлаттым. Гыйлаҗ Казанский көлемсерәде дә: «Локман сәхнәдә исерекләр булып уйнарга бик ярата, әйдә күңеле булсын, уйнасын», дип шаяртып куйды. Минем теләгемә каршы килмәделәр. Әсәр Казанский постановкасында куелды. Казанскийның бу шаярып кына әйтелгән сүзләрендә дөреслек тә бар иде. 1908 елда беренче мәртәбә сәхнәдә уйнавым «Казанга сәяхәт»тә исерек Хәйруч образыннан башланып китте. Аннан соң «Бәхетсез егет»тә Васька, «Уйнаш»та хулиган Әптери, «Мин-минлек корбаны»нда Әхмәтҗан, «Кайгы моңнары»нда Әхмәтша, «Өрәкләр»дә Ишми һәм башкалар. Гәрчә тормышта бу елларга кадәр эчкелекнең тәмен татыганым булмаса да, сәхнәдә бу образларны уйнарга аеруча ярата идем. Нигә шулай булгандыр, ачык әйтә алмыйм. Мөгаен, шуңа күрәдер: Пермьда, мин үсмер бала вакытларда, безнең квартирага каршы гына ачык һавада «обжорка рәте» дигән бик арзан бәя белән ашлар сата торган җир бар иде. Менә шунда инде шәһәрнең бөтен юлдан язганнары көннәр буена җыела, салышып эчеп, ашап ята иде. Без балалар шуларны карап, сөйләшкәннәрен тыңлап кызык таба идек. Хәтта, аларның шул кадәр аппетит белән тәмле иттереп ашаганнарын күреп, үзебезнең дә ашыйсыбыз килә башлый иде. Кыска гына әйткәндә, бу җир «исерекләр образының галлереясе» иде.

Мин рольләрне әзерләгәндә, әнә шул галлереяне күз алдына китерә идем дә, шулардан үрнәк алып, репетицияне башлый идем. Инде бу Йосыф ролен кулыма алып әзерли башлагач, авторның язган сүзләрен кат-кат укып чыккач, уйларга тотындым. Йосыфның исерек вакытта сөйләгән сүзләре дә ифрат мәгънәле, тәэсирле сүзләр. Мәсәлән, беренче пәрдәдә бакчадагы эскәмияләрне күрсәтеп: «Менә бу эскәмиядә дә минем хакым бар», үсемлекләрне күрсәтеп: «Менә бу агачларда да минем хакым бар», баскан җирен күрсәтеп: «Менә бу җирдә дә минем хакым бар. Хакым бик күп җирдә бар, әмма акчам юк, нигә болай икән?» дип уйга кала. Миңа Йосыф образының монархчы уйнаган гади исерекләр образына охшамавы ачык күренә башлады. Шунлыктан, теге «обжорка рәте»ндәге юлдан язган исерекләр галлереясенең дә ярдәме булмады. Тормыштан бу образга үрнәк эзли башладым. Уфада фабрика-заводлар булмагач, мәсьәлә бераз кыенлашты.

Көннәрнен берсендә афишалар белән типографиягә барган идем. шунда эшчеләрнен эбәткә туктаган вакытларына туры килдем. Кайберләре сөт эчә, тәмәке тарта; шулай төрле хәлләр турында сөйләшеп, көлешеп утыралар. Мене шундагы 15—20 эшче арасында мин үземнен Иосыфымны төсмерли башладым. Бу көннән соң мин типографиягә юк эшне дә бар итеп, бигрәк тә аш вакытларын туры китереп, ешрак йөрдем. Һәм әлеге кешеләрне күзәттем. Репетицияләрдә минем Иосыф күренә дә башлады. Хәзер инде мине Иосыфнын гади тормыштагы холкы-фигыле кызыктыра иде. Әмма минем Иосыф, аек вакытында, сәхнәдә бер генә пәрдәдә күренә, автор да сүзне ана аз бирә. Шунлыктан, Иосыфнын гали вакыттагы образын кору мәсьәләсе кыенлашты. Менә бусында инде мина типографиядәге үрнәк кешем бик зур ярдәм итте. Мин Иосыфны бала вакыттан ук нужа күреп үскән, белемле булмаса да, яшерен сәяси оешмаларда эшләүче Галиләр, Вәлиләр белән катнашып йөрүе аркасында, күзләре ачылып, эшчеләр хакын яклаучыга, иркен тормышка омтылучыга әйләнгән, тормышта очраган авырлыкларга артык исе китмичә карарга өйрәнгән кеше итеп күрсәтергә тырыштым.

Менә өченче пәрдә. Гали квартирасына килгән Иосыф, урамдагы тавышны ишетеп, тәрәзә янына килә. Ни күзе белән күрсен: Иосыфнын гомер буена тенкәсенә тиеп беткән городовойны урамда халык кыйнап ята. Иосыф бу вакыйганы күреп, башта тәрәзәдән генә кулларын селтәп, «Сал берне, сал берне, ныграк сал, кешеләрне кыйнарга ярата иден, менә үзен татып кара инде хәзер», дип кыйнаучыларга көч биреп тора да шатлыгыннан бала кебек биеп тә җибәрә, бии торгач, кинәт, пиджагын салып ташлый һәм җиннәрен сызгана да, ишеккә дә барып тормастан, туп-туры тәрәзәдән генә, городовойны кыйнаучылар янына сикерә.

Бу күренештәге бию детален мин үзем керткән идем һәм бу Иосыф образын җанландырган бер матур буяу булды. Чөнки тамашачылар бу күренешне аеруча күтәренкелек белән каршы алып, пәрдә төшеп беткәнне көтмичә, аякларын тибә-тибә алкышлый башлыйлар иде. Шулай уйлана-уйлана, эзләнә-эзләнә, тормыштагы күргән-белгән кешедән үрнәк ала-ала Иосыф образы туды һәм Гафур Коләхметовнын ун елга якын цензура арестында яткан «Яшь гомер» әсәре беренче мәртәбә татар сәхнәсенә менде. Бу хәл 1917 елнын 3 апрелендә булды. Зөләйха ролендә Волжская, Гали ролендә Гыйлаҗ Казанский, Вәли ролендә Гали Исхаковлар уйнадылар. Бу спектакль баштан ахырына кадәр күтәренке рухта барды һәм зур уңыш белән үтте. Зал тамашачылар белән шыгрым тулы иде. Спектакль беткәч, Мәҗит Гафури, Самат Шәрәфетдинов иптәшләр, сәхнә артына кереп, кулларыбызны кысып тәбрикләделәр.

Бу драмадан сон Фәйзерахман Нурмавинын «Кемдә гаеп» дигән әсәрен куйдык. Бу әсәр дингә, муллаларга каршы язылган бик көчле драма булганлыктан, шунын өстенә, әсәрнен баш каһарманы Әсма ролен Волжская уйнаганлыктан, халыкка бик ошады. Мәхмүт Нуримановнын 1905—07 еллардагы революцион хәрәкәтләр турында язылган «Чын мәхәббәт» исемле әсәрен дә тамашачы яратты. Пьесанын авторы Нуриманов әлек типографиядә хәреф җыючы иде, соңыннан «Нур» труппасынын артисты булды.

14 апрельдә кышкы сезонны ябу унае белән, Галиәсгар Камал тәрҗемәсендәге «Хөкемдә хаталык» әсәрен куйдык. Баш рольләрдә: Адрина ролендә Волжская, анын атасы Жан Рено ролендә Казанский, герцогиня ролендә Зөләйха Богданова уйнады. Мин ялган граф Лазарь ролендә идем.

Спектакль беткәч, сәхнә артына Уфанын күренекле зыялы тамашачылары, язучылары, шулар җөмләсендә Мәҗит ага Гафури кереп, һәркайсыбызнын кулларын кыстылар, кышкы сезонда Уфа халкын мәгънәви белем белән тәэмин иткәнебез өчен рәхмәтләрен әйттеләр.

Шулай итеп, Уфа шәһәрендә алты айдан артык сузылган кышкы сезонда, атнасына бер-ике спектакль үткәреп, барлыгы кырыктан артык әсәр куйдык. Уфа халкы каршысында имтиханыбызны бирдек.

Безнен эшебезгә Мәҗит ага Гафуринын, типография эшчесе Гали Исхаковнын, тәнкыйтьче-журналист Гыйнди Гыйзззтуллиннын һ. б. ларнын ярдәмнәре күп тиде. «Тормыш» газетасында басылып барган тәнкыйть мәкаләләре безнен спектакльләребезнен уңышлы үтүләренә бик нык ярдәм иттеләр.

(Ахыры киләсе санда)

Әдәби тәнкыйть

Шамил Маннапов

ӘНВӘР ДАВЫДОВ ПОЭТИКАСЫ

Әнвәр Давыдов, Бөек Ватан сугышыннан соң әдәбият мәйданына килеп, тиз арада үз укучыларын тапкан, шигырь дөньясында үз аһәңе, үз тавышы булган күренекле шагыйрьләребезнең берсе. Давыдов шигырьләре тыныч хезмәткә, кеше күңелендәге матур сыйфатларга соклану, дөнья турында фәлсәфи уйлану, сугыш уты кабызучыларга карата нәфрәтләнү рухында язылганнар. Аның лирик герое — киләчәккә тирән ышаныч белән караучы оптимист, кешелеккә һәрвакыт шатлыклы тормыш теләүче гуманист кеше. Давыдов поэзиясе фикерләү мәйданының киңлеге, хисләренең каршылыклы булуы, дөньякүләм конфликтларның кешелекнең иң якты идеалы — коммунизм файдасына хәл ителәчәгенә ышануы белән характерлы.

Нинди генә теманы алмасын, Давыдов аны төрле яклап, тирәннән ачарга омтыла. Шуның өчен поэмаларының күбесе бер үк мәсьәләләрне төрле яклап ача торган мөстәкыйль сюжетлы бүлекләрдән торалар. Аларның композициясенә симметриялелек хас. Мисалга шагыйрьнең соңгы елларда язылган иң уңышлы поэмаларыннан берсен алыйк.

Кайдадыр көн.
Кайдадыр төн.
Кайдадыр җылы.
Кайдадыр суык.
Гөлләр...
Көлләр...
Бакча...
Чүлләр...
Үлем...
Туу...

«Чорлар чатында» поэмасының шушы өзегендә генә дә шагыйрь алда тасвир ителәчәк вакыйгаларның, күренешләрнең каршылыклы гомуми сынын күз алдына китереп бастыра. Алдыбызда иске дөнья белән яңа дөнья, капитализм белән социализм илләре арасындагы конфликт ачылып китә. Бу — дөньякүләм, антагонистик каршылык. Поэма лирик типта булганлыктан, бу каршылык геройларның бер-берсенә симпатияләре яки антипатияләре аша түгел, ә лирик геройның уйланулары, каршылыклы хисләре аша бирелә.

Поэма барысы унике бүлектән тора. Беренче бүлектә лирик герой:

Без барабыз икәү янәшә,
— Беләсеңме, тормыш ул нәрсә?—

дип, янымнан барган сөйгәненә сорау бирә. Бу, шулай ук, укучыга бирелгән сорау булып та яңгырый. Шуннан соң шагыйрь, һәр бүлек саен ике дөньяны капма-каршы куеп, чагыштырып, алар арасындагы аерымлыклар турында төгәлрәк уйлый, югарыдагы сорауларга акрын-акрын җаваплар бирә башлый.

Ике дөнья — яшәү һәм үлем.

Ике дөнья — «көчле дошман раклар», һәм бу авыруга каршы көрәшүче врачлар.

Ике дөнья — фәнгә ике төрле караш, аның ачышларын ике төрле максаттан чыгып файдалану. «Совет кешесенең зирәк кыюлыгы галәм эченә яңа юл яулаганда, шашкан агрессорлар дәһшәтле утлы кораллар әзерлиләр» дигән фикерне әйтә шагыйрь һәм:

Тормыш, тормыш, тормыш галибәнә
Адым атлый бөтен галәмгә! —

дип, бу очракта да социалистик лагерь илләре тоткан юлның җиңеп чыгачагына тирән ышаныч белдерә.

Поэманың соңгы 11, 12 бүлекләрендә янадан тимер краннарның биналар салуы, ана төбәлгән ракеталар сурәтләнә һәм поэма, башлангандагы кебек үк, тормыш, бәхет турындагы фәлсәфә белән тәмам була. Композициядә шагыйрь тәгәл симметриягә омтыла. 1 бүлек белән соңгы 12 бүлекнең, 3 бүлек белән 11 бүлекнең, 4 бүлек белән 9 бүлекнең тематик яктан охшаш булуы шул турыда сөйли.

Һәр бүлек хис үсеше кульминацион ноктага житкәч тәмам була. Бүлектән бүлеккә дә хис зурая бара. 8 бүлектәге:

Кайгы җыерчыклары кими барган
Йөзе белән көлеп, уйланып,
Яңа кояш, яңа дөньяларга
Дуслык кулын суза безнең Җир,
Гакыл нуры белән нурланып! —

дигән юллар поэмадагы герой хисләренең иң югары ноктасын билгелиләр. Бу — 8 бүлекнең дә кульминацион ноктасы булып тора. Шуннан соңгы бүлекләрнең дә азаклары хис үсеше югары дәрәҗәгә җитү белән тәгәлләнә. Димәк, хис һәм вакыйгалар кульминациясе бер ноктага туры килә. Бу бүлекләр, баштагы бүлекләрне градацияле кабатлау булганлыктан, хис поэманың ахырынача сүрелми. Һәр бүлек капиталистик һәм социалистик җәмгыятьләрнең асылын ачуда кайсы да булса бер моментны сурәтләүгә хезмәт итә. Һәр бүлек, мөстәкыйль шигырь формасында төзелеп, гомуми теманы кайсы да булса бер яктан ачыклый. Бүлекләрне бер поэма итеп оештыручы көч — аларның тематик яктан аерылгысыз бәйләнгән булуы.

Моннан тыш Ә. Давыдовта композицион башламнар шактый күп очрыйлар.

Ш а т л ы к ө ч е н к ү п к и р ә к м е
к е ш е г ә?
Син анарга бир яраткан эш кенә,
Ямь өстим дип туган иле күркенә.
Хезмәт итәр
Җилкенә-җилкенә.
К ү п к и р ә к м е к е ш е к ү н е л е н
б о з а р г а?
Ул шатланып сиңа кулын сузганда,
Очраса күз карашында бозларга,
Шул җитә ана
Сызларга, сызларга.

Композицияне болай кору идеяне ача торган юлны кабатларга, аңа логик басым ясарга мәҗбүр итә. Нәтиҗәдә, фикер җыйнак булып укучы күңеленә урнаша.

Муса Җәлилнең «Ышанма» шигыре — композицион башламаның матур үрнәге:

С и ң а м и н н ә н х ә б ә р к и т е р с ә л ә р,
Муса инде үлгән, дисәләр,
Син ышанма, бәгърем, мондый сүзне
Дуслар әйтмәс, сине сөйсәләр.
Сиңа миннән хәбәр китерсәләр,
Алмаштырган илен, дисәләр...

М. Җәлил композицион башламаларны строфа аша куллана һәм шигырьнең буеннан-буена шулай дәвам итә. Ә. Давыдов, күбесенчә, строфа саен куллана, һәм күп шигырьләрендә композиция төзүче башка чаралар белән берлектә генә файдалана.

М о н д а к ү з к ү р е м е ш у н д ы й к и н:
Офыкта — урманнар тарагы,
Я н ы н д а —
трамвай:
дин-дин-дин!
Я р т ы гасыр артта —
богаулар:
дин-дин-дин!
Ә алда —
коммуна байрагы.
М о н д а к ү з к ү р е м е ш у н д ы й к и н!
К ү к л ә р д ә спутник эзләре.
Ә ж и р д ә
катламнар астында
Җәяүле каторжан сөяге.

(«Күз күреме».)

Бирелә, бүгенге киң колачлы төзелешләрне тасвирлаганда, шагыйрь бу көннәргә килүнең каршылыклар аша булуын ачык итеп күрсәтү өчен, антонимик параллелизмнар кулланган (янында — ярты гасыр артта, күкләрдә — җирдә). Нәтиҗә, әлбәттә, яхшы. Авторның әйтергә теләгән фикере укучыга тизрәк барып җитә.

Әлбәттә, композицион осталыкка шагыйрь кинәт кенә ирешмәде. Ә. Давыдовның беренче поэмаларында конфликт та шактый йомшак эшләнгән була иде. Бу, берьяктан, авторның каләме үткенәеп җитмәү белән аңлатылса, икенчедән, моны шәхес культы чорында шактый киң таралган конфликтсызлык теориясенең кире тәэсиреннән дип тә карарга кирәк.

Баштагы чор иҗатында Давыдов үз геройларына бик күп ремаркалар бирә һәм бу образны ачарлык тормыш конфликты булмаудан, ирексездән шулай эшләнә иде.

Соңгы әсәрләрендә ремаркалардан шактый читләшү сизелә. Моның өчен, башлыча, композицион детальләрдән файдаланыла.

Ә. Давыдовның поэмада композицион детальләрне кулланудагы үзенчәлеге шунда, ул бер тотып алган детальне идея максатларына тулысынча хезмәт иттерергә, аның бөтен мөмкинлекләреннән файдаланырга омтыла. Мисалны «Нигә?» поэмасыннан китерик.

Низам карый кызының күзенә:
«Үпкәләмә, кызым!»
Үз йөрәгең үз-үзенә
Үпкә тотамы соң?!

Авыру нарасыен үлем тырнагыннан ничек кенә булса да йолып алырга тырышкан ата образын бирүдә Й ө р ә к детале шушы строфада ук үз миссиясен үти. Әмма шагыйрь, тагын шул ук детальгә бәйләп, шактый нәрсәләр белдерә. Й ө р ә к детале бер җан, бер тән булып ут йотучы өч кешене бәйләүче буларак та, Фәния белән Низамның профессияләрен ачыклаучы буларак та ачыла.

Б е р к и с ә г е
Низам белән
Басуларда йөрсә,
Шытып чыккан бодайлардан
Аңа саф көч керсә,
Б е р к и с ә г е
Фәния белән
Класс ишеген ачкан...

Вакыйгаларны бер деталь тирәсенә туплап бирү хиснең киеренкелеген һәм эзлеклелеген тәэмин итә. Шуңардырмы, шагыйрь мондый детальләрне һәр бүлекнең (поэма өч бүлектән тора) кульминацион нокталарында куллана. Беренче бүлектә Фәния белән Низамның авыру балалары янында кайгырышып торулары Й ө р ә к детале белән бәйләнгән. Икенче бүлектә, Низам ярдәм сорап килгәч, үзенең уйларыннан аерыласы килмәгәнлектән, авыру бала янына бармый калган Галиянең борчылырга тотынуы «ишек шыгырашуы» детале аша бирелә.

Поэма композициясендә Ә. Давыдовның төп үзенчәлеге һәр детальне ахыргача үстерү булса, шигырьләрдә исә кайсы да булса бер ягы калкуландырылган күп детальлелек. **Ягъни ул бер үк шигырьдә, идеяне ачарлык якларын калкулатып, күп детальләр** куллана. Давыдов шигырьдә бер планлылыктан качарга, һәрвакыт полифониягә, күп тавышлылыкка омтыла.

Шигырьне күп детальләр белән язу хисләрне, тормыш күренешләрен төрле яклап тасвирларга мөмкинлек тудыра. Мисалга «Москвада» шигырен алыйк:

Нигә болай
күңелем ашкына?
Бигрәк матур бит
кичке Москва.
Яктылык
урамда
һәм күк йөзендә.
Ә ин көчлесе —
кешеләр күзендә.

Шагыйрь беренче строфада ук Москва халкының кунакчыллыгын, халыклар дуслыгын күрсәтеп бирде. Шуннан эпизодик детальләр өстәлә бара. Автор үзенә карата «һәр телдә җылы сүз әзер булуын», «машиналарның теләгән урынга илтергә әзер торуын, хәтта зур театр башыннан атларның сикереп төшеп, аны Москва буйлатып йөртергә теләүләрен» яза да, кинәт башка детальгә күчә. Лирик герой туган авылы турында уйлана башлый. Шул вакыт диктор тавышы:

— Башлана хәзер
трансляция
«Бәхет» колхозы
радиоузелыннан.

Шунда ук:

Гүзәл авазны
ашыга тиз генә
Отарга
халык артисты Глиэр.

Бер караганда, төрле-төрле эпизодлар, ә үзләре бер идея казагына беркетелгәннәр. Алар, бергә кушылып, социалистик җәмгыятьтә шәһәр белән авыл арасындагы аермаларның бетә бару идеясен ачуга хезмәт итәләр. Детальләр, хис үсеше ягыннан шулай ук шигырь идеясен ачуда тоткан рольләренә карап, логик эзлеклелектә урнаштырылалар.

Ә. Давыдовның шигырьдә күп детальлеккә омтылуын, аның бер деталь үстерелешенә корылган шигырьләрдән бөтенләй китүе дип аңларга ярамый, әлбәттә. Соңгы елларда иҗат ителгән «Шәм турында», «Эзләнгәндә», «Мәхәббәтлек турында», «Чылдыр-чылдыр», «Бөек үрнәк» һәм башка шигырьләре шуны раслыйлар. Автор үзе әйтергә теләгән фикерен бер деталь үстерелешендә генә дә бирә ала икән, шигырьгә

башка детальләр өстәүне кирәк санамый. Димәк, шигырьне күп детальгә кору шагыйрьнең үзмаксаты түгел, ә идея максатларыннан чыгып эшләнгән алым. «Шәм турында» шигыре бер деталь үстерелешенә (шәм детале) генә корылган. Идеяне ачу өчен бирелә бер деталь дә җитә. Тормышның катлаулы күренешләрен яки геройның катлаулы хисләрен сурәтләгәндә Ә. Давыдов шигырьне күп детальләрдән, ә гадирәк күренешләрне, инде исеме табылганрак хисләрне сурәтләгәндә бер деталь үстерелешенә кора.

Бу яктан карагандa, Ә. Давыдовның күп детальле һәм бер деталь үстерелешенә корылган шигырьләрендә рефреннарны куллану үзенчәлеге игътибарга лаек. Күп детальле шигырьләрендә Ә. Давыдов рефреннарга яңадан-яңа мәгънә нагрузкасы алып килү бурычын йөкләми, рефрен бирелә аңа эмоциональ чара һәм композиция төзү чарасы буларак кирәк. Ул рефренга башта яки шигырь уртасында әйтелгән берәр фикерне нәкъ шул көенчә кабатлау бурычын гына йөкли.

Мисалны шул ук «Москвада» шигыреннән, «Синең кулларың», «Совет характеры», «Урал колачы» һәм башка шигырьләреннән дә китерергә мөмкин.

Исәннәр! —
шатлыгым шушы бер сүзне
җыр итеп яңгырата
һаман
колакка...
Дусларым,
ләкин,
сез беләсезме,
бу эшнең тарихы
китә бик еракка.
(«Совет характеры».)

Шундый сорау туарга мөмкин: Ә. Давыдовка хис һәм фикер градациясе шигырьдәге рефренда кирәкмимени?

Югарыда әйтелгәнчә, Давыдов хис һәм фикер үсешенә бер үк шигырьдә кулланган күп детальләр аша ирешә. Шулай булгач, рефренга бурычны йөкләмәгәндә дә, шигырь әллә ни зарар күрми. Ә бер деталь үстерелешенә корылган шигырьләрендә рефреннар һ. Такташтагыча градацияләләр. Мисалга «Нәҗибә» шигырен алыйк:

Күктә болытлар ага
Ерак-ерак.
Бер каз канатын кага:
«Кыйгак-кыйгак!»

Тагын бер строфадан соң болай кабатлана:

Булмый алай гел генә
Уйнап, уйнап.
Үлән ашап йөр менә,
Кыйгак-кыйгак!

Каз белән кечкенә Нәҗибәне параллель куеп язылган бу матур шигырьдә рефрен, баштан ахыргача, композиция төзү чарасы, шул ук вакытта, хис һәм фикер үстерелешен бирүче чара буларак та кулланыла. Мондый шигырьләр рәтенә тагын «Солдат турында баллада», «Комбайнчы», «Муса Җәлил турында бер истәлек» һәм башка әсәрләрне кертергә була.

Шигырьне күп детальләрдән төзү көнбатыш Европа классик поэзиясеннән, бигрәк тә Н. Хикмәттән килә. Хәзерге яшь шагыйрьләрнең дә шигырьдә күп детальлеккә омтылуларын исәпкә алсак, бу алымның киләчәге шактый зур булуы турында фараз кылырга мөмкин. Әмма күп детальләр куллану максимум осталык сорый, аз гына саксызлык күрсәттеңме, детальләр дисгармониясе барлыкка килергә, яисә алар артык күбәеп китеп, шигырь идеясен аңлауга комачаулый башларга мөмкиннәр. Моны Ә. Давыдовның кайбер шигырьләрендә дә күрергә мөмкин.

Мәсәлән, «Минем буын» шигырендә алынган эпизодик детальләрнең идеяне ачарлык яклары калкулатылмаган, шулай ук алар артык күбәеп тә киткәннәр. Бирелә лирик герой «Революция утын аталардан да көнләшеп» йөри, «Освенцимнар мичләрендә кара күмергә дә әверелә», «фашизмны да җиңә», «сугыш кырыннан төзелешкә кайтып»та эшли,

...Без комсомол белән чирәм сөрдек...—
Язып китсәң, эш күп каләмгә.
Безнең буын яңа чорны ачты,
Юллар сызды ерак галәмгә, —

ди автор һәм яшьтәшләре турында:

Венерага карап очкан чакта,
— Ай, бил сызлый,— диеп әйтмәсләр,—

дип тәмамлый шигырен.

Автор бик күп нәрсәләр турында сөйләде, ләкин укучы яхшылап бер генә детальне булса да тотып кала алдымы икән?

«Безнең чор», «Бәлки артык сине мин очратмам», «Әйе, мин үзем дә солдат идем»... шигырьләрендә дә детальләр я күбәеп киткәннәр, я аларны автор тиешле урынга куя алмаган.

«Әнвәр Давыдов күп кенә шигырьләрендә һәм строфаларында аерым вакыйгалар-

дан алган тойгыларны билгеле бер идея итеп ахырынача оештырып бетерә алмый, аның әйтергә теләгән фикере поэтик детальләр, катлаулы хис ассоциацияләре астында югалып кала»,— дип язды Р. Башкуров «Олы мәхәббәт» рецензиясендә, һәм шунда ук кайбер очракларда детальләрнең үзара дисгармонияләнүләрен дә әйтте. («Совет әдәбияты» журналы, 1960 ел, 11 сан, 123 бит.) Бу фикере белән тәнкыйтьче тулысынча хаклы. Дөрес, Ә. Давыдов күп детальле шигырьләрдә туа торган мондый кыенлыкны җиңү өстендә туктаусыз эшли, эзләнә. Аның соңгы шигырьләреннән детальләр дисгармониясенә мисаллар табу һаман кыенлаша бара.

Ә. Давыдов — «җирне тетрәндергән чор давын» җырлаучы шагыйрь. Ул тормышның тирән катламнарын ачып карарга, төрле күренешләргә карата фәлсәфи фикерләр йөртергә омтыла. Аны аеруча туган илебездә барган гигант төзелешләр, аларның киң колачлылыгы дулкынландыра. Шагыйрь шул төзелешләрнең гомуми фонын шигырьгә сыйдырырга тырыша. Моның өчен, беренче чиратта, сынландырулардан файдалана.

Монда зур йорт күтәрелә җир астыннан...
Тегендә яңа тәрәзәдә нурлар сынган,
Монда яңа һәйкәл мәһабәт басып тынган.

. . . .

О, яратам мин бу хезмәт патшалыгын.

(«Хезмәт патшалыгы».)

Яңа зур йорт, һәйкәлләр аша күз алдына җанлы булып азат хезмәт картинасы гәүдәләнә.

Бу гигантлар эчендә төзүче кеше югалып калмый, киресенчә, фон зураю белән ул да зурая, мәһабәтрәк була бара.

Тормыш һаман, һаман биегрәк
Күтәрелә Урал сыртына.
Шушы трамплиннан инде кеше
Галәм киңлегенә омтыла, —

ди шагыйрь «Урал колачы» шигырендә. Бу — илебезнең гаять заманча сынландырылган техника үсеше. Аның заманча булуы Хәсән Туфанның 20 нче еллардагы Уралы белән чагыштырганда аеруча сизелә.

Кыңгыр яткан Урал
Чилем тарта.
Чилем сабы — озын таш торба;
Билгә кат-кат рельсе билбау урап,
Күпер белән муенын каптырган.

(«Еллар итәгендә».)

Ике шагыйрьнең Уралны сынландырудагы аермалары аша совет кешесенең хәзерге вакыттагы гаҗәп дәрәҗәдәге үсешен күрәбез.

Автор үзе кулланган сүзләрнең күбесенә символик мәгънә бирергә тырыша. «Тынычлык», «Хезмәт», «Ил», «Бәхет», «Тормыш», «Омтылыш», «Матурлык», «Коммунизм», «Кеше» һәм башка шундый сүзләр Ә. Давыдов поэзиясендә гомумиләштереләләр һәм баш хәрефләр белән языла-лар.

Әйе, партиябез Программасындагы бу сүзләр, бөтен кешелекнең теләк-уйларын белдерүче символлар буларак, поэзиягә күчәргә бик хаклылар һәм шагыйрь аларның шул үзенчәлекләрен уңышлы файдалана. Ә. Давыдов халыкта эшкәртелгән образ-символларны да, үзенә генә хас булган символик мәгънәле сүзләрне дә шактый күп куллана. **Ак күгәрчен** — тынычлык символы:

Зәңгәр һавага ак күгәрченнәр
Күтәрелә шунда, ялтырый канатлар.
Ышанам, дуслар, илем ел саен
Язны шушылай тыныч кабатлар.

(«Безнең яз».)

Ә. Давыдов, геройлары хәрәкәт итә торган фонны зур килеш алып, киң полотнода күрсәтә дигән идек. Фон зур булгач, герой үзе дә зурая дидек. Авторның шушы зурайтуда өстәмә чарадан — гиперболадан ничек файдалануына тукталыйк.

Мин беләмен, шулай мең-мең ел
Барырбыз без икәү елмаеп, —

ди «Чорлар чатында» поэмасының лирик герое.

Кешенең физик яктан мең яшь яши алмавын исбатлап торасы юк. Ләкин ил бәхете белән канатланган, мәхәббәт хисләреннән исергән лирик геройның «мең ел шулай барырбыз» дип әйтүе бер дә гаҗәп түгел.

Бу караңгылыкны
чакма чагып кына
җиңү юк.
Миллион күңелләрдән
чаткылар җыеп
һәм ялкынлы кылыч итеп
бөек Ленин
төшерде
шул караңгылыкның
бер читен кыеп!

Метафорик гипербола аша автор юлбашчының массалар белән бәйләнешен, аның эшенең җиңелмәслелеген бер строфада ук җыйнак кына әйтә алган.

Гиперболаның киресе булган литота, бер яктан, совет кешеләренең уңышларын тагын да зур итеп күрсәтү өчен файдаланылса, икенче яктан, Октябрьгача тормышның нинди авыр булуын күз алдына китерергә булышу өчен кулланыла. Бер-бер артлы тезелеп торган гигант шәһәрләрне, язын калыккан бәбкә үләне турында сөйләгәндәй, «шытып чыккан» дип әйтү совет халкының гомуми уңышларының бихисап зурлыгына ишарәли.

Капиталистик җәмгыять черүгә йөз тотканда, коммунизмның туып килә торган, зур киләчәкле җәмгыять булуы гипербола белән литотаның икесен бер строфада куллану аша ачылган.

Мең-мең люстралар яктысында
Капитализм череган чагында,
Коммунизм Ленин акылы белән
Бөреләнгән шул шәм алдында.

(«Шәм турында».)

Әнә шул рәвешчә, Ә. Давыдов кирәк урында объективны я гигант кинлектә зурайта, я кечерәйтә, ә әйтергә теләгән фикерне турыдан-туры әчүдә катнашмаган күренешләрне гомуми планда гына күрсәтеп уза. Шуның белән лаконизмга ирешә.

Инде килеп, Әнвәр Давыдов поэтикасының иң үзенчәлекле сыйфатларыннан берсенә, аның ритмикасына тукталыйк. Көйләм шигырен сөйләмгә якын интонацияле итүдә Дәрдмәнд, Һ. Такташ, Ф. Кәрим һ. б. шагыйрьләрнең традицияләрен дәвам итүчеләрнең берсе — Ә. Давыдов дисәк, хата булмас. Кайсы гына шигырен яки поэмасын алып карасак та, шагыйрьнең кешеләрне, аудиторияне күздә тотып язуын сизәсең. Хәтта интим шигырьләрендә дә ул кемгәдер эндәшә, кем беләндер киңәшә. Ялгызлык — шагыйрьнең дошманы. Коммунизм төзүче совет халкы белән ул һәрвакыт бер яктан атларга тырыша. «Стеналарым» шигырендәге

Юк, юк,
дуслар,
шагыйрь өчен
тавыш изоляциясе кирәкми! —

дигән юллар авторның үзе турында язылганнар. Шагыйрь еракгагы һәм якындагы кешеләргә дә, дусларына, замандашларына да, төрле предметларга да, җырларына да, үлемгә дә — бик күп нәрсәләргә мөрәҗәгать итә.

Үпкәләмә, Пушкин, кичер, Тукай,
Дөрес аңла, Маяковский,
Миңа үрнәк хәзер башка шагыйрь,
Шигърият миңа ул өсти,

Совет халкы ул! Галәм дәфтәренең
Иң беренче чиста битенә
Үрелеп язды матур, утлы юллар,
Укый-укый күңел сикеренә.

(«Мин бу җирнең иң җыр шагыйремен».)

Лирик шигырь бу. Ә шунда да шагыйрь үз эченә генә бикләнмәгән, ул коллегаларына эндәшә, алар белән хисләрен уртаклаша. Ә. Давыдов шигырьләренең күпчелеге кем беләндер, нәрсә беләндер сөйләшү алымына корылу аларның интонациясе дулкынланулы сөйләмгә якын булуны таләп итә дә инде. Ә шигырьне сөйләмгә якынайту үзе тагын бик күп ритмик чаралар куллануны сорый. Шигырьне сөйләмгә якынайту чараларының берсе — бер синтагмадагы сүзләрне аерып, ике юлга язу, ягъни күчерү алымы. Болай эшләү сүзләрнең эмоциональ көчен, мәгънә авырлыгын зурайтуга, ахыр чиктә, идеяне тулырак бирүгә кайтып кала.

Миллион чакрымнар, мең еллар
Артына яшеренгән б и л г е с е з л е к
А ч ы л ы р.
Балкыр яңа таңнар.
Кешелек өчен
Яулап алыныр чын-чын үлемсезлек.
. . . .
Дәһшәтле у т л ы к о р а л л а р
Ә з е р л ә ү ч е шашкан агрессор
Бәлкем, бу таңда шуны аңлар:
Тормыш, тормыш, тормыш галибәнә
Тормыш атлый бөтен галәмгә!

(«Чорлар чатында».)

«Билгесезлек ачылыр», «Утлы кораллар әзерләүче агрессор» сүз тезмәләре поэма идеясен әчүдә турыдан-туры катнашалар. Шуңа күрә шагыйрь, һәр сүзнең мөстәкыйль басым белән әйтелүләрен тәэмин итү өчен, аларны шигырь юллары ахырында аерган. Сүзләр мәгънә төсмеренә бай ый төшкәннәр, моннан тыш, аларның күчерелүе тормышның алга таба тыелгысыз хәрәкәтен, хәрәкәтнең эзлеклелеген дә сизем-ләргә ярдәм итә. Шул ук поэмадагы тагын бер мисалны алыйк:

Ә кайдадыр,
шул төзелешкә төзәп,
һәлакәтле
Ракет
Коралар.

Бездәге гигант төзелешләр турында сөенә-сөенә сөйләп килгән герой уйчанлана, империалистларның шундый акылсызлыгына гаҗәпләнү катыш нәфрәтләнә. Бер синтагманы өч юлга бүлү әнә шушы тәэсъратның тулысы белән бирә алган. Моннан шулай ук агрессив әзерлекнең вакыт ягыннан инде күптән башланганлыгы да сиземләнә.

Шигырь интонациясен дулкынланулы сөйләм интонациясенә якынайтуда, көйләүдән качуда Ә. Давыдовның үзенә генә хас тагын бер алымы бар. Бу, әгәр шулай әйтергә яраса, «абындыру» алымы. Ә. Давыдов шигырьләрен укыганда тигез генә интонация белән баштан ахыргача барып булмый. Автор, укучының көйләп укуын бозу өчен, ясалма кытыршылыклар тудыра, абындырып-абындырып куя. Моны ул шигырь юлындагы буыннарның табигый урыннарын алыштыру юлы белән эшли. Менә бу строфаны көйләп укып булмый инде:

Тар сандыкка гына сыешмыйлар
Б е з н е н и с к и т ә р л е к м ә һ ә р л ә р.
Көрәш белән үткән һәрбер карыш,
Бергә сугышып алган шәһәрләр;

(«Нинаги»)

Строфада «абындыру» икенче юлда эшләнелгән. Ритмик дулкынны тигезләү өчен, үз урыннарыннан алынган буыннарны тәртипкә китереп укып карыйк:

Искитәрлек безнен мәһәрләр.

Бу юлны үз урынына куеп укып карасак, строфаның тәүге көче шактый кимегәнен күрербез. Сәбәп нәрсәдә соң! Түмгәклерәк җирдән баручы кеше, аяк астындагы җиргә игътибарлырак була бит. Димәк, «абындыруларны» шагыйрь әнә шул максаттан чыгып эшли икән. «Абындырулар» кайбер очракларда стиль төгәллеген саклау өчен дә кулланылалар. Буыннарның урыннарын алмаштырмаганда, «Чыктым аркылы күпер» шикеллерәк «җөмлә»ләр барлыкка килү куркынычы булса, авторга теләсә-теләмәсә дә укучыны «абындырырга» туры килә.

Шуны да әйтергә кирәк, шагыйрь «абындыру»ны строфада күбрәк беренче юлдан түгел, аннан соңгы юлларда гына эшли. «Абындыру» беренче юлда ук булса, шигырьне уку кыенлашыр иде. Ә бер энергия алгач, абындырулар укучыны юлдан туктата алмый, бәлки, укуны беркадәр акрынлата гына.

Ә. Давыдов ритмикасында иҗекләр санының төгәллеге дә һәрвакыт сакланмый. Шагыйрь кеше психологиясендәге каршылыклы хисләрне, катлаулы тормыш күренешләрен мөмкин кадәр тулырак бирергә тырыша. Бу юлда иҗекләрне беркадәр арттыру яки киметү, артык буыннар өстәү, яки төшереп калдырулардан да тайчынмый. Югыйсә, «Кайвакытта юллар санының төгәл үлчәнгән булуы лаконизмга ярдәм итсә дә, еш кына образлы итеп бирүнең сәнгатьчә мөмкинлекләрен азайта, кайчак исә бөтенләй юкка чыгара». (Р. Бикмөхәммәт. Поэзиябезнең сулмас чәчәкләре. Казан. 1960. 28 бит.) Бу фикерне иҗекләр санына карата да әйтергә була. Шигырь үлчәмен бозудан куркып, иҗекләре артык булган өчен генә иң кирәкле сүзләрне төшереп калдыру, әлбәттә, шигырьнең идеясенә кимчелек китерәчәк.

Шигырьне дулкынланулы сөйләм интонациясенә якынайтуда эшләнелгән чаралар, ягъни артык иҗекләр, буыннар кертү яки иҗек һәм буыннарны төшереп калдыру, «абындыру»лар барысы бергә ритмик дулкынны бозалар. Ә ритм, Маяковский әйткәнчә, шигырьнең төп көче, төп энергиясе ул. Ә. Давыдов моны яхшы аңлый һәм ритмны тигезләү чаралары эзли. Профессор Х. Госман бу мәсьәләгә карата мондый фикер әйтә: «Интонация хакына строфадагы симметрияне җимергәч, тигезсез кисәкләрне ритмик яктан тигезли торган чаралар да кирәк. Бу чаралар элек-электән телнең үзендә дә, шигырьләрдә дә объектив мөмкинлекләр буларак яшәп киләләр» (Х. Госман. Татар шигыре. Казан. 1964 ел, 99 бит). Мондый чаралардан ул бигрәк тә ялгауларны, эндәш һәм сорауларны күрсәтә.

Ә. Давыдов поэзиясендә эндәшләрнең күплеге югарыда әйтелгән иде инде. Ялгаулар исә Ә. Давыдов тарафыннан аз, анда да ритмик тигезләү чарасы булудан битәр, нәфисләү чарасы буларак кына файдаланылалар.

Ә. Давыдов шигырь ритмын тигезләү өчен артык буын яки иҗекләр өстәләчәк юл алдындагы юлны беркадәр кыскарак итә. Бу кыскарту аннан соңгы артык иҗекләрне яки буыннарны «йотарга» җиңеллек тудыра.

Тарихта
 булган
 шундый
 көннәр, =9
Карыйсың шактый исең китеп, =9
Саклый аларны кешеләр =8
И с т ә л е к и т е п. =5
Шундыймы Октябрь
 Аның турында да бүген =14
Әйтикме:
 «Булган дип шундый заманнар...» =11

(«Октябрь».)

Мисалдан күренгәнчә, ритмик үлчәм артыр алдыннан килгән юл дүрт иҗеккә кыскартылган. «Шундыймы Октябрь?» дип кычкырып сорау да ритмик сикерешне тигезләргә ярдәм итә, әлбәттә. Мондый мисалларны Ә. Давыдов шигырьләреннән теләсәң күпме китерергә мөмкин.

Давыдов шигырьләрен укыганда, үзең дә сизмәстән, урын-урыны белән я бик тиз укыйсың, я ирексездән акрынаясың. Бу, бердән, хис, тойгы таләбе белән эшләнелсә, икенчедән, автор тарафыннан оста кулланылган ритмик дулкынны тигезләү чаралары тәэсиреннән килеп чыга. Бу чараларның берсе итеп, шигырь юлларын баскычларга бүлүне күрсәтергә була. Ләкин шагыйрь баскычларга гына ышанып бетми, шигырь синтаксисына мөрәҗәгать итә. Тиңдәш кисәкләрнең һәрвакыт санау интонациясе белән әйтелүләрен, ягъни мөстәкыйль интонацияләре булуны исәпкә алып, Давыдов аларны строфага күпме тели, шулкадәр кертә. Алар баскычларга бүлсәң-бүлмәсәң дә, пауза аша укылалар һәм никадәр сузганда да, ритмик кытыршылык тудырмыйлар, әйткәнебезчә, алар мөстәкыйль интонацион агымга ия булалар.

Түбәндә китереләчәк юлларда иҗекләр саны гаҗәп төрле. Әмма санау интонациясе ритмик кытыршылыкны сиздерми, томалап кита. Шигырьдә сүз робот турында бара.

Ул кайсы илләргә
һәм кайсы елларга барса да, —
ком чүле һәм далада
тормышка туарга,
кешеләрнен йончылган битеннән
тирләрен юарга,
халыклар муенына автомат кулын
сузган...

(«Акыллы машина».)

Тиңдәш кисәкләрне мул куллану шагыйрьгә тормыш күренешләренең, характерларның тирән катламнарын күтәрып чыгарырга мөмкинлек бирә. Җөмләдә идея ачуда турыдан-туры катнашучы сүзләрнең ишләрен, әлеге сүз биреп бетерә алмаган мәгънә төсмеренә ия булган башка сүзләрне эзләү тиңдәш кисәкләрнең күплегенә китерә, ә кайбер очракларда алар синонимнар булалар.

Сугыш һәлакәте,
Халыклар хәрәкәте,
Җимерү,
Төзү тетрәнүләре белән
Я ш и,
С у л ы ш ы н а л а б у Җир шары.
Сулышы кинәюеннән
өзелә,
т е т е л ә бара
Күгәреп беткән коллык чылбырлары.
Җир әрнеше,
Җир хурлыгы —
коллык.

(«Чорлар чатында».)

Җир шарында барган бөек үзгәрешләр, аларның тынгысыз һөҗүмчәнлеге, тарихи закончалыгы, эзлеклелеге тиңдәш кисәкләр һәм синонимнар аша тулы бер картина булып күз алдына килә. Ә тиңдәш кисәкләрне төшереп калдырганда, гәрчә шигырьдә иң күп мәгънә төсмерен җыйган сүз калдырылса да, бу картинада буяулар бик нык ярлыланыр, аның эмоциональ тәэсир көче бермә-бер кимер, нәтиҗәдә, идея дә укучыга тулы барып җитмәс иде. Авторның «Нигә?» поэмасындагы, «Гаҗәп», «Үтте инде» һ. б. шигырьләрендәге тиңдәш кисәкләр турында да шул ук фикерне шикләнмичә әйтергә мөмкин.

Ритмик дулкынны тигезләү өчен кайбер очракларда Ә. Давыдов интонациянең тизлеген арттыра. Болай эшләү бүселеп-бүселеп торган артык буын һәм иҗекләрне, ритмик агышка зарар китермәсен өчен, җыеп алуны тәэмин итә. Тизләтелгән интонациягә күчүне шагыйрь төп ике алым белән эшли: 1) тизләтергә кирәк булган юлларны цезураларга бүлми һәм 2) күчерүләр ясый.

Күчерүләрне шагыйрьнең идея максатыннан чыгып куллануына тукталган идек. Синтагмадагы сүзләрне ике юлга аерып язу аларның икесенә дә мөстәкыйль авырлык бирә дигән идек.

Бер синтагмадагы сүзләрне аерып куйсак та, алар интонацион яктан бер-берсенә тартылалар, табигый бөтенлеккә омтылалар. Әнә шушы омтылыш шигырьне уку темпын тизләтүгә китерә дә инде.

Мисал өчен:

Хәтеремдә шаулы яз көне, =9
Беренче кумәк б у р а з н а =8
С ы з а р г а дип китүе һәркемнең. =10
Камышлы тынды беразга. =8
Шунда М и ң н е ә х м ә т к у ш т а н н ы ң =9
У р ы с к а п к а с ы төбенә =8
Җилфердәтеп кижеле ыштанын =10
Җыелган кешеләр күренә. =9

(«Хатын-кызларга».)

Биредә тизләтелгән интонация, бердән, хис таләбе буенча барлыкка килсә, икенчедән, шагыйрь тарафыннан аерылган бер синтагма сүзләренең бер-берсенә омтылуы нәтиҗәсе булып тора. Тизләтелгән интонация ике урындагы артык иҗекне сиздерми йомып үтәргә мөмкинлек тудыра. Шулай итеп, Әнвәр Давыдовның көйләм шигыреннән сөйләм интонацияле шигырьгә бару юлында уңышлы эшләүче шагыйрьләрнең берсе икәнен күрдек. Интонацион шигырь төзүдә ул сүзләрнең укылышларын исәпкә ала, бер синтагмадагы сүзләрне төрле юлга язу, ягъни күчерү, цезуралар ясау, «абындыру», артык буыннар, яки иҗекләр өстәү, яки төшереп калдыру, үлчәмнәрне төрлеләндерү һәм башка алымнардан файдалана. Бу юлда, уңышлар белән беррәттән, җитешсезлекләрнең дә булуы сөйләнелде.

Интонацион шигырьдә ритмик төгәлсезлекләрне булдырмау өчен, шагыйрь шигъри эндәшләрне, сорауларны, кыскартуларны, шигырьне уку темпын тиңдәш кисәкләр хисабына акрынайту, көчәйтү хисабына тизләтү алымнарын куллана.

Җыеп кына әйткәндә, Әнвәр Давыдов заман белән бер аяктан атлау, тормыш, мәхәббәт шикелле мәңгелек темалар өстендә эшләү белән берррәттән, төп игътибарын бүгенге вакыйгаларга юнәлткән шагыйрь. Нинди генә теманы алмасын, ул аларга фәлсәфи якын килә, шагыйрь күзе генә күрә алган кызыклы ачышлар ясый. Заман каршылыкларын геройларының характерлар бәрелеше һәм герой психологиясендәге каршылыклы хисләр драмасы аша бирергә омтыла.

Ә. Давыдов поэтикасындагы үзенчәлекле яклар югарыда язылганнар белән генә чикләнмиләр, әлбәттә. Ихтимал, әле биредә күбесенчә өстәрәк яткан, күзгә бәрелеброк торган сыйфатлар урын алганнардыр. Аннары шагыйрьнең, бигрәк тә үсештәге шагыйрьнең иҗаты бер урында гына тормый, һаман алга бара, анда яңадан-яңа үзенчәлекле яклар арта тора бит. Ә. Давыдов — нәкъ менә шундый туктаусыз эзләнүче, үсүче шагыйрь.

Халык мәзәкләре

ТЕЛ ӨСТЕ — ЮЛ ӨСТЕ

Ике кодагый чәй эчеп утыра, ди. Кунак кодагый балны каерып каба икән дә:

— Бигрәк тәмле, кодагыйкаем. Авызга салу белән таралып китә, — дип мактый икән.

Кодагыйкаем «үзе туктый белер микән бу тәмле тамак» дип көтеп торган-торган да, ахры, түзмәгән:

— Кай җиреңә саласың син аны? — дип сораган.

— Тел өстенә салам, кодагыйкаем. Тел өстенә.

— Бигрәк тә юл өсте шул, — дигән тегесе көрсенеп.

ИЗГЕ КЕШЕ

Элекке заманда булган, ди бу хәл. Бер мулла күршесенең сыерын урлап суйган, ди. Сыеры югалган хатын, шикләнеп, мулла өенә кергән. Йорт хуҗасы намаз укып утыра икән.

«Сөбханалла, көр сыер, шушы бәладән котылсам, тагын суяр идем бер сыер», — дип пышылдый икән мулла әкрен генә.

Хатын карап-карап торган да: бу кадәр изге кеше юньсезлек эшләмәс, дип уйлаган һәм берсүз әйтмичә чыгып киткән.

ЕРТЫК ТИШЕКТӘН КӨЛӘ

Бер агайның хатыны бик шапшак була, хәтта өстенә кигән күлмәген дә ике-өч айга бер генә юа икән. Ә агайның андый эшләргә катнашып, вакчыл дигән исемне аласы килми. Шулай да бер көнне түзмәгән:

— Кара әле, Гайниҗамал, өстеңдәге күлмәгеңне юып кисәң иде ичмаса, кеше көлә бит,— дигән.

Тегe җавапка аптырап калмаган:

— Әй, юньсез, ертык тишектән көлә, дигәндәй, үзеңнең күлмәгең нинди соң, үзеңнекенә кара, — дип әйткән ди.

ӘДӘБИЯТ ТАРИХЫНА МАТЕРИАЛЛАР

ҺАДИ ТАКТАШ ХАТЛАРЫ

Такташның аерым кешеләргә язган хатлары ил буенча әллә кайларда таралып ята. Бу — татар совет әдәбияты фәненең зур кимчелеге. Ул хатлар, бер үзәккә җыеп алынмаганда, эссез-юлсыз югалырга да мөмкиннәр. Шушы кимчелекне бетерү юлында бер эш булсын өчен, без түбәндә шагыйрьнең кулга кергән хатларын басабыз. Аларның бер өлеше мәрхүм Мәхмүд Максудка, икенче өлеше мәрхүмә Гөлчәһрә Хәмзинага, калганнары шагыйрьнең үз туганнарына адресланган. Беренчеләре М. Максудның шәхси архивында саклана һәм журналга Гөлсем ханым Җиһаншина-Максудова тарафыннан тапшырылды; Сыркыды авыл Советына Габидуллага язылган хатларны һәм монда урнаштырылган фотоны шагыйрьнең улы Аван Такташ бирде; башкаларын исә Хатип Госман Татарстан дәүләт музее фондларыннан алып китерде.

Хатларга аңлатмалар Х. Госман тарафыннан бирелде.

Бер үк вакытта без укучыларга үтенеч белән дә мөрәҗәгать итәбез: аерым кулларда Такташның яки бүтән берәр язучының моңа хәтле матбугатта мәгълүм булмаган хаты яки нинди дә булса берәр язмасы саклана, журнал редакциясенә җибәрелсен иде. Журнал, үз нәүбәтендә, аларны басып чыгарачак.

Такташның моңарчы матбугатта чыкмаган фотосы.

Мәхмүд гакыллым!

Мин шулай киттем инде. Соңгы вакыттагы бераз рух төшенкелеге синең сүтенүенә сәбәп булган иде. Мин Фәхрелисламнан [1] акча ала алмадым. Аны Низамнан таптырдым.

Ул студент кеше, Тимер абый да аңа акчасын дүшәмбе көнгә алып бирергә тырышыр дип уйлыйм. Син инде минем соңгы сорауны үтә. Аңа дүшәмбе көнне үк акчасын алып бирегез. Мин аңар доверенность бирен калдырам. Подписемне син дөресләрсең.

Ул төрле кешеләрдән акча җыйды бугай.

Мәхмүд!

Син үпкәләмә, мин сиңа барын да әле язармын, яме.

Сау бул, ҺАДИ.

Хатның датасы куелмаган. Ул 1925 елда язылган булырга тиеш.

[1] Язучы Фәхрелислам Агеев булса кирәк.

9 октябрь, 1925 ел, Казан.

Мәхмүд!

Син кайткансың. Бер материал белән җибәргән ике сүзлек хатыңны алдым. Башка нәрсә юк. Сине сагынып беттем инде. Ләкин бу Мәскәүдә күрешкәндә мин ничектер синең яныңда үземне уңайсыз хис иттем. Әллә ничек син, Мәскәү кешесе булгач, бик гакыллы күрендең. Мин үземне бер дураграк хис иттем. Ни өчен, белмим, син минем шигырьне эштән чыгарып баскансың. Кыскартып эштән чыгаргансың. Мин сиңа киткәндә алай итмә, дип әйткән идем бит. Хәзер җибәрә торган нәрсәмне дә җибәрергә куркам. Ачуланып бөтен күләме белән «Татарстан»да бастырдым.

Нәрсәләр язасың?

Нигә озынрак бер хат язмыйсың? Мәскәүдән килгән хатлар безнең халыкка бик тансык. Синең хатлар — бигрәк тә.

Мин яңа гаскәрдән кайттым, шәпләндем. Тазардым. Рух бодрыйланды. Язуга дәрт бик зур да, бик... (сүз танылмый — ред.) — вак заботалар белән баш әйләнеп бетә. Кул тими. Акадцентр[1] мине өч айга ял итәргә рабочийлар арасына җибәрергә тора. Яхшы эш булыр иде. Казанда хәлләр бер төрле. Катын[2] укый. Мин эшлим. Журнал турындагы заметканы примем к сведению.

Хуш. Хат яз. ТАКТАШ.

[1] Ул вакытта Татарстанның фәнни эшләр үзәге. Җитәкчесе Г. Ибраһимов.
[2] Гөлчәһрә Хәмзина бу вакытта Казанда эшчеләр факультетында укый.

16 ноябрь, 1925 ел, Казан.

Мәхмүд!

Син миңа бер дә язмый башладың. Кайчакта синнән килгән хатлар рухны күтәреп җибәрә торган иде. Соң ничек яшисең? Бер дә язганың күренми. Бу — килешә торган эш түгел сиңа. Син матур язасың. Синдә — сине яратып, онытылып укучы мекләп кешеләрең бар. Шуларның берсе — мин. Алай бик прозага бирелмә. Әдәбиятта синең урының буш тора.

Мәхмүд!

Күңелсез вакытларымда минем башка һәрвакыт сиңа хат язу уе килә. Ләкин күп вакытта үземне көчләп тотып язмый каламын. Менә хәзер дә шулай, үзем белән тартыша-тартыша булдыра алмадым. Җиңелдем һәм яза башладым.

Мин үзем дә соңгы вакытларда бернәрсә дә язмыйм. Арыдым, Мәхмүд. Чөнки шигырь язуга китәргә тиешле энергия «Авыл яшьләре» журналына агрономический нәрсәләр (урлап) язарга китә. Бернәрсә эшләр хәл юк.

Яшәү өчен акча кирәк. Ә минем тормыш ягы бик авыр. Хәзер өйләнгән кеше бит. Табагачыннан алып себеркесенә кадәр кирәк. Гыйнварда бала да булачак. Аңарга да әзерләнергә кирәк. Ә минем эшләгән акча бик ничтожный. Теләсәң нишлә. Шулай шул. Башта эшләргә тиешле, язылырга тиешле планнар каһәр суккан тиеннәр турында уйләп таралалар. Кыскасы тормыш:

— Ата да бул, ир дә бул, яхшы шагыйрь дә бул, — ди.

Ә мин хәзерлексез авыл малае. Син аны беләсең. Ну чорт с ним. Халык, ялан аяк дип, хәзер көлеп йөрсәләр дә, киләчәктә мине ярлы булган дип хөкем итмәсләр, шагыйрь дип, үзләренең хөкемнәрен тудырырлар. Мин бу нәрсәләрне кемгә дә сөйләми, бары Мәхмүдкә — сиңа язам. Һәм бу хатны башка кеше күзе күрергә тиеш тә түгел.

Син үзең нәрсәләр эшләп ятасың? Яз, Мәхмүд! Синең язган әйберләр минем рухымны күтәрәләр. Нәрсәләр эшләргә уйлыйсың? Уку ничек бара?

Ну! Хуш. ТАКТАШ.

3 апрель, 1926 ел, Казан.

Мәхмүд!

— Кояш көлми дә, елмаймый да.

Чөнки ул синең кебек вечно шоколад ашап, авызын ерып йөрергә вакыт тапмый. Аның күзгә күз карашып утырып чәй эчкәндә көләргә хатыны да юк.



М. Максудка адресланган хатның фотокопиясе.

Ул ялгыз һәм көлми.

Аның эше дә күп.

Мәхмүд!

Ә без синең белән ике ачык авыз көләбез.

Шуның өчен дә мин сине өзелеп яратам. Син мәңге ачык — йөрәктән көлеп йөрисең. Шуның өчен дә мин синең хатларыңны яратып укыйм. Синең хатларны уку минем өчен матур бер шигырь уку белән бер. Шуның өчен дә мин сиңа хат язам.

Шуның өчен дә...

— Тфү!

Тәкрарлау киткән: картая башладым.

Мәхмүд!

Сиңа гел хат кына язып утырырга иде. Һәм шул хатларыңны бер жыеп бастырганда, гажәеп матур бернәрсә чыгар иде.

Соңгы вакытларда язасыңмы? Сине монда акадцентр язга ял итәргә жибәрергә йөри. Акча билгеләде бугай. Гариза язып жибәр. Мин үзем дә шулай итәм.

Сагындым үзеңне, күрешәсе иде.

«Безнең юл»ны [1] укып барасыңмы?

Анда минем «Нани разбойник» дигән нәрсәм басылган иде, үзем бик яратам. Син ничек карарсың. Язмый башладың бугай. Алай ярамый.

Мәхмүд!

Бу ел синең белән күрешәсе иде.

Мин сиңа ике сум илле тиен бурычлы бугай. Ничек түләрмен дип торам.

Үзем әле авырып кына тордым.

Шуның өчен баш кәбестә кебек таралган.

Казан үз эшендә.

Картлар

яшьләр әдәбиятын күмәргә тырыша.

Мәскәүдә дә шулай бугай.

Галимжан Нигъмәти [2] дигән халык хрестоматия чыгарганнар, яшьләрнең берәр әйберен дә кертмәгәннәр. Мәктәпләргә яңа әдәбият кирәргә вакыт иде.

Алай консерваторлык белән жинаятьләр эшләп ятмасыннар, әйт аларга.

Хуш. ТАКТАШ.

[1] «Безнең юл» — әдәби журнал, хәзерге «Казан утлары»ның 20 еллардагы исеме.

[2] Галимжан Нигъмәти — күренекле әдәбият галиме һәм тәнкыйтьче.

10 январь, 1927 ел, Казан.

Мәхмүд!

Хат язам, сагынып үзенне.

Син усаллангансың. Үпкәләгәнсеңдә диләр. Көлүен матур булса да, үпкәләүен ямьсез синең — хатларыңнан мәхрүм итәсең. Ә мин — синең хатларыңның поклоннигы.

Күнелемне күтәр. Матур гына бер хат яз.

Хәлемне Гөлчәһрә сөйләр.

Матур торам. Матур йоклыйм.

Төшләр генә ямьсезне күрәм. Иртәсе ничек булыр.

Кояшлы көннәр булсын инде дим.

Начальник булгансың. Шатланган идем. Мәскәүгә барып чыксам, аванс бирер, бер шагыйрь — начальник булды дигән идем.

Өмидем бушка чыга. Хат язмыйсың.

Казан — төкерми дә Мәскәүегезгә: сездә булган нәрсәләр бездә дә бар. Анысы белән ялындырмасагыз да, хатларыгыз белән моңайтасыз.

Кышлар килгәч, гыйнвар булгач, каникулга кайта торган иден. Сөйләшәдер идек. Акча сорап ала торган идем, үзеңне яратадыр идем. Бу ел кайтмадың.

Көткән булсам да, кайтмадың, усал. Язлар килер. Бер хайтырсың әле, алла боерса.

Язарга уйлыйм. Синең язуны көтәм. Саргайттың инде көттерә-көттерә. Конфет ашап йөрүдән үзең ләззәт тапсаң да, безнең күнелне күтәрә торган шигырь-нәсерләренне сирәкләдең.

Яз. Моңайтма.
Сагынам үзенне.
Бәхиллек (?) теләк!
ТАКТАШ.

Сентябрь, 1927 ел, Свияжск.

Хәнифә! [1]

Җаным, сиңа сәлам. Без Свияжскида. Казанга бер дә барып булмый. Шулай да шул көннәрдә барып чыгармын. Сездә ни хәлләр? Бала исәнме? [2] Гөлчәһрә Мәскәүгә киттеме? Ничек торасыз? Акча ягы ничек үзегездә? Журналдан барып алып, өйгә [3] җибәрсәң — яхшы булыр иде. Яки Гөлчәһрәгә бик тиз хат языгыз. Мин Татиздаттан алырга доверенность җибәрермен. Шуннан алу белән унбиш сум җибәрерсез. Йөрәк әллә ниләр өчен шул кадәр өзелә. Их, Хәнифә! Каһәр суксын семьясын да, чәнчелеп китсен бар да. Әниләр шундый авыр хәлдә булганда, күп, әллә күпме акча алып та, җибәрә алма!

Бик газапланам, тиздән Казанга кайтырга да, әниләргә акча җибәрергә ашкынам. 26 ларында, бәлки, бөтенләй китәрмен.

Бик тиз хат яз. Абыең ТАКТАШ.

Адрес:
г. Свияжск. Гайнутдиновская, 263. Ред. газ. «На походе» ТАКТАШУ.

Хатның датасы куелмаган. Шагыйрьнең 1927 елгы көзге хәрби маневрларда катнашуы вакытында язылган. Маневрлар сентябрь башыннан сентябрь ахырына кадәр дәвам иткән. Хатның төп нөсхәсе Татарстан дәүләт музеенда 9796-I номер белән саклана. Такташның музейдагы башка хатлары 101593, 101591, 9796-4, 9796-3, 9784, 101589, 101590 номерлары белән саклана.

[1] Хәнифә Хәйрулла кызы Такташева — шагыйрьнең сеңелесе. Ул чагында абыйсында торып, Казан медицина техникумында укучы. Хәзер Казанда яши.

[2] Шагыйрьнең беренче улы Рафаэль. Бөек Ватан сугышыннан соң Мәскәүдә живопись буенча художество академиясен тәмамлады, аннан соң, аспирантура бетереп, Суриков иҗаты турында кандидатлык диссертациясе яклады. Рафаэльнең рус классик һәм совет живописе турындагы гыйльми хезмәтләре үз илебездә рус телендә, шулай ук ГДР да немец сәнгать журналларында басылды. Хәзер Ташкентта Үзбәкстан фәннәр академиясенең Сәнгать институтында гыйльми эшче.

[3] Ягъни Сыркыдыга, әти-әнисенә.

М. Максудка адресланган открытка-хат.

5 июль, 1928 ел, Казан.

Мәхмүд!

Балык җибәрә алмадым. Астрахань безне бик әйбәт каршыласа да (мәгънәви яктан) [1], мадди яктан күп бирмәде. Чөнки кичәне 9 рабочий районда үткәрергә туры килде. Казанга бер тиенсез килеп чыктым. Синнән алган акчаны да бирми киттем. Мена хәзер иска төште дә, нервничать итә башладым. Син балык көткәнсендер.

Астраханьда үзем балык тотмакчы идем дә, тотып булмады. Син минем теге «Кызыл Татарстан»да язган чепухамны укып та сүгенгәнсендер. Редактор баскач, язган идем инде шунда.

Тимербай әкәгә көтмәгәндә сәламемне әйт. Мин аның белән күпләп сөйләшеп тә утыра алмадым.

Мәхмүд!

Ялкауланмасаң, ачуланмасаң хат яз. Үгетләп язган хатыңны да бик кыйммәтле бер язу итеп көтәрмен.

Ә беләсең, мин ни өчендер бу юлы Мәскәүне бик сагынам. Ә Казаннан артык туйдым.

Сау бул, Мәхмүд. ТАКТАШ.

---

[1] **1928 елның июнь аенда Һ. Такташ һәм Г. Минский Астраханьга укучылар белән очрашу командировкасына баралар һәм анда берничә әдәби кичә үткәрәләр. Бу сәяхәт турында Такташның «Сагынылган җирләрдә» исемле зур гына очеркы бар («Кызыл Татарстан» газетасы, 1928 ел, 29 июль).**

4 август, 1928 ел, Казан.

Мәхмүд!

Вобла алып кайтам дигән идем. Кайта алмадым. Мәскәүгә дә керә алмадым. Сине дә тагы күрә алмадым. Урамнарда да йөри алмадым. Коньяк та эчәсе илек. Тагын, очрасак та, эчмәбез.

Мин сине Казаннан — читтән торып кына ярата алам. Янында үземне начар хис итәм. Мин сиңа бу хакта әйткән идем инде. Синең белән бергә булганда, мин әллә нигә

артык уңайсызланам. Сине зурлыйсым килә. Синең зурланасың килми. Синә җылы сүзләр әйтәсем килә. Син алардан көләсең. Синең белән иптәшләрчә сөйләшәсем килә, ә син миңа шул чакта миннән күбрәк белгән абый булып күренәсең. Шуның өчен уйлабрак, кирыкны тоттырмаслык итебрәк сөйләшергә башлыйм. Үзем күзеңә туры карый алмыйм. Кулларымны кая итәргә белмим үзем. Тагы бернәрсәң һәрвакыт мине начар положениедә калдыра. Мин Мәскәүгә барган саен акчасыз хәлдә барам. Синнән акча алам да тули алмый китәм.

Бер акча белән барырмын. Сине үзеңне вобла белән генә түгел, асетрин белән сыйлармын. Тәмәке дә үзем алырмын. Столовойга кергәндә дә үзем түләрмен. Трамвайга утырсак та, сине буш итәрмен. Ничек тә киләчәк очрашуда күзеңә карап сөйләшермен.

Син усал үзең. Гәзиттә сүгәсең. Хатында чәчләрдән сыйпыйсың. Ачуланмыйм. Янымда утырып сүгүдән, гәзиттә уку минем өчен яхшырак. Тавыклар турында биргән справкаларыңны иҗадымда түгел, «Азат хатын» журналында файдаланырмын. Авыл хатыннарына синең ул гакыллы справкадан күбрәк файдаланырга туры килер.

Синең хатны уку алдында гәзитне укырга туры килде.

Толымбай:[1]

— Такташ, син нарошный шундый нәрсәләр язасың — шауласыннар, синең хакта сөйләсеннәр өчен, — ди. Дивана. Сүгелер өчен «нарошный» шундый нәрсәләр яза ди кеше.

Астраханьга бардым. Җанга азык теләп йөрдем юлларда. Юлда исереп йөргән йөрәк бернәрсә дә алып кайта алмаган. Пахмилиясен шуның уздырам. Тагын китәсе иде. Күбрәк йөрисе иде. Иөрәктә еллар буе әчеп йөргән хисләр саф һава белән таралсын, көнелдәге Казан рожаларын җанга якын кешеләрнең йөзләре алмаштырсын иде, Мәхмүд.

Бездә Горький хәзер[2]. Кичә күрештек үзе белән. Кул чабып куллар авыртты. Бәхетле карт. Бүген татар журналистлары белән мәдәният йортында танышу мәҗлесе була. Казан шунда билет алыр өчен чабып йөри.

Горький минем кебек икән. Оялчан. Күзен кая итәргә белми.

Ярлылык зур.

Отпускадан кайткач, бурычка баттым.

Сездә[3] минем, сиксән процент исәбеннән, 140 сум акча аласым бар.

Син шул акчаны бик тиз, бик тиз җибәртә алмассыңмы? Алар, бәлки, минем иске договор буенча тотып калырга уйларлар. Ләкин алар ул китапны әлек тапсыннар. Мин «Давылдан соң» китабын алмаштырып, икенче китап биргән идем аларга. Алар шуны кая иткәннәрдер.

Үзләре ул мәсьәләне кузгатмасалар, син кузгатмый гына, тиз генә акча җибәрт. Мин Низам Арслановка доверенность җибәргән идем. Ул Мәскәүдә юк, күрәсең: җибәрми дә, хәбәр дә язмый.

Тагын хат язармын. Ә хәзергә хуш, «акыллым» Мәхмүд.

ТАКТАШ.

Акчаны хат алу белән үк җибәрергә кара. Ради бога.

Адрес шулай:

Казань. Кооперативная 41, кв. 1.
ТАКТАШ.

Хатны ике көн җибәрми тордым. Хәзер авырып киттем. Аяклар авырта. Докторлар, туберкулез костей булу ихтималы бар, диләр. Кавказга барырга кушалар. Бүген телеграмма белән акча соратып җибәрдем. Сездән. Ашыктырыгыз.

ҺАДИ.

[1] Гомәр Толымбайский — татар совет язучысы һәм тәнкыйтьче.

[2] Горький Казан журналистлары белән 1928 елның 4 августында очрашкан. Бу хат та шул көнне язылган, ләкин ике көн җибәрелми торган. Өстәп язган өлеше 6 августка туры килә.

[3] СССР халыкларының Мәскәүдәге үзәк нәшрияты күздә тотыла. Ул чагында анда татарча китаплар да басыла иде.

3 октябрь, 1928 ел. Казан.

Галя![1]

Ничек анларга?

Инде ике атна үтте. Синнән бер хәбәр дә юк[2]. Исәнлегең булмаса, иптәшләреңнән булса да яздырып җибәргән булыр идең. Әллә бик якын дуслар безне оныттырдымы? Мин инде дүртенче хат язам. Әни өч хат язып җибәрде. Җиде хатка бер җавап язу, минемчә, бик кирәк иде инде. Белмим, тагы нинди сәбәпләр бардыр.

Без исәннәр. Сине бик нык сагына башладым. Бүген төнлә төшләремә кереп беттең.

Рафус[3] йөри. Хәзер зур гына нәрсә эшләргә торам. Кичә шигырь белән романымның өч главасын яздым[4]. Роман булып чыгармы. Романның героинясына синең характерны салырга уйлыйм. Кайбер юлларын язам:

Коридордан басып Алсу килә,
Үзе көлә, үзе сөйкемле,
Үзе усал, үзе болай бер дә
Усал кебек түгел шикелле.

Үзе дәрес тыңлый, үзе бер дә
Тыңламаган кебек итенә,
Үзе профессорга карамый да,
Үзе аның борнын кәкре итеп
Төшереп куя дәфтәр читенә.

Үзе зачетларын әзерләргә
Барыннан да соңрак тотына,
Үзе әллә ничек зачетларын
Алдан бирә, алдан котыла!

Собраниегә бүген ул соң килде,
Әллә кайда йөреп кичеккән.
Үзе соңга калган, үзе әле
Көлә-көлә керә ишектән...

һәм башкалар...

Бу — берничә юл гына. Алсуны син итеп тәҗәссем итәргә[5] тырышам, ничек чыгар.

Казанда андый-мондый хәбәрләр юк. Шул ук акчасызлык. Юллар күренми әле.

Рафус исән. Хәзер шытырдатып ике телдә сөйли. Татарлар белән — гел татарча. Әбисе[6] белән генә русча сөйли. Әни һаман укуында дәвам итә.

Сине бик нык сагындым.

Шуның нәтиҗәсе буларак, романымны язганда гел синең рәсемең чуала.

Хат язмавың мине артык борчый.

Бик тиз, бик тиз хат!

Туныцны тиздән җибәрермен.

Хуш, сөеклем. ТАКТАШ.

(Татар театрыннан акча алуны Низамга[7] тапшырып яздым. Берәр эш чыгармы. Һади.)

---

[1] Галя — Гөлчәһрә Хәмзина.

[2] Г. Хәмзина бу вакытта Мәскәү дәүләт университетының юридик факультетында укый. Җәйге каникулдан соң, Казаннан Мәскәүгә китүе күздә тотылса кирәк.

[3] Рафус — Рафаэль.

[4] Хәзер без белгән «Алсу» поэмасын шагыйрь башта зур күләмле әсәр — шигъри роман итеп язарга уйлаган.

[5] Тәҗәссем итү — гәүдәләндерү.

[6] Тәрбияче әбисе истә тотылса кирәк.

[7] Низам Арсланов — шагыйрьнең ерак кардәше һәм кордашы, балалык һәм яшьлек дусты.

6 ноябрь, 1928 ел, Казан.

Сыркыды авыл Советына

Мин шул көннәрдә авылдан хат алдым. Анда минем өчен кызык һәм серле бернигә нәрсә укырга туры килде.

Өйдән язуларына караганда, минем әтигә кырык сум налог салынган. Шуның өстенә үндүрт пот икмәк бирергә язганнар. Бу нәрсәләр, билгеле, авыл Советы тарафыннан эшләнгән.

Мин бу хәбәрне уку белән сөаль алдында калдым. Авыл Советында утыручы кешеләр нинди статьяларга таяныл бу нәрсәне эшләделәр икән?

Минем әти белән әни — алар 100 процент хезмәт көчен югалткан кешеләр. Шуның белән бераз яртылаш минем, яртылаш Хафиз абыйның иждивениесендә яшиләр.

Авылда хәзерге көндә председатель кем? — Белмим. Кем булса да, миңа бу мәсьәлә турында катгый җавап бирергә тиешле:

— 65 яшенә җиткән, хезмәт көчен югалткан, яртылаш уллары иждивениесендә яшәгән кешене Сыркыды авыл Советы кулак дип саныймы? — Бу бер.

Икенче:

— Әгәр саный икән, авыл хуҗалыгы кодексының ничәнче статьясы буенча?

Өченче:

— Күпме десятина һәм күпме ашлык хисабына исәпләнеп бу кадәр налог салынган? Мин Сыркыды авыл Советыннан минем сорауларыма тизлек белән җавап бирелүне сорыйм.

Җавапның официальный рәвештә бирелүе тиешле. Чөнки бу мәсьәлә дөрес булса, ул Сыркыды тирәсендә генә калмый, югарырак органнарга китәргә һәм тикшерелергә тиешле. Мине бу мәсьәлә бер икътисади яктан гына түгел, бәлки, кайбер сәяси яклары белән дә кызыктыра.

ҺАДИ ТАКТАШ.

12 ноябрь, 1928 ел, Казан.

Сөеклем Габидулла!

Хат язмыйсың дип миңа үпкәләгәнче, эне кеше, үзең миңа язарга уйламагансың. Мине язу эше артык арыта. Шуның өчен күп вакытта яза да алмыйм. Бүген алган үпкә белән тулы хатыңны укып, яздым үзеңә. Мәскәүдәге синең белән соңгы күрешү миндә онытылмаслык тирән авыртулы бер тойгы калдырды. Син үзгәргәнсең. Яхшы якка үзгәргәнсең. Синең беркаян ярдәм алмый, ярлы студент булып укуың, бер стипендия белән көн итүең минем йөрәккә әрнүле хисләр тудыра. Сиңа үземнең ярдәм итә алмавым оятында кайчакта коры хат язарга да уңайсызланам. Мин, Мәскәүдән бирсәләр, бер ун сум гына Гөлчәһрәгә сиңа бирергә кушкан идем. Ул акча да алына алмады. Кулымда минем акча бик сирәк була. Өйдән зарланып хатлар язалар. Мин 2 ноябрьда аларга егерме сум акча җибәрдем. Алганнардыр. Ләкин шул көннәрдә тагын хат алдым. Имеш, әтиләргә 40 сум налог салганнар. Бу минем әниләрнең алдауларыдыр. Алай зур налог салырга һич мөмкин түгел. Бәлки, күбрәк акча җибәрсеннәр дигән хәйлә белән язганнардыр. Анда Мәрзия: «Мине кулак — бай кызы дип, мәктәптән чыгардылар», — дип яза. Монысына да ничек карарга белмим. Әллә андагы бер төркем хулиганнар, үч алабыз дип, шулай итәләр микән?

Ничек торасың? Зур акчасызлыктыр үзеңдә. Ах, Габидулла, белсәйдең: синең шулай ярдәмсез укуыңны уйлау нинди авыр миңа. Кайчакта күзгә яшьләр килә. Мәскәүдә минем «Күмелгән кораллар»ны куярга җыенулары турында ишеткән идем. Аны куйдылармы? Әгәр куйсалар, алардан миңа гонорар килергә тиешле. Син шуны белеп яз. Мин Гөлчәһрә белән икегезгә доверенность җибәрермен. Сез алып үзара бүләр идегез.

Үзем исән. Рафус үсә. Шул көннәрдә «Югалган матурлык» дигән зур драма язып бетердем. Аңласалар, зур дискуссия булырга тиешле. Ничшләр. Каникулга, әлбәттә, Казанга кил. Шунда «Югалган матурлык»ны да күреп китәрсең. Аны Академия театрында декабрьның 15—20 ләрендә куялар.

Тагын нәрсә? Хәнифә нигәдер, дөрестән дә, хатлар сирәк яза бугай. Аның да психологический ягы бар. Ул өй турында бик нык кайгырта. Әниләрнең начар хәлдә калуларына 60 процент белән үзен гаепле дип саный. Шуннан аңар язарга авырдыр. Шулай да, шул көннәрдә язып җибәрде. Хәнифә яхшы гына укып бара. Егетләр — артыннан күп йөриләр. Ләкин үзен бик выдержанный тота. Хәтта чакырып килгән егетләренә дә, өйдә юк, дип кенә кайтара. (Үземне берничә шулай итте. Абыең дигәч кенә чыкты.) Ул, билгеле, яхшырганнан яхшыра бара. Хәзергә хатымны шунда бетерәм. Үзең тизлек белән хат яз.

Я, хуш, кыйммәтлем.
Абыең ҺАДИ.

Декабрь, 1928 ел, Казан.

. . . .

Сагынып кешем ерак, шунда оча уйлар, йөрәк ярсуларын басалмыйм. Вәгъдәсез кыз [1], хатың кыска синең, җылы сүзләрең дә күренми. Онытырсыңдыр, ахры, безне шулай.

Җавабымны сиңа озакладым. Рәсемнәрне көттем. Җибәрәм. Рафус [2] матур төшкән. Сакла. Кисеп таратма син өчлек гомерне...

Рафус терелеп килә. Уйный, көлә. Матурайды тагын син киткәч. Ютәлләми хәзер. Аның өчен кайгырма син.

Без торырбыз шунда ничек тә. Үзең ничек? Кара... вәгъдәсезлек итмә, тәзәл. Хәтереңдә тот биргән сүзеңне! Күбрәк аша, йокла, матур төшләр керсен йокыңа.

Мин аз йөрим. Күбрәк эшлим дип утырам булмады. Булмә, сине югалтуга, монсу хәзер. Бушлык сизәм бүлмә эчендә. Әллә нәрсә шунда. Матур үткән ахры бергә торган гомеребезнең соңы. Әле күрешүгә дә ерак. Кыш та озын...

Язлар килер. Бергә булалмабыз. Сагындырдың инде әле дә.

Утын алдым. Ләкин күпкә җитмәс. Акча алып булмый. Аз алдым. Бер олау ул хәзер безнең өчен — бер атнага. Казан салкын. Утыз-утыз биштән төшми салкынлык. Ә мин туңмый йөрим. Өйрәндем дә инде салкынга.

Хат яз, көтәм. Тиз яз. Озын булсын хатың. Габидулла [3] хат язмый тора. Үпкәләде, ахры. Язмасын, мин дә язмам.

Сау бул,
үбәм сине!
Хат язганда китапның язмышын белдер! [4]

ТАКТАШ.

Хатның язылу көне куелмаган. Шулай да аның 1928 елның декабрендә язылган булуы ихтимал.

[1] Хат адресатсыз язылган. Ләкин аның Гөлчәһрә Хәмзинага икәне ачык аңлашыла.
[2] Рафус — Рафаэль.
[3] Габидулла — Һадиның бертуган энесе.
[4] Мәскәүдәге нәшриятта басылачак китабы күздә тотылса кирәк.

16 январь, 1929 ел, Казан.

Сөеклем!

Сиңа хат язарга утырдым.

Авыр үпкә, авыртулы якынлык хисләре белән язылган хатларың мине борчыйлар. Мин сиңа язган хатларымны әллә ышандырырлык итеп язмаганмынмы, әллә син үзең шулай иманыңны минем сүзләргә югалттыңмы? Ни булса да, бала турында язган сүзләремә, үзем турында язган сүзләргә ышанмыйсың төсле. Рафуш әллә кайчан терелде инде. Терелде генә түгел, шаярып, дөнья җимереп үсә. Син аны өзелеп сагынсаң да, аның син исеңдә дә юк. Йөри, шаяра, уйный.

Бүген дә менә ике хатыңны алдым. Алар, берсеннән-берсе уздырырга теләп, мине тиргиләр. Нинди шикләр ышанычсыз хисләр белән тулы ул хатлар.



Такташ хатының фотокопиясе.

Мин телем белән алдасам да, каләмем минем алдарга өйрәнмәгән. Мин алдап бер юл шигырь дә язганым юк. Менә шул мәңге алдаусыз каләмем белән сиңа язам. Рафушның исәнлегенә дә минем сиңа булган алдаусыз якынлык хисләремә ышан. Биш ел синең белән үткән сансыз минутлар мине сиңа өзелмәслек бәйләгән. Аларны син дә, мин дә өзә алмабыз.

. . . .

Ни булса да борчылма. Мин теләмәгән нәрсәне эшләүгә бер адым да эшләмә. Башыңа да китермә. Акча тиздән җибәрергә тырышырмын.

Казан син киткәнче ничек булса, шулай. 18 ендә минем «Югалган матурлык» куела. Менә шул нәрсә йөрәкне бик дулкынлата. Нәрсә булып чыгар. Нишләрләр. Ә впрочем, барыбер. Мин ул нәрсәне курыкмый яздым. Аңа булган тәнкыйтьне дә шулай бодро, куркусыз каршы алам. 13 гыйнварда Габдрахман Сәгъди хәсрәтләренең минем хакта докладлары булды. Ләкин докладны куркып ясады, буталды. Гомәр Гали, Кутуйлар бик нык тәнкыйть иттеләр. Кыскасы, бик нык төште. Докладчы вакытында зал гел көлеп барды. Сәгъдигә биргән сорауларына караганда, залның Сәгъдине никадәр тиле итеп санауын күреп була иде. Ул бик зур җиңелде.

Башка язар хәбәрләрем юк бугай. Син киткәннән алып әле серьезный эшли алганым юк. Эшкә һаман кайтып булмый. Йөрәктәниндидер яшерен дулкынлану. Впрочем, таныш дулкынлану. Эшләр-язар алдыннан булган хисләрнең уянулары алар.

Синең хакта һаман уйлыйм. Әллә ниләр уйлыйм.

. . . .

Миндә инде кызык бернәрсә башланды. Син киту белән минем хыялымда эшләнгән синең рәсемең урыныңны ала. Ул рәсем синең үз төсеңнән күп матур. Аңлыйсыңмы, минем хыялымда яшәгән Галя ул усал түгел. Ул мин теләгән минутларда мине ярата. Чәчләремнән сөя. Ул хрусталь кебек саф. Тормыштагы Галя кебек юк нәрсәләр өчен ачуланмый да, тиргәми дә... һаман минем хыялымда елмая. Матур, хыянәтсез, йөрәгемне дулкынлатып елмая. Син ташласаң да, ул ташламас. Син башкаларга алыштырсаң да, ул алыштырмас. Чөнки ул рәсемне мин үземнең хыял көчем белән тудырдым. Чөнки ул Галя минем иҗат юлымның һәрбер хәрәкәтенә буйсына. Ул Галя бары минеке генә, аны беркем дә күрми дә, беркем дә белми дә. Үлгәндә дә ул минем белән үләчәк. «Югалган матурлык»та мин аның шәүләсен генә бирдем. Андагы Галия хыялымдагы Галяның айлы төндәге шәүләсе генә.

Сау бул. Оригиналь калам.

Хуш. ҺАДИ ТАКТАШ.

Бу хатның төп нөсхәсе сакланмаган. Мостафа Ногман күчерүендә сакланган. Күчермәне Гөлчәһрә Хәмзина үзе раслаган. Күчермә СССР фәннәр Академиясенең Казан тел, әдәбият һәм тарих институтында саклана.

7 март, 1929 ел, Казан.

Иптәш председатель!

Бу елгы сайлауларда авыл председателе булып кем үткәндер, белмим. Мин моннан ике атналар чамасы (элек) Хәйрулла Такташевның ни өчен тавыштан төшерелүе турында сорап хат язган идем. Авыл Советы ул хакта, тиеш булса да, ни өчендер, җавап бирмәде. Мин икенче мәртәбә сорап язарга мәҗбүр булам.

1. Җитмеш яшьләргә басып килә торган, хезмәт көчен 100 процент югалткан әти. Шулай ук хәзерге көндә урында ятучы әни бу елгы сайлауларда ни өчен тавыштан төшерелделәр? Алар хәзер(ге) көндә коммунист уллары ярдәме белән яшәп киләләр.

2. Алар сәүдә итүдә гаепләнсәләр, налоговой управлениедән патент түләүләре турында справкагыз бармы? Яки патентсыз сәүдә итүдә гаепләнсәләр, налоговой управление тарафыннан протокол төзелеп, судка бирелүләре турында кулыгызда кәгазьләрегез бармы?

3. Әгәр борынгы вакытта (революциягә кадәр) «бай» дип саналып төшерелгән булсалар, Хәмзә Такташевлар белән Хәйрулла Такташевлар арасындагы мөнәсәбәт сезгә билгелеме? Минем әти Хәйрулла Такташевның, Хәмзәләрдән аерылгач, бер улын заводка (Хафиз Такташев Ленинградта Путилов заводы рабочие), икенче улын (мине) малай итеп кеше кулына җибәрүенең сәбәпләре авыл Советында эшләүчеләргә билгелеме? — Тизлек белән җавап бирүегезне көтәм. Хатны волокита эченә күмеп калдырмагыз. Мин апрель башында заграницага китү алдыннан округка барып кайтырга торам. Округка барганда, минем кулда сезнең җавабыгыз булырга тиешле. Мин избирком тарафыннан бу нәрсә ялгышлык белән эшләнгән эш дип уйлыйм. Җавап бирүне тизләтегез.

ҺАДИ ТАКТАШ,

29 март, 1929 ел, Казан.

Мәхмүд әкә!

Сиңа бер идеологический невыдержанный бер хат язып җибәргән идем. Гөлчәһрә аркылы. Ахры, эчеңне авырттырды. Җавап бирмәдең. Этләшергә калгач, тагын бер язам. Ачуына түзми бер язарсың әле. Мин хәзер безработный кеше. Акча юк, билгеле. Ун тиен көмешкә җанымны сатарга хәзер. Серьезно. Мин урыннан чыктым. Хәзер бер өч-дүрт ай язып торырга, Татарстан күләмендәге колхозларга барып йөрергә-торырга исәп. Сезгә басылып, таралып беткән нәрсәләремнән бер өч табак мәҗмуга төзеп җибәрсәм, басарсызмы? — Җавап бир. Тимербай абый синең кебек начар Мәхмүд түгел. Ул да карышмас, бәлки. Ах, Мәхмүд, каһәр, шулкадәр яратам үзеңне. Салам саплау түгел. Үпкәм генә бар үзеңә.

Хат яз. Элекке хатларың кебек матур яз. Синең соңгы «Музыка сөюче» дигән әйбереңне укып чыктым. Бик матур, бик гакыллы язылган. Стилеңдәге юмор оттеноклары әсәреңдәге тенденциозностьне дә югалткан.

Хатымны алу белән үк җавап яз. Мәҗмугамә түбәндәге нәсерләрне кертергә исәплим: «Кояш көлми дә, елмаймый да», «Кыш җыры», «Пожалуйста», «Протоколлар эчендә хикәя» һәм «Азат хатын»да басылган ике хикәя. Җавап бик тиз бир.

Сәлам белән ҺАДИ ТАКТАШ.

10 апрель, 1929, Казан.

Мәхмүд!

Бу хатны клиникадан язам. Ә клиникада күңелсез. Шуның өчен синең җавап хатыңны алу белән үк каршы язам. Гөлчәһрә миңа язган соңгы хатында:

— Син Мәхмүдне дустым, дустым дип йөрисең дә, ул монда сине сүгеп, яманлап йөрүдән башка нәрсә эшләми бугай. Шуның өчен хатыңны бирмәскә дип йөрим, — дип язган иде.

Соңгы чыгышларыңда да шундый ук яратмаучылык билгеләрен аңлаган идем. Хәерле булсын. Бөтен дөнья өчен бер бәлеш пешереп булмый.

Клиникадан чыккач, сина жыентыкны жибәрермен. Син мөмкин кадәр идеологический якка карамый гына жибәрерсен. Хәер, ул нәрсәләремдә идеологический як шәп булыр. Художество ягы гына әйбәт булмас. Договор Гөлчәһрә белән төзерсез яки 20 ләрендә Мәскәүгә үзем барырмын. Хатыңны латин хәрефе белән язгансың, мин Панаит Истрати[1] французча язып жибәргән дип торам. Без аның белән язышабыз. Ничек укыйм дип аптырап калган идем. Соңыннан татарча икәнен белдем. Уку жиңел булмады. Миңа, зинһар гарәп хәрефе белән генә язып жибәр әле.

Я, сау бул.
ТАКТАШ.

---

[1] **Панаит Истрати** — шул елларда Казанга килеп киткән грек язучысы.

7 апрель, 1929 ел, Казан.

Мәхмүд!

Өченче хатны язам үзеңә. Ә жавап язмыйсың. Кирәксез кеше булдым үзеңә. Ну ярый. Ни булса да көчләп булмый. Мин клиникада ятам. Сәламәтлек какшады. Әле билгеле түгел. Күкрәк авырта, изжога, тагын әллә нәрсәләр.

Син, бу кеше сафтан чыкты, хәзер хат язмасаң да була, дип торма. Терелермен. Үлмәм әле. Бик нык торасы килү үтермәс.

Ничек торасың? Жавап язмасаң да, тагын бернәрсә турында сорыйм. Мин бит хәзер эшсез ятам. Акча килер жир юк. Син бер өч табак минем басылган хикәяләремә урын бирмәссеңме? Болай, аптырагач кына сорау бу. Терелгәч, авылга китәргә исәп. Әгәр яхшы бер фикергә килсәң, шул турыда язып жибәр. Кирәк булса, адресны язам:

Казань, Кооперативная 41, кв. 1.

Мәскәүдә миңа яхшы хисле кешеләр булса, сәлам әйт.

Мин үземне яраткан кешеләрне яратам.

Сау бул.
ТАКТАШ.

Казан почтасы печатендә 1929 ел 7 апрель дип куелган.

9 август, 1929 ел, Казан.

Әти, әни, Мәрзиям!

Сезгә сагыну сәламнәре жибәрәм. Үзем дә, бала да, Гөлчәһрә дә сәламәтләр. Сезгә дә сәламәтлек телим. Гөлчәһрә белән Рафаэль Кырымга киттеләр. Мин дә бүген татар язучылары белән Кавказга, Кырымга китәм. Хатымны бик ашыгып язам. Кырым-Кавказдан кайтышлый авылга тияргә тырышырмын. Ничек тә. Үзем белән Рафаэль дә булыр.

Сезне, әти, әни, бик сагындым. Бу ел берәр елга авылга да кайтып торырга уйлаган идем. Кайтышлый өч-дүрт көннән артык торалмамдыр. Юлдан газитләр, хатлар жибәреп торырмын. Кыска язуым өчен зинһар, үтенәм, гафу итегез.

Радич мин барганчы торып торсын.

Күзләрегездән үбеп, якын, жылы йөрәк сәламнәремне жибәрәм.

ҺАДИ.

Габид!

Төшенке рух — авыр хисләр белән хат язасың. Жылы хисләр, якты уйлар иптәш булсын сиңа. Күңелсезләнмә! Все пройдет, все проходит. Тормышка бары тыныч күзләр белән генә карарга кирәк. Мин нинди авырлыкны үз итә алдым үземә. Дөнья матур, ләкин үзенең авырлыклары белән матур ул.

Син авылда мужик булып бетүең турында язасың. Это не беда. Ул гакыл эше өчен зур бер ял итү бит. Кыш килер, син тагын да йотылып укырга башларсың. Ә мин? Мин гакыл-хис эшеннән арыдым.

Өйдәге авырлыкларны беләм мин, Габидулла. Ләкин син якты киләчәгеннең тынычлыгы өчен шулай эшләргә тиешлесең. Әтиләргә-әниләргә бүгенге ярдәмең киләчәктә сиңа жан тынычлыгы;

— Картлык көчнәрендә ярдәм итә алдым,— дигән онытылмаслык жылы хисләр калдырыр. Мин әниләргә әз генә ярдәм иткән минутларымда бөтен нәрсәмне онытырлык жылылык алам. Ләкин күп ярдәм итә алмыйм.

Мона барысына да үзем гаепле. Мин күбрәк тә ярдәм итә алыр идем. Ләкин необузданная воля, которая владеет мною, киртә булып бара. Мин артык жиңел күтәрелдем. Шушы жиңеллек миндә безвнимательность дигән бер чирне тудырды. Артык бесхозяйственный мин.

> **Тәүфикъсызлык белән гомер узды,**
> **Рәтле кеше булып булмады,**
> **Әнкәй.**
> **Ул асрады,**
> **Ләкин**
> **Уңмады!**

Әнкәй генә түгел, мин үзем дә уңмадым... Үзем дә уңмадым дияр идем — гөнаһ булыр.

Мин хәзер, Габидулла, артык басылдым. Тормышка тыныч карыйм. Пессимист та түгел. Авыр уйлар гына күп вакытта йөзне караңгылый, әти-әниләрнең положениеләре, әле сезнең балалыктан чыга алмаулар, семьядагы кайбер авырлыклар күп уйлата мине, хәтта 70 процент энергия шуңарга китә.

Булмаса, дөнья шундый матур, Габидулла, мин әлеге яшемә кадәр аның бу кадәр матурлыгын сизә алганым юк иде — дөнья үзенең авырлыгы белән матур икән.

Соңгы язуларымда минем елмайган йөзем күпләргә күренерлек инде. Мин ялганламыйм. Чыннан да, елмаям, киләчәктә, бәлки, бик матур, бик шатлыклы көлә дә алырмын. Син әле яшь. Үзеңдә булган көч — академия капкасыннан кереп, бер курсын бетереп чыгу — синдә горурлык уятсын.

Бел, Габидулла!

Авыр адымнарны син батырларча атладың, ә соңгы дүрт баскыч сиңа яңа дөньялар ачар. Сине көләргә дә... (Хат язылып бетмәгән, шушында өзелә — ред.)

18 август, 1929 ел.

Сөеклеләрем![1]

Сезгә сагыну сәламнәре язам. Без 10 августта 18 татар язучысы Казаннан Идел белән, Астраханьга карап, юлга чыктык. Диңгез пароходы белән Махач-Кала (Бикәрскигә) килеп, икенче көн шунда уздырабыз. Бу шәһәрдә... әнинең кызы...[2] булырга тиешле. Адресы булмау сәбәпле, аны күрәлми китәм. Хатымны тауларга автомобильдә утырып китү алдыннан язам. Без 120 чакрымнар тауларга барып киләбез.

Кайту белән Бакуга утырып китәрбез.

Аннан Тифлискә, Батумга, Кырым, Украинага, Мәскәүгә барырбыз.

Мин Мәскәүдән, әлбәттә, авылга төшәргә тырышырмын. Заявлениене жибәрәм[3].

Хәнифә!

Бу хат белән медтехникумга хат язам, син мине көтми бар. Мин килгәнче анда тор. Мин, әлбәттә, бу мәсьәләне кайтышлый да әйтеп кайтырмын.

Хушыгыз.
ҺАДИ.

---

[1] Хат шагыйрьнең Сыркыды авылындагы ата-анасына һәм туганнарына адресланган.

[2] Бу урыннар танылмый.

[3] Авылдашларыннан үчле кешеләр «Такташевлар — кулак калдыклары, чит элементлар» дип, төрле урыннарга язгалап торалар. Ул чагында Казан медицина техникумында укучы Хәнифә Такташева өстеннән дә язу килә. Аны укудан чыгаралар. «Заявление» шул мәсьәләгә караган булса кирәк. Бөек Ватан сугышыннан соң Хәнифә Такташева бу турыда Х. Госманга түбәндәгеләрне сөйләде: «Абый медтехникумга килгән. Коридорда эленеп торган стена газетында мине «чит элемент» дип язган материалны укыгач, шунда ук шигырь язып, шигырен стена газетасы янына ябыштырып киткән». (1929 елның 26 сентябрендә шагыйрьнең «Сеңелем!» дип, Хәнифәгә шигырь белән язылган һәм монда басылган хатын карагыз.)

26 сентябрь, 1929 ел.

Сеңлем![1]

Болай безнең йортка бертөрле дә
Алпавыт та килеп йөрмәгән,
Тирә-күршеләр дә анабызны
Азгын хатын диеп белмәгән,
Ә шулай да синең башка атадан
Булуыңны монда белгәннәр,
Стенага эре хәреф белән:
«Дворян кызы» диеп элгәннәр...
Өй эчендә булган күп серенне
Күршең сөйләгәннән беләсең,
Әнкәй,
Әткәйне алдап, алпавытлар белән
Гуләйт итеп йөргән, күрәсең.
Күз яшь түкмә, бала,
Без әнкәйнең
Саф булуын яклый алырбыз,
Син дә
Алпавыт кызы түгел,
Сукачы карт
Хәйрүк кызы булып калырсың!!

Крестьян атаңнан туган абыең
Һ. ТАКТАШ.

[1] **1929 елның 18 августында язылган хатка бирелгән аңлатманы карагыз.**

21 ноябрь, 1929 ел, Казан.

Сөеклем!

Хатыңны бүген иртә белән укып, ашыгып кына бер хат язган идем. Содержаниесендә сиңа тәнкыйть күзе белән карау бар иде. Үпкәләмә. Сиңа авыр вакытыңда ул сүзләрне әйтергә кирәк түгел иде төсле. Бит синең кебек кечкенә генә нәрсәне дә бик авыр переживать итә торган кешегә болай да авырдыр. Хатың бик авыр тәэсир калдырды. Һәр сүзең нинди переживание белән язылуы миңа билгеле, бәгырем. Ул кадәр кайгырма. Бик юк нәрсә өчен, никадәр тырышсалар да, пычрата алмаслар. Чын хисләр, алдаусыз сүзләр белән мин миллионнарны үземә ышандырам. Яраттырам. Неужели, синең саф йөрәктән чыккан сүзләрең залга — комиссиягә җитмәс!

Тыныч кына хәрәкәт ит. Паникага бирелмә. Көрәштә гаскәрләрнең җиңелүе күп вакытта җиңүгә ышанмаудан, дошманның көчлелегеннән куркып була.

Синең дошманнарың андый көчле — үлемгә алып килә торган кораллар белән коралланмаганнар. Алар хәйлә-мәкер белән эш итәләр. Шундый вакытта сиңа бары осторожностьлык белән генә хәрәкәт итәргә кирәк. Үзеңә ышан. Бу көрәштә үзеңә ышану бик нык кирәк.

Тагы нәрсә? — Хатны алу белән үк тизлектә хат яз. Бөтен нәрсәне миңа белдереп тор. Булмаса, мин синең хакта бик нык тынычсызланам.

Балаң үбә сине!
Ирең сагына. Хуш, Галя.
ТАКТАШ.

Хатта сүз Гөлчәһрә Хәмзинаны (бу вакыт ул Мәскәү университетының студенткасы) урынсызга гаепләү һәм шул эшне тикшерү турында барса кирәк.

19 март, 1930 ел, Мәскәү.

Хәнифә!

Мин сиңа адресымны күрсәтеп хат язган идем. Син вообще хат язарга ялкау кеше. Ләкин, ни булса да, өй хәлләрен миңа белдереп тору кирәклекне аңларга тиешлесен дип уйлыйм.

Бала ничек яши, исәнме? Үзегез ничек? Акча ягы ничек? Бу хатны алу белән срочно барысын да белдереп хат яз. Адресым шул:

Москва.
Лосино-островская, Коминтерневский пер. дом 65,
Дубровскому[1] для передачи Такташу

Мин 28 мартларга кадәр Мәскәүдә булырмын. Акчагыз булмаса, җибәрермен. Бик тиз хат яз.

ҺАДИ.

Хатның датасы юк. Почта печатендә 1930 ел 19 март дип басылган.

[1] Дубровский — Такташның «Камил» сценариесы буенча «Восток кино»да картина эшләүне өстенә алган режиссер.

Кыймммәтлем Габидулла!

Син миңа хат язуны үзеңнең бишьеллык планыңа кертмәгәнсең бугай. Ә бит аратирә язгалап тору яхшы булыр иде. Сиңа беренче хәбәр итеп, Гөлчәһрә белән бөтенләйгә аерылуымны язып үтәм. Мин инде мәңге аны күрмәсәм дә риза. Очраганда үзенә дә әйт. Мин үземнең аның белән тора алмавымны өйләнгән көннәремдә үк белсәм дә, җимерергә теләмәгән идем. Һаман, төзәтеп булмасмы дип, әллә күпме көчемне, биш ел буена кыйммәтле энергиямне әрәм иттем. Ә хәзер үкенәм дә...

Вообще, үземне яхшы хис итәм. Өйләнмәскә дип, йөрергә исәпләсәм дә, шул көннәрдә, бәлки, Казанның бик матур бер кешесенә өйләнеп куюым ихтимал. Мин аны бер елга якын яратып йөрдем. Бу юлы ялгышмам дип уйлыйм. Шулай да куркам, «ходай» тагын бер бәласенә очратмасын дим. Гөлчәһрә белән без бу ел Мәскәүдә үк аерылган булсак та, тагын бераз калырга булган идем.

. . . .

Бу нәрсә самолюбиема тия. Син алар күптән аерылдылар инде дип, хәбәр тарат. Яме.

Хәнифә укый. Аны рабфакка күчерергә йөрим. Шулай итеп университетка җибәреп булмасмы. Матди ягым бик начар. Шуның өчен өйгә бернәрсә ярдәм итә алмыйм. Шул нәрсә бик борчый. Синең матди ягың ничек?

Тормышыңны, уйларыңны белдереп, озын бер хат яз. Сагынып кө тәм.

Я, хуш, Габидулла.

Абыең ҺАДИ ТАКТАШ.

Габид!

Бәлки, каникулга Казанга кайтырсың. Яңа җиңгәңне дә күрү ихтималың бар. Килсәң, күңелле булыр иде.

ТАКТАШ.

4 октябрь, 1930 ел, Казан.

Рафаэльгә[1] үзенә укырга гына хат яза алмыйм. Шуның өчен миңа бик авыр. Аны өзелеп сагынуымны (бу хат — ред.) аңарга кечкенә булса да аңлата алырмын? Аның еракта үзен сагынучы, өзелеп сагынучы атасы барын һәм аның бик сагынуын кем генә булса да аңар аңлата алырмы? Мин күптән инде аның «папа» дигән сүзен ишеткәнем юк. Миңа бик авыр, ул, бәлки, инде ул сүзне әйтергә дә оныткандыр. Ә аның тавышы һаман минем колагымда, рәсеме һаман йөрәгемдә булуы, ул әле аңлау дәрәҗәсенә җитмәгәнгә, йөрәгемне авыр сагыну тойгылары каплый.

Хатым аңар җылы хисләремне алып бара алсын иде. Бер генә минутка ул минем яратуымны, өзелеп сагынуымны хис итә алсын иде.

Ерактан күрәлмим.

Бәхетсез минутларында янында булалмыйм.

Ул шуны аңласын иде.

Кайчан күрә алырмын.

Күрә алырмынмы?

Аңа Казанда икәнемне әйтегез.

Сагынуымны аңлатырга тырышыгыз!

Үземнең сәламәтлегемне, эшемнең бик күп булуын, тиздән, бәлки, Казаннан Донбасска бер алты айга китәргә җыенуымны әйтегез.

Тизрәк үссен, минем хатларымны укыр дәрәҗәгә җитсен.

Күз яшьләрем белән язган юлларымны үбәм. Хатымны укый алмаса да, кулына бирегез, өзгәләсә дә, идәнгә таптаса да...

ҺАДИ ТАКТАШ.

---

[1] Бу хат язылганда Һади белән Гөлчәһрәнең аерылган булулары, Гөлчәһрәнең инде башка кешегә чыккан булуы һәм Рафаэльнең анасы тәрбиясендә калган булуы аңлашыла.

ЯҢА ТАБЫЛГАН ӘДӘБИ, ТАРИХИ ИСТӘЛЕКЛӘР

Халкыбыз бай язма хәзинәгә ия. Дистәләгән гасырлар буена ул, кулына каурый каләм тотып, үзенең уй-фикерләрен, кичерешләрен, дөньяга карашын ак кәгазьгә төшереп барган. Кызганычка каршы, безнең чорга андый язмаларның бик аз өлеше генә килеп җиткән, һәм шул «килеп җиткәннәре» дә өйрәнелү генә түгел, тиешлечә барланып исәпкә дә алынмаган әле.

Шундый материалларны эзләгән чакта, төрле җирләргә барып чыгарга туры килә. Мин Уфадагы Диния нәзарәте архивында утырам. Ул архив дәүләт милке булып исәпләнә. Һәм мин бирегә очраклы рәвештә генә килмәдем: монда заманының күренекле галиме — әдип, педагог, киң мәгънәсендәге зур тарихчы һәм журналист Риза Фәхретдиновның шәхси архивы сакланган булырга тиеш. Бу галимнең әдәби, гыйльми мирасы гаҗәп бай. Төрле темаларга багышланган дистә-дистә китаплар, йөзәрләгән мәкаләләрнең авторы ул. Безнең өчен аның хезмәтләре иң элек гаять бай документаль чыганакларга нигезләнгән булулары белән әһәмиятле. Мисалга «Асар» исемле биобиблиографик очерклар җыелмасын алып карыйк: биредә, теге я бу шәхеснең биографиясе, иҗаты яктыртылу белән бергә, әлеге кешенең барлык язма әсәрләре саналып, басылмый калганнарыннан үрнәкләр китерелә. Шулай ук ул кеше язган яисә аңар килгән төрле хатларның һәм башка документларның текстлары бирелә. Әйтергә кирәк, узган чорның күп кенә шәхесләре турында без бары шул «Асар»ны укып кына беләбез. Мәсәлән, XIX гасырда яшәгән талантлы һәм катлаулы иҗат юлы үткән шагыйрь Шәмсетдин Зәкине алыйк. Аның безгә килеп җиткән шигырьләренең зур өлеше шул «Асар» битләрендә сакланып калган бит. Мондый фактларны күп санарга мөмкин...

Билгеле булганча, Р. Фәхретдинов, «Шура» журналы редакторы булып эшләгән чакта, матбугат трибунасыннан файдаланып, әдәби-тарихи материаллар җыюны җайлап җибәргән. Үзләрендә борынгы язма истәлекләр сакланган кешеләр галимгә ул документларның оригиналларын яисә күчермәләрен җибәреп торганнар. Шул рәвешчә, Р. Фәхретдиновның шәхси архивы, тора-бара, халык тарихы хәзинәсенә әверелгән. Ул кыйммәтле чыганакларның бары бер өлеше генә дөньяга чыгып, икенче зур өлеше исә кульязмалар хәлендә генә калган. Менә шуңа күрә дә Р. Фәхретдинов архивы табылу — әдәбият һәм культура тарихыбыз өчен гаять әһәмиятле факт.

Әйе, минем алда моңарчы исәнлеге билгеле булмаган һәм әлегә хәтле галимнәребез тотып карамаган язма истәлекләр[1]. Менә «Асар»ның кульязма хәлендә сакланган өченче томы. Ул 1911 елга хәтле язылып беткән була. Тик басылмый кала. Нигә? Яңа материаллардан бу мәсьәлә дә ачыла: 1911 елның февралендә полиция һәм жандармнар, Р. Фәхретдинов фатирында тентү ясап, күп кенә кульязмаларны, шул исәптән «Асар»ны да, алып китәләр. Дөрес, бер ел узгач «Асар» кульязмалары кире кайтарыла, тик өлеше генә. Бу, минем алдагы өченче том, әлеге вакыйгадан соң яңадан төзелә башлап, бары 30 елларда гына тәмам ителгән. Безнең өчен шул өченче томның табылуы да зур казаныш иде, ләкин биредә элеккеләренә өстәмә рәвештә төзелгән дүртенче том да бар икән!

Р. Фәхретдинов — революцияне, Октябрь китергән бөек яңалыкларны аңлый алмаган буржуаз галим. Шул ук вакытта башка сыйныфташлары кебек контрреволюция юлына баскан кеше дә түгел ул. Күрәсең, ул да Дәрдмәнд кебек:

Илдә бер дус булмаса гәр,
Ил бөтен дошман түгел,—

дигән позициядә торган булырга тиеш. Һәм яңа табылган документлар аның тирән пессимизмга бирелүен, шулай да язу өстәленнән, каләмнән аерыла алмавын күрсәтә. «Бу көн инде,— дип яза ул дүртенче томның кереш сүзендә,— «Асар»ны бер кеше укымаслыгыны беләм. Язып вә күчереп утыруларым бездән соңгылар укырлар рәвешендә бер фикер түгел».

Бу сүзләрдә дөреслек тә, тирән ялгышу да бар: үзе әйтмешли, безнең чор кешеләре аның тарихи әсәрләрен зәвык «вә ләззәтләнүләр» белән, бәлкем, укымаслар да. Әмма аның әсәрләрендә, кульязмаларында сакланып калган уникаль документларны бүген түгел, иртәгә дә җентекләп тикшерәчәкбез. Татарлар арасында иҗтимагый, тарихи фикерләрнең үсешен, аларның эволюцияләрен өйрәнгәндә шул ук Фәхретдинов эшчәнлеге дә мөһим бер объект булуны исбатлап торуның кирәге юктыр.

Тарихи әсәрләр өстендә эшләвен, әйткәнебезчә, Р. Фәхретдинов революциядән соң да дәвам иттерә. Борынгы татар шәҗәрәләрен (генеалогияләр) җыеп тикшерү белән бергә, атаклы илгизәр Ибн-Фазланның Болгар иленә сәяхәтен дә җентекләп өйрәнә ул. Дөрес, Фәхретдинов революциягә хәтле үк Ибн-Фазлан турында бер китап бастырган иде. Әмма әле табылган кульязма әсәр, яңа чыганакларга таянып, кайбер мәсьәләләргә принципиаль ачыклаулар кертүе белән кызыклы.

Менә киндер бау белән бәйләнгән дәфтәрләр — әле китап итеп төпләнелмәгән брошюралар төркеме. Барлыгы 23 кисәк. Кульязма Р. Фәхретдиновныкы түгел. Тышлыктагы сүзләрне укуга, ашыгып-ашыгып, аның эчен актара башлыйм. Әйе, минем алда Шәмсетдин Зәкинең моңарчы билгесез булган әсәрләре. Кырыклап шигырь. Ә бит безгә аның 5—6 гына әсәре мәгълүм иде! Биредә исә тагын бик бай язылган биографик мәгълүмат та бар.

---

[1] Р. Фәхретдинов архивы хәзер СССР Фәннәр академиясенең Уфа тел, әдәбият һәм тарих институтына күчерелде.

Зиннәтулла Гыйсмәтулла улы дигән кеше тарафыннан төзелгән бу китапта шулай ук Мәнди Котош углы дигән, иҗаты түгел, исеме дә бөтенләй билгесез булган кыпчак кабиләсеннән чыккан бер башкорт шагыйренең дә биографиясе, шигырь үрнәкләре китерелгән... Бу китапны Зиннәтулла Зәки (Зәк авылы кешесе, ягъни Шәмсетдиннең авылдашы) 1916 елның 20 январенда (һиҗри белән 1334 ел) күчереп бетергән. Димәк, андагы материаллардан Р. Фәхретдинов элек файдалана алмаган булып чыга. Бу исә яңа кульязманың никадәр әһәмиятле икәнлеген күрсәтә. Һәрхәлдә, әсәрләренең әдәби сыйфаты, философик эчтәлеге белән башка рухани каләмдәшләреннән нык аерылган татар шагыйре Шәмсетдиннең әдәби мирасын җентекләп өйрәнер өчен киң мөмкинлекләр ачылды.

Янадан «Асар» битләрен актарам. Менә Габделгаллә Фәезхановның кыскача биографиясе. Казан һәм Петербург университетларында укыткан Хөсәен Фәезхановның энесе ул. Сабачай исемле караңгы авылдан чыгып, чын гыйлемнең якты юлына баса алган бу бертуганнарның иҗтимагый эшчәнлеге аерым бер ихтирамга лаек. Хөсәен олы фән дөньясында үзен сәләтле ориенталист, татар мохитында исә атаклы мәгърифәтче итеп танытса, эшчәнлеге әлегә бөтенләй өйрәнелмәгән Габделгалләм дә үзеннән соң игътибарга лаек хезмәтләр калдыра алган. Аның «Хикаят вә мәкалат» исемле китабы фольклор дөньясында беркадәр мәгълүм инде. Болар өстенә, Габделгалләмнең грамматика, гомум география буенча язган әсәрләре дә бар. Шәрык әдәбиятлары җәүһәрләреннән исәпләнгән «Тутый-намә» белән «Кәлилә вә димнә» әсәрләрен дә ул тәрҗемә иткән. Абулгазиның «Шәҗәрәи төрек» исемле зур хезмәте дә, аның каләменнән кичеп, Казанда нәшер ителгән. Ләкин Габделгалләмнең алардан башка да әһәмиятле хезмәтләре булган икән. Мин хәзер Уфа тарих, тел һәм әдәбият институты китапханәсендә рб/3760 номеры белән саклангаң кульязманы күздә тотам. «Китабе мәҗалис-әс-сәрвәт [1] вә әл-мәгаш» дип аталган бу зур хезмәттә экономиканың бик күп тармаклары карала. Автор популяр алым белән сәүдә, һөнәр кәсеп, производство, финанс, капитал мәсьәләләрен тикшерә. Анда, мәсәлән, кәсепләрнең төрләре, хезмәт, кеше һәм хезмәт, хезмәт бүлү, эш хакы, производствоны үстерү, рента, хосусый милек, капитал, акча, кредит, банк кебек экономия фәне мәсьәләләренә багышланган 20 «мәҗлес» (бүлек) бар. Кыскасы, бу — чорына күрә политэкономия буенча язылган зур монография. Әмма ул китап, гәрчә аңа 1892 елның 20 ноябренда басарга рөхсәт белән цензор печате сугылып, Смирновның имзасы куелса да, нәшер ителә алмыйча кульязма халендә калган. Һәм ул институт китапханәсенә Р. Фәхретдинов архивыннан күчкән...

«Асар»да шигърият мәйданында мәгърифәт факелын күтәреп чыккан атаклы демократ, трибун шагыйрь Мифтахетдин Акмулла турында да гаҗәп бай өр-яңа мәгълүматлар бар. Анда Р. Фәхретдиновның Акмулла хакындагы зур гына истәлеге китерелә. Безнең күз алга шагыйрь гади, җанлы кеше булып баса. Менә аның тәрмәдән язылган бер хаты һәм озын гына мөнәҗәте. Мифтахетдин социаль тигезсезлеккә, капитал ялчыларының, сый-хөрмәткә чумып, югары дәрәҗәләргә ирешүенә протест, нәфрәт белдерә.

> **Гаҗәп, һәркем гани булса**
> **Аңа хөсне дидар әйләр;**
> **Фәкыйрь мескенгә пәрва юк,**
> **Мәзәллләт берлә зар әйләр.**
> **Фәсахәттә хисан булса,**
> **Ки Локман хикмәте булса,**
> **Дәрига, бәхете юк ирне**
> **Фәкыйрьлек шәрмсар әйләр...**

Р. Фәхретдинов Акмулланы 1894 елны Уфага килгән вакытында күрә. «Бер тарафтан, — ди Р. Фәхретдинов, — сынган күңелне вә калган хәтерене төзәтү касды берлән, икенче тарафтан, күңелене табуга иҗтиһад иттем. Шул сәбәптән, һәрвакыт үз урыныма чакырдым, озын вакытлар сөйләшеп утырдым. Мәгәр гыйлеме вә икътидары Шәмсетдин Суфи дәрәҗәсендән күп түбән булыр дип зәнн иттем. Гарәп вә фарсы шагыйрьләрендән хәбәре аз иде; гыйльми мәсьәләләрдә дә ерак бара алмыйдыр иде. Бөтен кәмалаты казакъ сахрасында алынган вә казакъ шагыйрьләрендән истифадә ителгән иде. Мин үзем шулай таптым».

Дөрес, Р. Фәхретдинов Акмулла иҗатының социаль мотивларын аңлаудан бик ерак тора, һәм аның очеркында без ул мәсьәләләрнең яктыртылышын таба алмабыз. Шулай да истәлектә, бөтенләй яңа янсә элек тулы мәгълүм булмаган шигырьләр китерелү өстенә, шагыйрьнең биографиясенә бәйле мөһим яңа фактлар да бар. Мәсәлән, Акмулланың этник яктан кем булуы шактый бәхәс тудырган мәсьәлә. Әле бүген дә аны берьяклырак хәл итәргә тырышучы галимнәр юк түгел. Фәхретдинов истәлегендә бу мәсьәләне дә дөрес хәл итә алырлык хәбәрләр бар. Акмулланың Уфага килүе хакында сөйләп, ул болай яза: «Бу вакытта бу кешенең Мәрҗани хакында басылган мәрсиясене укып күргән вә шул васыйта берлә үзене ерактан торып беркадәре генә булса да белгән идем. Моны казакъ акыннарының берәрсе булыр дип йөридер, ләкин мәзкүр мәрсия эчендә үземезнең шивәмезчә тәртип ителгән шигырьләре булганлыктан, бу гөманымның тугры булуына шөбһә берлә карыйдыр идем».

Чак кына алдарак Р. Фәхретдинов Акмулланың озак еллар казакъ арасында яшәп, «казакъ углы казакътан аерып алмаслык бер дәрәҗәгә ирешкән» булуын күрсәтеп, аның үзенчәлекле иҗаты да шул киң

---

[1] **Ә. Харисовның «Башкорт халкының әдәби мирасы» исемле китабында (208 бит) бу сүз «әл-шрут» дип ялгыш укылган. Хезмәтнең татарча исеме: «Капитал һәм тормыш чыганаклары турында мәҗлесләр (аңгәмәләр) китабы».**

сахраларда канат җаюен әйтә. Нићаять, очеркта мондый мәгълүматлар бар: «Үземездән элек дөньядан күчүене хәтеремә китермәгәнем, hәрвакыт (минем үз) гомерем кыска булуыны уйлаганым сәбәбеннән, бу адәмнең тәрҗемәи хәленә мөнәсәбәтле мәгълүмат хакында бернәрсә дә сорашмадым вә язмадым. Мәгәрдә үзе сүз арасында ата-анасыннан бере Казан кешесе булганы хәлдә, икенчесе халис башкорт икәнлекне сөйләгән иде. Шул нәрсә хәтеремдә калган».

Акмулла белән бергә булган чакларын сагынып, автор: «Мондый вакытларның кадере белинмәгән!» — дип көрсенә.

Татар әдәбиятында үзенең тиешле урынын алган шагыйрь Дәрдмәнд (З. Рәмиев) турында да Р. Фәхретдинов архивында шактый материал табылды. «Асар»ның өченче томында шагыйрь хакында биографик белешмә бирелгән. Бик кыска булуга карамастан, анда гаять кызыклы фактлар бар. Мәсәлән, үлү датасы. Безнең әдәбиятта Дәрдмәнд 1921 елның 9 октябрендә вафат булды, дип йөртелә. Р. Фәхретдинов та 10 октябрь (hиҗри белән 1340 ел, 7 сафар) дип күрсәтелә.

«Вакыт» һәм «Шура»ларның нашире Дәрдмәндкә карата, Р. Фәхретдинов, табигый, бик-бик югары фикердә. Моны ул үзе дә ачык әйтә: «Фәһеме вә фикере дөрес, табигате сәламәт вә аңлы, хуш мәҗлесле, дин вә дөнья гыйлемнәреннән хәбәрдар, сөхбәт әдәпләрене белеп ригаять итүче дәрес мәгънәсе берлә шагыйрь вә әдип бер зат иде. Байлар арасында да, голәма сыйнфы арасында да нәзире (тиңдәше — М. Г.) аз иде. Без моның берлә ун ел кадәр бер мөддәт катнашып йөрдек вә халене ошбу урында тәгъриф итканемезчә таптык».

Октябрь революциясеннән соң Дәрдмәнд үз урынын (алтынчы Закир Рәмиев буларак) «үлекләр аймагында» дип икърар иткән. Һәм бу миллионер өчен бик дөрес нәтиҗә иде. Шул ук вакытта аның Бөек Октябрьдан соңгы тормышын, кайберләребез суратләгәнчә, берьяклырак, наив итеп күрсәтү дә дөреслеккә туры килеп җитмәс иде. Р. Фәхретдинов хәбәрләре менә бу катлаулы ребусны аңларга бераз ярдәм итәләр:

«Оренбургтан Уфага сәфәремдә янына кереп видаг иттем. Авырып түшәк өстендә иде. «Хәлем яхшыланадыр», — дигәненә һәм дә үзенең беркадәре сөйләшәсе килүене белүемә күрә, янында беркадәр утырдым. Шул вакыт: «Хәзрәт, бу көнгә хәлләр беркадәр төзәлсә, без «Вакыт» берлә «Шура»ны тәкрар чыгарырмыз. Шул вакытта Оренбургка кайтып, әүвәлге хезмәтеңезне дәвам итүеңезне өмидләнәмез вә үтенәмез; сезнең берлә берлектә Хиҗаз сәфәренә бару фикерем дә камил. Моны үзенез берлә сөйләшкән дә идек», — диде. «Алла насыйп итсә, безнең тарафымыздан эш калмас», — дип, видаг кылып чыгып киттем. Ахыргы күрешүем шушы булды».

Дәрдмәнднең тирәннән уйлаучы хаким һәм сабыр кеше булуын исәпкә алганда, аның бу көчсезлеге һәм пассивлыгы («яхшы көннәрне» көтеп кенә ятуы) мәгънәле дә, аңлаешлы да булса кирәк. Шул ук вакытта дини мотивларның көчәя төшүе дә бик характерлы симптом. Бу хәл «Асар»да «иң соң сөйләнгән» дип тәкъдим ителгән «Әлвидаг» исемле шигырендә ачык күренә. Бу әсәрен шагыйрь халык арасында таралган ураза ае белән хушлашу мөнәҗәтеннән файдаланып язган булса кирәк. Бер карауга автор, чыннан да, «мөбарәк рәхмәт ае рамазан» белән саубуллаша кебек. Болай булганда элек дини мотивларга бик исе китмәгән Дәрдмәнд идеализм сазлыгына ярыйсы гына баткан булып чыга. Ләкин, безнеңчә, бу шигырьдә автор бер «хөрмәт ае» белән генә түгел, бәлки үзенең элекке шәүкәтле узганы белән дә бәхилләшә сыман. Рамазан унбер айдан соң тагын килә, ә шигырьдә кабат очрашу өмете сизелми...

Р. Фәхретдинов архивында Дәрдмәнднең башка шигырьләре язылган кәгазьләр дә саклана. Аларны 30 еллар тирәсендә Җәгъфәр Рәмиев күчергән.

Бу язулар арасында Дәрдмәнднең элекке кайбер билгеле әсәрләренең яңа редакцияләре бар. Мәсәлән:

Фулад такмый кәмәрләргә конан бил,
Тазый атлар ялын какмый җилә җил;
Кешәнләнде даланың толпар аты,
Урал шоңкарының сынды канаты.

Элекке вариантта «өшәнләнде далаиның..» булып, атның арып, хәлдән таюы хакында сүз барса, соңгысында толпарны богаулап куя (кешән — богау). Әлбәттә, трагизм көчәя төшкән.

Дәрдмәнднең шигырьләре арасында кызыклы тәрҗемәләре дә, оригинал парчалары да бар. Аларның кайберләрен, автор үзе әйтмешли, «вәзен өчен» язган. Димәк, шигъри техниканы камилләштерү өстендә ул соңгы елларына хәтле эшләгән булып чыга.

Түбәндә яңа табылган әдәби истәлекләрдән Акмулланың ике һәм Дәрдмәнднең алты шигырен тәкъдим итәбез.

М. ГОСМАНОВ.

Редакциядән:

Мәкалә редакциягә бирелгәч, автор Ленинградта булып кайтты. Анда Фәхретдиновның тагын бер архивы табылды.

Тулаем алганда, яңа архив гел документлардан — беренче кулдан алынган чыганаклардан гыйбарәт. Мәсәлән, йөзгә якын татар халкы шәҗәрәләрен, галимгә урыннардан әдәби, тарихи мәгълүматлар хәбәр итеп язылган берничә йөз хатларны һәм XVIII—XIX гасырларга караган дистә-дистә юридик документларның төп нөсхәләрен эченә ала ул. «Фәхретдинов архивы — халык истәлекләре хәзинәсе» дигән фикер артыгы белән раслана.

Документларны, академик А. Н. Самойлович соравы буенча, вафатыннан чак кына элек Фәхретдинов үзе җибәргән булган. Алар хәзер «Востоковедлар архивы»нда сакланалар.

Мифтахетдин Акмулла

●[1]

Минем кебек булыр микән бәхетсез,
Егет башым әсир булды вакытсыз;
Әсир диеп, берадәр, сукмәнезләр,
Күземдән канлы яшем түкмәнезләр.
Теләп алмадым моны үземә, әй яр!
Кадәр [2] килсә япан булыр икән тар.
Бәла килсә, күрер күз күрмәс улыр,
Каза килсә, аяклар йөрмәс улыр;
Кеше мәхбүс булыр тәкъдир эшендән,
Сәбәп булган исә дә кылмышындан.
Сәбәп булыр дәхи дошман кешедән,
Тәҗәссос әйләюп мәстур эшедән [3].
Бу эштә мөбтәлядер [4] канча әхъяр [5],
Асыл фетнәгә мәншаэ тагны әгъяр [6].
Кәзаликә [7] мөбтәля канча мөшаһир [8],
Мөгаллиме санидәк [9] хикмәттә маһир,
Шифа, шиддәт күрә килгән галиләр,
Әфазилдән [10] пигамбәрләр, вәлиләр.

Касыдәдән өзек

Бәгъд әс-сәлам, Нургали мулла, сезгә
Ходаем инсаф бирсен күнеленезгә;
Бозау улып уйнакласа утка басар,—
Тик ятмасаң төштең инде безнең күзгә.

Сез дә бер йөгерексенгән төлке икәнсез,
Без йөреп төштек инде сезнең эзгә;
Бер дә нәүбәт килде инде бу көн безгә,
«Безгә йитәр кеше юк», — дип өмид өзмә.

Синең дә бер әруахың күтәрелсен,
Җәелсен хасиятең бераз «йөз»гә [12],
Хәрарәттән мәхмүм булып [13] эчең көйсә,
Сусыныңны кандырыр безнең сөзмә.

---

[1] Бу шигырьне Акмулла төрмәдән Троицк шәһәрендәге Хафиз исемле танышына язган хат белән җибәргән.
[2] Тәкъдир, язмыш.
[3] Яшерен эшеннән (сәбәп) эзләп.
[4] Дучар булу.
[5] Яхшы, изге, дус кеше.
[6] Мәгънәсе: асылда фетнә өчен явызларның сүгенүләре чыганак (була).
[7] Нәкъ шулай ук.
[8] Мәшһүрләр.
[9] Атаклы шәрык галиме Ә. Фәрабинең кушаматы.
[10] Хәкимнәр, белем ияләре.
[11] Р. Фәхретдинов шигыренең башына: «Акмулланың озын бер касыйдәсеннән бәгъзе бер бәетләр» дип язып куйган.
[12] Сүз казакълардагы кабиләләр берләшмәсе турында бара булса кирәк.
[13] Эсседән бизгәк тоту.

Мөхаккак [1] Мәржанигә авызын ачкан
Еландай зәһрен сачкан мулла сезмә?..
Монынны аяймын, берадәрем! —
Котырсаң да Уралдай тауны сөзмә!

Һәр шәйне мәузыйгына куймак кирәк [2]
Мөрәүвәрне [3] мунчак берлә бергә тезмә!
Мулла дигән кари була беләсезме?
Тасаувыф [4] китапларын күрәсезме?

Башкортның нәград алган кантонындай,
Мулласызмы йә чинауник түрәсезме?
Мөҗтәһид [5] галимгә каршы торып,
Кабергә талаш берлә керәсезме?

Гомерецезнец күбе үтте гауга берлә,
Мәржанине йиткәрмәм дигән сәүда берлә,
Сөннәтчә эшемез юк һәм алдаймыз
«Әһле сөннәт»мез дигән дәгъва берлә.

Артыцызны ачкан соң күрәсез йик [6]
Әйтәсез шул сәбәптән «Залл-мозилл» дип [7],
Кәламулладан әсдәкъ [8] ни нәрсә бар?
Әйттеләр «әсатирел әүвәлин» [9] дип.

Сез дә шулай тәҗавез кылдыңыз [10] күп
Йортымызга фетнә салды ушындай гәп.
Сезгә каршы без әйтсәк ник ярамый
«Вә һом фи тогъяниһим йәгъмәһун» [11] —
дип?

Батырны «батыр» диләр көчен күргәч,
Останы «оста» диләр эшен күргәч,
Ул минем атам имәс, остаз имәс [12],—
Хаклыкны тәсдикъ зарур эшен күргәч.

Фикъһдә [13] бу заманның Ногманы бу,
Хикмәттә бу заманның Локманы бу,
Үткәннәр үтеп китте, инде хәзер
Әһле сөннәт рәһбәре [14], солтаны бу!

Берадәр, син үзеңне ихтисаб ит [15],
Мәржанине мөҗтәһиддән син хисап ит!
Пир йөзенә нуры төшкән ул бер кояш,
Ул кояшның нурыннан икътибас ит!.. [16]

---

[1] Хаклык эзләүче.
[2] Мәгънәсе: һәр әйберне үз урынына куярга кирәк.
[3] Энҗе-мәрҗән.
[4] Суфыйчылык.
[5] Иң югары белемгә ирешкән философ, галим.
[6] Бу сүзгә Р. Фәхретдинов «Фәналык, йөдәү, бәд мөгамәлә» дип аңлатма биргән (начар мөгамәлә, хурлау).
[7] Аздыручы, адаштыручы.
[8] Дөресрәк.
[9] Борынгы риваятьләр.
[10] Агрессивлык күрсәтү, һөҗүм итү.
[11] Мәгънәсе: алар үзләренең азгынлыкларына баталар.
[12] Түгел.
[13] Юриспруденция.
[14] Җитәкче, юлбашчы.
[15] Тикшерү, контроль ясау.
[16] Кабул итү.

●[1]

Дәрдмәнд

Жырлыйм әле,
Гөрлим әле, —
    Бәбкәм йокласын;
Жыламасын,
Дуламасын,
    Инде туктасын.

Тубын атты,
Бәбкәм ятты,
    Инде уйнамый,

Күзен йомды,
Тынды, тынды...
    Әнә, жыламый!

Кил, жылагым,
Ал колагым,
    Йоклыек икәү;
Йокла, иркә,
Йокла, бәбкә,
    Бүкәй бәллү-бәү!

●

Таулы матур илләрендә
Гөрли агым сулары;
Тонык ялтыр күлләрендә
Каңгылдый аккулары[2].

●

Аның янында кичкә котлы көндә
Гажәп ләззәтле төшләр күрдем өндә.
Хәзин[3] гомрем чүлендә санкем ул көн —
Ачылды күк-капу золмәтле төндә.

●

Ят илнең яд итеп якты кояшын,
Камышлы суларын, кырчынлы ташын,
Тавышлар чыңрауын ул саф һавада!..
Сагышлар яңратып иркен далада
Ерак диңгездә ул кышлар кичергән;
Чит илләрдән гарип моңлар китергән...

Сыер

(тәрҗемә)

Аһ, мин матур сыеркаемны сөямен,
Аһ, мин сыеркаема кечерткән төямен.
Аша туйганынча, газиз иптәшем минем,
Аша туйганынча, аша, һаукәшем минем!

Аһ, мин матур сыеркаемны сөямен,
Көрпә болгам[4] сыеркаема куямын;
Минем сыеркаем эчсен, туйсын дип,
Зур жиленкәенә каймак тулсын дип.

Тәрҗемә

(вәзем өчен)

Тәрәкнең[5] салкын суында
Чәчәләп уйный ай нуры.
Уйнатып атын аулакта,
Чиркәс йөридер аръякта.

Көмештән авызлык тешләтеп,
Уйнатып атын кешнәтеп.

Качыгыз кач, матурлар,
Качыгыз форсат бар чакта,
Чиркәс йөридер аръякта.

Якты жиһаннан бизденме,
Жаныңдан өмид өзденме...
. . . .

---

[1] Билгеле «Бәллү» шигыренең варианты булырга кирәк.
[2] Аккош.
[3] Кайгылы, хәсрәтле.
[4] «Болгап» булуы ихтимал.
[5] Терек. Кавказдагы елга исеме.

Мөхәммәт Гайнуллин,
филология фәннәре докторы

Дөреслекне төгәл яктыртыйк

„Казан утлары» журналының быелгы өченче санында Ибраһим Нуруллинның «Шагыйрьне өйрәнү юлында» исемле мәкаләсе чыкты. Бөек шагыйребезнең 80 еллыгын бәйрәм итәргә әзерләнгән көннәрдә аның күпкырлы бай иҗат мирасын бәяләү һәм өйрәнүдәге элекке ялгышларны һәм кимчелекләрне төзәтергә омтылу — табигый һәм кирәкле эш. Бу турыда ике сүз булырга мөмкин түгел. И. Нуруллин Габдулла Тукай иҗатын өйрәнүче галимнәрдән объективлык, хакыйкатьне дөрес һәм тулы яктыртуны таләп итә, урыны-урыны белән халык шагыйренең әдәби мирасын бәяләүдәге берьяклы һәм ялгыш карашларны күрсәтеп тә уза. Тик башкалардан объективлык таләп итүче, дөреслек өчен көрәшүче кеше үзе дә бик объектив булырга, берьяклы тенденциоз нәтиҗәләр ясарга ашыкмаска тиеш иде. «Шагыйрьне өйрәнү юлында» исемле мәкаләдә исә, кызганычка каршы, андый урыннар байтак. Дөреслек, объективлык артыннан куам дип, мәкалә авторы хәтта шул дәрәҗәгә барып җитә: Тукай үзе үк кире каккан, үзе үк тәнкыйть иткән әйберләрен казып чыгарырга тотына. Менә шунда инде гафу ителмәслек гаделсезлек башлана.

Сүзне Тукайның рус телен әйбәт белү-белмәве мәсьәләсеннән башлыйк. Әлегә кадәр Тукайның бу өлкәдә әзерлекле булуына, талантлы тәрҗемәче икәненә беркем дә шик тотмый иде шикелле. Хәтта «Татар шагыйрьләре» китабының авторы Галимҗан Ибраһимов та Тукайның бу өлкәдәге эшчәнлеген мактап уза: «Тукай гомумән яхшы тәрҗемәче. Ул сайлый да белә. Мәфһүмне дә җанлы вә әдәби рәвештә күчерә ала... Баштанаяк рус шагыйрьләреннән алынган «Балалар күңеле», Пушкин вә Лермонтовтан тәрҗемә кылынган мәхәббәт шигырьләре шагыйрьнең үз оригиналларының күбеннән матур һәм самимилардыр»,— ди [1].

Тукай тәрҗемәләренә карата шундый ук уңай фикерләрне үз вакытында Фатих Әмирхан да әйтеп узган иде. Соң безнең кайсыбыз Тукайның әйбәт тәрҗемәче булуына, аның поэтик тәрҗемә өлкәсендәге сәләтенә таң калмый?!

Ә менә иптәш Нуруллин «Алдынгы татар иҗтимагый-политик фикернең формалашуы һәм үсүе» исемле хезмәттән «Рус телен Тукай шулкадәр яхшы белгән ки, газета сотрудникгының истәлегенә караганда, ул рус телендә шигырьләр язган», дигән сүзләрен күреп ала да, моны зур гаеп санап, Р. Нафиговны «әрләргә» тотына.

«Р. Нафигов исә, — дип яза И. Нуруллин, — 40—50 ел үткәннән соңгы истәлеккә таяна (язма истәлекме, телдән генә әйтелгәнме — билгесез)».

Кирәк булса, язма истәлек тә бар. Мин үзем ике мәртәбә Уральск шәһәрендә булдым һәм шагыйрьнең бик күп замандашларын күреп сөйләштем. Тукай белән типографиядә эшләгән Батин һәм Александр Гладышевлар кульязма истәлек тә язып бирделәр. Алар һәр икесе Тукайның югары культуралы кеше булуы турында сөйләделәр. И. Нуруллинның үз фикерләрен исбатлау өчен китергән дәлилләрен шулай ук соңгы хакыйкать дип әйтеп булмый. Имештер, Тукай Гыйльметдин Шәрәфкә: «Минем русчам Уральскидан килгәндә зәгыйфь иде. Үзем теләгән нәрсәләрне тәрҗемәгә куәтем җитсә дә, ни бирсәләр, аны тәрҗемә итәргә үземдә икътидар хис итми идем», — дип сөйләгән булган икән. Ярар, табигате белән үк шапырынырга, мактанырга яратмаган Тукай нәкъ шулай дип әйткән дә булсын, ди. Шагыйрьнең иҗатына, бу өлкәдәге практик эшчәнлегенә күз салыйк. Г. Шәрәф язган, И. Нуруллин яклаганның киресе килеп чыга түгелме соң? Уральск чорында ук Тукай Бахның марксистик политэкономия нигезләрен пропагандалауга багышланган «Царь-голод» әсәрен тәрҗемә иткән. «Әлгасрел-җәдид» журналында басылган бу әсәр оригиналы төсле үк аңлаешлы һәм уку өчен гаять кызыклы. Шуның өчен дә беренче төзә-

[1] Г. Ибраһимов. Татар шагыйрьләре. 1913 ел, 81 бит.

түсез Тукайның барлык басмаларына кертелә килә. 19—20 яшьлек Тукайның шундый зур, катлаулы хезмәтне аңлап, оста тәрҗемә итүенә сокланмый булмый. Менә шул хезмәтнең әлегә кадәр Тукай томнарына кермәгән бүлекчәсеннән кыска гына бер өзек:

«Җефәкне, ситсаны, пустауны фабрикантлар саталар. Вәхаләнки, кем белер? Ул фабрикантлар шул товарларга бармак очларын да тидермәгәннәр. Бодайны алпавыт сата... бу товарларны чын эшләп чыгаручылар үзләре кая киткәннәр соң? Кайда соң ул (тәңренең эшчеләре)... кайсыларының җан-тәннәре вә каннары илә бу байлыклар хасил булганнар? Алар да монда, монда аларсыз базарда эш буламы соң? Менә ул таланган, өтелгән, яртылай ач «тәңренең эшчеләре». Менә ич алар базарларда груһ-груһ йөриләр, алар да базарга товар алып чыкканнар, ләкин үзләре эшләп чыгарган товарны түгел, юк! Юк! Һәртөрле фабрикантлар вә алпавытлар күптән инде аларның эшләп чыгарган товарларын үзләренә ана сөте шикелле хәләл күреп, иямләнеп алганнар.

Эшчеләр базарда бөтенләй башка товар саталар, алар базарга үзләренең «эшче кул»ларын алып чыкканнар, алар көчләрен саталар. Бу ничек булган соң?»

Шунысы характерлы, Тукай, бик күп специфик терминнарны татар теленә һәркем аңларлык итеп тәрҗемә итү белән бергә (берләшмәк, эш бүлмәк, алмашмак, товарларның кыйммәте, эшче куллар, сорау-сорату, чыгару һ. б.), конкуренция, эксплоатация кебек тәрҗемә өчен аеруча кыен сүзләрне турыдан-туры русчадагыча ала.

«Шагыйрьне өйрәнү юлында» исемле мәкаләнең авторы, Тукайның революцион-демократик эшчәнлеген бәяләгәндә, аның оригинал әсәрләрен генә хисапка алырга, ә тәрҗемәләрен счет төймәсеннән алып ташларгарак куша кебек. Моның белән һич тә килешеп булмый. Тукай заманы өчен гаять актуаль һәм политик әһәмиятле мәкаләләрне тәрҗемә иткән һәм аның дөньяга карашы үсүе турында сөйләгәндә, ул тәрҗемәләрне читләтеп үтәргә ярамый. 1906 елның апрель-май айларында, ягъни нәкъ Дәүләт думасы чакырылган вакытларда, Габдулла Тукай, мәсәлән, большевистик матбугат материалларыннан файдаланып язылган «Мәхарәбә вә Государственная дума» дигән мәкаләсен бастырып чыгара. Шул мәкаләсе белән шагыйрь татар хезмәт ияләренең һәм алдынгы интеллигенциясенең Думага карата ышанычын какшатуга үзеннән өлеш кертә.

Аннан соң 1905 елның ахырларында, башка демократик язучылар шикелле үк, Тукайның да патша манифестының серенә төшенеп җитмәвен, мәгълүм бервакытта конституцион иллюзияләр белән мавыккан чагы булуын бер кеше дә инкарь иткәне юк. И. Нуруллин, ни өчендер, бик тырышып, кат-кат шул мәсьәләгә басым ясый һәм, Р. Нафиговны шагыйрьне беркадәр иртәрәк революцион-демократ «ясауда» шелтәли.

Башка талантлы язучылар һәм бөек фикер ияләре шикелле Тукай да үз иҗат юлына, үз әсәрләренә тәнкыйть белән карый алган. Мәгълүм булганча, авырып больницага кергәч, хәленең начар булуына карамастан, ул, үз әсәрләрен яңадан күздән кичереп, башлангыч иҗат чорында язылган кайбер уңышсыз әсәрләрен «яраксызга» чыгарган. «Уянгач беренче эшем» исемле мәгълүм мәкаләсендә, Тукай «Кичке азан», «Шәкерт яхуд бер тәсадеф» кебек шигырьләрен бернигә торгысыз әйберләр дип атый да, шундый шигырьләренең үз теләгеннән башка әллә ничәшәр кат басылып таратылуларына җан ачысы белән борчылып, түбәндәге юлларны яза:

«Соң боларның җидешәр ел буена бүлмәмдә ятуына ни сәбәп булган? Менә шул чүпләрнең язылуына нинди кабахәт вә кара көч сәбәп булса, шул сәбәп булган... Инде мин аларны себердем... Бүлмәмдә «үз сөйгәнем», «үзем сөйгән шигырьләрем» генә калдылар...

Тормыш юлымда очрап, минем белән белешләнгән вә дусланган кешеләр бәгъзан аларга бөтен диваннарымны һәдия итүемне сорыйлар иде. Чит шәһәрдә налож белән җибәрүемне үтенәләр вә, күпме хак куйсам да, түләп алачакларын вәгъдә итәләр иде.

Ул китапларның кибетләрдә сатылуына да төрле сәбәпләрдән нашир туктата алмаганыма ләгънәт укып йөргән мин, һичбер вакыт үз кулым белән, «борыны сизми» дип, чын дустыма үлгән мәче һәдия итәмме соң? Юк!»

Шунда ук Тукай әлеге начар әсәрләре белән аны битәрләргә тырышучы тәнкыйтьчеләрнең мәкаләләрен басмаган өчен, «Вакыт», «Шура» һәм «Идел» редакцияләренә рәхмәт белдерергә мәҗбүр була: «Әгәр алар, — ди ул, — мине үз-үземә дә, кешегә дә шул шигырьләр белән тәкъдим итсәләр вә миннән мәлгунанә бер сурәттә шаркылдап көлсәләр, вакыйган, максатларына җитәрләр иде. Ләкин мина эш башында рух биргән идарә мөхәррирләре эш уртасында мине мәсхәрә иттермәделәр. «Тегеләрнең мәкаләләре дә басылмадылар»[1].

Күрәсез, Тукай шул елларда ук иҗатының башлангыч чорында язылган шигырьләренә тәнкыйть белән карый, үз сүзләре белән әйткәндә, аларны «браковать» итә: соңгы дүрт йөз битле җыентыгына кертми. Шулай булгач, шагыйрь үзе «мәче үләксәсе» дип атаган әсәрләрен аның җыентыкларына кертергә һәм яшьләр кулына бирергә безнең ни хакыбыз бар? И. Нуруллин исә шундый шигырьләрнең дүрт томлыкка кертелмәвен кимчелек саный. Дөрес, шагыйрьнең васыятен үтәү йөзеннән үзе тәнкыйть иткән әсәрләренең кертелмәве турында искәрмәдә әйтергә була. Ләкин алар — гыйльми басмаларда эшләнәчәк эшләр.

Халык бәхете өчен көрәшкән демократик язучыларның патша властьлары тарафыннан бертуктаусыз кысрыклануы килү-

[1] Габдулла Тукай. Әсәрләр. 1956 ел. 4 том. 187—188 битләр.

ләре һәм күзәтү астында яшәүләре — һәркемгә ачык һәм дәгъвасыз нәрсә. Бу хәлдән, билгеле, халык шагыйре Г. Тукай да азат булмаган. Мәгълүм булганча, цензорлар Тукай шигырьләрендә дә («Иттифак хакында», «Хөррият хакында», «Китмибез») яшәп килүче строй өчен зарарлы фикерләр тапканнар һәм аны хөкемгә тарту өчен статьялар да әзерләп куйганнар. Тик хөкем итмәгәннәр. Шуннан чыгып иптәш Нуруллин болай яза: «Тукайга карата нинди чара күреләсе соң? Берниндидә чара күрелми, мәсьәлә үзеннән-үзе сүнә... Тукай... хәтта полиция күзәтүе астында да тормаган». Бу сүзләрдән патша властьлары Тукайны бер дә борчымаганнар диган фикер чыга. Әлбәттә, мондый нәтиҗә ясау зур «кыюлык». Чөнки «архивның ишеге һәркемгә ачык» булса да, аннан барысын да тиз генә эзләп табу — И. Нуруллин уйлаганча ук җиңел түгел.

И. Нуруллин тапырга теләмәсә дә, патша властьлары исә Тукайны, чыннан да, эзәрлекләгәннәр һәм бик нык эзәрлекләгәннәр.

«1912 елның ахырында (числосы исемдә калмаган), — дип яза, авыр көннәрдә шагыйрьгә ярдәм кулы сузган профессор Клячкин, — миңа, авырып калган язучы Тукайны барып карарга үтенеп, татар яшьләреннән берничә кеше килде. Исемдә калганынча, Тукай ул вакытта Московский (хәзерге Киров) урамда номерларда тора иде.

Мин анда авыр неврастения күренешләре белән бергә җитди авыру таптым. Иптәшләре аның мондый нервлы хәлдә булуын буржуаз язучыларының кайберләреннән һәм полиция агентларының аны туктаусыз эзәрлекләүләреннән килеп чыккан даими борчылулар аркасында булган дип уйлыйлар иде».

Ничек инде шагыйрьне күреп белгән профессор Клячкинның үз кулы белән язып биргән бу сүзләренә игътибар итмәскә һәм ышанмаска мөмкин?

Ниһаять, Нуруллин концепциясе белән килсәк, жандармнар большевистик «Урал» газетасының фактик редакторы Хөсәен Ямашевка һәм революционер язучы Гафур Коләхметовка карата да «каты чара» күрмәгәннәр бит. Патша чиновниклары аларны да официаль рәвештә суд аркылы хөкем итеп, гаепләп өлгермәгәннәр. Ләкин бу бит әле патша хөкүмәтенең шәфкатеннән яки бөтенләй гафу итүеннән түгел, ә бәлки, үзенчә мәсьәләгә сак килергә тырышуыннан, дөресрәге, халык көченнән куркуыннан. Хөсәен Ямашевны, мәсәлән, 1907 елда политик ышанычлы түгел дип, университетка укырга алмаган булсалар, 1911 елда инде ул кабул ителә һәм университет студенты була. Ләкин аның өстеннән һаман да яшерен күзәтү алып барыла. Оренбург, Саратов һәм Казан губернаторлары арасында шул турыда язышу бара. Шундый документларның берсен (22 октябрь, 1911 ел датасы куелган) мин, Казагыстанда конференциядә булганда, Алма-Ата архивыннан табып алдым. Димәк, патша властьлары тарафыннан башланган эзәрлекләү беркемгә карата да үзеннән-үзе сүнеп калмаган. Яшерен күзәтү, эзәрлекләү Ямашев һәм Тукай үлгәннән соң гына туктатыла. Ә Мәҗит Гафури, Гафур Коләхметов, Галимҗан Ибраһимов кебек язучылар өстеннән күзәтү империализм сугышы елларында дәвам итә. Шушыларны белә торып, Тукай полиция күзәтүе астында яшәмәгән дип расларга тырышу — иң кимендә тыйнаксызлык.

Тукай турындагы документларны һәм кыйммәтле истәлекләрне җыеп өлгерә алмаганыбыз төсле, безнең аның турында матбугатта күренгән материалларга да тиешле игътибар һәм бәя бирә алганыбыз юк әле. Шул ук Клячкин Тукайның гаять киң карашлы һәм фикер алышу өчен күңелле кеше булуын басым ясап әйтә:

«Дәвалау өчен кергән вакытларда мин аның белән танышып, тиздән мин аның башкалар белән тиңдәштермәслек кызыклы, киң карашлы, акыллы бер кеше икәнлеген белдем.

Больницада ихтыярсыз эшсез ятарга мәҗбүр булган Тукай миңа җитди әдәбият табып бирү турында үтенеч белән мөрәҗәгать итте. Мин аңа Гейненең русчага тәрҗемә ителгән шигырьләренең, башка чит ил һәм рус шагыйрьләренең кулымда булган җыентыкларын бирдем. Болардан тыш, таныш адвокатым О. аркылы политик әдәбияттан да кайбер китаплар табып бирә алдым. Бу китаплар арасында «Колокол»ның аерым номерлары, Герценның «Былое и думы» диган әсәре, Чернышевскийның «Что делать?» диган әсәре һ. б. барлыгы хәтеремдә. Ул бу әдәбиятны бик зур кызыксыну белән укый иде»[1].

Әлегә кадәр без кирәгенчә игътибар итмәгән булсак та, Тукайның Казан университетына йөрүе, проф. Богородицкийның экспериментал фонетика кабинетында булуы һәм анда рус галимнәре, музыка белгечләре белән еш очрашуы турында да мәгълүматлар бар. Бу яктан, шул чакларда ук музыка белгече булып танылган, соңыннан Башкортстанның халык артисты, композитор Л. Эйхенвальдның 1946 елның 27 апрелендә «Красная Башкирия» газетасында бастырган мәкаләсе бик характерлы. Ул бу мәкаләсендә түбәндәге кызыклы фикерләрне әйтә:

«1907—1911 елларда мәрхүм проф. Н. Ф. Катанов белән берлектә Казан университетының экспериментал фонетика кабинетында эшләгән вакытта, мин Г. Тукай белән еш очраша идем...

Билгеле ки, Тукай халык иҗатын көчле рәвештә сөючеләрнең берсе иде, ул үзе халык көйләрен һәм җырларын җыя иде, бу өлкәдәге эшләр белән бик кызыксына иде. Фольклорга булган мәхәббәт игезендә безнең арабызда дусларча мөнәсәбәтләр урнашты. Тукай беренче очрашуларда ук минем эшем белән кызыксынды, күп мәсьәләләрдә миңа ярдәм итә торган булды.

[1] Габдулла Тукай. Шагыйрьнең тууына 60 ел тулуга багышланган гыйльми сессия материаллары. Татгосиздат. 1948 ел, 87 бит.

Ул профессиональ музыкант түгел иде, ләкин ул халык көйләрен көйләгән вакытларда яки көйләрне ул үзе иҗат иткән-төзегән вакытларда гаҗәпләнергә туры килә иде. Музыканы язу эшенә дисциплина кертү һәм халык җырларын гармонизацияләү аша аны югары баскычка күтәрү юлында эшләгән минем беренче адымнарым Тукайны бик тиз кызыксындырдылар.

Күп сәгатьләр буенча мин аның белән дусларча фикер алышып утыра идем. Татар һәм башкорт музыкасына карата минем тарафтан кулланылган гармониягә Тукай зур сизгерлек белән колак сала иде. Профессиональ музыкант булмавына карамастан, ул кайсы гармониянең татар музыкасына якын булганын, кайсысының аңа чит булганын гаҗәп бер сизгерлек белән тоя иде. Озак вакытлар һәм зур тырышлык белән эшләгәннән соңында, Тукайның барлык күрсәтмәләрен дикъкатьләп һәм бик җентекләп анализдан үткәргәннән соңында, мин үземнең хаталарым нәрсәдә булганлыгын аңладым. Тукай миңа күп нәрсә бирде. Минем музыка өлкәсендәге күп еллык хезмәтләрем һәм Европа музыкаль техникасына нигезләнгән белемнәрем миңа Тукай биргәнне бирә алмаганнар иде»[1].

Менә бу китерелгән документлар һәм истәлекләр Тукайның никадәр киң карашлы, белем даирәсенең никадәр бай булуын раслыйлар һәм аның рус галимнәре белән аралашканда аларда җылы тәэсир калдыруын күрсәтәләр. Тукайның халык иҗаты белән кызыксынуы да очраклы гына булмыйча, Уральск чорында ук башланып, Казанда да дәвам иттерелә. Соңыннан, ягъни 1910 елда Казанда «Халык әдәбияты турында» сөйләгән лекциясендә Тукай:

«Безнең җырланмакта булган көйләребезнең һичберсе дә бер-бер сәбәпсез, бер-бер нәрсәнең тәэсиреннән башка чыкмаган булса да, мәгатәэссеф, аларның сәбәпләрен вә тарихларын тикшерергә кулымда материал булмады. Җырларыбыз вә көйләребезнең тарихын вә мәнбәгъләрен тикшерергә берзаман махсус хезмәт куярмын да, шаять халыкка шул тугърыда әсаслырак мәгълүмат бирермен дигән өмитем бар әле», ди.

Димәк, Тукай һаман да эзләнү уенда булган, тагын да күбрәк эшләү, төплерәк материал җыеп, халыкка бирү дәрте белән янган. Бу инде аның шагыйрь генә түгел, галим булуына да ишарә ясый. Университетның фәнни кабинетларында йөреп, рус галимнәре белән очрашуы да шул төп максатыннан килеп чыккан булуы шиксез.

Талантлы шагыйрь, революция һәм халыклар дуслыгы җырчысы Габдулла Тукай бик күп халыкларның алдынгы вәкилләре тарафыннан тирән хөрмәт белән искә алынды һәм бүген дә хөрмәт ителә. Ләкин без үзебез, ни өчендер, бөек шагыйрьнең уңай якларын күрсәтүгә, бигрәк тә, аның иҗади эволюциясен ачып салуга саранлык күрсәтәбез. Мин монда, әлбәттә, шагыйрьнең фикерләрен бозып яки булмаганны булган дип күпертеп күрсәтүләрне якламыйм. Тукай мирасы аңа мохтаҗ түгел. Ләкин тәнкыйтьченең шагыйрь үзе кире каккан, шулай ук Тукайны яратмаган кешеләр тарафыннан кабат-кабат искә алынган вак мәсьәләләрне яңадан кузгатуы белән һич тә килешеп булмый. Тукай атеист дип чыгучылар хаксыз булганы шикелле, Тукайның яшь буынны аек карашлы итеп тәрбияләргә омтылган («Эшкә өндәү», «Сабыйга») һәм тормышны реалистик күзәтүеннән килеп чыккан («Авыл халкына ни җитми?», «Золым», «Сайфия», «Бәет») әсәрләренә бәя биреп җиткезмәү һәм аның «Алла гыйшкына» кебек шигырьләре дә бар дип, аларны да җыентыкларына кертергә тырышучылар белән дә килешеп булмый.

Тукайның иҗат эволюциясен һәм аның дөньяга карашы эзлекле, реалистик сызыкта үсә барганын дөрес төшенергә теләсәк, без, аның фикер баскычында соңгы нокта итеп 1908 елда ук язылган «Васыять» шигырен телгә алмас идек. Бәлки, үләренә 18 көн генә калгач, Клячкин больницасыннан торып язган «Уянгач беренче эшем» дигән мәкаләсеннән чыгып аның мирасына якын килер идек. Шулай ук соңгы сулышында язган, ул больницада чакта басылып чыккан «Кытгга» исемле шигыре кебек әсәрләренә карап бәяләр идек. Тукай шул шигырендә:

Көчләремне мин кара көннәргә
саклый алмадым.
Көннәремнең һич берен дә, чөнки,
ак, ди алмадым.
Булды юлда киртәләр, әттән күбәйде
дошманым,
Чөнки залимнәрне, өстеннәрне
яклый алмадым. —

ди.

Менә бусы инде Тукайның үз каләме белән язылган. Шулай булгач, без моңарга күбрәк ышаныбыз.

[1] Габдулла Тукай. Шагыйрьнең тууына 60 ел тулуга багышланган гыйльми сессия материаллары. Татгосиздат. 1948 ел, 87 бит.

Рәис Сафаров

Тукайга—яхшы тылмач

Русчага тәрҗемә аша татар әдәбияты күптән инде күп милләтле совет әдәбиятының зур сәхнәсенә чыкты һәм үзенә лаек уңай бәя алды. Башта тәрҗемә эше, нигездә, рус тәрҗемәчеләренең көче белән алып барылса, соңгы елларда бу өлкәдә милли кадрларыбыз житешеп чыкты. Татар әдәбиятын тәрҗемә итүнең масштабы да һәм бу эш белән шөгыльләнүче кадрлар сафы да елдан-ел үсә, киңәя бара. Бу — милли культура үсешендә заманыбызга хас яңа бер күренеш, тәрҗемә тарихында яңа бер этап. Ләкин бик мөһим һәм житди игътибарга лаек бу мәсьәлә безнең дикъкатебездән бөтенләй диярлек читтә калып килә. В. Ганиевның моннан дүрт ел элек «Совет әдәбияты» журналында басылган мәкаләсеннән кала, тәрҗемә турында фикер алышу һәм тәҗрибә уртаклашу да, хәтта кош теледәй генә рецензия булса да язылганын хәтерләмим.

Вил Ганиевның шигъри тәрҗемәләрдә төгәллек һәм нәфислек турындагы фикерләрен Тукай поэзиясен анализлаудан башлап китүе очраклы хәл түгел, әлбәттә. Татар классик әдәбияты үрнәкләрен башка милләт укучыларына без башлап Тукай исеме белән алып чыктык. Һәм Тукай әсәрләренең тәрҗемә сыйфаты турында кайгырту — әдәбиятыбызның абруе турында кайгырту ул. Шуның өчен Ганиев башлаган сүзне, соңга калып булса да, дәвам иттерәсе, бу юлы бөек шагыйрьнең проза әсәрләренең русчага тәрҗемәләре турында бер-ике сүз әйтәсе килә.

1962 ел ахырында Татарстан китап нәшрияты рус телендә Тукай әсәрләренең икенче томын — аның кайбер публицистик, әдәби тәнкыйть мәкаләләрен, очеркларын, фельетоннарын, памфлетларын һәм хатларын басып чыгарды. Бу, беренчедән, тәрҗемә өлкәсендә үзе бер вакыйга, зур казаныш булса, икенчедән, рус һәм башка милләт укучыларына әдипнең гаять күпкырлы иҗат мирасын мөмкин кадәр тулырак итеп житкерүдә мөһим бер адым да булды.

Тукайның шигъри әсәрләрен тәрҗемә итүдән аермалы буларак, монда тәрҗемәчеләр үзләре татарлар, оригинал телен яхшы беләләр, шагыйрь белән бер телдә сөйләшәләр. Бу уңай яклар проза тәрҗемәчеләре алдына бөтен игътибарны бер юнәлешкә тупларга — оригиналны тулы кыйммәтле итеп бирүгә, тәрҗемә сыйфатын тагын да югарырак күтәрергә мөмкинлек бирә. Димәк, Тукайның проза әсәрләре тәрҗемәләренә карата без тагын да ныграк таләпләр куя алабыз: аларда кимчелекләр бөтенләй диярлек булмаска, яки һич югында, аларның сыйфаты шигъри тәрҗемәләрдән калышмаска тиеш.

Тукай прозасын тәрҗемә итүдә унлап тәрҗемәче катнашкан (Б. Антов, А. Ахунжанов, Р. Башкуров, Ф. Вәлиева, Ш. Мөхәммәтъяров, Р. Нафигов, М. Рафиков, Р. Такташ, З. Халитова). Билгеле, аларның тәҗрибәләре дә, бу кыен һәм четрекле эшкә хәзерлекләре һәм сәләтләре дә төрлечә. Җыентыкта, начарлары белән бергә, бик уңышлы, тәрҗемә практикасын, методологиясен баета алырлык тәрҗемәләр дә байтак очрый. Бигрәк тә М. Рафиков, Р. Башкуров, А. Ахунжанов тәрҗемәләреннән үрнәккә лаек мисалларны күпләп китерергә була. Аларның эше нигезендә дөрес принцип — әсәрнең чын әдәби рухын дөрес итеп бирүгә омтылу ята.

Ләкин безнең максат — аерым тәрҗемәчеләрнең эшенә бәя бирү, яки күзгә бәрелеп яткан фактик хаталарны, сәер тәрҗемәләрне капчыкка җыеп, кешеләр алдында чыгарып селкү һәм ырҗаеп көлү түгел, ә бәлки, туплам тәрҗемәсенә тәрҗемә принцибы һәм методологиясе таләпләреннән чыгып карау, бу таләпләрнең практикада ни дәрәҗәдә гамәлгә ашуын күздән кичерү.

Билгеле булганча, тәрҗемә өлкәсендә, һәрвакыт кулланып килгән, бүгенге тәрҗемә теориясе иң дөрес дип тапкан бер генә принцип — тулыкыйммәтле (адекват) реалистик тәрҗемә принцибы яши. Бу принцип оригиналның идея-художество, формаэчтәлек бердәмлеген, әдәби-эстетик кыйммәтен дөрес һәм тулы итеп бирүне, оригинал нинди сыйфатларга ия булса, тәрҗемәдә дә нәкъ шундый ук сыйфатларны саклауга ирешүне, аларның икесенең дә бер үк әдәби кыйммәткә ия булуын таләп итә.

Югарыда әйтеп үткән таләпләрдән чыгып караганда, Тукай прозасын рус теленә тәрҗемә итүдә нинди житешсезлекләр бар соң?

Иң әүвәл күзгә ташлана торган нәрсә— авторның фикерен аңлап житкермәү нәтиҗәсендә, аны бозып бирү. Бу кичерелмәслек хата тәрҗемәченең игътибарсызлыгыннан гына пәйда булмый. Аның нигезендә авторның иҗади юлын тирән өйрәнмәү, аны бәяли белмәү, текст өстендә тирән уйланмау, төпченмәү ята. Фикеребезне дәлилләү өчен, фактларга мөрәҗәгать итик.

Тукай: «Синең шикелле ушбу түбәндәге бәетнең мөсәддәкате булган татарларга халыкны сәләфе салихин тарикына өндәргә оят дип беләбез» [1], ди. Дини ялагайлык белән дәүләт Думасына үтәргә, политик карьера ясарга йөргән эре сәүдәгәр,

[1] Габдулла Тукай. Әсәрләр. III том, 41 бит. Барлык мисаллар да шушы басма буенча китерелә.

тире бае Сәйдәшевка карата бу нәфрәтле һөҗүм тәрҗемәдә автор һич вакытта да уйламаган якка — бөтен татар милләте өстенә яудырыла: «Стыдно, когда татары учат народ идти по пути древних праведников, а сами живут по принципу следующего баита». (Г. Тукай. Избранное. Рус телендә, II том, 97 бит.)

М. Гафуриның «Хәмитнең хәяты» әсәренә карата язылган рецензиясендә Тукай: «М. Гафуриның бу әсәре, аның «Яшь гомеремъ»ендәге «Электрик фонарена» һәм дә мәзкүр (шушы ук — Р. С.) китап әүвәлендәге бәгъзи гүзәл тасвиратны истисна иткәндә (хисапка алмаганда — Р. С.), ул язган әсәрләрнең иң яхшысы вә тормыштан алып язылганыдыр», — ди. (IV том, 88 бит.) Авторның фикере ачык: «Электрик фонарена» һәм кайбер тасвиратлардан кала, «Хәмитнең хәяты» иң яхшы әсәр, ди Тукай. Тәрҗемәче исә телгә алынган бу әсәрләр бары да бер кыйммәтле, бер рәттә торалар дип уйлый һәм Тукайның югарыдагы фикерен: «...произведение М. Гафури «Жизнь Хамита», как его стихотворение «Электрическому фонарю» и ряд других художественных зарисовок из сборника «Молодая жизнь» самое лучшее и самое жизненное» (83 бит) рәвешендә тәрҗемә итә. Шагыйрьнең Ф. Әмирханга язган хатында сүз арасында шаярып әйтелгән «күңел эчү белән бозылган» (IV том, 214 бит) җөмләсен тәрҗемәче, Тукай аракы мичкәсенә кереп баткан, эчүдән башы чыкмый мәгънәсендә: «полностью отравлен водкой», — дип әйләндерә. Авторның иҗатын, оригиналның текстын яхшы өйрәнмәү аркасында килеп чыккан мондый хаталарны байтак очратырга була.

Уңышсыз, урынсыз лексик чаралар сайлап алу, ялгыш синтаксик конструкцияләр төзү, үзенең тәрҗемәсен дөрес укый һәм ишетә алмау һәм башка лингвистик кимчелекләр аркасында, тәрҗемәченең төп нөсхәдәге мәгънәне бозуы, иркен, табигый, җиңел аңлаешлы текстны буталчык, авыр аңлаешлы, көчәнеп укыла торган, хәтта бөтенләй аңлап булмый торган тәрҗемәгә әйләндерүе мөмкин. Мондый тәрҗемәләр тәҗрибә юклыктан да, катлаулы, читен текстлар алдында гаҗиз калудан да, мондый текстларны җиңеп чыгуның практик юлларын, методологиясен белмәүдән дә, рус теленең бөтен грамматик чараларыннан, барлык лексик хәзинәсеннән һәм мөмкинлекләреннән оста һәм акыллы файдалана алмаудан да килеп чыга. Мондый тәрҗемәче, текстның мәгънәсен бозудан куркып, автор җөмләсенең итәгенә ике куллап ябыша, текст өстендә иҗади эшләү аның асыл мәгънәсен, интонациясен, стилен саклап калу өчен рус телендә грамматик, стилистик һәм әдәби чаралар эзләү урынына, авторның җөмлә конструкциясен ничек тә булса бозмаска тырышып, тир түгә, көчәнә һәм, табигый, теләгән нәтиҗәгә ирешә алмый. Чөнки чит семьялардан булган бу ике телнең синтаксик конструкциясе бер-беренә туры килми, ә туры китерергә тырышу телне көчләү була. Гади, аңлаешлы, нәфис җөмлә урынына, кытыршы, көчәнеп укыла торган җөмлә, К. Чуковский әйтмешли, бума ютәлле тәрҗемә килеп чыга. Сәйдәшев белән аның кияве Шайхгаттарның ни өчен җиңел генә Думага депутат итеп күрсәтелүләрен Тукай бик ачык аңлата: «Аларның җиңел үтүенә нифакъ (ялагайлар — Р. С.) гаскәренең главнокомандующие ителергә мөстәхикъ (тиеш — Р. С.) булган бер-ике могътәбәр вә аннан да бигрәк, монафикъ димәк артык булган бер-ике хәзрәт сәбәп булды» (IV том, 164 бит). Бу җөмлә русча болай килеп чыга: «Причиной того, что эти люди так легко стали избранниками, оказались несколько известных, а еще более двоедушных, лицемерных мулл, достойных стать главнокомандующими армии двурушников; они все равно были не у дел». (49 бит.) Тәрҗемәченең оригиналдагы конструкцияне сакларга маташуы аркасында буталчык, аңларга кыен җөмлә барлыкка килгән. Бер-ике могътәбәр һәм бер-ике хәзрәт урынына берничә мулла, алар барысы да нифакъ гаскәренең главнокомандующие, барысы да монафикъ һәм могътәбәр. Тәрҗемәче хыялы белән яратылган соңгы «они все равно были не у дел» тезмәсендә «они» кемнәр алар? Сәйдәшев белән аның киявеме, берничә мулламы? Бу — тәрҗемәчегә генә мәгълүм сер булып кала. Аннан соң, «избранник» сүзенең берничә мәгънәсе булганын да онытырга ярамый. Биредә ул сайланган депутат мәгънәсендә килгән. Хәлбуки, Сәйдәшев һәм аның кияве депутат итеп күрсәтеләләр генә.

Тукайның А. Кариевка язган хатындагы «Мин хәзер Казанда инде. Уральскида вакыт сөйли-сөйли авыз суларым кибеп бетдеке вә шунда бару хакында шигырьләр яздыгым Казанда инде!» җөмләләрен тәрҗемәче, шагыйрьгә ияреп тырышып: «Я теперь уже в Казани, о которой, будучи в Уральске, говорил, пока не пересохло горло, и о поездке, куда я писал свои стихи» (239 бит), дип бирә. Нәтиҗәдә, җылы, дәртле, чын шигъри ритмикада язылган гүзәл җөмләләр урынына ямьсез, өтерләр белән киртәләнеп беткән, буталчык текст килеп чыга. «...О поездке, куда писал стихи» кисәгеннән нәрсә аңлап була? Шигырьне «куда» түгел, бәлки «о чем» гына язарга мөмкин бит!

Бу рәвештә текстка, җөмләгә ябышу бара-бара турыдан-туры сүзгә ябышуга, буквализмга алып килә. Мәсәлән, «Яшь гомерләр мөһмәлат (юк-бар — Р. С.) чәйнәп була монда һәлак» җөмләсе сүзгә-сүз: «молодые жизни, жуя бессмыслицу, погибают здесь» (209 бит) дип бирелә. Һәм яшь гомерләр юкка, әрәмгә уза урынына яшьләр үләләр булып чыга. Менә бу русча җөмләдән берәр нәрсә аңлап буламы: «Бай скорее согласится сунуть подачку, чтоб дать поручение, нежели платить, наняв слугу». Ә бит бу бик матур һәм аңлаешлы итеп төзелгән түбәндәге җөмләнең тәрҗемәсе: «Байлар өчен хак биреп хезмәт кылдырудан, сәдака биреп йомышка кушу җиңелрәк».

Тәрҗемә эшендә сүзләр сайлау иң мөһим һәм җаваплы иҗади процесс. Сүз-

ләрне унышлы сайлап ала алмау коры формализмга гына түгел, текстның мәгънәсен, авторның фикерен бозуга да алып килә. Тәрҗемәче, тәңгәл мәгънәле сүзләр, кирәкле эквивалентлар, синонимнар, урынлы лексик берәмлекләр табу өстендә җентекләп эзләнүләр урынына, тел очында торган беренче формаль сүзне, күп очракта аның доминант мәгънәсен генә алып, үзе теләгән урынга яза да куя.

«Тәрбиясез» сүзенең берничә мәгънәсе, лексик синонимнары бар. Тукай, бу сүзнең күп мәгънәлегеннән оста файдаланып, «Тәрбия» журналының ябылуы уңае белән, үткен кинаяле каламбур төзи: «Тәрбия» журналы... тәрбиясез генә дәфн ителде» (IV том, 29 бит). Тәрҗемәче өчен исә бу сүзнең формаль кыйммәте генә яши, ул аның бу текстта нинди мәгънәдә килүе турында баш ватып та тормый һәм: «Журнал «Тәрбият», говорят, ...был похоронен без всякой в о с п и т а н н о с т и» (122 бит) дип тәрҗемә итә дә куя. Димәк, русча: «был похоронен с воспитанностью» дип тә әйтергә була?! Өстәвенә, кая монда авторның сатирик интонациясе, үткер теле, мәсхәрәле каламбуры?

«Кәсеп итү»не русча з а н и м а т ь с я ч е м-л и б о (ремеслом, торговлей һ. б.) дип тәрҗемә итеп була. «Бер дә кәсеп итмичә... мич башында ята иде ялкау» җөмләсендә бу мәгънәләрнең кайсын сайлап алырга? Автор монда нәрсә әйтергә тели? Тәрҗемәче аны «он никакого ремесла не знал», дип бирә, авторның фикерен боза, логик буталчыклык китереп чыгара. Ялкау ялкаулыгыннан түгел, ә кәсеп, һөнәр белмәгәнлегеннән мич башында ята булып чыга. Сүзләрнең мәгънә төрләрен аныклый һәм сайлый алмау нәтиҗәсендә килеп чыккан мондый кимчелекләр китапта тулып ята: «бөти» (бу очракта «амулет» мәгънәсендә) — «заговорное письмо» (134 бит) дип, «лөгатьче» (лексикограф) — «лингвист»; «иркә җырлар» (возвышенные, веселые песни) — «песни про милочек»; «хөкүмәт газетасы» (правительственная газета, правительственный орган) «орган власти»; «инсаният» (человечество) — «гуманизм» дип бирелгән.

Рус лексик фондының гаять бай хәзинәсеннән ахырынача файдалану, сүз кулланыш осталыгына өйрәнү урынына, кайбер тәрҗемәчеләр кирәкмәс яңа сүзләр ясау, урынсыз «неологизмнар» белән мавыгалар. Мәсәлән, «Бәхетлеләр кырда җәйли, валлаһи»ны тәрҗемәче «счастливые в поле л е т у ю т, честное слово», дип җибәрә. «Летовать» сүзе рус лексикасында юк. Бу «кышлау — зимовать»ка ияреп ясалган калька гына. «Зимовать» сүзенә карап кына «осеновать», «весновать» дип әйтеп булмый бит инде!

Тәрҗемәдә, бигрәк тә үткән чор әдәбиятын тәрҗемә иткәндә, сүзләрнең тарихын, э т и м о л о г и я с е н яхшы белмичә эшкә тотыну мөмкин түгел. Заманнар үтү белән сүзләрнең мәгънәләре дә үзгәрә: тарая яки киңәя, яисә яңа төсмер, башка оттенок ала. Бу — һәр телнең үсү диалектикасы. Шулай икән, тәрҗемәче үзенең эшендә теге яки бу сүзнең бүген яшәгән мәгънәсен генә түгел, бәлки аның эволюциясен, тәрҗемә ителәчәк әсәр язылган чорда ул нинди мәгънәләрдә кулланылганын яхшы белергә тиеш. Моны белмәү житди хаталарга алып килүе мөмкин. Менә берничә мисал. «Малай» сүзе бездә хәзер фәкать «ир бала» (мальчик) һәм халык сөйләмендә эндәш сүз (Әйтмә дә инде, малай!) мәгънәсендә генә йөри. Тукай заманында бу сүз «хезмәтче», «йөгердәк», «ялчы», «йомышка чабучы» мәгънәләрендә дә кулланылган. Тәрҗемәче моны белмәгәнлектән, оригиналдагы «акча малае» атамасын «денежный мальчик» дип тәрҗемә итә. Нәтиҗәдә, И. Гаспринский капиталга хезмәт итүче, капитал ялчысы — «акча малае» (прислужник капитала) дип әйтү урынына, Исмәгыйль абзый ни бары «денежный мальчик» — а к ч а л ы м а л а й гына булып чыга. «Җыю» сүзе элек «ашау», «ризыклану» мәгънәсендә дә актив кулланылган. Ләкин тәрҗемәченең моннан хәбәре юк. Шуңлыктан ул «К о р с а к: кеше хакын җыяр (ашар — Р. С.) өчен булган бер аппарат» җөмләсен «Ж и в о т: аппарат, существующий для сбора дани с человека» (118 бит) дип «тәрҗемә» итә. Бу җөмләне яңадан татарчага тәрҗемә итсәк, «Карын: кешедән ясак туплау өчен яшәүче аппарат» булып чыга. «Мәҗлес» сүзе Тукай чорында, күбрәк, «җыелыш» мәгънәсендә йөртелгән. Ләкин тәрҗемәче моны белми, һәм бу сүзне «обед» дип әйтә. Искергән сүзләрнең мәгънәләрен белмәү, яки аларны дөрес ача алмау нәтиҗәсендә барлыкка килгән мондый тәрҗемә «үрнәкләре» китапта әллә ни кадәр.

Ярый, искергән сүзләрнең мәгънәләрен ачуда хаталар котылгысыз да булсын ди. Әмма инде бүгенге рус һәм татар әдәби телләрен яхшы белү — тәрҗемә эшенә керешкән кеше өчен мәҗбүри шарт. Мондый сәләткә ия булмый торып эшкә тотыну, — тәрҗемәне куралэтә бозуга керешү була. Әйтик, к а б а н д у ң г ы з ы русча — к а б а н, д и к а я с в и н ь я. Татар телендә дә, рус телендә дә бу сүзнең күчермә мәгънәсе бар: зур, килбәтсез гәүдәле, симез, тупас кеше. Тукай А. Сәйдәшевны шулай атый. Тәрҗемәче исә аны «Свинья с озера Кабан» (?) дип җибәрә. Ата дуңгыз русча кабан яки хряк, боров дип атала; ана дуңгыз — свинья, свиноматка. Тәрҗемәче аларны, «бутамас» өчен булса кирәк, «свинья-самец», «свинья-самка» дип атый (93 бит.)

Шундый ук «тәрҗемәләр» аркасында «арба кендеге» — «железный засов» (172 бит), «халык бәгыре» (душа, сердца народа) — «печень народа» (12 бит), «рәссам» (художник) — «картина» (24) булып чыга, «адәм балалары» — «дети Адама»га әйләнә.

Хәрефкә, сүзгә ябышу һәртөрле тәрҗемәдә зарарлы алым. Ә инде ф р а з е о л о г и я н е т ә р җ е м ә иткәндә, моңа һич тә юл куелырга тиеш түгел. Дөрес, ике телдә дә фразеологиянең лексик составы һәм мәгънә кыйммәте бер-беренә туры килүе, ярашуы мөмкин. Ләкин монда да сак булырга кирәк. Әгәр фразеологиядә реалияләр

очраса, ул милли төстә булса, икенче телдәге ярашкан фразеологияне китерү, яки сүзгә-сүз тәрҗемә итү дөрес булмый. «Мәхәлләсенә күрә мулласы» әйтемен русчадагыча «каков поп — таков и приход» белән бирсәк, татарларда да поп бар булып чыга. Монда «мулла», «поп» милли реалияләр, алар тәрҗемә ителмиләр, бер-берсен алмаштыра да алмыйлар. Мондый очракларда фразеологиянең логик эчтәлеген саклый ала торган эквивалентлар табарга кирәк. Кагыйдә буларак, фразеологияне икенче телгә ритмик яктан якынлаштырып, кирәк урында сүзләрнең әйберлек (реалия) мәгънәсен үзгәртеп, ләкин логик функциясен бозмыйча, иҗади тәрҗемә итәргә кирәк. Ул икенче телдә дә яшәргә хаклы яңа фразеология булып яңгырасын, ул телне баетсын. Шуңа күрә «Чиләгенә күрә капкачы» әйтемен Тукайны тәрҗемә итүчеләр шикелле сүзгә-сүз «по ведру и крышка» дип түгел, бәлки рус телендәге аналогларының берсе («каково лукошко — такова ему и покрышка», «по горшку и покрышка» һ. б.) аркылы бирергә кирәк. Урманчиевка язган хатында Тукай: «А воз и ныне там»ны «Ә йөк һаман да шунда» дип язып, татарга ни аңлатабыз?» дигән иде. Тәрҗемә итүче шул ук җыентыктагы «уеннан уймак чыкты» әйтемен күз дә йоммыйча, «из игры получился наперсток» дип әйләндерә дә куя. Искәрмәдә «татарская поговорка» дию белән, руслар бу «татарская поговорка»дан нәрсә аңларлар икән? Мәкальләр, әйтемнәр телебез шикелле үк борынгы. Аларда бик иске лексик һәм грамматик элементлар яшеренгән. Кайбер фразеология берәмлекләрен бу яктан анализлау шактый читен эш. Чыннан да, югарыдагы әйтемдә «уймак» сүзе нәрсә аңлата? Без аны ансат кына «наперсток» дип әйтә алабызмы? Әлбәттә, юк. Ләкин шунысы ачык: мондагы «уймак»ның элекке лексик мәгънәсе югалган. Гомумән, мәкальләрдә аерым сүзләр түгел, бәлки мәкаль үзе, ул ничә лексик берәмлектән булуына карамастан, бер мәгънә, бер берәмлек булып килә. Шуның өчен мондый мәкальләрне сүзгә-сүз тәрҗемә итәргә тырышу үзе бер мәгънәсезлек.

Оригинал телендәге шәхси атамалар — исем-фамилияләр, кагыйдә буларак, икенче телгә тәрҗемә ителмиләр. Ләкин монда бер мөһим искәрмә ясарга кирәк. Алар автор тарафыннан махсус әдәби максатта — киная, кушамат, сатирик-юмористик алым урынына, яки башка әдәби функцияләрдә кулланылган булырга мөмкин. Мәсәлән, А. П. Чеховның «Ат фамилияле» хикәясе нәкъ шул нигездә язылган. Әгәр андагы фамилияләрне (Лошадкин, Жеребцов, Кобылин һ. б.), бигрәк тә әсәрнең бөтен серен, интригасын чишүче Овсов фамилиясен тәрҗемә итмибез икән, бу әсәрне тәрҗемә итүнең бөтенләй мәгънәсе, кирәге юк. Мондый очракларда алар, әлбәттә, тәрҗемә ителергә тиеш.

Димәк, Тукай әсәрләрендәге махсус әдәби алым, сатирик чара сыйфатында кулланылган «Сапсата сатаров», «Ахмак Шәрик», «Ахмакҗан Чәйдәшев», «Кишери», «Аптрар Аптрарович», «Бытбылдыкитдин» кебек атамалар, мәсәлән, Глупостидругов, Глупость Жевалкин, Морковин-Морковцев, Оторопий Удивленцев, Перепелкинга охшаш тәрҗемә ителеп, искәрмәдә аларның эчке мәгънәсе, нинди сүзләр белән әһәңдәш килеп, сүз уйнатылуы, каламбур ясалуы турында аңлатма бирелергә тиеш иде. Әмма тәрҗемәчеләр моны эшләмәгәннәр. Бытбылдыкитдин, Сапсата сатаров һ. б. дип бирелүеннән руслар нәрсә генә аңлый соң? Әлбәттә, алар гади татар фамилияләре булып кына күренәләр һәм укучы дикъкатеннән бөтенләй читтә калалар. Авторның нияте, әйтәсе сүзе, бу кешеләргә булган мөнәсәбәте, саркастик каламбурларның тексттагы идея роле укучыга бөтенләй җиткерелми.

Тәрҗемәләрдә реалияләрне — иҗтимагый тормыштагы төшенчәләрне, материаль көнкүрештәге әйберләрне, предметларны аңлатучы сүзләрне — бирүдә күп чуарлык сизелә. Реалияләр милли обстановканы, колоритны бирүдә сизелерлек роль уйныйлар. Аларны гел тәрҗемә итеп барсаң, әсәрнең милли төсмере югалуы, үзенә генә хас буявы үзгәрүе, ә инде транслитерация аркылы гел үзгәртмичә биреп барсаң, оригиналның чамадан тыш экзотик, үтә милли төс алуы мөмкин. Шуның өчен бу өлкәдә билгеле бер чама булырга, фәкать бер милләткә хас, икенче телдә эквивалентлы, тиң кыйммәте булмаган реалияләрне генә үзгәртми бирү урынлы. Мәсәлән, Тукай әсәрләрендә очрый торган бәлеш, шәригать, азан, хәзрәт, мулла кебек сүзләрне җәя эчендә аңлатма белән, шул килеш бирү дөрес булыр иде. Ләкин тәрҗемәчеләрнең абый, апа, иҗек, мәнтыйкъ, мөгаллим, нәху, түрә, әфәнде шикелле атамаларны үзгәртмичә бирүләре дөрес түгел. Чөнки бу реалияләргә әсәрнең милли оттеногына һич зыян китермичә, рус сүзләре табып була.

Тәрҗемәләрдә башка төр кимчелекләр, хаталар да шактый күп очрый. Җыентыкны баштанаяк укып чыкканнан соң, андагы әсәрләрне Тукай — гаҗәеп үткер каләмле бөек әдип язганына ышанасы килми тора. Аларның стиле, теле тәрҗемәчеләрнең үз сәләтләреннән югары түгел. Тукайның прозаик әсәрләрен унлап кеше тәрҗемә иткән. Аларның күбесенә иҗади эш итү, кыюлык, мөстәкыйль фикер йөртү җитешми. Тәрҗемә принцибын, методологиясен аңлауда һәм куллануда төрлелек, чуарлык күренеп тора. Шуннан, табигый сораулар туа: бер Тукайны ун төрле дәрәҗәдә әзерлекле, ун төрле стильдә, принципта эш итүче ун кеше тәрҗемә итүе үзе дөресме? Тәрҗемәләрдә методологик чуарлык, сыйфат төрлелеге шуннан килеп чыкмаганмы? Һәр ун тәрҗемәченең һәрберсендә унар процент Тукай булу белән йөз процент Тукай килеп чыга дип уйлау әдәбият белән арифметиканы буташтыру түгелме?

Тукайны бөтен дөнья укучысына тәкъдим итү гаять мөһим, җаваплы эш. Ул аерым тәрҗемәчеләрнең генә эше түгел. Бөек шагыйребезнең мирасындагы һәр сүз, һәр җөмлә ничек җитте шулай түгел, фәкать ничек кирәк шулай тәрҗемә ителергә тиеш.

Шәриф Байчура

Инәсеннән җебенә кадәр...

I

Халык шагыйре Габдулла Тукайның шигырь мәҗмугалары, сайланма әсәрләре, тулы җыелмаларының саны берничә дистәгә җитә. Аның әсәрләренең русча тәрҗемәләре дә күп тапкыр басылып чыкты инде. Бу мәкаләдә без шагыйрь әсәрләренең һәм аның турында язылган китапларның соңгы елларда чыккан басмаларының сыйфат ягына, аларда очраган төгәлсезлекләргә тукталып үтәчәкбез.

Сүзне «Тукай турында замандашлары»[1] дигән җыентыкны күзәтүдән башлыйк. Бу китап шагыйрь үлгәннән соң басылып чыккан истәлекләр, шигырьләр һәм мәкаләләрдән торган алтмыштан артык әсәрне эченә ала. Төрле урыннарда чәчелеп яткан ул кыйммәтле истәлекләрне бергә туплап чыгару — инде үзе үк әһәмиятле, зур вакыйга. Анда, Фатих Әмирхан, Галиәсгар Камал кебек, халык шагыйренең иң якын дуслары һәм күп кенә иптәшләренең хатирәләре урнаштырылган. В. И. Ленинның һәм А. М. Горькийның халык шагыйре Габдулла Тукай турында әйткән кыска, ләкин тирән мәгънәле сүзләре, китапка аерым бер күркәмлек биреп торалар. Шуның белән бергә, өстән генә күз йөртеп чыкканда да, бу җыентыкта без төрле кимчелекләргә, урынлы-урынсыз кыскартуларга, кайберәүләрнең карашларын үзгәртеп күрсәтүләргә, җитди бозуларга очрыйбыз. Бу хәлләр шагыйрьнең замандашы, шагыйрь яшәгән шартларны яхшы белгән өлкән буын кешеләргә бигрәк ачык күренә. Менә кайбер мисаллар. Китапның 112 битендә шагыйрь һәм язучы Мәхмүд Галәүнең (Мәхмүд Мәрҗани) «Тукай турындагы истәлекләрдән бер кисәк» дигән мәкаләсе басылган. Бу мәкалә «Совет әдәбияты» журналының 1936 елгы 5 санында чыккан булган. Җыентыкка ул шуннан күчереп урнаштырылган. М. Галәү бу мәкаләсендә «Болгар» номерларында яшәгән Тукай янына килеп, аны бик күнелсез, бик борчулы килеш ятып торган хәлдә туры китерүен сөйли. Бу борчылуга, имештер, Исхак Бикчурин дигән бер журналистның үз-үзен үтерүе сәбәп булган икән. Автор яшьләр тормышындагы шундый күңелсез күренешләр турында Тукай белән сүз алып барганлыгын хикәя итә. Тукайның өстәлендә яңа гына язылган «Қатиле нәфескә» («Үз-үзен үтерүчегә») дигән шигыре дә ята иде, бу шигырь әнә шул Бикчуринга карата язылган иде, ди М. Галәү. Ләкин М. Галәү Тукай үлгәннән соң 23 ел үткәч

[1] Тукай турында замандашлары. Татарстан китап нәшрияты. Казан, 1960 ел.

язып бастырган бу истәлегендә күп нәрсәләрне буташтыра.

Дөреслектә исә хәл менә ничек тора. Революциядән соң провокаторлыгы ачылган И. Бикчурин Тукай үлгәндә әле исән иде. Ул Тукай үлгәннән соң 18 көн үткәч, ягъни 1913 елның иске стиль белән 20 апрельдә үз-үзен үтерде[1]. Тукай «Қатиле нәфескә» исемле шигырен исә аннан өч ел элек — 1910 елда ук бастырган иде. Димәк, бу шигырьнең Бикчурин белән һич бәйләнеше юк.

Җыентыкның 246 битендә «Татар халкының олуг каһарманы» дигән кечерәк бер истәлек урнаштырылган. «Ялт-Йолт» журналының 1913 елда чыккан 55 санында «Исәнбай» кушаматы белән басылган бу истәлек Фатих Сәйфи-Казанлыныкы. Җыентыкта тупланган кайбер истәлекләрне «редакцияләү»нең ничек эшләнүен күрсәтү өчен ул характерлы мисал була ала. Мәкалә башына, Тукайдан алып, эпиграф итеп куелган «Зур җаным сөйми җиһанны, чөнки бар дөнья фәна...» шигыре төшереп калдырылган. Ә мәкаләнең ахырына «Тукай халык шагыйре иде, ул капитализм тормышының корбаны булды» дип, яңа җөмлә өстәлгән. Бу җөмлә мәкаләдә юк һәм булырга да мөмкин түгел. Чөнки 1913 елда Ф. Сәйфинең фикер үсеше һәм дөньяга карашы ул җөмләне кулланырлык дәрәҗәгә җитмәгән иде әле.

Мәкаләне җыентыкка урнаштыру уңае белән, Ф. Сәйфинең халык шагыйре Г. Тукай иҗатына мөнәсәбәте турында укучыларга аңлатма биргәндә, әйбәтрәк булыр иде. Чөнки Ф. Сәйфи-Казанлы 1913 елда язылган ул мәкаләсендә «...Тукаебыз да татар тарихының ае, ае гына түгел, кояшы иде» дип әйткән булса да, революциядән соң инде ул Тукайны халык шагыйре дип тануга каршы позициядә торды. Ф. Сәйфи, 1929—31 елларда Тукай әсәрләренең латин хәрефе белән бастырып чыгарылган икенче томына язган сүз башында халык шагыйренә карата кире караштa торганлыгын ачык әйтә[2].

Язучы А. Шамов та «Казан утлары» журналының быелгы январь санында басылып чыккан «Бер кичәдә» исемле истәлегендә Ф. Сәйфинең 1923 елда ук инде Тукайны халык шагыйре дип тануга каршы булганлыгын һәм Тукай иҗатына уңай бәя биреп доклад ясаган Фатих Әмирхан белән кискен бәхәсләшкәнлеген күрсәтә.

[1] «Кояш» газетасының 1913 ел 21 апрель санында Бикчуринның үлүе турында басылган белдерүне карагыз.

[2] Казан университетының гыйльми китапханәсендә Тукай әсәрләренең бу басмасы хәзерге көндә дә саклана.

Тукайның якын иптәшләреннән Вафа ага Бәхтияров мәкаләсенең ахырында (92 бит) «...Галимҗанның «Татар шагыйрьләре» исемле әсәре Тукайга авыр тәэсир итте», дип әйтелә. Бу сүзләрдән «Татар шагыйрьләре» Тукай исән чакта ук матбугатта чыккан икән дип аңларга мөмкин. Чынлыкта исә, ул вакытта бу китапның чыгачагы турында «ым-шым» гына таралган иде, китап үзе Тукай үлгәч басылып чыкты. Дөрес, ул китапның беренче бүлеге 1912 елның җәендә «Идел» газетасында басылды. Шулай да, аның турыдан-туры Тукайга караган өлеше чыкмаган иде әле. Тукай моны белмичә үлде. Тукайның замандашы һәм шәкерте булган күренекле шагыйрь Г. Харисның «Тукай рухына» дигән шигырендә «Син терек чактук колакка кергән иде пыш-пышы, үлгәч үч алды, хәзер һич калмагандыр үкенече» дигән ике юлы «Татар шагыйрьләре» авторына каратылган һәм бу юллар ул китапның Тукай үлгәннән соң чыкканлыгын ачык күрсәтеп тора. Без тикшерә торган җыентыкның 224 битендә Г. Харисның әлеге шигыре дә урнаштырылган. Ләкин шигырьдән югарыдагы ике юл «төшеп калган».

Җыентыкка кергән бүтән истәлекләргә (Г. Камал, Ф. Әмирхан, М. Гафури, Г. Кариев истәлекләренә) карата да кайбер кыркулар яки кайбер өстәүләр ясалуын, шулай ук башка җитешсезлекләр турында И. Нуруллинның кечерәк бер мәкаләсендә дә кагылып үтелгән иде. («Совет әдәбияты» журналы, 1961 ел, 12 сан.) Без бирелә аларны кабатлап тормыйбыз.

Истәлекләр китабында псевдонимнар мәсьәләсендә дә чуалчыклыклар очрый. Китапның 254—255 битләрендәге «Юксынабыз» дигән мәкалә Габдрахман Кәрәмнеке итеп бирелгән. Бу мәкалә «Ялт-Йолт» журналының 1915 елда чыккан 88 санында «Әкмәли» имзасы белән басылган булган. Хәлбуки, бу псевдоним Г. Кәрәмнеке түгел. Ә 1907—1909 елларда «Әлислах» газетасында язышкан, аннары, 1914 елдан башлап, Ф. Әмирхан белән берлектә «Кояш» газетасында эшләгән Ибраһим Биккулов дигән журналист псевдонимы ул. «Аң» һәм «Ялт-йолт» журналларында да, «Кояш»та да Биккуловның шул имза белән күп кенә мәкаләләре басылып килде.

Бу мәкаләдә сүз чыганаклары билгеле булган истәлекләр турында гына барды. Инде төрле фондларда сакланган яки турыдан-туры җыентык төзүчеләргә тапшырылган хезмәтләрнең ничек редакцияләнүен ачыклау мөмкин булмады. Бу китапны яңадан бастырганда (аның тиражы инде күптән таралып беткән), бөек шагыйрьнең тормышы һәм иҗат эшчәнлеге турындагы материалларны компетентлы комиссия җитәкчелегендә тирәнтен өйрәнеп, зур игътибар белән карап, төзәтеп чыгарырга кирәк.

II

1963 елда «Советский писатель» нәшриятының Ленинград бүлеге Габдулла Тукайның шигырь һәм поэмалар җыентыгын рус телендә бастырып чыгарды. Җыентыкка текстларны Пехтелев белән шагыйрь Сибгат Хәким әзерләгәннәр, кереш сүзне профессор И. Г. Пехтелев язган. Автор шагыйрьнең әсәрләрен җентекләп тикшерә, рус классик әдәбиятын, бөек рус шагыйрьләре А. С. Пушкин, М. Ю. Лермонтов, Н. А. Некрасов әсәрләрен татар телендә популярлаштыручы булуын да күрсәтеп үтә. Алга таба, Тукайның патриотлыгы турында сөйләп, Пехтелев «Тукайның ватанга мәхәббәте аңа 1907 елда патриотик идеяне әйтеп бирүе ягыннан аеруча көчле булган «Китмибез» дигән шигырен язарга мөмкинлек бирде» дип әйтә дә, шигырьнең язылу тарихын болай аңлата: «Революция вакыйгаларыннан куркуга төшкән татар реакционерлары татарларны Төркиягә, солтан тәбәгалегенә (подданствосына) күчерү кампаниясен җәелдереп җибәрделәр». Тукай, бу шигыре белән, янәсе, әнә шул татар реакционерларына гына җавап биргән була.

Дөреслектә, бу шигырьнең язылуы бөтенләй башка вакыйга белән бәйләнгән. 1907 елның 4 маенда икенче дәүләт Думасы утырышында уку-укыту мәсьәләләре карала. Элекке Уфа губернасы (хәзерге Башкортстан) территориясеннән сайланган депутат, трудовиклар фракциясе члены Кәримулла Хәсәнов думада речь белән чыга һәм, мәктәптә укыту һәр халыкның үз ана телендә (украин теле, поляк һ. б.) алып барылырга тиешлеген яклап, болай ди: «Без мөселманнар рус телен өйрәнү кирәклеген һич инкарь итмибез... Ләкин без рус телен кемнең булса да басымы астында түгел, бәлки үз ихтыярыбыз белән өйрәнергә телибез (сулдан кул чабулар). Без мөселманнар укырга телибез, ләкин Ильминский, Победоносцов һәм башка миссионерлар методы белән түгел, бәлки үз туган телебездә укырга телибез (уң депутатлар ягында зур шау-шу күтәрелә һәм «Төркиягә китегез!» дигән тавыш ишетелә»)[1]. Икенче Думаның бу утырышы ул вакытта бөтен Россия матбугатында зур тавыш күтәрде. Утырышта карагруһ депутатлар үзләрен гаять тәртипсез тотканлыктан, Пуришкевич, Келеповский һәм Сазонович дигән уң депутатларны Думаның 15 утырышына катнашудан мәхрүм итү турында махсус карар чыгарыла. Халык шагыйре Габдулла Тукайның «Китмибез» дигән шигыре нәкъ менә шушы вакыйгага карата язылган да инде. Шигырьнең эчтәлеге дә моны ачык күрсәтә. Ләкин аның русча тәрҗемәсе төгәл булып җитмәгән. Шигырьдәге «кара йөзләр» сүзе кеше йөзе, кеше бите мәгънәсендә алынмаган бит. Тукай «кара йөзләр» сүзен 1905—1907 еллар

[1] Бу өземтә Петербургта татар һәм әзербәйҗан телләрендә чыгып килгән «Дума» исемле газетаның 1907 ел 8 май саныннан алынды. Думадагы 1907 ел 4 май вакыйгасы рус телендә чыккан «Речь» газетасының 1907 елгы 5 май санында аерым сәхифә итеп бирелгән. «Новое время» һәм «Русское слово» газеталарының 5 май саннарында да бу вакыйга киң яктыртыла.

революциясе чорында, патша монархиясен яклап, революциягә каршы чыккан кара көчләр (черносотенцы) мәгънәсендә куллана. Шуңа күрә аны «нам предлагают подлецы» дип тәрҗемә итү мәгънәне дөрес бирми. Шигырьнең «Если лучше вам, туда сами пожалти, господа!» дип, русча сүзләр белән тәмамлануы да аның кемнәргә юнәлдерелүен, ягъни Пурешкевичларга адресланган булуын ачык күрсәтә.

Шигырьнен язылу вакыты да шул ук фикернең дөреслеген раслый. Шигырь 1907 елның май аенда, ягъни Думадагы теге вакыйгадан соң ук язылган булырга тиеш. Тукай шул ук елның май аенда Казандагы «Мәгариф» китап нәшрияты белән хат аша бәйләнешкә керә һәм бу нәшриятка язган икенче хатында (1907 ел, июль) җыентыкка керәчәк шигырьләре арасында, «Шүрәле», «Бездә истигъдат бар» дигән шигырьләре белән беррәттән, «Китмибез» не дә саный. Аларны җыентыкның башынарак урнаштыруны кирәк таба [1]. Кыскасы, шигырьнең әлеге вакыйгага бәйләнешле булуы, аның самодержавиегә дә, реакцион татар милләтчеләренә дә каршы язылуы бәхәссез.

III

Габдулла Тукай әсәрләренең 1955 елда чыгарылган 4 томлыгы чагыштырмача яхшырак басмалардан санала. Биредә, тулы булмаса да, Тукай шигырьләренең язылу тарихлары күрсәтелгән, әдипнең үз әсәрләренең һәм аның турындагы әсәрләрнең бай библиографиясе бирелгән, текстта очраган гарәп, фарсы һәм төрекчә сүзләргә аңлатмалар язылган. Ләкин бу аңлатмаларда ялгыш һәм уңышсыз тәрҗемәләр шактый күп очрый. Биредә шуларның кайберләрен күрсәтеп китик. Беренче томның 91 битендә «сәнгать» сүзе «һөнәр, эш» дип аңлатыла. Бу, әлбәттә, дөрес түгел. Һөнәр, эш мәгънәләрен гарәпчә «сәнәгать» сүзе бирә. «Әгәрчә зәррә мыскал һиммәте бар, аның артында тау-тау миннәте бар» тезмәсендәге «миннәт» сүзен «мактанып сөйләү» дип тәрҗемә итү дә дөрес түгел (шул ук том, 151 бит). Бу сүз бераүнең сиңа кечкенә генә бер яхшылык эшләп тә, шуны һаман синең исеңә төшереп, күзенә бәреп әйтүен аңлата. Мишәрләр: «Җә житәр, п и н ә л ә м ә инде» диләр. Аннары «Мөбтәла» сүзе «мавыгалар» дип тәрҗемә ителгән (икенче том, 200 бит). «Анда тормакка һәвәслек берлә ваклар мөбтәла» ди шагыйрь. «Мөбтәла» сүзе «бәлагә төшү» «бәлагә тару» мәгънәсен белдерә. Фарсычадан алынган «Нәгыз» сүзен «Нәкъ үзе» дип әйтү дә ялгыш (дүртенче том, 136 бит). «Юынгыч — мәрмәрнең нәгызе» диелә шагыйрьнең текстында. Бу сүз бик яхшы, бик әйбәт мәгънәсендә йөри. «Ижра кылмадылар» йөртмәделәр дип тәрҗемә ителгән (шул ук том, 165 бит). «Үтәмәделәр» яки «эшләмәделәр» дип аңлатканда, уңышлырак булыр иде кебек.

Академик басмада төрле белешмәләрне күрсәткәндә дә кайбер төгәлсезлекләргә юл куелган. Урынсыз кыскарту яки төшереп калдыру очраклары да бар. Мәсәлән, икенче томның 196 битендәге «Аң» шигыреннән беренче басылуында ук патша цензурасы тарафыннан сызылган «Кем бу гафләттә итә файда, шуны күрдек торып» дип башланган дүрт юл текстка яңадан кертелмәгән.

Тукайның кайбер әсәрләрендә, бигрәк тә сатирик һәм памфлет шигырьләрендә, ул вакыттагы татар җәмгыятендә булган кайбер вакыйгалар һәм аерым шәхесләрнең исемнәре, «Җиңги Садыйк», «Ончы хаҗи» кебек төрле кушаматлары телгә алына. Боларны аңлатканда да кайбер буташтырулар күренә. Өченче томның 348 һәм 349 битләрендә «Кәҗә Якуб» дигән кушаматка бөтенләй ялгыш аңлатма бирелә. Ул Якуб Хәлили кушаматы дип күрсәтелә. Чынлыкта исә, «Кәҗә Якуб» кушаматы Яңа Бистәдә кәҗә тиресеннән күн эшли торган завод хуҗасы, һәр яңалыкка, прогресска каршы торучы реакционер бер татар баеның кушаматы. Якуб Хәлили исә вакытында Буби мәдрәсәсен тәмамлаган прогрессив бер кеше. Ул татар телендә беренче буларак хатын-кызларга махсус «Сөембикә» журналын чыгарып, шуңа редакторлык итеп килде. 1916—17 елларда «Балалар дөньясы» исемле журнал чыгаруда катнашты.

Дүртенче томның 274 битендә «Усал» псевдонимы Фатих Әмирханныкы итеп күрсәтелгән. Бу — ялгыш. Ул псевдоним — ак эмигрант Ф. Туктаровныкы.

Югарыдагы фактлар бөек әдип иҗатын өйрәнү өлкәсендә әле күп җитешсезлекләр булганлыгын, Габдулла Тукай тормышына һәм иҗат эшчәнлегенә карата фәнни тикшеренү эшләре өзлексез дәвам иттерелергә һәм шагыйрьнең иҗаты тагын да тирәнтен өйрәнелергә тиешлеген ачык күрсәтәләр.

1961—1966 еллар.

[1] «Тукай турында замандашлары» китабының 97 битендәге Гыйльми Шәрәф мәкаләсен карагыз.

Әдәби тел мәсьәләләре турында сөйләшәбез

МИЛЛИ ТЕЛЛӘРНЕҢ ФУНКЦИЯЛӘРЕ ҺӘМ ҮСҮ ДИАЛЕКТИКАСЫ

Билгеле булганча, Октябрь революциясенә кадәр шактый үсеш алган милли телләрнең дә (мәсәлән, украин, белорус, үзбәк, әзербәйҗан, грузин, әрмән телләренең) иҗтимагый функцияләре киң җәелеп китә алмады. Бу хәлне без татар теле мисалында да ачык күрәбез. Революциягә кадәр эш кәгазьләре, рәсми документлар татар телендә алып барылмады. Фән һәм сәнгать теле буларак та, аның кулланылыш сферасы нык чикләнгән иде. Дөрес, татар теле матур әдәбият, вакытлы матбугат һәм укыту теле буларак, шактый киң кулланылды. Шулай да, ул чорда татар теле, башка милли телләр кебек үк, иҗтимагый функцияләре ягыннан һәм фәнни эшкәртелеш ягыннан артык зур үсеш ала алмады.

Бары Октябрь революциясеннән соң гына милләтләр, шул исәптән татарлар, үзләренең әдәби телләрен үстерергә, аларның иҗтимагый функцияләрен киңәйтергә, ә язма әдәби телләре булмаган халыклар язма әдәби тел барлыкка китерергә мөмкинлек алдылар.

СССРдагы милли телләрдә фәнни әсәрләр, тикшеренүләр басыла. Мәсәлән, украин, белорус, әрмән, грузин, әзербәйҗан телләрендә философия, политэкономия, математика, физика, атом энергиясе физикасы, геология, техника, лингвистика буенча фәнни хезмәтләр басылып чыга. Фәннең һәм техниканың күп кенә тармакларына караган байтак кына оригиналь һәм тәрҗемә хезмәтләр татар телендә дә даими рәвештә чыгып килә.

Милли телләрдә философия фәне буенча күп кенә оригиналь һәм тәрҗемә хезмәтләр басылып тора. Мәсәлән, милли телләргә В. И. Ленин әсәрләренең күбесе, Маркс, Энгельс, Плеханов әсәрләре тәрҗемә ителгән яки тәрҗемә ителә. Милли телләрнең философия теле буларак кулланылуы аларның һәм структурасы, һәм иҗтимагый функциясе ягыннан бик нык үсүе турында сөйли.

Барлык милли телләр укыту теленә, мәктәп теленә әйләнделәр. Союздаш һәм автономияле республикаларда, милли өлкәләрдә, ата-аналарның ихтыяры буенча, урта мәктәпләрдә укыту ана телендә алып барыла. Балалар укыту эшен ана телендә алып бару Россиянең бөтен халыкларын грамоталы итәргә, аларны алдынгы культура белән таныштырырга, культура һәм белем дәрәҗәсен күтәрергә мөмкинлек бирде. Шул нигездә милли республикаларда һәм өлкәләрдә белемнәрнең төрле тармакларына караган тәрҗемә һәм оригиналь дәреслекләр һәм кулланмалар барлыкка китерелде (физика, география, математика, зоология, ботаника, ана теле һ. б. буенча).

Милли телләрнең Октябрь революциясенә кадәр бөтенләй булмаган иҗтимагый функциясе барлыкка килде һәм үсте. Хәзерге көндә милли республикаларда һәм өлкәләрдә эш кәгазьләренең, рәсми документларның бер өлеше милли телләрдә алып барыла (протоколлар, белешмәләр, рәсми хатлар, эш кәгазьләре, отношениеләр һ. б.). Бигрәк тә милли телне аңлый һәм ул тел белән эш итә торган коллективтан торган учреждениеләрдә, оешмаларда эш кәгазьләре, белешмәләр милли телдә языла. Ә эшнең характерына бәйләнешле рәвештә, төрле милләт кешеләре белән эш йөрткәндә, рәсми кәгазьләр, документлар милләтара телдә — рус телендә алып барыла. Бу хәл исә СССРда телләрнең тигез хокуклылыгын юкка чыгармый. Билгеле булганча, күп милләтле Совет дәүләтенең тел өлкәсендәге политикасының төп принцибы — бөтен милли телләрнең үзара тигез хокуклылыгы. Бу принцип, ягъни телләрнең үзара тигез хокуклылыгы, СССРда закон тәртибен алган. Илебезнең һәр гражданы теләсә нинди дәүләт һәм җәмәгать оешмасына үз ана телендә мөрәҗәгать итә ала.

Ләкин телләрнең үзара тигез хокуклылыгы совет җәмгыятенең гомуми интересларына каршы куелмый — совет кешеләре телләрнең үзара тигез хокуклыгы принцибын эзлекле рәвештә яклап, ул хокукны үзмаксатка, абсолютка әйләндермиләр, — коммунистик төзелешнең гомуми интересларына буйсындыралар. Димәк, хәзерге көндә рус теле белән милли тел арасында иҗтимагый функцияләрнең бүленүе СССР халыкларының гомуми интересларына, идеалларына туры килә һәм телләрнең үзара тигез хокуклыгын инкарь итми.

Пропаганда-агитация теле, вакытлы матбугат һәм публицистика теле буларак, хәзерге вакытта милли телләр үзләренең

иҗтимагый функцияләрен бик нык үстерәләр. Радио һәм телевидение тапшыруларында милли телләр зур роль уйный. Милли телләрнең бу функцияләре торган саен киңәя һәм үсә бара. Күп кенә очракларда авыл, район һәм кайбер вакытта өлкә, республика күләмендә оештырыла торган җәмәгать эшләре ике телдә алып барыла (сайлаулар кампаниясе, зур коллективлар белән оештырылган җыелышлар, митинглар, җыеннар һ. б.).

Совет власте шартларында милли әдәби телләр, художество әдәбияты теле буларак, үзләренең иҗтимагый функцияләрен нык үстерделәр һәм киңәйттеләр. Язма әдәбият традициясе көчле булган милләтләрдә (украиннарда, татарларда, әзербәйҗаннарда, грузиннарда, әрмәннәрдә, үзбәкләрдә һ. б.) милли телләрнең бу иҗтимагый функциясе яңа баскычка күтәрелде. Әдәбиятның барлык жанрлары барлыкка килде һәм үсте. Рус һәм дөнья классикларының әсәрләре бу милли телләргә шактый күп тәрҗемә ителде һәм ителә. Шулай итеп, милли өлкәләрдәге, республикалардагы хезмәт ияләренең киң массалары дөнья күләмендәге күренекле рухи байлыклар белән танышырга мөмкинлек алдылар.

Сәнгатьнең сүзгә нигезләнгән башка төрләрендә милли телләр шулай ук зур әһәмияткә ияләр. Революциягә кадәр күп халыкларда һәм милләтләрдә драма, опера театрлары, эстрада сәнгате бөтенләй юк иде. Ә революциягә кадәр азмы-күпме сәнгате булган халыкларда милли телнең бу төр функциясе бик киң җәелде (мәсәлән, украиннарда, грузиннарда, татарларда һ. б.).

Югарыда сөйләнгән фактлар милли телләрнең иҗтимагый тормыш һәм культураның бөтен сфераларына үтеп керүе турында сөйлиләр һәм социализм шартларында, структурасы ягыннан үсүе белән бергә, иҗтимагый функцияләре ягыннан да нык үсүен һәм киңәюен күрсәтәләр.

Социализм һәм киң колач белән коммунизм төзү чорында СССРда яшәүче халыкларның үзара ныклы ярдәме һәм тыгыз бәйләнеше кирәк булды. КПСС программасында болай диелә: «Милләтләрнең үсеше, капитализм вакытында булган кебек, милли дошманлыкны, милли чикләнгәнлекне һәм эгоизмны көчәйтү юлы белән түгел, бәлки милләтләрнең якынаю, туганнарча ярдәмләшү һәм дуслык юлы белән бара»[1].

Шуңа күрә дә, күп милләтле социалистик җәмгыять шартларында һәрьяклап үсә торган тигез хокуклы милли телләр арасыннан, милләтләрнең дуслыгы һәм аралашу чарасы буларак, табигый рәвештә бер милләтара телнең кирәклеге килеп чыкты. Шуның өчен күп милләтле социалистик дәүләттә милләтара телнең барлыкка килүе — тарихи котылгысыз һәм прогрессив күренеш.

Милләтара тел өчен ясалма телләр (эсперанто, интерлингва һ. б.) яраклы түгелләр. Чөнки, беренчедән, ясалма телләрне үзләштерү бик күп көч куюга, энергия, байлык түгүгә бәйләнгән булса, икенчедән, аларның социаль-тарихи җирлеге юк.

Тәҗрибә күрсәткәнчә, милләтара тел ясалма рәвештә килеп чыкмый, ә акрынлап, башка милли телләрдә сөйләшүчеләрнең ризалыгы белән, тигез хокуклы милли телләрнең берсенең милләтара телгә әйләнүе рәвешендә бара. Күп милләтле совет дәүләтендә гомуми, уртак телгә ихтыяҗ тугач, бу рольне, акрынлап, тигез хокуклы милли телләрнең берсе — рус теле үти башлады.

Әгәр конкрет милли тел билгеле бер милләт вәкилләре арасында аңлашырга ярдәм итсә, милләтара тел төрле милләтләрнең вәкилләре арасында аралашу чарасы булып тора. Милләтара тел производство эшен җиңеләйтә, рухи бердәмлек барлыкка китерергә ярдәм итә. Милләтара тел булган рус теле милли республикаларда һәм өлкәләрдә нинди иҗтимагый функцияләрдә кулланыла соң?

Рус теле Советлар Союзында яшәгән барлык милләтләрнең вәкилләре өчен милләтара аралашу чарасы булып тора. Бу хәл бигрәк тә производство сферасына карый. Милли республикаларда һәм өлкәләрдә фән һәм техниканың күп кенә тармаклары рус телендә үстерелә. Бу — прогрессив күренеш һәм ул фәннең тәэсирен, йогынты сферасын киңәйтә. Эш кәгазьләренең, рәсми документларның күп өлеше рус телендә алып барыла. Бу бигрәк тә производство, техника өлкәләренә карый. Эш кәгазьләренең, рәсми документларның рус телендә язылуы милли телләрнең үзара тигез хокуклыгын инкарь итми. Чөнки тигез хокуклылык бездә гомуми интересларга бервакытта да каршы куелмый.

Милли республикаларда һәм өлкәләрдә югары һәм махсус уку йортларында укыту, кагыйдә буларак, рус телендә алып барыла.

Хәзерге көндә милли республикаларда һәм өлкәләрдә ике теллелек шактый нык үсеп бара. Милләтләрнең аерым катлаулары, мәсәлән, интеллигенциянең шактый күп өлеше, рус телен, кагыйдә буларак, үзләренең ана теле кебек үк яхшы беләләр. Киләчәктә ике теллелек үсә барачак. Бу күренешләр исә рус теленең фактта икенче ана теленә әйләнә баруы турында сөйлиләр. Ләкин бу күренешнең телләрнең кушылуы турындагы хата фикер белән бернинди дә уртаклыгы юк.

Хәзерге көндә, экономиканың уртак булуы нигезендә, совет милләтләренең культурасы гомумиләшә бара. Шуннан чыгып, кайбер кешеләр «тел культураның формасы, шулай булгач, телләр дә кушыла башлый» дигән нәтиҗә ясыйлар.

Милли телләрнең кушылуы турындагы хәзерге көндәге фикерләр И. В. Сталинның бу турыдагы хата гипотезасын кабатлауга кайтып кала. И. В. Сталин, мәгълүм булганча, грамматик төзелешнең һәм төп сүзләр фондының тотрыклыгына нигезләнеп, телләрнең кушылуын инкарь итте. Ләкин үзенең шул фикеренә каршы буларак, телләрне киләчәктә башта бер

---

[1] КПССның XXII съезды материаллары. Казан, 1962, 375 бит.

зона теленә әйләнер, аннан соң бу зона телләр бер гомуми халыкара телгә кушылыр дигән гипотеза белән чыкты [1].

Бу гипотезаның чынбарлык белән берниндн дә уртаклыгы юк. Ул башыннан алып ахырына кадәр утопия. Советлар Союзында милләтләр һәм телләр үсеше аны расламый. Бу гипотеза СССРда милләтара теленең килеп чыгуын һәм яшәешен инкарь итә. Шуның белән бергә, ул тикшеренүчеләрне, фән кешеләрен ялгыш юлга этәрә. Шулай ук В. И. Ленинның бу мәсьәләгә карата әйткән билгеле фикерләренә каршы килә: «...экономик әйләнеш ихтыяҗлары бер дәүләттә яшәүче милләтләрне (алар бергә яшәргә теләгән чакта) һәрвакыт күпчелек телен өйрәнергә мәҗбүр итәчәк» [2], — ди В. И. Ленин. Күп милләтле совет дәүләтенең тәҗрибәсе Ленин положениесеның дөреслеген раслады. Социалистик строй милләтләр теленең үсеше өчен киң юл ачты. Шуның белән бергә аерым милләтләрнең вәкилләре арасында рус телен өйрәнүгә теләк арта бара. Киләчәктә СССРда яшәгән милләтләрнең телләре һаман да үсәчәк, чәчәк атачак. Һәм милли телләрне киләчәктә бетәчәк дип әйтү дөреслеккә туры килми.

КПСС программасында бу хакта мондый аңлатма бирелә: «СССРда коммунизмның җиңүе белән милләтләр үзара тагын да ныграк якынаерлар, аларның экономик һәм идея гомумилеге артыр, аларның рухи йөзенең уртак коммунистик сыйфатлары көчәер. Ләкин милли аермаларның бетүе, бигрәк тә тел аермаларының бетүе, сыйнфый аермаларның бетүенә караганда, шактый дәвамлырак процесс» [1].

Шулай итеп, күп милләтле социалистик дәүләтнең тел тормышындагы диалектикасы, бер яктан, милли телләрнең бик нык үсеш алуы һәм иркен үсүеннән, икенче яктан, милләтара теленең барлыкка килүе һәм аның киң таралуыннан гыйбарәт. Өстән караганда, бу ике күренеш бер-берсенә каршы киләләр кебек. Ләкин бу ике процесс та тарихи мәҗбүри һәм прогрессив күренеш, аларның икесен дә кире кагарга ярамый.

Милли телләр дә, милләтара тел дә Советлар Союзы халыкларының культурасының һәм экономикасының үсүе, күтәрелүе өчен бер үк дәрәҗәдә мөһимнәр һәм кирәкләр.

Милли телләр һәм милләтара тел берберсен үзара тулыландыралар һәм бары бергәлектә генә һәр милләтнең һәм күп милләтле бөтен совет дәүләтенең телгә булган ихтыяҗын бөтен яклап канәгатьләндерә алалар.

Бу өлкәдә ленинчыл милли политиканы тормышка ашыра барып, ике фронтка каршы, беренчедән, милли телләрнең әһәмиятен аңлап җитмәгән кешеләргә каршы һәм, икенчедән, милләтара телнең прогрессив икәнен аңламаган кешеләргә каршы көрәш алып барырга кирәк.

---

[1] И. В. Сталин. Марксизм һәм тел гыйлеме мәсьәләләре. Казан, 1950, 50—52 битләр.

[2] В. И. Ленин. Телләр мәсьәләсендә либераллар һәм демократлар. Әсәрләр, 4 басма. Казан, 1960, 19 том, 345 бит.

[1] КПССның XXII съезды материаллары. Казан, 1962, 376 бит.

Ф. ГАНИЕВ,
филология фәннәре кандидаты.

Халык мәзәкләре

ӘМӘЛЕН ТАПКАН

Әлең берәүнең ике хатыны булган.
Бервакыт хатыннары аңардан:
— Син кайсыбызны күбрәк яратасың? — дип сораганнар.
— Икегезне дә бик яратам, — дигән ир кеше. Ләкин хатыннар моның белән генә канәгатьләнмәгәннәр:
— Әгәр су кергәндә икебез дә бата башласак, беренче булып кайсыбызны коткарыр идең? — дип бәйләнгәннәр.
Шулчак ир кеше картрак хатынына:
— Син үзең дә йөзә беләсең бит! — дигәнен сизми дә калган.

ШАЯН БАБАЙ

Хатын-кызлар кырда чүмәлә куялар икән. Алар белән бик шаян бер бабай да эшли икән. Шул бабай бер кызга әйткән:
— Кара әле, кызым, юл буйлап куян чаба түгелме?
— Юк, бабай, бернәрсә дә күренми.
— Алайса, кызым, чүмәләң өстенә менеп кара, бәлки, шуннан күрерсең.
Кыз чүмәлә өстенә менгән икән, чүмәлә бөтенләй җиргә сеңгән. Кыз эшне аңлаган да, чүмәләсен яңадан куя башлаган.

КИТАП КҮЗӘТҮ

Гүзәл шигърият хәзинәсе

Жырлар... Халкыбызның иң тирән һәм самими уй-кичерешләрен, ышану-өметләрен, моңнарнең йөрәк жылысы белән сугарылган чиксез бай хистойгыларын гажәеп бер шигъри нәфислек белән әйтә алган жырлар.

Моннан бернична еллар элек, фольклор экспедицияләрендә катнашып йөргән чакларда: «Их, бу авылда сюжетлы жырлар очраса гына икән!» — дип, рухланып та, офтанып та эшкә керешкән сәгатьләр аз булмады. Татарстанның үзендә мондый жырларның жыеласы жыелган һәм аерым китапларда басылып та чыккан иде. Кызганычка каршы, үз республикабыз озын жырларга әллә ни бай түгел икән. Өмет күрше республика һәм өлкәләргә юнәлде. Һәм чыннан да чит якларга (Киров, Пенза, Оренбург, Астрахань, Горький өлкәләренә һәм Мордва республикасына) барып чыккач та, фольклорчылар жыр диңгезенә чумгандай булдылар. Халкыбыз тормышының кайсы якларына гына багышланмаган, кеше күңеленең нинди кылларын гына тибрәндермәгән һәм тибрәндерми ул жырлар!

Һәм менә китап инде кулларыбызда [1]. Зәңгәр төстәге гади катыргы тышлы, артык гади, хәтта беркадәр зәвыксыз эшләнгән тышлы. Хәер, монысына әллә ни игътибар итмәстән, күңел тизрәк аның эченә үтәргә атлыга...

Жыентыкны төзүче һәм дөньяга чыгаручы И. Надиров, халык жырларын чынчынлап яратып, жылы тоннарда һәм беркадәр лирик планда язган кереш мәкаләсендә (жырлар турында, мөгаен, бүтәнчә язып та булмый торгандыр!) болай ди:

«Жыр сөйләр өчен түгел, ә көйләр өчен чыгарыла. Әгәр халыкның моңлы, аһәңле, матур көйләре аның тиңдәшсез һәм оста композитор булуы турында сөйләсәләр, шул көйләрнең нәфис сүзләре аның акыллы һәм талантлы шагыйрь булуын раслый».

Китапка исә халык жырларының текстлары гына урнаштырылган. Халкыбыз телендә «көй — күңелнең моңы» дигән тирән мәгънәле әйтем яшәсә дә, ноталары кертелмәгәнлектән, жыентыкта тупланган ул жырларны, һәрхәлдә байтагын, көйлижырлый алмыйбыз. Димәк, китапта жыр төшенчәсенә туры килгән чиксез бай хәзинәнең бер ягы гына яктыртыла, ул бөтен тирәнлеге, киңлеге һәм мөмкинлекләре белән алынмый. Чөнки китап таррак максатны күз алдында тотып чыгарылган: төзүче аны киң катлау укучыларга бүгенге совет фәнендә булган нигез принципларга таянып әзерләнгән филологик жыентык рәвешендә тәкъдим итә. Ягъни халкыбызның «сүнмәс вә сүрелмәс» поэзиясеннән мәгълүм жанрларның иң кызыклы, иң күркәм әсәрләрен бергә туплап, кире халыкка кайтару бурычын алга сөрә. Һич икеләнмичә әйтик: төзүче үз алдына куйган катлаулы бурычны намус белән башкарып чыккан. Һәм без, бу жыентыкта урнаштырылган поэзия үрнәкләре белән танышып алгач, татар халкының «акыллы һәм талантлы» шагыйрь, бөек әдип икәнлегенә чын-чынлап ышанабыз.

Сүз уңаенда шуны да хәбәр итеп китик: Казан тел, әдәбият һәм тарих институтының халык иҗаты һәм сәнгать тарихы секторында эшләүче музыка белгече М. Нигъмәтҗанов тарафыннан жырларыбызның сүзләре дә, көйләре дә бергә тупланган махсус жыентык әзерләнгән. Анда И. Надиров төзегән китаптагы жырларның байтагын кабат күрергә мөмкин булыр. Ул жыентык якын киләчәктә, китап нәшриятының бормалы-сикәлтәле юлларын имгәнмичә һәм тиз арада үтәр дә, жылы кулларыбызга килеп кергәч, күңелләрне куандырыр дип өметләник.

И. Надиров жыентыгына нигездә моңа кадәр беркайда да басылмаган әсәрләр тупланган. Аларның күпчелек өлешен төзүче һәм аның иптәшләре, фольклор экспедицияләрендә йөреп, халык талантларыннан үз куллары белән язып алганнар. Моның өстенә, төзүче Тел, әдәбият һәм тарих институтының элек-электән жыйналып килгән фольклор фондыннан, Татарстан радиокомитеты архивыннан һәм хәтта аерым язучыларның шәхси жыйнамаларыннан киң

---

[1] **Татар халык жырлары. Лирик жырлар, йола жырлары. Татарстан китап нәшрияты, 1965 ел.**

рәвештә файдаланган. Китапта шулай ук кайчандыр басылып та, инде онытыла барган җыр текстлары да очраштыргалый. Боларны табу һәм яңадан җанлы тормышка кертеп җибәрү өчен дә Октябрь революциясенә кадәр һәм аннан соң басылып чыккан дистәләрчә җыентыкларны өйрәнеп-үзләштереп чыгарга кирәк иде. Китапта игътибарны җәлеп иткәне дә шул: төзүче, һич иренмичә, булган бөтен хәзинәдән зур эстетик һәм фәнни таләпчәнлек белән энҗе бөртекләрен барлап-сайлап ала белгән һәм китапны җитди бер фәнни хезмәт дәрәҗәсенә җиткергән. Аның гыйльми тирәнлеге тупланган әсәрләрнең бай эчтәлек һәм формаларыннан да, аларның идея-тематик яктан төркемнәргә бүленеп, мәгълүм бер системада урнаштырылуыннан да, кереш мәкаләдә актуаль һәм җитди мәсьәләләр кузгатылуыннан да, искәрмәләрнең төгәл һәм тулы булуыннан да килә.

Дөрес, җыентыкның корылышында кайбер чатаклыклар да юк түгел. Үзенең кереш мәкаләсендә төзүче йола җырларының идея-тематик һәм генетик яктан лирик озын җырлардан бик нык аерылганлыкларын әйтә. Бу шулай. Ләкин эшкә килгәндә, ул үзе үк, халык лирикасының бик борынгы төре булган йола җырларын мөстәкыйль бер бүлеккә (иң дөресе, хезмәтнең алдагы өлешенә) аерып алмыйча, аларны лирик озын җырларның тематик төркемнәре арасында урта бер җиргә тыгызлап кертеп куя. Моның белән төзүче үзе утырган ботакка үзе балта чаба түгелме соң? Лирик озын җырларның тематик төркемнәргә бүленеше дә мәгълүм шартлылыктан азат түгел. Мәсәлән, «Ялчы егетләр, батраклар һәм ярлылар турында» һәм «Бәхет эзләп читтә йөрүчеләр моңы» төркемнәре арасында принципиаль аерма күренми. Аларны бергә туплап биргәндә дә ярар иде. «Рекрут һәм солдат җырлары» бүлекчәсенә кергән «Сандугач идем илемдә» җыры эчтәлеге белән «Бәхет эзләп йөрүчеләр моңы» төркеменә тартымрак кебек тоела. «Туган ил» җыры да исеме белән үк «Рекрут һәм солдат җырлары» бүлекчәсенә ялгыш эләкканлеген әйтеп тора. Шулай ук кайбер текстларның гомумән җыентыкның рухына һәм характерына туры килүе-килмәве, аерым җырларның исем-атамалары уңышлы яисә уңышсыз булуы хакында да бәхәс кубуы мөмкин. Ләкин нинди җитди фәнни хезмәтнең бәхәс кузгатмыйча калганы бар икән?!

«Татар халык җырлары» җыентыгына кергән әсәрләрнең күбесенә композицион төгәллек, форма гадилеге һәм киң гомумиләштерү хас. Җыр халык характерының иң төп сыйфатларын берничә типик штрих белән генә дә рәсемдәге шикелле итеп күз алдына бастыра. Анда аерым шәхеснең бүтәннәрне кызыксындырмаган вак кичерешләре турында сөйләү, аның эчке дөньясын да «казыну» юк. Шуңа күрә, халык җырында геройның биографиясе дә бирелми, хәтта аның җенесе дә ачык күрсәтелми. Җыр шул милләтнең күпчелек кешесенең яисә билгеле бер социаль төркеменең рухи халәтенә якын булганда гына халык җыры була ала. Җырда шәхес һәм халык арасында искиткеч тыгыз бәйләнеш яши. Әмма җырның бу үзенчәлеге аның иң интим, халык иҗаты әсәрләре арасында иң субъектив жанр булуына каршы килми. Кайбер җырларда без шактый тирән психологизм элементлары белән очрашабыз. Мәсәлән, «Батрак җыры»ндагы «Күңелем шат булса да, күздә яшь», «Җәмилә, җаныем ла»дагы «Синең күңелең ник салкын», «Табалмадым» әсәрендәге «Сөясеңме диеп син сорама, йөзләремә карап үзең бел», «Ак бүрек» исемле лирик җырдагы «Исләремә төшсә, исем китә, төшкә керсә, башым әйләнә, яна йөрәгем, ничек түзәргә?» шикелле гыйбарәләр кешенең рухи кичерешләрен шактый тулы чагылдыралар. Бик күп җырларда («Күктә лә болыт», «Сөйгәнемә баралмадым» һ. б.) геройның эчке дөньясы турыдан-туры табигать күренешләренә бәйле рәвештә ачылып китә. Соңгы елларда туган «Вәгъдә», «Озата барма» шикелле җырларда психологизм тагын да көчлерәк һәм эзлеклерәк бирелгән. Әлбәттә, биредә язма поэзиянең халык җырына тәэсирен дә читләтеп үтеп булмый. Шунысы кызык, соңгы елларда иҗат ителгән һәм киң таралган җырларның сүзләрендә, әдәби җырдан бигрәк, лирик поэзия йогынтысы ныграк сизелә. Бу хәл, бәлки, профессиональ җырларның сәнгатьчә эшләнеше түбән булудан килә торгандыр.

Җырлар — халык тормышына иң якын жанрларның берсе. Нәкъ менә шуңа күрә, Г. Тукай халык җырларын: «безнең бабаларыбыз тарафыннан калдырылган иң кадерле вә иң бәһале мирастыр» дип атый.

Әйткәнебезчә, халык үзенең җырлары өчен теманы да, образны да күктән эзләми. Җырның нигезендә безне чолгап алган чынбарлык, туган илнең, табигатьнең матурлыгы, замандашының күркәм уйлары, тирән һәм катлаулы кичерешләре ята. Җыентыкка тупланылган әсәрләрнең дә тукымасына туган як табигате («Ямьле Агыйдел буйлары», «Туган җирләр калды еракта»), яши торган җир («Сарман», «Арча», «Шөгер»), сөйгән яр образы («Гөлҗамал», «Әсмабикә», «Мәдинәкәй»), яисә аларны алыштырып килүче шигъри образ-символ («Бөдрә тал», «Сандугач күгәрчен», «Ай, былбылым») үрелеп кергәнлеген күрәбез. Җырның төп композицион элементын тәшкил иткән шул конкрет төшенчәләр һәм образлар аша кеше рухының диалектикасы гәүдәләнә. Бу хәл халык җырларындагы эчтәлек белән форма арасында тыгыз бәйләнеш һәм тәңгәллек барлыгы турында сөйли.

Безнең җырларның халык фикерләренә барып тоташа торган үз шигъри теле, традицион образлар системасы бар. Ул искиткеч тотрыклы. Җыр образларының телдән-телгә, бер әсәрдән икенчесенә күчеп йөрүләре һәм шул телдә сөйләшүче күпчелек халыкка таныш булулары аркасында җырчы белән тыңлаучы үзара бик тиз «уртак тел» таба алалар. Халык җыры эчтәлеккә караган нейтраль сүзләрне дә образга әйләндерә. Мәсәлән, бер төркем халык җырларының атамасы аерым төбәккә

янсә кеше исеменә карый. Жырның эчтәлеге дә күпмедер күләмдә исеме белән бәйле була. Әмма акрынлап жырның төп эчтәлеге исеменнән читләшә бара. Атама бер шартлы элементка — бизәкләү чарасына, янсә композиция ысулына әйләнә. Мисалга совет чорында туган «Арча», «Шөгер» жырларын алыйк. Бу жырларда төбәк исеме композицион элемент булып кына калган, ул хисси эчтәлеккә кереш ролен генә үти, әсәрдә сүз бөтенләй башка нәрсә турында бара:

Арчаларга, барсаң, бәгырем,
Ал гөлләрне өзәрсең,
Үзәгемне бик өзәсең
Үзең ничек түзәсең?

Шөгерләргә барам әле,
Шөгер суы тәмлегә,
Бир кулыңны, мин дә бирәм
Аерылмаска мәңгегә.

Илебезнең төрле почмакларында яшәүче татар кешесе өчен Арчамы, Сарманмы, Шөгерме ул, барыбер — тик жыр аның рухына, кичереш-уйларына гына туры килсен. Мисалга тагын «Мәдинәкәй»не алып карыйк. Бу жыр, бәлки, иң әүвәл бер конкрет кешегә багышланып чыгарылгандыр. Әмма ул, яшьлек хисләрен матур, самими һәм тулы ачып биргәнгә күрә, үзенең иҗатчысыннан да, Мәдинәкәйдән дә озынрак гомерле булып чыккан. Бу жыр әле һаман да дулкынландыра, тыңлаучыга эстетик ләззәт бирүен дәвам итә. Аның «тел тибрәтеп әйткән сүзләре», «синнән матурны тапмадым», «бик күп йөрдем, жаным» шикелле фразеологик әйләнмәләре, «бөрлегәннән кызыл йөзләрең», «карлыганнан кара, ай, кашларың» шикелле традицион чагыштырулары яңа шартларда да гаҗәп матур яңгырыйлар. Димәк, безнең көннәрдә дә *Мәдинәкәй* матурлык, гүзәллек символы булып кабул ителә. «Гөлҗамал», «Галиябану», «Хәтирә» шикелле жырлар белән дә шул ук хәл. Жыр туктаусыз гомумиләштерүгә, шигъри горизонтын киңәйтүгә омтылыш күрсәтә.

Бирелә халык жырларының «икенче тормышы» турында да онытырга ярамый. Алар безнең бүгенге поэзиябездә яшәүләрен дәвам иттерәләр. Поэзиянең нигезендә яткан бик күп үзенчәлекләре халык жырына барып тоташканлыгын күрүе артык читен түгел. Бу нәрсә халык жырының зур эстетик кыйммәткә ия булуы турында сөйли. Халык жыры белән поэзия арасындагы уртаклык шигырь төзелешеннән алып типиклаштыру алымнарына хәтле килә. Әмма безнең поэзия халык жырының барлык мөмкинлекләреннән дә файдалана алмый әле. Профессиональ жырлар арасында халык жырларыннан күп түбән торганнары да очрый. Еш кына без халык жырының форма байлыгын үстерәсе урынга, булганнарны да югалта барабыз. Бирелә халык жырына зур мәхәббәт белән караган, аны бүгенге поэзиянең аерылмас бер өлеше дәрәҗәсенә күтәргән С. Хәкимнең мәгълүм сүзләре искә төшә: «Халык жырларында нинди генә формалар юк! Алар кая ташланган, ник өйрәнелми. Нигә бу нәрсә поэзиянең төп көчләрен борчымый?» [1]

Халык үзенең кайгысын, шатлыгын, туган иленең матурлыгына соклануын, сөйгәненә булган зур мәхәббәтен сөйләмичә түзә алмаганда, хисләре ташкын булып тышка бәреп чыкканда гына образга, жырга күчергән. Шуңа күрә, халык жырында олы хисләр турында гына сүз алып барыла. Татар халык жырларына вакыйгаларны һәм геройларны беркадәр идеаллаштыру, чынбарлыкның реаль вакыйгаларын романтик күзлектән чыгып сурәтләү хас. Шәрүк беглый белән Хәмидулла качкыннарның батырлыгы да, буй кызларының матурлыгы да, туган илнең яме дә бераз күпертеп бирелә. Татар халык жырларында сез урта кул егетне янсә урта кул кызны күрмәссез — алар берсеннән-берсе матурлар, батырлар, бар да нәзек биллеләр, зифа буйлылар... Әмма һәр жырда персонажның төп бер билгесе үзәккә алына. «Нәзек бил», «Зифа буй», «И, алтын чәч», «Гөлкәй» шикелле жырларның исемнәренә мөрәжәгать итү генә дә бу нәрсәне ачык күрсәтә. Халык жырының әлеге үзенчәлеге иҗатчының күңелендәге гармония, фантазия байлыгы, чынбарлыкны хыял белән баету турында сөйли.

Инде кереш мәкалә турында кайбер фикерләр. Алда әйткәнебезчә, кереш, үзенең лирик стиле белән, китапта тупланган жырларның рухына бик тә туры килеп тора. Шул ук вакытта, автор анда өлгергән фәнни проблемаларны да кузгата. Ул, ирешелгән уңышларга таянып, халык жырларын өйрәнүнең яңа классификациясен тәкъдим итә, жырларга карата *сюжет* терминын куллануның зарури булмавы турында әйтеп үтә. *Сюжет* термины бер-берсенә тыгыз бәйләнгән берничә куплеттан торган һәм билгеле бер көйгә беркетелгән жырларның татар фольклорында зур урын тотуын исбатлау ягыннан уңай роль уйнады, әлбәттә. Әмма ул хәзер лирик озын жырларның эчтәлеге һәм форма тукымасын, эстетик тәэсир көчен өйрәнү юлында киртә булып тора, аларның санын да бик нык чикли. Чөнки сюжет терминын кулландыкмы, анда кечкенә генә булса да сәбәпле бәйләнеш, гадиләштереп әйткәндә, сөйләп бирерлек вакыйга булырга тиеш. Ә безнең фольклорның тезмә жанрларында, «Шәрүк беглый», «Хәмидулла качкын» шикелле эпик жырлардан һәм бәетләрдән башкаларында, әдәбият белемендә кабул ителгән сюжет төшенчәсенә җавап бирә торган сюжетлы әсәрләр юк диярлек. Татар халык жырларына тирән лиризм, эмоциональлек хас. Шуңа күрә аларның үзәгендә, И. Надиров кереш мәкаләсендә бик дөрес күрсәтеп үткәнчә, кеше кичереше, хис хәрәкәте ята. Кичереш жырның сурәтләү объекты булып тора, форма ягыннан караганда, аның композициясен дә үзенә буйсындыра. Автор «сюжетлы жырлар» терминыннан баш тартып, дөрес иткән дияргә килә.

[1] С. Хәким. Безнең көннәр поэзиясе. «Совет әдәбияты» журналы, 1958 ел, 7 сан, 111 бит.

И. Надиров җыентыкка кергән һәр төркемчәгә кыскача характеристика бирә, аның үзенчәлекле сыйфатларын ачып салырга омтыла. Мәсәлән, рекрут һәм солдат җырлары турында сөйләгәндә ул: «Солдат җырында иҗтимагый мотив көчле», дип бик дөрес күзәтү үткәрә, кайгы-хәсрәт җырлары тууының иҗтимагый нигезен ачып салырга омтылыш ясый. Туй йолаларының килеп чыгуын да И. Надиров, нигездә, дөрес аңлата. Әмма туй йолаларының һәм җырларының тоташ кара төскә буялган булуы яшьләрне үзләренең теләкләреннән башка өйләндерү мотивы белән генә аңлату хәзерге укучыны ышандырып җиткермәстер. Монда «туй җыры» янына өстәлә торган «йола» сүзе дә күп нәрсә турында сөйли. Бу җырлар йола булып халык теленә килеп кергәннәр һәм, буыннан-буынга тапшырыла килеп, сәнгать әсәренә әверелгәннәр. Хәер, автор үзе дә бераз соңрак шул ук фикергә килә һәм туй йоласы «театраль-драматик бер күренешкә әйләнгән», ди.

И. Надиров, шактый киң рәвештә, халык җырларының поэтикасына да туктала. Бу — татар фольклористикасында бөтенләй диярлек өйрәнелмәгән өлкә. Биредә җырларның шигъри төзелешенә, образлар системасына, кушымтаның ролен ачыклауга багышланган кызыклы күзәтүләр бар. Күбесе ышандыра. Әмма авторның бер кискен фикере белән килешәсе килми. «Ритмик үлчәве, шигырь төзелеше буенча татар халык җырлары силлабик системага керәләр. Бу система шигырь юлында иҗекләрнең тигез булып кабатлануына нигезләнгән», — ди автор. Дөресрәге, силлабик системада иҗек саны һәр юлда да тигез булырга тиеш. Әмма силлабик система өчен иҗек саны бертигез булу гына җитми. Биредә басым зур роль уйный. Силлабик системада басым сүзнең аерым бер иҗегенә беркетелгән була. Мәсәлән, француз телендә басым соңгы иҗеккә, поляк телендә арттан икенче иҗеккә төшә. Ә безнең телдә, И. Надировның үзе әйткәнчә, «басымнар татар җырларында сан ягыннан да, урыннары ягыннан да төрлечә булырга мөмкин, чөнки безнең телдә басым даими түгел». Шулай булгач, татар җырының ритмик төзелеше силлабик система рамкаларына сыеп бетми түгелме соң?

Китапның искәрмәләр бүлеге соңгы фәнни казанышларга нигезләнеп төзелгән. Анда җырның язып алынган урыны, вакыты күрсәтелгән, әсәргә характеристика, кирәк урында тарихи белешмә һәм вариантлар бирелгән.

Искәрмәләрдә без халык күңеле гәүһәрләренә зур мәхәббәт белән караган, аларны саклаган һәм кыйммәтле байлыкны буыннан-буынга тапшырып калдырырга омтылган олы йөрәкле кешеләрнең исемнәре, кыскача биографияләре белән танышабыз. Шунда ук җырны язып алган кешесе дә күрсәтелгән.

Казан тел, әдәбият һәм тарих институты фольклор секторы бу җыентыкны чыгарып халык иҗатын өйрәнүдә һәм популярлаштыруда зур адым ясаган. Институт халык лирикасының һәм эпикасының башка жанрларын да чыгару; җыелган материалларны иҗатчысына кире кайтару эшен тизләтсә, әйбәт булыр иде.

Э. КАСЫЙМОВ.
Т. ГАЛИУЛЛИН.

ИҖАТ ҖИМЕШЛӘРЕ

Күренекле әдипләребездән Гомәр Бәшировның «Сайланма әсәрләр»енең икенче томы басылып чыкты. Ул ике бүлектән тора. Беренче бүлеккә ун хикәя һәм «Сиваш» повесте урнаштырылган.

Җыентыкка кергән хикәяләрдән «Кунак егет», «Урман шаулый», «Әни», «Көннәрнең берендә», «Гармунчы егет» исемлеләре аеруча әйбәт. Ул хикәяләрдә күрсәтелгән кешеләр, аларның язмышлары укучыны һич тә битараф калдырмый, уйландыра, дулкынландыра.

«Көннәрнең берендә» дигән хикәяне алыйк. Анда алдынгы колхоз председателе Хәлим Нәгыймовны, төрле нахак гаепләр ягып, партиядән чыгаралар, эшеннән алып ташлыйлар. Дөрес, бу темага багышланган әсәрләр соңгы елларда байтак язылды. Әмма «Көннәрнең берендә»нең язылып басылу елына игътибар итик: 1938 ел. Бу хикәянең ул елларда тууы, гәрчә азагы беркадәр «шомартылып» төгәлләнгән булса да, авторның кыюлыгын, принципиальлеген күрсәтә. Хикәя кешегә карата гадел һәм сизгер булырга чакыра, «үтә бдительный» булып күренергә маташкан зарарлы элементлардан саклану, аларның чын йөзен күрә белү кирәклеген искә төшереп тора.

«Урман шаулый» хикәясен укыганда, әсәрнең төп герое Фәтхи белән бергә, укучы да оста каләм белән тасвирланган матур табигать күренешләренә гашыйк булмый кала алмастыр. Кечкенә генә хикәя өчен бу зур нәрсә. Фәтхинең музыкаль иҗат турындагы фикерләре, уй-хыяллары матур, дөрес, кыйммәтле һәм бүген дә актуаль.

Томда беренче булып урнаштырылган «Кунак егет» исемле хикәя гаять таләпчән авторның үзенә дә бик ошый икән: «Күбрәк иҗат канәгатьлеге китергән, күңелдәгечә язылган беренче әсәрем — «Кунак егет» исемле хикәям булды»,— ди Г. Бәширов. Белгәнебезчә, әниләр үз балаларының һәммәсен дә яраталар. Ләкин кайвакыт арадан берсен артыграк та ярата торган булалар. Биредә дә нәкъ шулай. Бу хикәямдә мин үз-үземне тәмам «табып» житкердем шикелле». (384 бит). Һәм бу дөрес тә. Хикәядәге вакыйгалар да, андагы кешеләр дә, аларның үзара мөнәсәбәтләре дә сокланырлык, матур булып истә калалар. Монда ул вакыйгаларны һәм кешеләрне ягымлы бер күңел җылысы белән, мәхәббәт белән җылытып, үз халкының уйларын, яхшы гадәтләрен лирик буяулар ярдәмендә тасвирлауга уңышлы омтылыш ясаган һәм шуңа ирешкән дә.

«Сиваш» — Гомәр аганың күләмле әсәрләреннән иң күренеклесе һәм беренчесе. Ул аны беренче тапкыр 1937 елда ук бастырып чыгарган иде. Һәм бу повесть шул елларда ук авторның иҗат көчен һәм колачын характерлауда да, гомумән әдәбиятыбыз мәйданында алган урыны белән дә куанычлы вакыйга булып әверелде. Аннан бирле повесть күп тапкырлар басылды. Һәм ул гел таралып тора, кат-кат укыла, үзенең яңадан-яңа укучыларын таба тора. Һәрбер яхшы әсәрнең сокландыргыч язмышы шундый була. Шуны да әйтик, һәрбер яңа басмасында автор аны гел яхшырта, төзәтә, шомарта, камилләштерә бара. Бу очракта эш аерым сүзләрне, җөмләләрне җиңелчә төзәтеп чыгуда гына да түгел икән. Повестьта образлар, вакыйгалар, бит-бит тасвирлаулар үстерелгән, я кыскартылган, я бөтенләй яңадан язылып чыккан. Кыскасы, әсәрнең идея-художество дәрәҗәсен тагын да күтәреп-үстереп җибәрү өстендә автор нык көч куеп, җитди эшләгән. Үз-үзенә таләпчән һәр зур әдипкә хас мактаулы сыйфат бу, һәм игътибарлы укучы моны да күрми-сизми калмастыр.

Г. Бәшировның бу повесте турында матбугатта аз язылмады инде. Хәзер «Сиваш»ка карата әллә ни яңа сүз дә әйтеп булмас һәм моның кирәге дә юк кебек. Бу зур томны, матур да, батыр да булып, күтәреп торганы — шул повесть.

Инде икенче бүлеккә — авторның публицистикасына карата берничә сүз. Бу бүлектәге мәкаләләр Габдулла Тукай һәм Муса Җәлил турында, халык әкиятләре, мәзәкләр, гореф-гадәтләр турында, әдәби телгә караган күп кенә мәсьәләләр турында сөйли.

«Тылсымнар дөньясында», «Халыкныкы — халыкка» исемле мәкаләләрендә автор әкиятләрнең, мәзәкләрнең халык тормышында тоткан урыннары, тарихлары, аларның идея эчтәлекләре, социаль нигезләре турында сөйләп-аңлатып бирә. Аларның бик кызыксынып, мавыгып укыла торган итеп матур әдәби тел белән язылган булуларын да әйтеп китик. Тар белгечләр өчен генә түгел, ә киң масса укучылар өчен дә кирәкле, файдалы, кызыклы, әһәмиятле мәкаләләр алар.

Тел матурлыгы, тел байлыгы, тел сафлыгы... Бу мәсьәләләр Гомәр аганы гел уйландырып торалар, аның иҗат практикасында, хаклы рәвештә, зур урын алалар. Публицистика бүлегендәге алты мәкаләнең әдәби тел мәсьәләләренә багышланган булуы да моны ачык күрсәтеп тора. Ә тел турында, китапларыбыздагы, газета-журналлардагы, радиотапшырулардагы тел турында безгә сөйләргә һәм күп итеп, житди итеп сөйләргә бик кирәк икән. Г. Бәшировның тел турындагы мәкаләләрен хуплап кабул итәлә торган һәм бу томны баетып торган бик әһәмиятле, кыйммәтле материаллар дип санарга кирәк. Мәкаләләрдә күтәрелгән проблемалар да, конкрет тәкъдимнәр дә барысы да диярлек дөрес. «Бай булсын, матур булсын» — авторның туган телебезне әнә шундый итеп күрәсе килә. Бу мәкаләдә аерым сүзләрнең кулланылышлары, урынлы яки урынсыз булулары турында сүз бара. Биредә мин бер сүз турында гына кайбер фикерләрем белән уртаклашып китүне урынсыз булмас дип саныйм. Ул да булса — «работник» сүзе. Баширов бу сүзнең әдәби телдә кулланылышы белән риза түгел. Дөрес, автор белән бер мәсьәләдә килешергә мөмкин. Чыннан да, «эш — работа» тамыры белән бәйләнгән саф татарча сүзләр бездә әллә никадәр икән. Ләкин нишлисең, «работник» сүзе үзенең татарча вариантын таба алмыйча калган. Бер дә тикмәгә генә түгел бу. Аннары, карап торырга бик гади һәм татарча яңгырый торган андый сүзләр тикшереп карасаң, бездә байтак икән әле. Менә, сайлап тормастан, хәтергә килеп төшкән беренче сүзләр: самовар, пароход, самолет, паровоз... Бу сүзләр тулы хокуклы булып йөриләр һәм алар беркемне дә борчымый.

Китерелгән бу мисаллар, ихтимал, бик уңышлы да түгелдер. Ә менә **самолет** белән **самосвал** арасында нинди аерма бар икән? Сүз буларак, алар **рабочий** белән **работник** кебегрәк игезәк сүзләр. Самолет хәзер бездә тулы хокук белән файдалана, ә менә самосвал үзбуштаткыч булып керде дә китте. Телдә, күрәсез, шундый хикмәтләр дә аз булмый. Минемчә, **работник** сүзе дә шул категориягә кера ала торгандыр. Югыйсә бит, бу сүзне кире кагу белән бергә, автор үзе дә бернинди яңа сүз тәкъдим итми. Аннары, мәкаләнең беренче тапкыр басылып чыгуына да еллар үтеп китте. Әмма шуннан бирле хәтта әдипләр, тел белгечләре тарафыннан да берәр тәкъдим кертелү факты билгеле түгел. Ярар, мин тел белгече түгел, ә бу әйтелгәннәрне сүз уңаенда туган кайбер фикерләрем белән уртаклашу дип кенә карарга кирәк.

Бу икенче томның публицистика бүлеге «Тормыш сукмаклары» дип исемләнгән әсәр белән очлана. Ул үзенең эчтәлеге белән дә һәм язылышы белән дә бик оригиналь. Аның яңарак кына язылып тәмамланган һәм моңача беркайда да басылмаган булуын да искә алсак, әһәмияте һәм кыйммәте тагын да үсә төшә. Автор анда үзенең тормыш юлын сөйли, әдәбиятка килү юлларын ачыклап күрсәтә, әдәби иҗат мәсьәләләренә, аерым әдипләргә шактый урын бирә. Боларның һәркайсын автор, үз характерына һәм иҗат почеркына хас булганча, җентекле рәвештә салмак кына агым белән хикәяли, ә кайбер урыннарда дулкынланып китеп тә сөйли, үз тормыш юлында очраган теге я бу шәхесләр турындагы фикер йөртүләрен кәгазьгә теркәп бара. Анда, табигый ки, әдәби иҗат мәсьәләләре, авторның үзенең иҗат принциплары һәм тәҗрибәсе дә зур урын алып тора. Әсәр шул ягы белән кыйммәтле дә.

Бик матур башланып китә ул: данлы еллар, олы социаль вакыйгалар, төрле авырлыклар, кайнап торган тормыш диңгезе, зур омтылышлар... Шунда яшь малай Гомәрнең бөтерелеп йөзеп китүе. Беренче адымнар, беренче эшләр, беренче китаплар һәм шуларның гел ишәя, киңәя баруы... Ниһаять, ныклы адымнар белән зур әдәбиятка кереп китү. Шигъри публицистика дип әйтимме, шундыерак алым белән язылган бу әсәр. Тик шуны да әйтик, бара торгач, кайбер кабатлаулар да очрый, тар сукмакларга кереп китүләр дә бар. Хәер, болары әллә ни сизелми дә, күзгә бик ташланмый да.

«Тормыш сукмаклары»н, жанр ягыннан, мемуар әдәбиятка якын тора дияр идем. Ә бу төр әдәбият бездә бик-бик аз әле, һәм шунлыктан бу әсәрне һәркем кызыксынып укыячак. Китапның публицистика бүлеге яхшы тәэсир калдыра, томны тулыландырып, баетып тора. Бүлекне ачып җибәргән «Бөек Тукай, остаз Тукай» исемле мәкаләдәге: «Габдулла Тукай турында салкын кан белән, дулкынланмыйча гына язу мөмкин түгел», дигән беренче җөмләсе үк публицистика бүлегенең гомуми стилен билгели. Һәм шулай булуы бик дөрес тә, әйбәт тә.

Йомгак ясап шуны әйтәсе килә: күренекле әдипләребезнең сайланма әсәрләрен шулай томлап-томлап бастырып чыгару кебек бик вакытлы һәм кирәкле эш хәзер бездә системага кереп бара. Бу бик яхшы. Формасы белән милли, эчтәлеге белән социалистик культурабызның тагын бер баскыч югары күтәрелүен раслый торган күркәм факт бу.

ГАЗИЗ ИДЕЛЛЕ.

Рэдиф Гатауллин

ШАГЫЙРЬ КҮҢЕЛЕНӘ СӘЯХӘТ

(Ш. Галиевнең «Уйларым, серләрем» китабына карата)

Бөек француз язучысы В. Гюгоның шундый сүзләре бар: «...Диңгез чиксез, аннан да чиксезрәге мәһабәт зәңгәр күк, ә кеше күңеле исә тагын да чиксезрәк, мәһабәтрәк...»

Бу сүзләр барыннан да бигрәк шагыйрь күңелен характерлыйдыр кебек: чынлап та, тормышны бөтен нечкәлекләре белән белгән, кешеләрнең күңеленә үтеп керә алган шагыйрь, үзенең һәрбер әсәрендә хисләр дөньясының байлыгы, анда җемелдәгән йолдызлары белән сокландыра, бер үк вакытта үзенең дә күңел тирәнлекләрен, чиксезләгән укучыга ача бара.

Шәүкәт Галиевнең иҗаты да шагыйрь күңеленең киңлеге, чиксезлеге, буяуларының төрлелеге, мөмкинлекләренең күплеге турында сөйли. Лирик та, юморист та һәм шулай ук балалар шагыйре дә булган Шәүкәт һаман саен күңелләр дөньясына сәяхәт итә, тормышны ныграк өйрәнә, тирән гомумиләштерүләр ясый.

«Уйларым, серләрем» китабы шагыйрьнең соңгы елларда язган лирик һәм сатира-юмор әсәрләрен эченә алган «Күңелләргә сәяхәт» һәм «Үтереп мактыйм» исемле ике бәйләмнән тора.

Беренчесе, без югарыда әйткән сәяхәтнең үзе, шагыйрьнең очрашулары, аның сөенүләре, көенүләре, сиңа да, миңа да әйтер сүзләре, күңел күзләре, уйланулары булып алга баса.

Соңгы елларда совет поэзиясендә горизонты киң ачылган фәлсәфи шигырь, сигезьюллыклар формасында үстерелеп, татар поэзиясендә дә чагылыш тапты: «Күңелләргә сәяхәт»нең дә бер өлеше шундый сигезьюллыклардан тора. Алар конкрет, тормышчан фактлар, фәлсәфи детальләр, төгәл образ һәм идея синтезыннан туганнар. Бер мисал:

— Ир-егеткәй, нигә йокламыйсың?
— Поклый алмыйм эчем пошканга:
Әллә ничек шунда, урынсызга,
Бер авыр сүз әйттем дусларга...

— Ир-егеткәй, нигә йокламыйсың?
— Поклый алмыйм эчем пошканга;
Әйтим дигән каты сүзләремне
Әйтә алмый калдым дошманга.

Уйланулар тормышның күп якларына кагыла: монда бәхетле һәм үкенечле мәхәббәт турында да, яшьлеккә хас омтылышлар турында да фикерләр тулы.

Уйлануларның бер өлеше шагыйрьнең юл гизүләреннән туган хисләрен чагылдыра. Кавказ һәм Кара диңгез табигате турында уйлар җир язмышы, тынычлык өчен көрәш, үткәннәр һәм киләчәк турындагы уйлар белән тоташа. Бу яктан: «Егерме биш моряк ята ярда...», «Бер як яры белән диңгез бездә...», «Сапун гора — сабын тавы икән...» кебек шигырьләр характерлы.

Шагыйрь гадәти генә юлда бару күренешләрендә дә тормышның катлаулылыгын ачып бирә.

* * *

Юан хатын кайта көньяктан,
Егет бара сынау бирергә,
Геолог кыз китә Себергә,
Тайгаларны айкап йөрергә.

Карчык кайта оның карарга,
Солдат кайта ялга ун көнгә;
Бер карт бара улын жирләргә,
Сүз катмыйча юлда беркемгә...

Шагыйрьне авыл үстергән, шуңа аның авыл, туган жир тематикасына еш мөрәжәгать итүе табигый: ул «Мәҗлесләрдә җырламаса да», «...басуларда җырлап җибәрә», «Таныш таулар кичерәйсә дә», якташларының үсүен күрә.

Бер үк вакытта ул үзенең туган җирдән шактый ераклашуын да тоя.

«Ленин сәгате» исемле шигырь илнең үсешендәге бүгенге этапны характерласа, «Җирдә ята икмәк сыныгы» шигырендә шагыйрьнең кешелеккә кадерле нәрсәләргә мөнәсәбәте, гуманистик тойгысы ачыла. Ә «Ак калфаклы кыз китә» кебек шигырьләрендә лирик моңсулык чагылып үтә.

...Китапның икенче бүлеге шагыйрь күңеленең җор якларын ача, аның үткен укларга ия булуын күрсәтә.

Карап торуга гади көлү объекты итеп кенә алынган нәрсәләр дә, сүз уйнатулар да уйландыралар, сагайталар. Моның үрнәге итеп «Куркынычлы Аюлар»ны күрсәтергә була. «Спекуляция турында», «Яхшы характеристика», «Безнең эшләр ал да гөл», «Сәләп кырылу сәбәпләре» шигырьләрендә дә тормышта очрый торган кимчелекләр нигезле тәнкыйтьләнә.

Кызганычка каршы, Шәүкәт Галиевнең кайбер юмористик шигырьләрендә үзенчәлеге кабатлаган урыннар да сизелгәләп куя.

Шагыйрьнең индивидуаль почеркы турында әйтмичә мөмкин түгел: халыкчан ифадәләр, җыр элементлары, мәкаль һәм әйтемнәр, кителмәгән яңа образлар, метафоралар һәм антитеза әсәрләрнең канвасы булып тора.

Теләк рәвешендә шуны әйтәсе килә: шагыйрьнең киләчәк җыентыкларында зуррак күләмле әсәрләргә дә урын бирелсен иде.

Минемчә, укучы аннан Ш. Бабичның «Китабен-нас» һәм «Исемнәр бакчасы» кебек сатира-юмор әсәрләре көтәргә хаклы.

Җыеп әйткәндә, Ш. Галиевнең «Уйларым, серләрем» китабы бик уңай тәэсир калдыра.

Сәяхәттән тулы канәгатьләнү белән, шагыйрьгә иҗатында уңышлар теләп сүзне тәмамлыйсы килә.

ТӨРЛЕСЕННӘН

И. Рәми

ЧӘЙ ҺӘМ ЧӘЙЧЕЛӘР

(Чәй эчкәндә чәйнәр өчен тарихи мәзәк)

Белешмә: «Чәй эчемлеге Россиягә беренче тапкыр 1638 елларда Кытайдан китерелә. XVII йөз азагында инде илебездәге халыклар арасында чәй эчү гадәткә кереп, күпләп тарала башлый». («Энциклопедик сүзлек»тән.)

Бу юлларны укыгач, Идел — Кама буенда яшәгән бабаларыбыз кайчанрак чәй эчмәгә керештеләр икән, дигән сорау күңелгә килде ләбаса. Табигый сорау. Чөнки без, әлхәмделиллаһи, чәйгә мәхәббәт утырткан халыклар тезмәсендә торып киләбез. Белмәссең, алдынгысы булып куймагаек.

Башкасы турында бәхәскә керешмәсәк тә, әмма ләкин чәй эчүдә сер бирмәгәнбездер. Чәй дигәндә — халкыбызның аягы идәндә булып килгән. Россиядә иң элек күпләп чәй эчмәгә, мөгаен, татар халкы керешкәндер.

Нигә дисәң, дәлилем бар. Тарих әйтә, XVII йөз уртасыннан алып татарның сәүдә кешеләре Казан белән Кытай арасында сәүдә бәйләнеше урнаштыру чарасына кергәннәр. Чит илләр белән сәүдә җәелдерүне күздә тоткан Петр I нче, казанлыларның бу эшенә юнәлеш-этәреш биреп килгән. Кытай чигендәге Кяхта, Гулҗа, Үргәнеч якларына Казаннан кәрван артлы кәрван китеп, киткәне кайта торган.

Киләдер-лә кәрван, һай,
киләдер,
Үргәнечтин микән,
Хивадин...—

дигән борынгы җырыбыз да шуны сөйли.

Сәүдә кәрваннары бирелән төсле сахтиян, болгари һәм саурый күн товары, бал белән балавыз, сабын төяп киткәннәр; югарыда исемнәре саналган базарлардан бөртек чәй, шыр чәй, фарфор чәйнек, чынаяк (чин аяк, ягъни кытай савыты), ефәк тукымалар алып кайтканнар. Казан каласы чәй сәүдәсе белән күренекле урын тоткан.

Шул заманнарда Кытай белән зур эш иткән чәйчеләрдән берсенә, халык «кытай» дигән кушамат таккан. Кытай, кытай ди торгач, шул нәсел кешеләре Кытаев аталып киткәннәр. Татар чәйчеләреннән атаклысы әнә шул Кытаевлар була. Алар әллә үлә, әллә бөлә, алардан соң чәй базарында Үтәмеш токымы көн күрә. Башка чәйчеләр дә булган, ләкин бу ике фамилия кешеләре заманында чәйчеләрнең атаклысы булганнар. Элекке чордан калган бер белдерү әйтә: «Үтәмишевләрнең чәй сәүдәсе Казанда 1780 елдан алып дәвам итмәктә. Үзебез сайлап китерткән хуш исле вә чыгышлы Һинди, Кытай, Цәйлүн чәйләреннән төрелгән «Үтәмеш чәен» генә эчегез», ди. Заманында бу чәй — чәйләрнең дә чәе булып исәпләнгән.

Үтә заманнар... күчә кәрваннар... бетә эз... Борынгыча — бабайларча эш йөртеп килгән татар сәүдә капиталы чәй монополиясен кулдан ычкындыра. Промышленность капиталы белән ярыша алмый. Казанның чәй сәүдәсе сүнә. Үткән йөз уртасында инде чәй сәүдәсе Попов, Губкин-Кузнецов, «Кәрван» Высоцкий кебек эре капиталистлар кулына күчә.

Чәй сәүдәсе «Кәрван»нар кулына күчсә күчкән, аңар карап, татар, башкорт табигатендә чәйгә мәхәббәт һич тә сүрелмәгән. Халыкка барыбер ич, «Кәрван»да буш бирмәгән, Үтәмеш тә аллаһ-әкбәргә өләшмәгән. Әйтергә кирәк, көне — чәе барлар кәеф чигеп эчкәннәр.

Эчеп кенә калмаганнар, халыкның сөйләм телендә чәйгә бәйле йөзләрчә мәкаль, әйтем туган. Чәй турында җырлар чыккан. Моннан 60 еллар элек «Чәйчеләр» дигән көй дә телдә иде. Җыр гынамы дисез, үткән йөз уртасында Казанның Шәриф шәкерт дигән берәү «Чәй бәете» иҗат иткән. Чәйне яклап та, яманлап та бәет әйткәннәр. Яклаучылар күбрәк була.

Җиһан эчрә ул алланың
Ләзиз нигъмәтләре
күптер,
Вәләкин бу безем җирдә
Бу чәй кеби бере юктыр.
Бу чәй кеби дәва һич юк,
Гаҗәп хасиятедер чук,
Әгәр сезләр эчәр булса —
Булырдыр барчасы,
бел, хуб.

Озын сүзнең кыскасы, чәйгә мәхәббәт тормышыбызның төрле-төрле тармагына үрелеп килгән.

Статистика: «1850 елны Россиягә 363 мең пот чәй кертелсә, 1901 елны инде 3.484 мең пот — 50 миллион сумлык чәй кертелгән», — дип белдерә.

Ху-уш, бу чаклы чәйне ничек эчеп бетерәбез инде?

Беләсез, чәйне коры килеш чәйнәп булмый, 3 миллион 484 мең пот чәйне «эшкәртү» өчен, мин сиңа әйтим, елына ничәмә-ничә миллиард чиләк су кайнатып эчәргә туры килде икән?

Түшәмнән алып куеп та, сан җиткерә алмассың.

Аның исәбе-хисабына кем чыккан.

Бу дөнья һич тигез түгел,
Адәмнәр дә игез булмый;
Кеми эчкән чынаяк чәй,
Кеми өчне, кеми бишне,
Кеми бер самовар эчеп
туймый,
Ходай тигез яратмаган...—

дип Тукайча сүз уйнатмасаң, ул чактагы хәлне башкача аңлатып булырмы?

Булырмы, булмасмы, сөйләргә алынгач, сөйләмичә булмый инде.

Шулай, чәй эчмәк рус халкында нинди урын тотса, татар тормышында да ул төп эчемлекнең берсе булып әверелә. Чәйсез эш башланмаган кебек, тәгалләнмәгән дә. Эше торса торган, әмма чәйне көттермәгән.

Чәйгә мөкиббән киткән кешегә, хәтта иртән чәй эчми торып, җан кермәгән. Өйгә килгәнне чәйсез озатмаганнар. Башка сые булмаса, «Якты чырай — тансык чәй» белән булса да, кунак иткәннәр. Кыз яучылап килгәннең чәйсез теле ачылмаган. Сөйли китсәң, һәр эшнең очы чәйгә барып терәлгән инде. Сәбәбе булса да, булмаса да чәй эчкәннәр. Эше үтә ашыгыч булган чагында да, авызы пешсә пешкән, кайнар килеш эчкән, әмма чәйне ташлап китмәгән. Бераүгә:

— Хаҗәли, нишләп утырасың, күршеңдә пужар, чиләк алып чык! — дигәч:

— Ха-əзер, чәй эчеп булам да чыгам, — дигән. Ул чәй эчеп булганчы күршенең өе янып бетеп, үзенең өен ут алган, ди.

Чәйгә багышланган бәет һәм җырлар чәе белән шикәре барларны күздә тотып әйтелгән. Чәй турында җыр әйтүчеләрдән берсе:

Чәй эчәбез шикәрләп,
Җаный белән икәүләп...—

дигән җырны кияүләп йөргән егетнең теленә салган. Аны башлы-күзле, бала-чагалы иткәч:

Чәй эчәбез бал белән,
Бала-чагалар белән...—

дип җырлаткан.

Чәйхурлар турында телдә йөргән, аннан әдәбиятка кергән мисаллардан берсен әйтим. Казан өязе Иске Кенәр авылының Салих мулла бер утырганда, аз да түгел, күп тә түгел, 60 чынаяк чәй эчкән. Шуның белән шөһрәт тапкан. Көннәрдән бер көнне шул авылның баена кунаклар килгән, ди. Кунакларына кызык күрсәтмәкче булып, бу бай Салих мулланы чәйгә чакырган. Ике чиләк су сыешлы зур самоварны чыгарып табынга куйганнар. Сизгер мулла мәсьәләгә төшенгән. Бер чынаяк чәй эчкән дә каплаган.

— Хәзрәт, бу ни эшегез, сезне 60 чынаяк чәй эчә дип сөйлиләр иде, дигәч:

— Рас әйтәләр, менә сезгә килер алдыннан 59 ны өйдә эчкән идем, — дигән.

Чәй дигәндә абыстайлар да калышмаган: кунак килсә, күрше керсә, дәррәү самоварга тотынган. «Чәй янында сүз чыга», дигәннәр. Самоварын яңартаяңарта утыра торгач, берсен эләп алып, икенчесен селкеп салып сөйләнә торгач, «Пәрәмәч, чәй эчмәгә өйрәндек, ялкаулыкка көйләндек», яки «Чәй эчәргә өйрәндек, җеп эрләргә оныттык» булып киткән эшләр.

Билгеле, ул чаклы чәйне өйдәге табын янында гына эчеп бетерә алмаганнар. Кала базарларында, ярминкаларда руслар өчен «Чайная» яки чәйле «Трактир» булса, татар, башкортлар өчен «Чәйхана»-лар яшәп килгән. Мәсәлән, 1900 елларда Казанның Базар мәйданында Юсупов подворьясе, Җамалый харчәүнәсе, Рамазанов чәйханәләре, барысы уннан артык татар чәйханәсе эшләгән. Базар халкы берәр әйбер сатса яки алса, чәе синнән дип килешкәннәр дә чәйханәгә кергәннәр. «Синең белән гап бар әле» дип тә чәйгә кергәннәр. Авылдашын очратса да, чәйгә алып кергән. Чәйсез бер эш тә башкарылмаган.

Әнә шулай, татар җәмәгате дә хәл кадәренчә, кайберәүләре хәлдән тайганчы тырышканнар. Ләкин өйсәң тау булырлык чәйне, диңгез чаклы кайнар суны татар халкы бер үзе эчеп бетергән дип уйламагыз тагын. Тәүбә. Илебездә чәй эчүдә алдынгы раттә, әлбәттә, рус халкы торган. Аның купец катлавы, алпавыты, архимандрит-поплары чәй эчүдә, мин сиңа әйтим, Салих мулладан калышмаган. Тик алар махсус җыр, көй чыгарып, бәет әйтеп эчә белделәр микән? Ул чаклысын үзләре әйтер.

Ул чагында илдә көнкүреше рәтсезләр-чәйсезләр күбрәк булган, алар нишләгән? Андыйлар чәйгә үрелмәгән, «Ярар безгә, каткан тезгә — чәй булмаса, мәтрүшкә!» дигәннәр. Болында үлән күп булгач, әйткәннәр шул...

Борынрак безнең халык арасында шыр (яфрак) чәй худта булган. Шыр чәйне сөт, май, тозын, борычын салып казанда кайнатканнар да, чәй шулпасы итеп эчкәннәр. Дөньясы төрләнә торгач, бөртек чәй өстенлек алган, шыр чәй бабайларга калган да онытылган.

Бөртек чәй кәяз эчемлек исәпләнгән. Билгеле, кәязнең бәясе дә кәяз була. Күпчелекнең аңар буе җитмәгән. Чәй фирмалары бу якны искә алмаганнар түгел. Бөртек чәйгә үрелә алмаганнар өчен, такта чәй, анысына чамасы килмәганнәргә — барман чәй чыккан.

Ничек кенә булмасын, чәй чыгымы кесәгә суккан, күрәсең. «Чәй күңелгә җәй дә, акчасын түләгәндә әй-вай», дигәннәр. Әйтерсең дә. Борынгысын белмим, революция алды елларында бөртек чәйнең чирек кадагы (йөз граммы) 33 тиен иде. Кара эшченең эш көне 15—20 тиен торганда, чәйгә үрелә алмассың шул. Андыйлар өчен тузан чәй —

бармак чәй чыккан, ике эчемлек бер бармагы бер тиен. Анысына да хәле җитмәгәннәр турындадыр инде, «Ярлыга — кишер дә чәй» дигәннәр.

Шулай кылә-кыла безнең халык арасында «Кәрван» чәе асруча абруй казана. Бу фирма үзенең чәй этикеткасын, игъланнарын ике телдә — русча һәм татарча бастырып килде. Татар телендә реклама-календарь чыгарды. Көйле белдерү таратты:

Иртән дөнья җанлана,
Мәшрыйк ягы аллана,
Кояш чыгып нурлары
Төшеп җиргә ялгана.

. . . .

Бу вакытта йорт саен,
Кайный самовар һаман,
Чәйнүкләрдә пешмәктә
Чәй — фирмасы «Кәрван».
Өйдә хуш ис чәчелгән,
Һәркем күңеле ачылган,
Нинди фирма чәе бу?
«Кәрван»дыр, «Кәрван».

Бакчы, эчмәс җирдән эчәрсең...

Ярый, киттек арый. Чәй белән эш бетми. Самовары гөрләп, чәйнегә сайрап тормаса, «Табынның ни яме, чәйнең ни тәме» дигәннәр. Дөньясы түгәрәкләнсен өчен, самовары да кирәк.

Самовар килмешәкләрдән түгел, үз йортыбызда туган. Җир йөзендә самоварлы ил берәү генә булган. Ул — Россия. Самоварның туган җире Тула каласы. Каласында атасы-баласы самовар остасы булып килгән. XVIII йөзнең беренче яртысында аны аерым һөнәрчеләр эшләгән. Аннан самовар эшли торган заводлар ачылган. Шулардан иң атаклысы Баташов заводы, бер үзе генә дә елына 700 мең самовар эшләп чыгарган, ул да җитмәгән.

Җитәме соң? Башкасын белмим, әмма рус белән татарда самоварсыз өй булмаган. Безнең халык:

Самовары җиз генә,
Кайнаулары тиз генә...—

дип юкка җырламаган. Тула самовары алуны сагышлап йөргән. Җиз самоварга буе җитмәгәннәр өчен, калайдан люмпен самовар эшләп чыгарганнар. Чүтеки, самоварсыз булмаган.

Кара син, ярлы-йорлыны һич тә генә онытмаганнар, бармак чәйме дисең, калай самовармы кирәк...

Өйләнәм дигәне самоварлы кыз эзләгән. Кыздан битәр, самоварына өйләнгән. Яучылар — «Кызы чистни кыздыр, самовары чисти җиздер» дип мактаганнар. Бай йортны әйтәсе түгел, әүкатьлерәк өйгә барып кердеңме, шкаф өстендә яки мич кашагасында ялт иткән самовар белән поднос күзгә чалынган. Янәсе, кызыбыз мәһәрсез түгел. Кияү йортына җиз самовар китермәгән килен, килен чутында да йөрмәгән. Ярлы йорттан төшкән киленне: «Алай икән, самовары калай икән» дип кенә каршылаганнар.

Шулай итеп, чәе, самовары татар тормышының атрибуты булып килгән. Чәе ифрат-тафрит (чиктән чыккач) кебек, самовары да ифратка киткәч, «Самовар көлдерер, көлдерер дә бөлдерер» дигәннәр.

Мәзәктән тыш. Кайберәүләрнең чәй эчүдә чиктән чыгып китүләре турында сөйләдек. Андыйларга карамастан, гомумән, чәй тормышыбызда уңайлы урын биләп, культуралы эчемлек булып килгән. Шул хасиятен әле дә югалтканы юк. Бу гадәтнең безгә килеп керүе дә яхшы максатлардан килеп туа. «Татарның укымышлы кешеләре чәйне шифалы эчемлек дип таныйлар, яклап бәетләр чыга, аракы һәм башка төр исерткечләргә каршы кәрәштә чәйне культуралы эчемлек итеп табалар» (Н. Исәнбәт, «Татар халык мәкальләре»).

Хәзерге көндә без үз илебездә җитешкән, хуш исле, чыгышы, тәме ягыннан Һинди, Кытай чәенә бирешкәсез «Гөрҗи чәй» эчәбез. Һәркем өчен кулай эчемлек. Шунысы кызганыч ки, бездә чәйнең үткәндәге даны, шаны югалып бара. Буфет һәм ашханәләрдә иң абруйсыз эчемлек — чәй. Андый урыннарда чәй эчкәнне түгел, мәй эчкәнне ярагалар. «Чәй» дигән булып, шикәрле юынтык су эчерәләр.

Кагыйдәсенә туры китерелеп аерым чәйнектә пешкән, хуш ис чәчеп торган кайнар чәй алдында торса, күпләр өчен мәең берьяктa торсын.

Яшәсен чәй!

Мәзәкләр

ЯҢА МОДА ТҮГЕЛ

— Мансур, Син укыдыңмы, ирләргә төймәсез күлмәк модасы чыккан икән. Менә модалар журналына язганнар.

— Безнең өчен яңа мода түгел ул, Зөбәйдә. Без синең белән торa башлаганнан бирле төймәсез күлмәк киям инде мин.

ТӘРБИЯЧЕ

— Сезнең класс җитәкчесе ифрат яхшы кеше.

— Аның яхшылыгы турында авыз да ачмалы түгел. Бер генә сүз эндәшсәң дә, линейка белән «чәп» итә дә класстан куып чыгара.

Җыючысы: ФАТИХ САБИТОВ.

Шәүкәт Шәрәпов

Игелекле ир

Иртәгә туган көнем бит,
Кунак дәшик, Нурулла?
— Кунак җыйгач, иркәм, сиңа
Мәшәкате зур була.
— Күп дәшмәбез, тик әйтербез
Туган-тумачаларга.
— Шулай да кунак—кунак ул,
Туры килер чабарга...
Үзебез генә үткәрербез,
Ял итәрсең, Маһруй,
Тик вак-төяк эшләреңне
Бүген үк бетереп куй:
Ташы суыңны күп итеп,
Утын да яр җитәрлек...
Иртәгә тынычлап кына
Булсын бәйрәм итәрлек.
Иртән мичне томалагач,
Ягарсың мунчасын да.
Камыр-фәлән дә куймассың,
Ясарсың сумса гына...
Балаларны мунча керткәч,
Пешерерсең аш кына.
Алып кайтырсың «кызыл»ны,
Төшерербез аз гына.
Үткәрербез «во» иттереп
Туган көнеңне, иркәм.
Ярый, кара эшләреңне,
Ә мин бераз ял итәм.

Җаен тапты

Гарәфетдин кул астында
Эшли хор түгәрәге.
Халык алдында түгәрәк
Концертлар биргәләде.

Сүрән-сүлпән генә чаба
Халык нишләптер кулын...
Гарәфетдин күп эзләде
Кул чаптыруның юлын.

Эзли торгач, уйлый торгач,
Җаен тапты ахырда:
Магнитофон белән «бис»ны
Полный ходка акырта.

А. Шамуков

Чүлмәкче белән исерек

Чүлмәкче чүлмәк ясый. Ул үз эшен
Эшли сөеп. Савыты шәп чыксын өчен
Сала бөтен
Иҗат көчен.
Шуңа күрә тезеп куйган чүлмәкләре
Һәр кешене сокландыра.
Нәкъ шул чакта бер исерек үтеп бара:
Аның тонган күзләренә
Очкан чебен бүдәнәдәй,
Яткан салам бүрәнәдәй
Булып күренә.
Тезеп куйган чүлмәкләргә күзен текәп
Катып кала:
— Бу ни хикмәт?
Нигә болар мондый гарип?! —
Дип җибәрә ул акырып. —
Безгә мондый кыйшык савыт кирәкми, — дип,
Чүлмәкләрне сала кырып.

Айныгач та аның күзе төзәләчәк,
Бу эш өчен үкенәчәк
Һәм сүгәчәк
Үзен-үзе;
Әмма, дустым, һич тә көтмә,
Төзәләр дип өмет итмә
Аек килеш кыйшык күрүченең күзе.

Шәукәт Галиев

Дусларча шаярулар

Габдрахман Әпсәләмовка

«Ак чәчәкләр» романы басылып чыгу уңае белән.

Бирәм, диде, роман бирде,
Әпсәләм ул алдамый;
Әле бусы — чәчәкләре,
Җимешләре алда! — ди.

Аяз Гыйләҗевка

Шактый бәхәсләр сәбәпчесе булган «Өч аршын җир» повесте «Дружба народов» журналында басылып, еллык бүләк алды.

Юкка йөрде кайберәүләр:
«Алай язма, болай яз!..»
«Өч аршын җир» өч карышка
Үстерде сине, Аяз!

И. Хантимиров шаржлары.

Илдар Юзиевка

Авторның «Яшь наратлар» исемле яңа китабы чыкты, анда укучылар җылы каршылаган «Язылмаган поэма» да бар.

Кем генә поэма язмый,
Төшеналми җаена...
Ә синңа уңыш китерде
«Язылмаган поэма»!

Х. Әхмәтҗанов шаржы

Мәзәкләр

САРАН КЕШЕ

Гайфулла абзый һәрчак үзенең акылын сакларга, күбрәк хатыны — Гөлҗамал җиңги акылы белән гомер итәргә тырышкан. Ә Гөлҗамал җиңгинең акылы үзенә дә чамалырак булган, ди.

АҢЛАШТЫЛАР

Ике яшь килен су юлында очрашып сөйләшә торгач, берсе үзенең ирен мактарга тотынган:

— Мин иремнән шулкадәре уңдым, мин сиңа әйтим, барлык таләпләремне дә тоткарсыз үтәп килә, — дигән.

Тыңлаучы килен тегеңә карап елмайган да:

— Алай булгач, ахирәт, ирeңә карата синең таләпчеллегең артык йомшак икән, — диеп куйган.

Җыючысы: ФАТИХ САБИТОВ.

Укучыларыбызга җавап

«Кадерле редакция!

Мин Муса Җәлилнең тиңдәшсез батырлыгы, аның бик әйбәт шагыйрь булуы турында шактый күп укыганым һәм ишеткәнем бар. Кечкенә чагымда әнием миңа аның шигырьләрен дә укый торган иде. Ләкин мин хәзергә кадәр М. Җәлилнең бөтен дөньяга даны таралган «Моабит дәфтәре»н дә, башка шигырьләрен дә укый алуга ирешкәнем юк. Таба алмыйм мин аның китапларын. Каян алырга икәнен белмим. Менә шуңа күрә сездән үтенәм: журналыгыз битләрендә М. Җәлил язган китапларны кайдан, ничек итеп алырга мөмкин булуын, һәм ул китапларның исемнәрен әйтеп язсагыз икән? Моның бер миңа гына түгел, минем шикелле Татарстаннан читтә яшәүче бик күп татарларга да файдасы зур булыр иде».

Бу юлларны Камчаткада яшәүче Марсель Янгурчин хатыннан алдык без. Мондый рухтагы хатлар редакциягә әледән-әле килеп тора.

Укучыларыбызның үтенечләрен искә алып, без Татарстан китап сәүдәсе каршындагы «Книга-почтой» бүлегенә мөрәҗәгать иттек. Анда безгә Муса Җәлилнең түбәндәге китаплары булуын һәм аларны кирәк кешегә почта аша җибәрергә мөмкин икәнлекне әйттеләр:

1. МОАБИТ ДӘФТӘРЛӘРЕ. Татар һәм рус телләрендә. Бәяләре: татарчасы — 44 тиен, русчасы — 43 тиен.

2. МУСА ҖӘЛИЛ. Фотоальбом. Татар, рус һәм немец телләрендә. Бәясе 3 сум.

3. ӘСӘРЛӘР. Рус телендә. Бәясе 1 сум 33 тиен.

М. Җәлилнең тормышта нинди кеше булуын, аның гадәт-холыкларын белергә теләгән укучылар өчен, сатуда шагыйрьнең замандашлары һәм көрәштәшләре тарафыннан язылган «МУСА ҖӘЛИЛ ТУРЫНДА ИСТӘЛЕКЛӘР» исемле китап (татар һәм рус телләрендә) бар. Бәяләре: татарчасы — 85, русчасы — 55 тиен.

Бу китапларны түбәндәге адрес белән хат язып, соратып алырга мөмкин: г. Казань, Баумана, 19, Таткниготорг, отдел „Книга-почтой."

Яңа китаплар

НУРИ АРСЛАНОВ

Дилбәр. Шигырьләр.

Бәясе 11 тиен.

Ярты гасыр җирдә яшәдем мин,
Бер гасырлык хәлләр кичердем.
Замандашлар белән бергә яндым,
Хыялларда бергә исердем...
Кайберәүләр кебек качып-посып,

Ышык урын эзләп йөрмәдем:
Ватан өчен утта, походларда
Үткәрдем мин сугыш көннәрен.
Зур тау булыр иде иткән хезмәт,
Өеп куйсаң аны әгәр дә...

Өлкән шагыйребез Нури Арслановның иҗат һәм тормыш юлын характерлый торган бу юлларны без аның әле шушы айларда гына басылып чыккан «Дилбәр» исемле яңа җыентыгында урнаштырылган «Илледә» исемле шигыреннән алдык. Сиксәнгә якын әсәрне эченә алган ул җыентык ике бүлектән тора. Беренче бүлектә шигырьләр, икенче бүлектә җырлар тупланган. Шигырьләр бүлегендә, Н. Арслановның үз әсәрләреннән тыш, рус һәм дөнья әдәбиятлары классикларыннан (Пушкин, Лермонтов, Байрон, Шелли) тәрҗемәләре дә кертелгән. Җырлар бүлегендә урнаштырылган егерме бер җырның барысы да диярлек теге яки бу композитор тарафыннан көйгә салынган әсәрләр.

Хәзерге татар әдәби теле

Бәясе 64 тиен.



Хәзерге татар әдәби теле күп миллионлы татар халкының аңлашу, аралашу чарасы булып хезмәт итә. Бу тел Татарстанда яшәүче халыклар арасында гына түгел, бәлки илебезнең башка бик күп өлкәләрендә һәм республикаларында да киң таралган. 1959 елгы халык санын алу мәгълүматларына караганда, татар халкының гомуми саны 5 миллионга җитә, шуларның 92,1 проценты ана телендә сөйләшә.

Тел, культура формасы буларак, шуңа ярашлы рәвештә өзлексез үзгәреп, яңарып, камилләшеп тора. Иҗтимагый тормышта булган яңарышлар, фәнни ачышлар телгә зур йогынты ясыйлар.

Хәзерге татар әдәби теленең закончалыклары нинди соң, анда нинди үзгәрешләр, яңалыклар бар? СССР Фәннәр Академиясенең Казан тел, әдәбият һәм тарих институты Гыйльми советы карары нигезендә, әле күптән түгел генә Татарстан китап нәшриятында басылып чыккан «Хәзерге татар әдәби теле» исемлек җыентык авторлары әнә шул сорауларга җавап бирүне күздә тотып эш иткәннәр. Югары уку йорты студентлары һәм урта мәктәп укытучылары өчен чыгарылган бу җыентыкта хәзерге татар әдәби теле лексик, фонетик, орфоэпик, график, орфографик һәм морфологик яклардан тикшерелгән. Китапның «Кереш», «Лексикология» бүлекләрен К. Сабиров, «Фонетика» бүлеген Р. Шакирова, «Орфоэпия», «Графика һәм орфография» бүлекләрен Х. Курбатов, «Морфология», «Татар теленең грамматика китаплары язылу тарихыннан кыскача белешмә» бүлекләрен В. Хангильдин язган.

Җыентыкта төп тикшерү объекты итеп хәзерге татар әдәби теле алынган булса да, урыны-урыны белән, бу хезмәттә кайбер тел фактларына тарихи күзәтүләр дә ясалган. Мондый алым, бердән, тел категорияләрен динамик үсештә карарга ярдәм итсә, икенчедән, әлегрәк чыккан язма әсәрләрне аңлау өчен дә таяныч, нигез булып тора. Бу җыентык урта мәктәп укытучылары һәм студентлар өчен генә түгел, язучылар, журналистлар һәм гомумән татар әдәби теле белән кызыксынучы бик күпләр өчен файдалы булыр.

М. ХӘМИТОВ

Күтәрелештә. Очерклар.

Бәясе 4 тиен.

Малик Хәмитов бу китабында республикабызның «Ирек» колхозы кешеләренең бүгенге эшләре һәм тормышлары турында сөйли, колхоз экономикасының елдан-ел үсә, ныгый баруын бик ачык һәм дәлилле итеп

сурәтләп бирә. Китап авторының үзе яза торган материалын бик әйбәт белүе белән огышлы чыккан. М. Хәмитов, чыннан да, «Ирек» колхозы экономикасы һәм ул колхоз кешеләре белән яхшы таныш. Аның «Ирек» колхозы кешеләре турында әлек берничә очеркы матбугат битләренә басылып чыккан иде инде. Бу китабында нигездә шул очерклар тупланган. Ләкин автор китап итеп әзерләгәндә ул очеркларын баштанаяк карап, яхшыртып, ваграк детальләрен төшереп калдырып, яна, әһәмиятле фактларны өстәп, эшкәртеп чыккан һәм, шулай итеп, әлек язган материалларын тоташ бер әсәргә әверелдергән.

МӘҖИТ РАФИКОВ

Илһам авазы. Хикәяләр.

Бәясе 7 тиен.

«Завком председателе Нурия Әхъяровна кабалана иде. Кәгазьләре папкада, өсте башы килгән, иреннәргә буяу яңартасы гына калды. Хәзер китә, хәзер...

Әкрен генә ишек кактылар.

— Да! — дип кычкырды Нурия Әхъяровна. — Ашыгыч китәсең буллымы, юлыңны бүлүләрең көт тә тор. Гел шулай, гел шулай!

Ишектән почык борынлы, кәкре аяклы, буйга тары көлтәсе генә хәтле бер карт килеп керде. Кырынган, киенгән, соры эшләпәсен кулына тоткан.

— Ни булды, Сәйфи абзый? Гомеремдә бер завкомга аяк атлап кергәнең юк иде. Йомышың бик срочный булмаса, берсекөнгә калдырып торыйк. Обкомсоюзга ашыгам.

— Срочный иде шул, Нурия сеңелкәш...»

Сәйфи абзыйның нинди йомыш белән килүен, аның йомышын завком председателе ничек хәл итүен язучы Мәҗит Рафиковның «Мыек» исемле хикәясен укыгач беләрсез. Хикәя М. Рафиковның әле күптән түгел генә дөньяга чыккан «Илһам авазы» исемле хикәяләр җыентыгында басылган.

РӘШИТ ГӘРӘЙ

Һаваларда йолдыз.

Шигырьләр.

Бәясе 8 тиен.

Рәшит Гәрәй — инде укучыларга билгеле шагыйрь. Аның шигырьләрендә күңелгә йогарлык, уйландырырлык фикерләр, вакыйгалар һәрвакыт була. Ул, гадәттә, шигырьләрендә туган якның матурлыгы, якынлыгы турында, газиз анага ихтирам, аны зурларга, хөрмәт итәргә кирәклек турында, бер сүз белән генә әйткәндә — авыл халкы, аның уй-фикерләре, тормыш-көнкүреше турында яза. «Һаваларда йолдыз» исемле җыентыгын укыгач, Р. Гәрәй әсәрләренең тематикасы киңәюен күреп, куанмыйча мөмкин түгел. Моннан бер-ике ел әлек ул Кузбасска барып, «Кара алтын» чыгаручылар арасында беразяшәп кайткан иде — шахтерлар тормышы турында зур бер цикл шигырьләр язган. Һәм әлеге җыентыкның яртысын диярлек шул цикл тәшкил итеп тора.

Забойда мин якты димәс идем,
Төшми анда аең, кояшың.
Кешеләрнең күңел яктылыгын,
Монда шуна күбрәк тоясың.

Яки:

Өстебезгә калын киенсәк тә,
Җир салкыны үзен сиздерә.
Эш урынына барып җитми торып,
Җылынырмын димә тиз генә,—

дип язар өчен, шагыйрь булу өстенә, забойга төшеп, аны үз күзең белән күрергә дә кирәк, әлбәттә.

Әдәбият һәм сәнгать яңалыклары

ПРОЗА СЕКЦИЯСЕ УТЫРЫШЫ

Татарстан Язучылар союзы каршындагы проза секциясенең егерменче майда уткәрелгән чираттагы утырышында Ибраһим Газиның «Канатланыр чак» исемле яңа повесте (повесть «Казан утлары» журналының бу елгы 3—4 саннарында басылган иде) тикшерелде. «Онытылмас еллар» трилогиясенең соңгы, өченче кисәге булган бу әсәр секция утырышында тикшерелүгә авторның үз теләге буенча куелды.

— Мин, — диде автор, секция бюросы председателе А. Расих утырышны ачканнан соң, — иптәшләрнең әсәргә карата үз фикерләрен турыдан-туры әйтүләрен үтенәм. Күңелегездә булганны ачыктан-ачык әйтсәгез, китап итеп чыгарганда повестьны яхшырту, төзәтү өчен файдалы булыр.

Утырышта катнашучылар «Канатланыр чак» повесте турында шактый күп сөйләделәр.

Ә м и р х а н Е н и к и: «Бу әсәр И. Газиның элекке повестьларыннан вакыт белән дә, урын белән дә аерылып тора, төп герое гына шул ук. 24—26 еллар безгә таныш инде, ул заман бик ачык күз алдында. Бу хәл зур кызыксыну тудыра. Белмим шуңа күрәдерме, мин әсәрдән тулы канәгатьләнү алмадым. Мин авторның үзенә дә, бу әйберенне көчен-куәтен житкәнчә эшләп бетермәгәнсең, дип әйттем. Ничектер житдилек, колач киңлеге житеп бетми кебек әсәрдә... Ләкин повесть, Ибраһимның каләменә хас булганча, ачы гына елмаю белән, киная белән язылган икән, шулай калыр инде ул, күрәсең. Шулай да кайбер детальләрне әйбәтрәк эшләргә, вакыйгаларны, образларны ышандырырлыграк итәргә кирәк булыр инде».

А. Г ы й л ә ж е в: «Бу чор турында күп әсәрләр язылган. Мин бу повестьны бик кызыксынып укыдым. Ибраһим абыйның бу әсәрне тагын да яхшыртырга мөмкинлекләре бик күп. Гражданлык кыюлыгы, минемчә, әсәрдә житеп бетмәгән кебегрәк. Хәзер безгә ул чордагы эшләрнең нәтиҗәләре ачык бит инде. Тавыш мөмкинлекләреннән файдаланып, көчлерәк, кыюрак жырларга булмас идеме икән ул заман турында? Китаң итеп чыгарганда, минемчә, боларны төзәтеп булыр. Әсәр киңрәк диапазонлы булсын иде дим мин, анда шул чорның уңай яклары да, тискәре яклары да тулырак чагылсын иде...»

И б р а һ и м Н у р у л л и н: «Мин бу әсәрне мавыгып укыдым. Һич тә аның кимчелеген күрергә тырышып, уйланып укымадым, ләззәтләнеп укыдым. Шуңа күрә берниндп дә тәнкыйть фикерем юк. Повестьта сурәтләнгән бик катлаулы, кызыклы чор киңрәк панорамада күрсәтелсә, яхшырак булыр иде дигән фикер миндә дә булды. Әмма язучы андый нәрсәне үзенә бурыч итеп куймаган булса кирәк... Монда яңалык бар бит. Үткәнне сурәтләп бирү генә түгел, бүгенге көнге проблемаларны тарих аша аңларга тырышу бит бу. Мәсәлән, футуристлар турында автор тикмәгә генә язмаган, әлбәттә. Бүген дә бар бит андыйлар... Инде колхозлашу мәсьәләсе. Күп төрле бизәкләре, эчке тирәнлеге белән язылса — яхшы булыр иде ул. Әмма болай эләктереп-эләктереп кенә киткәләсә дә, кыю-кыю фикерләр әйткән. Заманга авазлашлык бар әсәрдә...»

Ф а т и х Х ө с н и: «Мин бу әсәрне бик кызыксынып, ялыкмыйча укыдым. Өзек-өзек булса да, шул чорның характерлы бизәкләре бар. Футуристлар һ. б. Әсәр авылдан килгән чабаталы малай күзлегеннән күрсәтелә, шуның мөнбәреннән торып сөйләнелә. Күп нәрсәне аңламый ул, күп нәрсәгә беркатлы карый. Шулай да повестьта ниндидер җиңеләйтелгәнлек сизелеп тора. Төп әсәрнең дәвамы, эпопеяның соңгы өлеше буларак, бу җиңеләйтү бигрәк тә сыймый. Трилогиянең алдагы ике кисәгендә вакыйгаларның диапазоны киңрәк иде, монда таррак алынган... Крестьянны, авылны бик яхшы белә Ибраһим, матур-матур урыннар бар әсәрдә. Ләкин повестьның җиңелчә, юмористик тоны артыкка китми микән дим мин... Хәлимне дә артык башлы егет иткән шикелле. Бөтен нәрсәгә дөрес карый ул, бигрәк уңган, бигрәк чибәр, кешеләр ялгышканда да ялгышмый. Везет бу кешегә, ике кыз ярата аны... Кафиянең язмышы тетрәтми, күрәсең, ул укучыга тиешенчә барып житәрлек итеп сурәтләнмәгәндер...»

А т и л л а Р а с и х: «Повесть җиңел укыла. Оста кул белән язылганлыгы сизелеп тора. Әмма автор ялыга төшкән ахы-

ры бу әсәрендә. Урыны-урыны белән ашыгып китүләр, киңрәк итеп, җәелебрәк язасы моментларны йомып, өстән-өстәнрәк кенә сурәтләп үтүләр сизелә. Әйтик, Хәлим авылына кайта. Монда безгә әлектән таныш булган ул авыл һәм аның кешеләрен, алардагы үзгәрешләрне киңрәк күрсәтергә бик мөмкин булыр иде, чөнки беләсе килә безнең бу турыда. Әсәрнең бүлекләре арасында пропорция бозылса бозылыр, әмма укучыга күп кенә төеннәр чишелә төшәр иде... Ф. Хөснинең әсәр җинелрәк тонда язылган дигән сүзе белән килешмим мин. Әмма вакыйгаларны тагын да тирәнрәк, киңрәк сурәтләгәндә А. Гыйләжев әйткән моментлар ачыклана төшәр иде... Шул ук ашыгучанлык аркасында Кафиянең үлеме дә укучыны тетрәтерлек була алмаган, ә ул тетрәтергә тиеш иде. Колхозлашу чорында киткән хаталарны төзәтергә килгән вәкилне җигеп йөрү дә сәеррәк, монда образга эзлеклелек җитеп бетми шикелле... Йомгак ясап, мин шуны әйтергә телим: мондагы сүзләр, минемчә, барысы да изге, авторга ярдәм итү нияте белән сөйләнелде һәм аларны Ибраһим дөрес аңлар дип уйлыйм».

Ибраһим Гази: «Әйе, повестьны укып, үз фикерләрен әйтүләре өчен, бик зур рәхмәт иптәшләргә. Мин әйтелгән тәкъдимнәрнең бер өлешен кабул итә алам. Бүлекләр арасында пропорция бозыла бугай дип, кайбер моментларны мин, язылган булса да, юри төшереп калдырган идем. Хәзер сизәм, күрәсең, аларны китапка кертергә кирәктер. Әмма әсәрне киң полотнолы итәргә, вакыйгаларны тирән һәм һәрьяклап яктыртырга вәгъдә итә алмыйм, чөнки ул чор бик катлаулы, ә мин аңлы рәвештә теманы таррак алдым һәм әсәрне катлауландырмадым...»

ТУКАЙ КӨННӘРЕНДӘ

Шагыйрь Әхмәт Ерикәй Тимирязев исемендәге авыл хуҗалыгы Академиясендә һәм СССР тарих китапханәсендә Габдулла Тукайның тууына 80 ел тулуга багышланган кичәләрдә катнашып, халыкның сөекле шагыйре һәм гомумән татар әдәбияты турында чыгышлар ясады.

* * *

Ташкентның Ахунбабаев исемендәге культура йортында татар халкының бөек шагыйре Габдулла Тукайның тууына 80 ел тулуга багышлап үткәрелгән кичәдә шагыйрьне яхшы белгән Ш. Мөхәммәдъяров истәлекләрен халык бик кызыксынып тыңлады. Сүз осталары Г. Тукай шигырьләрен укыдылар һәм соңыннан татар үзешчәннәре көче белән бик әйбәт концерт бирелде.

* * *

Тукай иҗатын өйрәнүче тәнкыйтьче һәм язучы Ибраһим Нуруллин белән шагыйрь Шәүкәт Галиев, Тукай көннәрендә Чиләбе һәм Троицк шәһәрләрендә булып, укучылар белән очрашулар үткәрделәр. Тукай иҗаты, бүгенге әдәбиятыбыз турында сөйләшүләр Чиләбе өлкәсенең Конашак район культура йортында, Аргаяш медицина училищесында, Аргаяш урта мәктәбендә, Чиләбедәге һәм Троицкидагы татар-башкорт китапханәләрендә булды. Авторларның үз әсәрләрен укуларын да халык җылы каршылады.

ЯЗУЧЫЛАРГА — ҖӘЛИЛ ЙОЛДЫЗЫ

«Мәктәптә Җәлил музеен оештыруда күрсәткән зур ярдәме өчен, Татарстан Язучылар союзы секретаре шагыйрь Зәки Нуриның дружинаның почетлы члены итеп сайларга һәм аңа Җәлил йолдызын тапшырырга.

Зәки Нури исемен мәктәпнең Почет китабына кертергә.

Музей директоры: Шакирова.
Дружина Советы председателе: Халитова».

Түбән өлкәсе Аслан урта мәктәбендәге Җәлил музее һәм пионер дружинасы советлары чыгарган карар бу. Муса Җәлил әсәрләрен бастырып чыгаруда һәм аның әдәби эшчәнлеген гомумиләштереп халыкка җиткерүдә күрсәткән хезмәтләре өчен Гази Кашшафны, «Муса» романын язган өчен Ш. Маннурны, сугышка кадәрге чорда М. Җәлил белән бергә эшләгәне өчен композитор Заһид Хәбибуллинны һәм мәктәптә Җәлил исемендәге музейны оештыруда күрсәткән зур ярдәме өчен яшь язучы Хәлаф Гардановны да музей һәм дружина советлары почетлы пионер итеп сайлаганнар, исемнәрен мәктәпнең Почет китабына керткәннәр һәм аларга да Җәлил йолдызларын — биш почмаклы пластмасса йолдыз уртасындагы түгәрәккә Муса Җәлил рәсеме урнаштырылган йолдызлар — җибәргәннәр.

РАЙОННАРДА ӘДӘБИЯТ АТНАЛЫКЛАРЫ

Язучыларыбызның күп санлы китап укучылар белән бәйләнеше соңгы елларда аеруча нык төште. Укучыларның үз яннарына барып чыгышлар ясау, аларны иҗат планнары, әдәбиятыбыздагы яңалыклар белән таныштыру — язучыларыбызның күркәм традициясенә әверелде. Татарстан язучылары республикабыз районнарында гына түгел, илебезнең бүтән өлкә һәм шәһәрләрендә дә әдәбият атналыкларына катнашалар. Мондый атналыкларның әһәмияте зур: бер яктан, ул көннәрдә китап сөючеләргә үзләре укыган әсәрләрнең авторларын күреп, аларга шул әсәр турындагы фикерләрен әйтергә, теләкләрен белдереп калырга мөмкинлек туса, үз чиратларында, язучылар да үзләренең укучыларын күреп, аларның уй-фикерләрен ишетеп, тормышлары белән танышып, үзләренчә әйтсәк, язачак әсәрләренә илһам алып кайталар. Шул ук вакытта укучы белән язучы арасында танышлык, элемтә дә урнаша.

Шундый әдәби атналыклар май аенда да үткәрелде. Язучыларыбыздан Г. Минский, И. Гази, Ә. Еники, Г. Латыйп, Ә. Юныс, И. Юзеев, Л. Ихсанова, С. Шакир, Р. Ишморатова, А. Сәлахетдинов республикабызның **Саба** районында; Н. Арсланов, А. Гыйләжев, Ш. Галиев, Р. Гатауллин, Г. Мөхәммәтшин, З. Нури, А. Расих, Ф. Хөсни, М. Садри, М. Фәйзуллина, К. Фәсахов **Балтач** районында; Татарстанда яшәүче рус

язучылары Т. Журавлев, К. Лебедев, Г. Паушкин, Р. Кутуй, И. Данилов **Куйбышев** районында әдәби атналыкларда булып кайттылар. Чувашиядән килгән чуваш язучыларыннан И. Малгай, Г. Ефимов, Т. Педерки, М. Сениэль, А. Талвир (Казан) һәм чуваш халык шагыйре П. Хузангай республикабызның Аксубай районында әдәби атналык үткәрделәр. Ә июнь башында Әлмәттә яшәүче язучылардан Г. Ахунов, Р. Төхфәтуллин, Ә. Маликов, С. Сөләйманова, Г. Афзал, С. Кальметов һәм Алабугада яшәүче Э. Касыймов Башкортстанның Янаул районында һәм Уфада үткәрелгән татар әдәби атналыкларында катнаштылар.

Санап үтелгән район үзәкләрендә һәм авылларында үткәрелгән әдәбият атналыклары көннәрендә язучылар әдәби кичәләр үткәрделәр, укучылар конференцияләрендә катнаштылар, яшь һәм башлап язучыларның әсәрләрен тикшереп, аларга киңәшләр бирделәр.

СУГЫШТА КАТНАШКАН ЯЗУЧЫЛАРГА МЕДАЛЬЛӘР

13 майда Язучылар союзының Габдулла Тукай исемендәге клубында Бөек Ватан сугышында катнашкан язучыларга «Бөек Ватан сугышының XX еллыгы» медальләрен тапшыру тантанасы булды. Юбилей медальләре язучылардан Г. Әпсәләмов, Г. Бакиров, Г. Галиев, Б. Гыйззәт, Ә. Еники, Р. Ишморат, И. Гази, Г. Минский, З. Нури, Г. Паушкин, М. Садри, Н. Дәүли, Г. Иделле, С. Хәким, П. Евгеньев, Г. Хуҗи һәм А. Шамовка бирелде.

Казан шәһәренең Совет районы хәрби комиссары полковник А. М. Труфанов Фатих Кәримнең хатыны Кадрия Ишуковага шагыйрьнең орденын тапшыра.

Шул ук җыелышта 1945 елның язында, сугыш бетәргә санаулы гына көннәр калганда, батырларча һәлак булган атаклы шагыйрь Фатих Кәрим семьясына шагыйрь үзе үлгәннән соң бирелергә тиешле булып та бирелмичә калган «Ватан сугышы» ордены да тапшырылды.

Г. КАРИЕВНЫҢ ТУУЫНА 80 ЕЛ

Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры бинасында күренекле артист һәм режиссер Габдулла Кариевның тууына 80 ел тулуга багышланган кичә булды. Г. Кариевның тормыш юлы һәм иҗатын чагылдырган докладны сәнгать фәннәре кандидаты Хәсән Гобәйдуллин ясады.

Кичәдә драматург Н. Исәнбәт, РСФСРның атказанган, Татарстанның халык артисткасы Г. Болгарская, Татарстанның халык артистлары Касыйм Шамиль, Х. Сәлимҗанов һәм З. Тинчурина сәхнә остасы Г. Кариев турында истәлекләр сөйләделәр.

Соңыннан Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры коллективы Габдулла Кариевның «Артист» исемле комедиясе буенча эшләнгән спектакль күрсәтте.

Татарстан дәүләт музее тарафыннан Г. Кариев иҗатын чагылдырган күргәзмә дә оештырылган иде.

ОЧРАШУЛАР, ӘДӘБИ КИЧӘЛӘР

Казан дәүләт университеты тулай торагында үткәрелгән ял кичәсендә шагыйрьләрдән Илдар Юзиев һәм Шәүкәт Галиев катнаштылар, яңа әсәрләрен укыдылар.

* * *

6 майда Мәскәү фәнни атеизм йортында шагыйрь Әхмәт Ерикәй, татар укучылары белән очрашып, анда үзенең яңа әсәрләрен укыды, иҗаты турында сөйләде.

* * *

14 майда Казанның Куйбышев исемендәге клубында шагыйрьләрдән Ә. Давыдов һәм Ә. Ерикәй эшче яшьләр белән очраштылар. Очрашу вакытында ТАССРның халык артисты У. Әльмиев, артистка Ф. Сөләйманова һәм композитор Ф. Әхмәдиев Ә. Ерикәй сүзләренә язылган җырларны башкардылар.

* * *

Язучыларның Г. Тукай исемендәге клубында шагыйрь Әхмәт Ерикәй иҗатына багышланган әдәби-музыкаль кичә булды. Кичәдә шагыйрь турындагы кереш сүзне Нури Арсланов сөйләде. Өлкән шагыйребез зал тулы тамашачыларны үзенең яңа әсәрләре белән таныштырды.

Кичәдә композитор Р. Яхин, артистлар М. Булатова, В. Шәрипова, У. Әльмиев, В. Минкина, А. Арсланов, Ә. Яһудин, Ә. Афзалова, Э. Җәләлетдинов һәм Ф. Сөләйманова Әхмәт Ерикәй шигырьләрен һәм аның сүзләренә язылган җырларны башкардылар.

«МУСА ҖӘЛИЛ» ТЕПЛОХОДЫ

Советлар Союзы заказы буенча Югославиядәге Пула шәһәренең «Ульяник» верфендә төзелгән теплоходның Олесса диңгез порты карамагына тапшырылуы һәм аның, йөк алып, ерак сәяхәткә — Африкага юл тотканлыгы турында журналыбызның алдагы санында хәбәр иткән идек инде. Бу санда «Муса Җәлил» теплоходын озату вакытында төшерелгән ике рәсем урнаштырабыз.



Өстәге рәсемдә — «Җәлил» теплоходының Одесса диңгез порты причалында торган вакыты; аста — (сулдан уңга) Ә. Миндубаев, теплоход капитаны Р. А. Довгаль һәм Г. Кашшаф теплоход бортында.

КИТАП БӘЙРӘМЕ

Казанның М. Горький исемендәге Үзәк культура һәм ял паркында китап бәйрәме оештырылды. Анда язучылар Г. Минский, А. Расих, Ә. Ерикәй, Ш. Маннур, Г. Хуҗи, Н. Дәүли, Н. Арсланов, Р. Әхмәтҗанов һәм Р. Гатауллин китап укучылар белән очраштылар, әдәбият сөючеләрне иҗат планнары белән таныштырдылар, шигырьләрен укыдылар.

Сәүдә работниклары ул көнне барлыгы 1000 сумлык китап саттылар.

ЯШЬ ШАГЫЙРЬ УҢЫШЫ

ВЛКСМ Үзәк Комитеты һәм СССР Министрлар Советы каршындагы радио һәм телевидение Комитеты Бөтенсоюз күләмендә яшьләр поэзиясе фестивале үткәрделәр. Май аенда шул фестивальгә йомгак ясалып, әсәрләре иң яхшы дип табылган 18 яшь шагыйрьне Мәскәүгә телевидение аша чыгыш ясарга чакырдылар. Алар арасында Татарстаннан яшь шагыйрь Равил Фәйзуллин да бар иде. Ул ВЛКСМ Үзәк Комитетының Мактау грамотасы һәм кызыксындыру премиясе белән бүләкләнде.

КИТМӘ, САНДУГАЧ!..

РӨСТӘМ ЯХИН музыкасы. *ГӨЛШАТ ЗӘЙНАШЕВА сүзләре.*

Сандугач! Сандугач!
Китмә, китмә, сандугач!
Канатларын талдырып,
Туган илне калдырып;
Бездә туып үстең син,
Чык суларын эчтең син.

Сандугач! Сандугач!
Син китәсең, мин калам.
Дусларыма җырлар өчен,
Җырыңны отып алам.

Сандугач! Сандугач!
Китмә, китмә, сандугач!
Курыкма син кышлардан,
Кал син башка кошлардан,
Саклармын салкын җилдән,
Китмә син туган илдән.

Сандугач! Сандугач!
Син китәсең, мин калам.
Дусларыма җырлар өчен,
Җырыңны отып алам.

Җаваплы редакторы Рафаэль Мостафин

Редколлегия: Хәй Вахит, Ибраһим Гази, Әмирхан Еники,
Гази Кашшаф, Шәйхи Маннур, Габдрахман Минский,
Сибгат Хәким, Нил Юзиев

Производствога бирелде 16/V-1966 ел. Басарга кул куелды 29/VI-1966 ел. ПФ 15017. Кәгазь форматы 70×108 1/16. Учетн.-изд. табак 12,2. Басма табак 10(14). Тираж 35000 экз. Заказ Н-734.
Бәясе 40 тиен.

ТАССР Министрлар Советы каршындагы Матбугат идарәсенең Камил Якуб исемендәге матбугат комбинатында басылды. Казан, Бауман урамы, йорт 19. 1966 ел.

КИТМӘ, САНДУГАЧ!...



Бәясе 40 тиен
Цена 40 коп.

Индекс
73210

*Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал*
КАЗАН УТЛАРЫ
(Огни Казани)
ОРГАН СОЮЗА ПИСАТЕЛЕЙ ТАТАРИИ